ISSN 0206—418

# Казан утлары

6 . 1984



# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

6

1984

## Бу санда

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНЫҢ ДЕКАБРЬ (1983 ЕЛ) ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН ТОРМЫШКА!

М. ЗАРИПОВ. **Тәвәккәл таш яра** . . . . . . . 3

М. МӘҺДИЕВ. **Мәңгелек яз.** Роман . . . . . . 14
Ф. ЯРУЛЛИН. **Шигырьләр** . . . . . . . . . 90
РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ. **Кошлар бәйрәмена чакыру.** Шигырьләр . . . . . . . . . . 95

«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

М. ӘМИРХАНОВ. **Гармун. Хикәя** . . . . . . . 102

С. БАТТАЛ. **Шигырьләр** . . . . . . . . . 106
М. ГАЗИЗОВ. **Шигырьләр** . . . . . . . . . 107
Р. ФӘИЗОВ. **Җир хакына. Хикәя** . . . . . . 109
К. ЛАТЫЙПОВ. **Төньякта да күбәләкләр яши. Хикәя** . . . . . . . . . . . . . . 116
Я. ИГӘНӘЙ. **Шигырьләр** . . . . . . . . . 120
РӨСТӘМ ФӘЙЗУЛЛИН. **Неон уты.** Шигырьләр . 122

ТАРАС ШЕВЧЕНКОНЫҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

З. НУРИ. **Шевченконы укып уйланам** . . . . . 125
Т. ШЕВЧЕНКО. **Шигырьләр** . . . . . . . . . 129

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

**Казанда Тукай урыннары** . . . . . . . . . 130
Х. ЗӘБИРЕВ. **Тукай һәм аның тирәлеге** . . . . 131

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Ә. ГАЛЛӘМОВА. **Калаларга карап** . . . . . . 133
Ф. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ. **Туар көннәр яктылыгы** . . 136
Г. ЗАКИРОВА. **Күтәрелү** . . . . . . . . . 137

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

З. МАНСУРОВ. **Халыкка бөек эшләрендә булышучы** . . . . . . . . . . . . . . 140

БИБЛИОГРАФИЯ

М. МӘХМҮТОВ. **Китап турында китап** . . . . 149
Р. ЮНЫСОВ. **Исем артында нәрсә!** . . . . . . 152

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия:*
**ШАМИЛ БИКЧУРИН**
**МАНСУР ВӘЛИЕВ**
**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**РӘИС ДАУТОВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ЗӨЛФӘТ**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**ЗӘКИ НУРИ**
**РӘФЫЙК НӘФЫЙКОВ**
**АТИЛЛА РАСИХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**НИЛ ЮЗИЕВ**

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Җ. ЗӘЙНУЛЛИН. **«Кәлилә вә Димнә» — татар әдәбиятында** . . . . . . . . . 155
Ф. ВӘЛИЕВ. **Борынгы сәнгатебез сәхифәләреннән** 162
И. ИЛЯЛОВ. **Ике хатирә** . . . . . . . . . 167

СӘНГАТЬ

Ш. РАХМАНКУЛОВ. **Цирк кабызган йолдызлар** 169

ФОЛЬКЛОР

Ш. МАННАПОВ. **Сүз янчыкта ятмый** . . . . . 176
М. ӘХМӘТҖАНОВ. **Бер сорауга — бер җавап** . . 179

ЮБИЛЕЙЛАР

Т. ГАЛИУЛЛИН. **Фидакарьлек** . . . . . . . . 180
**Хәмит Ярмигә татар язучыларының фронттан язган хатлары** . . . . . . . . . . . . 182
М. ШАКИРОВ. **Шәмдәлләрдә генә утлар яна...** . 187

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . 188

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Решения декабрьского (1983 г.) Пленума ЦК КПСС — в жизнь!» Очерк писателя **М. Зарипова** о генеральном директоре производственного объединения «Нижнекамскнефтехим» Н. В. Лемаеве.
Роман **М. Магдеева** «Вечная весна» (окончание). На конкурс «Подвиг продолжается» — рассказ **М. Амирханова** «Гармонь».
Рассказы **Р. Фаизова, К. Латыпова**. Стихи **Ф. Яруллина, Рашита Ахметзянова, С. Баттала, М. Газизова, Я. Иганая, Рустема Файзуллина.**
Статья **З. Нури** «Над строками Шевченко». Стихи **Т. Шевченко** в переводе М. Аглямова.
«К 100-летию Тукая»: публикация **Х. Забирова,** рис. **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
«Продовольственная программа — всенародное дело»: очерки **А. Галлямовой, Ф. Гильмутдинова, Г. Закировой.**
Статья **З. Мансурова** о современной поэзии.
Рецензии на новые книги А. Каримуллина и А. Еники.
Статьи об истории татарской культуры: об истоках народного искусства (автор — **Ф. Валеев**), о цирковом искусстве (**Ш. Рахманкулов**), о влиянии древнеиндийской литературы и фольклора на развитие татарской литературы (**Дж. Зайнуллин**).
Воспоминания **И. Иляловa.**
Материалы к юбилеям ученого-фольклориста Х. Ярми и народной артистки РСФСР М. Булатовой.
Из сокровищницы татарского фольклора.
«Занимательные истории». Дневник культурной жизни.
«На наших обложках»: творчество художника Ф. Аминова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова* Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 19.3.1984 ел. Басарга кул куелды 23.5.1984 ел. ПФ 02255. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70\times108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64549. Заказ К-101. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

*КПСС Үзәк Комитетының декабрь (1983 ел) Пленумы карарларын — тормышка!*

## Марсель Зарипов

# ТӘВӘККӘЛ ТАШ ЯРА

Аның, Совнархоздагы җылы кабинетын калдырып, Түбән Камага, ул чакта әле салына да башламаган шәһәргә нефтехимия заводлары торгызырга килүенә чирек гасыр вакыт үтте. Василий Николаевич Лемаев карамагындагы берсеннән-берсе катлаулырак бу заводларда туган җиребезнең кыйммәтле байлыгы саналган нефтьтән бездә моңарчы ишетелмәгән дә, күрелмәгән дә әйберләр җитештерелергә тиеш иде: пропан газы, полимерлар ясарга китә торган этилен һәм төрледән-төрле полиэфирлар. Болардан, үз чиратында, кешегә кирәкле әллә ниләр эшләп була. Гомер-гомергә чит илдән кертелә торган каучук үзе генә ни тора! Ул бит — бөтен төр автомашиналарга, тракторларга, комбайннарга, мотоциклларга, велосипедларга кирәк.

Гомер дигәнең очар коштан да җитезрәк, бугай. Хәзер бу якларда Николай Васильевич килеп урнашкан еллардагы күренешләрнең эзе дә калмаган: йөз илле мең кешелек шәһәр, унбишләп заводны берләштергән олы комбинат, юллар, яңадан-яңа төзелешләр... Түбән Каманың эшчеләре илгә ел саен ике миллиард сумлык байлык бирәләр. Монда ясала торган каучук Көнбатыш Европаның бик алга киткән илләрен дә көнләштерерлек.

Еллар бу төбәкне әнә шундый юнәлешкә борганнар. Һәм, әлбәттә, Лемаев та элекке Лемаев түгел, ул да нык үзгәргән. Аның завод аппаратчысы булып, боргычлар көйләп йөргән чагы хәтердә әле. Аннары аны цех җитәкчесе итеп билгеләгәннәр. Утызы тулганда, гомеренең гена түгел, һөнәре серләрен белүдә дә егәр үренә менеп баскач, илнең мөстәкыйль вәкиле итеп танылгач, зур колачлы эшне тулаем үз кулына алган ул. Монда инде һәр нәрсә өчен башың белән җавап бирәсең. Кулыңнан эш килми икән, әллә нинди үткен сүз дә синең булдыксызлыгыңны томалап калдыра алмый. Яхшы ниятең барып чыкса, бик хуш, хата җибәрдеңме — үзеңә үпкәлә.

Түбән Камада уздырган елларында Николай Васильевич Лемаев кешеләр белән аралашу ысулларын яхшы үзләштергән, эшенең бөтен нечкәлекләренә төшенгән. Элекке гайрәтенә, башлап йөрергә һәвәслегенә киң колачлылык, тирәннән уйлау, үз каланчасыннан гына түгел, ил экономикасының олы максатларыннан чыгып фикерләү кебек кыйммәтле яңа сыйфатлар өстәлгән.

Иясе нинди — хуҗалыгы шундый. Кайбер директорлар сунарчылыкны, балык каптыруны яраталар яки гөмбә җыйганда дөньяларын онытталар. Лемаевның мавыгуы башка, аңа, халык әйтмешли, фәнни эзләнүләр җене кагылган. Мин монда аның «Нижнекамск-

нефтехим» берләшмәсе генераль директоры вазифасы белән фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗәсен генә дә күздә тотмыйм. Миңа Лемаевның фәндәге яңалыкларны үз берләшмәсе хаҗәтләренә, производство мәнфәгатьләренә җигәргә тырышып, янып-көеп, тикшереп йөрүләре аеруча кызыклы тоела.

Безнең әңгәмәбез дә, нигездә, шул хакта барды. Алдан унберенче бишьеллык чорына кабул ителгән социалистик йөкләмәләре белән таныштым. Башта ул миңа гадәти бер рәсми язу булып күренде. Андый документлар һәр коллективта бар, хәтта кайбер пунктлары да уртак. Шунлыктан, әллә ни исем китмичә, күз йөртеп кенә утырам. Кинәт, бик үк гадәти булмаган сүзләргә игътибар итәм: «...яңа утыз ачыш иҗат итәргә һәм эшкә җигәргә!» Сүз яңа тәкъдимнәрне, фәнни ачышларны файдалану турында гына барса, мин әллә ни гаҗәпләнмәгән дә булыр идем әле. Шулай булмаганда, аның кирәге дә юк. Тик бу йөкләмәгә ачыш ясау турында да өздереп язып куелган бит! Монысы хакында галимнәр кайгыртырга тиеш кебек. Шунлыктан мин Николай Васильевич Лемаевка биргән сорауларны, башлыча, шул юнәлешкәрәк бордым. Сөйләшүебез фәнни-техник бәхәс төсен алды кебек.

Мин. Николай Васильевич, иң алдан бу әңгәмәнең иң мөһим мәсьәләсен ачыклыйк әле. Һәр фәнни яңалык — талант, илһам җимеше. Аны тормышка ашыру, әйтик, кулга тотып карарлык хәлгә китерү мең төрле мәшәкатьләргә бәйле. Ярый ла барысы да синең җайга гына барып торса! Көткәнеңнең киресенә тап булуың да бик ихтимал. Күпме ыгы-зыгы кубачак: вәгъдә бирдең, ышандырдың, азагына илтеп җиткерә алмадың... Иңгә мондый авыр йөк күтәрүнең нигә кирәге булды?

Ул. Сез, кешенең талантын, илһам куәтен планлаштырып, йөкләмәләр кысасына кертеп булмый, дияргә телисезме? Минемчә, «җитәкчелек итү» төшенчәсенә, кешеләрнең сәләтен кирәкле юнәлешкә борып җибәрү бурычы да керә. Моны мин хәтта безнең берләшмәгә генә хас үзенчәлеккә дә санамыйм, бу, миңа калса — төп кагыйдәләрнең берсе.

Мин. Барлык тармакларда дамы?..

Лемаев, дөнья күләм әһәмиятле берләшмәнең генераль директоры постындагы бик зур кеше булса да, кыланчыклыкка, тәкәбберлеккә һичнинди юл куймыйча, гап-гади иттереп сөйләшә, үз-үзен тотышында да нәзберекләнеп тормый. Әмма аның тел төбе кая барып чыгасын аңлап бетерүе кыен. Фикерләре тыгыз аның, уйлары тирәннән чыга һәм ул әңгәмәдәшенең сүзендә дә примитивлыкны, ахмак беркатлылыкны кичермидер, мөгаен. Чыннан да, без шул кадәр киеренке чорда яшибез, кыска гына вакыт эчендә гасырлар буе чишелми яткан глобаль мәсьәләләр хәл ителә, телгә әллә нинди төшенчәләр килеп керә — атом, космос заманы. Шундый чорда генераль директор сиңа үз эшенең элифбасын аңлатып утырсынмы? Юк! Берәү дә аңардан моны таләп итә алмый — бигайбә!

Мин үз хәлемне чамалыйм, Лемаев та сизенә, бугай, ашыктырмый, җавапларын да, буташтырмыйча, иплән кенә кайтара.

Ул. Фәнни ачышлардан, һичшиксез, һәр җирдә файдаланырга тиешләр. Кеше галәм киңлегенә юл ярганда, атомны эшкә җиккәндә, химия ярдәмендә табигатьнең үзен камилләштерү әмәлләрен тапканда, галимнәрне санга сукмасаң, техник прогресс машинасы әрҗәсеннән төшәсең дә каласың. Бүгенге тормыш тәгәрмәче бик кызу тәгәри, бездән дә күз иярмәслек тизлек таләп итә. Аз гына салмаклану да «шып» туктауга тиң хәзер. Безнең карамакта ике генә юл бар: я прогресска ияреңгә, я аннан да бераз алгарак үтеп, теге ма-

шинаны үз артыңнан ияртергә! Икенче юл мең мәртәбә авыррак, аның каравы, дәрәҗәсе дә зур. Мөмкин булмастайны башкарган кешенең кыйммәте башка. Безнең уйлап табулар белән шөгыльләнә торган фәнни-тәҗрибә лабораториябездә фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә ирешкән унике галим бар. Аннан башка да иллеләп фәнни тикшерену һәм проект-конструкторлык учреждениеләре, вузлар, фән академияләре белән элемтәдә торабыз. Берләшмә үзе үк эзләнүләр дә алып бара, фәнни ачышлардан файдалану алымнарын табарга да тырыша. Бу эшнең башына Казан химия-технология институты профессоры Александр Григорьевич Лиакумовичны куйдык. Ул — бик гайрәтле администратор да, күп кырлы галим дә, йөзләрчә ачышлар авторы да.

Фәнни ачышларны алдан планлаштыру хыялга, тәвәккәллеккә, аннары какшамас эзлеклелеккә нигезләнгән. Унынчы бишьеллыкта производствога кертелгән сиксән алты ачышыбыздан кырык миллион табыш алдык... Мин аңлыйм: хыял чикләрен чамалау, илһам көчен алдан билгеләп кую — бер карасаң, кеше кулыннан килмәстәй авыр эш. Бу сиңа — компьютерны җайлау гына түгел. Әмма хәзер башкача ярамый.

Безнең берләшмәдә бу алымны социалистик йөкләмәгә үк теркәүнең хикмәтен йөрәк белән тоя белергә кирәк. Әйтик, ачышның турыдан-туры практик эшкә җигелүе кешегә әхлакый бер таяныч та булсын, ди. Монда гыйльми авторитет, башкалардан аерылып торырга омтылу кебек хисләр уйный. Адәми затның кайсы гына яңа ачыш ясарга теләмәс икән?! Минемчә, бу — һәр кешегә хас изге теләк. Синең дә, минем дә башкаларга үрнәк булырдай казанышка ирешәсе киләме? Килә! Бәс шулай икән, тырыш, эзлә, тап!

Аерым кешенең дә, коллективның да яулап алган уңышлары төбендә тырышлык, тәвәккәллек, үз-үзен корбан итәргә әзерлек кебек сыйфатлар белән бергә һөнәренә тугрылык, аны олылау, горурлык хисе дә ята. Беренчелеккә хирєслек, спортчыларга гына түгел, һәр акыллы кешегә хас омтылыш. Химия — гаҗәп фән бит ул! Ул хәтта табигатьнең үзенә дә төзәтүләр кертә ала. Химия ярдәмендә табигатьнең үзендә юк әйберләрне ясап була. Шушы сыйфаты химияне һәм аңа бәйле һөнәрләрне күз иярмәслек тизлек белән үстерә.

Мисалларга да тукталырга мөмкин. 1961—1970 еллар эчендә, дөньякүләм исәпләгәндә, промышленность елга уртача 6,7 процентка үсте, ә химия тармагындагы алга китеш — 9,7 процент, исәп-хисап белән шөгыльләнүчеләр бу гасырның соңгы чирегендә химия җитештергән әйберләр өч тапкырдан сигез тапкырга кадәр артачак, диләр. Безнең нефтехимия исә, яшьрәк тармагы булганга күрә, химиянең гомум алга китешенә караганда, өч мәртәбә тизрәк күтәреләчәк. Менә шушындый берсеннән берсе зуррак тизлекләрдә син иң алдан юл ярып очасың икән — начармыни?! Башкалар синең арттан килә. Кеше хыялый фикерләренең җиңүенә омтылып яши һәм иң татлы ләззәтне ул шуннан ала. Совет космонавтларының барысы да безне сокландыралар. Әмма, минем өчен галәм каһарманы — Юрий Гагарин. Ул — беренче! Ул — бердәнбер!

Мин. Нефтехимикларыгыз арасында «Гагариннар» бармы соң? Алар нинди юл ярдылар, ул эздән хәзер кемнәр атлый?

Ул. Гагарин кебекләр адым саен очрамый. Тик без шунысын да онытмаска тиешбез: җәмгыять үсеше, алга китеш гел кискен сикерешләрдән генә тормый, андый зур ачышлар меңнәрчә кечерәк яңалыкларга нигезләнеп туалар. Гагаринны да шул җиңүне күз алдында тотып, хыялланып иҗат иткән Кибальчич, Циалковский, акаде-

мик Королевның каһарманлыгы, ышанычлы техника, аппаратлар, приборлар ясаучы меңләгән осталар гасыр батыры итмәдемени?!

Инде менә бер рәсми кәгазьне укып күрсәтим: «...Түбән Кама нефтехимия берләшмәсендә ясала торган каучук шиннар өчен иң кулай каучук дип табылды...» Бу — безнең коллективның гражданлык бурычын үтәргә маһирлыгын, осталыгын, үз һөнәренә ни дәрәҗәдә тугры икәнлеген күрсәтүче бик кадерле документ! Изопрен каучугының төрләре егермедән артык, каучукның бүтән сортлары иллегә дә туладыр шәт, әмма табигый каучукка бик якын торганын, илдә беренчеләрдән булып, без бирдек. Түбән Камада җитештерелә торган гель-молекуласыз каучукның 98 проценты дәүләтнең Сыйфат билгесе белән озатыла.

Мин. Гель-молекуласы булмагач, каучук бик әйбәтләнәмени соң? Бу бик мөһиммени? Отышлымыни?

Ул. Бу — безнең һөнәрдә алга таба ясалган бик кирәкле, яңа, кыю, әллә каян күренеп тора торган олы бер адым. Совет галимнәре, каучук ясау мөмкинлеген ачкач, кешеләр «шук» бер молекулага тап булалар. Шул «шук» молекула структурасында, үзе ничек теләсә, шулай шаярып йөри, ә кешегә кирәкле урынга керми йөдәтә. Структура — материалның төп тамгасы, аның йөзе, көзгесе. Әйтик, бер үк углеродтан, атомнарындагы структур тезмәне үзгәртеп, карандаш үзәгенә куела торган йоп-йомшак графитны да, минераллар падишасыннан саналган алмазны да ясап була. Химикларның осталыгы матдәдәге серле кисәкчәләрне кеше ихтыяҗына буйсындырып, ныгытып утыртып куюга кайтып кала.

Ясалма каучук барлыкка килгәнгә илле еллап вакыт үтте. Әмма кырык процентлабында гель-молекула килеп чыга. Аптыраш, нишләргә? Көннәрдән бер көнне С. В. Лебедев исемендәге Бөтенсоюз фәнни тикшеренү институтының С. Будер җитәкчелегендәге бер төркем галимнәре яңа төрле процесс тәкъдим итәләр. Һәр яңалыкка хас сораулар, икеләнүләр, шикләр дә куера, әлбәттә, һәм... безгә кадәр берәү дә бу эшкә алынмаган. Без тәвәккәлләдек. Ике елдан соң ук эшебезгә менә шушы рәсми бәяне алдык.

Безнең каучукның ниндилеген яхшылабрак аңлату өчен шуны гына әйтим: аңардан коелган ун шин гель-молекулалы каучуктан ясалган унбер тәгәрмәчне алмаштыра. Аны СЭВ илләре дә, Италия, Франция, Япония, Испания кебек илләр дә бик кирәксенеп сатып ала.

Нефть каучугыннан моннан илле ел элек ясалган шиннар белән автомобильләр сигез мең чакрым үтә. Безнекеннән коелган шин илле меңнән алып сиксән мең чакрымга кадәр чыдый. Шушындый шинның өч-дүрт комплекты машинаның бәтен гомеренә җитә дигән сүз. Эзләнүләр әле һаман да дәвам итә. Иртәме-соңмы машина гомеренә чыдарлык шиннар ясалачагына да ышанам әле мин. Кем өлгеррәк, ачыш шуныкы булачак. Дан, шөһрәт, рәхмәтләр — барысы да аңа!

Мин. Шөһрәте-фәләне — мәсьәләнең әхлакый ягы. Мондый сүзләр, күзгә күренердәй файдасын күрсәтә барсаң, үтемлерәк. Без һәрвакыт җитештерелгән әйберңең бәясе аны ясауга тотылган чыгымнардан зуррак булуына омтылабыз. Уйлап табулар шактый кыйммәткә төшә. Берләшмәгез фәнни ачышларны эшкә җигүдән отамы соң?

Ул. Уңышка ирешүнең юлы бер генә — ачышлардан мөмкин кадәр тизрәк файдалану. Ленинград галимнәренең «каталик комплекс»ын без, бер ел дигәндә, йөгәнләп алган идек инде. Күп очракта тәвәккәллектән куркалар, «тирә-күршенең» сынап каравын көтәләр.

Фән исә тиз үсә, вакыт очар коштай фырлап узып тора. Химия яңалыкларының эшкә җигелү вакыты, дөньякүләм исәпләгәндә, уртача биш-алты ел.

**Мин.** У-у-у! Әгәр бөтен ачышлар ленинградлыларныкы кебек барса, сез — иң алдынгылар икән!

**Ул.** Аһ, шулай гына булсачы! Ачышларны производствога кертү зур чыгымнарга бәйле. Шунлыктан бу шөгыльнең шөһрәт өчен генә түгеллеген аңлау кыен булмас. Иң зур өметләр, әлбәттә, экономиканы алга җибәрүгә, матди отышка тоташа. Менә үткән елгы тырышлыгыбызның нәтиҗәләренә күз салыйк: безнең конвейерга галимнәрнең нинди ачышлары күчкән һәм күпме файда алганбыз?

Ярославльдагы синтетик каучук мономерлары институты эшкәрткән процессны производствога кертеп, без елга дүрт миллион ярым сумлык табыш ала башладык. Ачышның яңалыгы бутиленны таркату процессына эффектлылык китерде. Ленинград белгечләре изобутилен белән формельдегидтан изоцрен алу ысулын камилләштерергә ярдәм иттеләр. Еллык файдасы — миллион ярым сум. Бөтенсоюз синтетик каучук фәнни тикшеренү институты бер заводыбыздагы кыйммәтле дезактиватор-катализаторны бик арзанлысы белән алмаштырырга өйрәтте. Ел саен тагын дүрт йөз мең сумыбыз янга кала.

Әмма кайбер ачышлардан табыш алу шактый озакка тартыла, дөнья күләмендә уртача дип кабул ителгән биш-алты елга да сыярсыймас буласың. Ярославль галимнәре 1966 елда эшләп биргән ацетонитрил дигән эретмә мисалына тукталырга мөмкин. Бу эретмә ярдәмендә аппаратчылар чималны төрле компонентларга таркаталар. Аңардан теләсә кайсы якта файдаланырга мөмкин иде, тик ачыш үз сәгате сукканны сигез ел буе көтеп яткан. Без, дивинил заводын салганда, аны тормышка ашырырга алындык. Эшкә тотынгач, проектка үзгәрешләр дә кертәләдек. Гаҗәпкә каршы, иң кыены ацетонитрилны табу булды. Аны бит, зарарлы калдык-постыкка санап, яндырып кына бетерәләр. Шулай да мең ишекне шакый торгач, аныcын таптык. Төп прсектта каралган дүрт аппаратның икесен генә эшләтергә хәл кылдык. Көйләп җибәргән елда ук — ике миллион ярым табыш! Безнең отышка кызыгып, башкалар да бу эретмәгә ябыштылар. Бу чакта ачыш ясалганга ун ел иде инде.

**Мин.** Бераз сыналган фикергә таянуны хуп күрәләр икән, монысы аңлашыла. Яңа завод салына башлагач, төзүчеләрне ашыктыра алмый интегәсездер әле?

**Ул.** Анысын әйткән дә юк: җан әрни, яңа завод салам, дип, күкрәк киереп йөрибез, ул инде, кем әйтмешли, «былтыр кылган гөнаһы» булып чыга. Гигант корылмалар белән эш итү бигрәк тә катлаулы. Аларны мең бәла белән сафка бастырып кына өлгерәсең, инде синекеннән камилрәк ысул ачылган була. Бер-ике ел эчендә түгәрәкләнә торган төзелешләр аклана. Зур аппаратуралы цехларның исә үз өстенлеге бар: андыйларда эшләү нәтиҗәлерәк, югалтулар азрак анда, биредә калдыклардан файдалану мөмкинлеге зур. Тик гигантлар төзелешкә вакытны күп алып үзәккә үтәләр. Иң камил техник-технологик ысуллар, завод өлгергәндә, нәкъ төзелешкә киткән еллар кадәр искергән була. Шулай да чигенер урын юк: һәрчак фәнни ачышларны күзәтеп торырга, проектта чактамы, төзелеш дәвамындамы, инде заводың эшкә тотынырга җыенгандамы — отышлы яңалыклардан файдалану җаен табарга кирәк. Авыр, тик башка юл күрмим мин.

**Мин.** Алайса, сез яңалыклардан калышмаска өметләнәсез? Бу

омтылыш яңа заводларны, бер баштан, салырга, икенче ягыннан сүтә баруга китермәсме?

Ул. Һәрхәлдә, мондый борылышларга әзер торырга тиешбез. Акыллы җитәкче, яңа төзелешкә тотынганда ук, аңа киләчәктә өлешчә үзгәрешләр кертеләчәген чамаларга тиеш.

Мәсәлән, без бутадиен җайланмасында, элекке технологиядән баш тартып, кислородтан файдалану ысулын керттек. Билгеле булганча, химик аппаратчының төп эш коралы — җылылык белән суыклык. ТЭЦыбыз бер төрле гидростанцияләрдән дә куәтлерәк безнең. Бер тонна дивинил җитештергәнче генә дә алтмыш тонналап пар сарыф ителә. Без реакторга кислород кертергә булдык. Чималыбыз үзе үк энергия чыганагына әйләнде. Молекуладан «ычкынган» водород өстәмә җылылык бирә башлады. Елга — өч миллион табыш!

Изопрен заводында, яңа төр катализатордан файдаланып, илле миллион сумны янга калдыру җаен таптык. Минемчә, химия белән бәйле эштә фән яңалыкларын тормышка ашыруга тотылган чыгымнар үзен бише белән кайтара. Бу очракта халыкның, тәвәккәл таш яра, дигән сүзен истә тоту хәерле.

Мин. Николай Васильевич, сез фәннең химикларга гаҗәеп отышлар китерүен раслыйсыз. Бу хакыйкатьне, мәгаен, башкалар да беләләрдер инде. Шуңа да карамастан, яңаны иҗат итү белән аны эшкә җигү арасында ун-унбиш еллап вакыт уза. Бу акрынлыктан шактый зыян күрәбез. Ничек уйлыйсыз: техника прогрессы тизлегеннән калышмас өчен, нишләргә кирәк?

Ул. Иң элек, бу эшне алдан күрүчәнлек сәләтен җигеп, халыкны да дәртләндерерлек иттереп планлаштыру кирәк. Социалистик хуҗалыкның иң изге максаты һәр тиеннең кадерен белүгә, отышлырак ысулдан, фән яңалыкларыннан тизрәк файдалануга юнәлдерелгән.

Ачышның асылы галим исәп-хисабында яки сынау лабораторияләрендә генә дә хәл ителми. Болары — мәшәкатьләрнең башы гына. Галимнәр, инженерлар, төзүчеләр, эшчеләр, кулга-кул тотынып тырышасы бер урында, әй китәләр буталып, әй куера сафсата, бик вак мәсьәләләр бердәм булырга тиешле кешеләрне тәмам ызгыштырып бетерә. Монда, миңа калса, чиктән тыш үзәкләштерү дә, күзәтергә куелган, виза салып, ризалыгын белдерергә тиешле оешмаларның, җаваплы кешеләрнең биниһая күплеге дә комачаулый. Фәнни ачышны тизрәк эшкә җигәсе урынга әнә шул оешмаларга, уннарча белгеч-киңәшчеләр артыннан йөреп күпме вакыт исраф ителә?!

Илебез экономикасын бөтенләй яңа баскычка күтәргән, дөньяда тиңнәре булмаган Татарстан һәм Себер нефть промыселлары, КамАЗ, Түбән Кама һәм Тобол нефтехимия комплекслары кебек гигантлар идарә итүнең дә үз колачларына тиң камил ысулына мохтаҗ.

Мин. Сез үзегезгә генә бирелгән өстенлекләр кирәксенәсез инде, алайса?

Ул. Мин бу мөстәкыйльлекне «өстенлек» дип атамас идем. Олы вазифалы җитәкчеләргә социалистик хуҗалык итү принципларыннан тулысынча файдалану мөмкинлеге һәм аларны камилләштерә бару кирәк. Магнитка, Днепрогэс, ГАЗ, ЗИЛ кебек каһарманнарны җитәкләгән беренче «кызыл командирлар» хезмәте хуҗалыкны социалистик юлдан алып баруның сокландыргыч үрнәген күрсәткәннәр иде. Исәпләсәң, ис китәрлек: ул чордан соң күпме вакыт узган! Бүген экономикабызның нигезен аерым завод-фабрикалар түгел, ә киң колачлы гигантлар, комбинатлар, эре берләшмәләр тәшкил итә, җитештерүчән көчләрнең йөзен концентрацияләү алымы билгели, шул гына иҗтимагый хезмәтнең иң зур җитештерүчәнлеген тәэмин

итэ ала. Түбән Кама нефтехимия комплексы синтетик каучукны, Көнбатыш Европаның иң алга киткән илләренә караганда, күбрәк бирә. 1983 елда безнең шәһәрнең нефтехимиклары гына да бер миллиард сумлык байлык җитештерде, 1990 елга бу сан икеләтә артачак. Олы адымнарыбыз идарә итүне камилләштерүдә кискен таләпләр дә куялар, берләшмәләрне җитәкләү бурычы йөкләнгән кешегә мөстәкыйльлек бирүдән куркырга ярамый. Ул, бәләкәй генә мәсьәләне чишкәндә дә, әллә кемнәргә: «Рөхсәт итегезче!» — дип инәлмәскә тиеш.

Мин. Николай Васильевич, бу кадәресе — шактый гомуми мәсьәлә, бугай. Шул ук хәлне фән кешеләре белән производство вәкилләре арасындагы мөнәсәбәттә аңлатып булмыймы? Сез практиклар һәм галимнәрнең уртак хезмәтенә этәргеч ясардай нинди отышлы алымнар күрәсез?

Ул. Моның бер бик күркәм үрнәге бар — үзенең ачышын азагына кадәр илтеп җиткерү өчен, Эдисон үз кул астында ук приборлар конвейеры, станоклар, кирәкле материаллары булган махсус фабрика салдырган. Безнең хезмәт мең тапкыр катлаулырак, максатлар да бөтенләй башка. Бүген иҗат итүче галимнәр үз эчләрендә генә кайнап ятсалар, һичнинди уңышка да ирешә алмаслар иде. Безнең көннәрдә «тирә-күрше» ярдәменнән башка яшәү мөмкин түгел. Электрик лампа ясауны көйләп җибәрү — бер нәрсә, атом реакторын, синхрофазотронны яки лазер җайланмаларын җитештерү — башка. Бары бер генә юл кала: халык хуҗалыгы тармакларын кыюрак специальләштерә барып, галимнәр һәм практикларның элемтә челтәрен камилләштерергә иде!

Эдисонның эш алымыннан өйрәнер нәрсәләр дә бар. Аның тәҗрибәсеннән күренгәнчә, фән белән элемтәгә кергән эш кешесе шактый мөстәкыйль булырга тиеш. Заказ бирә икән, акчасын үзе түләсен, бер төрле тәкъдимнәрне кабул итсен, кирәксез санаганыннан баш тартсын. Файда китерүчеләргә бүләк өләшсен, зарар гына итәрдәйләренә сәлам да бирмәсен.

Мин сезгә безнең коллективның тынгысызлыгы, фидакарьлеге, тәвәккәлеге аркасында табылган миллионнар турында сөйләдем. Беләсезме: шулардан без үзебез телэгәнчә файдалана алмыйбыз. Минемчә, бу нәрсәгә төгәллек кертергә кирәк: өстәмә табышның фәлән проценты берләшмәнең үзенә кала, дип кистереп куярга! Дөрес, предприятиеләрнең хокукларын һәм бурычларын өйрәнеп тәҗрибәләр дә ясала. Тормышчан бер чишелеш таба алганыбыз юк. Әйбәт кенә бер тәкъдим закон төсен ала башласа, шуны тикшерүче канцелярия юлга мең төрле киртә түшәп куя да, кирәкле яңалык тагын нәтиҗәсез кала.

Мин. Николай Васильевич, халык хуҗалыгын тагын да алга җибәрердәй, иң эффектлы ысуллардан файдалану сезнең кулда түгелмени? Идарә итү ачкычы, сметаларны, лимитларны, проектларны раслаулар; нинди машинаны сайлап алу хокукы, кайсы технологик системага тукталу, яңа тәвәккәл фикерне тормышка ашыру өчен, өстәмә реакторлар, цехлар, заводлар салдыру — барысы да сезнең ихтыярда түгелмени?!

Ул. Өстән генә карасаң, барысы да — минем кулда. Чынбарлыкта, бераз башкачарак. Менә шул «бераз» дигәне аякны-кулны тышаулый да куя. Фәнни ачышны эшкә җигәргә җыенган генераль директорның нинди хокуклары бар дип уйлыйсыз. Һәр яңалыкны тормышка ашырырга биш йөз мең сум акчасы бар аның: проектка заказ да бир, җиһазлар да сатып ал, берәр нәрсәне үзгәртеп тә кор, өр-яңа завод та сал. Унбиш ел элек, әле бу мәйданда бер генә произ-

водство эшләп ятканда да, хәл шундый иде, заводлар саны унбишкә тулгач та, шул ук күренеш. Әле еллык продукциябез ике миллиардка җиткәндә дә нинди дер үзгәреш булачагына ышаныч юк. Ярты миллион сум акча безнекедәй баһадирның ихтыяҗлары алдында — эссе чүлдәге бер тамчы су. Кайбер яңа фикерне тормышка ашыру өчен үз көчләребез дә җитәрлек була, мин барыбер әллә кемнәрдән рөхсәт сорарга мәҗбүр: кешедән-кешегә, ишектән-ишеккә, шәһәрдән-шәһәргә йөгерәм, поездан төшәм, самолетка ашыгам.

Бер мисал да китерим инде. Безнең «Этилен-450» комплексын салганда без аның продукциясенә ихтыяҗ зур булуын күздә тоттык. Комплексның аппаратлары Казан, Уфа, Стәрлетамак кебек ерак шәһәрләргә җир асты торбалары белән тоташтырылды. Мондый масштаблы төзелеш дөньясында да бик сирәк. Агрегатларның нәтиҗәле эше, үзеннән-үзе аңлашыла инде, комплекстагы хезмәткәрләрнең фидакарьлегенә генә түгел, җитештерелгән продукциянең әзлекле кабул ителүенә дә бәйле. Торбаларыбызның аргы очында аз гына тоткарлык булдымы, без кадерле этиленыбызны факел итеп яндырырга мәҗбүрбез.

Әлеге уникаль комплексыбызның сафка басуына җиде ел үтте, әмма бар куәтенә эшли алганы юк. Этилен — нефтехимиянең иң кадерле чималы, аңардан әллә ниләр ясап була. Без шуны яндырырга мәҗбүрбез. Нишләргә? Уйладык, уйладык та, этиленыбыз юлына өстәмә аппаратлар корып, аңардан дивинил алу әмәленә керештек. Дивинилны мономер-изопренга, аннан каучукка әйләндереп була. Этиленнан дивинил чыгарырга кирәкле катализатор эзләргә тотындык. Ярославльдагы синтетик каучук мономерлары институты галимнәре Ленинградтагы коллегалары белән бергәләп әле 1977 елда ук бер процесс эшкәрткәннәр икән. Безгә кирәге чыкканчы, биш ел тик яткан. Галимнәрнең пошмаслыгына да искитәрлек! Хезмәтләре тузан җыеп тик яткан. Без аны ике йөз илле сәгать буе сынадык та нәтиҗә чыгардык — нәкъ безгә кирәкле процесс!

**Мин.** Менә бит! Юньле эш барыбер үз юлын таба ул!

**Ул.** Ашыкмагыз! Башлаган эшебезнең очына чыкканыбыз юк бит әле. Ерактанрак алдырып сөйләмәсәм, аңламассыз. Кыйммәтле этилен янмасын, дәүләтебезгә байлык өстәсен өчен, әүвәл, этиленны яндырырга көйләп, сузып куелган «юл»да төрледән-төрле уннарча аппаратлар булдырыла. Аларны без үз көчебез белән дә «кырт» иттереп ясый алабыз, әмма ләкин шул корылмага рөхсәт юллый-юллый күпме вакыт китә! Проекты артыннан йөрисең, сызымнарын ясатасың, сметасын раслатырга барасың — ким дигәндә өч айлап вакыт үтә. Проектның әзер вариантын Госплан карарга тиеш. Тикшерүләр, чагыштырулар. Вакыт уза тора. Госпланның хуплавын алгач, төрледән-төрле комиссияләр аша үтеп, төзүчеләргә килеп егыласың: машиналарга, җиһазларга заказ бирергә кирәк. Заказлар исә елга бер тапкыр гына ясала. Тире сату аукционы диярсең, валлаһи! Хәер, юк, тире аукционында җиңелрәк, күңелеңә ошаганын, кул сугасың да аласың. Госснаб исә заказны үзенә бер-ике еллык җай калдырып кабул итә. Безнең этилен мәсьәләсенә үткән ел тотындык. Этилен факелыннан файда күргәләгәнче, тагын күпме вакыт үтәр? Канцелярия сазлыгының аяусыз суыру көченә чыдый алмыйча, нинди генә кыйммәтле фикерләр сүнми дә, никадәрле файдалы эшләр юл башында ук тукталып калмый!

**Мин.** Кат-кат тикшерүләр, бәхәсләр зур ялгышлар җибәрмәскә яхшы инде ул үзе, нәтиҗәсе ышанычлы була.

**Ул.** Әлбәттә, бу баскычланып тезелгән тикшерү-күзәтү системасының уңай яклары да бәхәссез. Шундый эшкуарлар да очраштыр-

галый ки, аларның лаф орып йөрүләреннән бер тиенлек куян, мең тиенлек зыян гына килеп чыга. Тик мондыйлар — меңгә бер. Шулар аркасында җиң сызганып, янып-көеп эшләүче йөзләрчә директорлар күпме гомерләрен исраф итәләр. Фән-техника прогрессы безнең уннарча ишекләрне кагып йөрүебезне көтеп тормый, бүген гаҗәеп отышлы булып күренгән ачыш та иртәгә инде безне сокландырмаячак, чөнки яңасы туа, эш кешеләрен шунысы кызыктыра башлый.

Мин. Николай Васильевич, сез — директор да, фән кешесе дә, ягъни галим һәм практик буларак, бу мәшкел хәлдән ничек чыгар идегез?

Ул. Иң мөһиме — кәгазь боткасыннан котылу! Госплан, Госстрой, Госбанк, министрлык кебек дәүләтнең бинһая җаваплы оешмаларын вак-төяк инспекторлык-тикшерү вазифасыннан азат итәргә иде. Агымдагы мәшәкатьләрне башы-аягы белән турыдан-туры эш кешеләренең үзләренә йөкләргә. Бу адым, бердән, дәүләткүләм бурыч үтәүче оешмалар хезмәтенә дә җиңеллек китерә, икенче яктан, КамАЗ, нефть промыселлары, Түбән Кама нефтехимия берләшмәсе кебек гигантларны җитәкләүче кешеләрнең кул-аягын бушата. Аларның мөстәкыйльлеге, һәрхәлдә, ярты миллион сум белән чикләнмәскә тиеш. Бу зурлыкны ун-егерме тапкыр арттырганда да, андый адым акланачак. Ул чагында әлеге коллективлар фәнне чын мәгънәсендә эшкә җигә алачаклар, яңа ачышларны тормышка ашыру тизләшәчәк, дип ышанам.

Мин. Шулаен шулайдыр. Миңа калса, сезнең сүзләрдән бу юлдагы тагын ике чатаклыкны тотып алырга була. Беренчесе — эш кешеләренең фән яңалыклары белән соңга калып танышуы. Икенчесе — галимнәрнең үз ачышларына битарафлыгы. Яңалык ачкан, шуны тормышка ашыру турында уйлап та карамый. Статистика мәгълүматлары да илдәге фәнни ачышларның өчтән бере генә производствога кертелеп баруын раслый.

Ул. Эштә фән яңалыклары белән вакытында танышып өлгерә алмау хак. Аларны тулысынча барлап бетерү мөмкин дә түгел. Билгеле ки, хәзер дөньяда химия фәне турында гына да 325 журнал, ел саен өч меңләп китап чыга, меңнәрчә диссертацияләр яклана, җитмеш меңләп мәкалә языла. Моннан эшкә чумган инженер аларның һәммәсен дә карап өлгерә аламы? Иманым камил: вакыты сыйдырса, һәр ачыш белән танышуны ул зур бәхеттән санар иде. Сез күтәргән таякның икенче башы, минемчә, үтемлерәк. Галимнәр ачышларының эштә файдаланылуы өчен ныграк кайгыртсалар, без күбрәк отар идек. Һәр институт кайда нинди химия заводы эшләп ятуын бик яхшы белә, яңалык турында шуларга хәбәр итәргә мөмкин бит. Безнең үз галимнәребез ачкан яңалыклар, башка тарафлардагы ачышларга караганда, производствога тизрәк керә. Чөнки безнекеләр берләшмә ихтыяҗларын күздә тотып иҗат итәләр. Аларны шикләнмичә планлаштырып куярга да була. Читтәге галимнәрнең ачышы гомумирәк тәстә чишелә, аны безнең җайга борырга кирәк әле. Аннары фәнни яңалыкның нәтиҗәсен күргәнче, бик күп «карарак» эшләр үтисе була. Институт галимнәре мәсьәләнең бу ягы белән шөгыльләнергә атлыгып тормыйлар. Ачышның илгә турыдан-туры байлык китерүе галимнәрне матдиаль яктан да кызыктырмый. Андый чаралар юк дәрәҗәсендә. Ә яңа фикернең тузан җыеп, киштәдәге папкада ятуын акларга мең төрле сәбәп табарга була.

Мин. Николай Васильевич, сез, галимнәр ачышларын үзләре юллап йөрергә тиеш, дигән фикердә торасыз кебек.

Ул. Бу хакта күп тапкырлар әйтелде инде. Безнең илнең эретеп ябыштыру өлкәсендәге мөхтәрәм галиме, сәләтле оештыручысы һәм

олуг практигы Е. О. Патон моннан шактый еллар элек: «Конкрет эштә сыналып, расланып күрсәтелмәгән теориянең бер тиенгә дә кирәге юк! — дип чыкты.— Ачык максаты булмаган, практик файдалану тапмаган ачыш — җимешсез агач...»

Мин бу фикер белән тулысынча килешәм. Советлар Союзында бер миллион дүрт йөз мең фән эшлеклесе бар. Иөзләрчә институтлар. Мондый байлык дөньяның башка бер илендә дә юк. Әмма галимнәребезнең хезмәте ачышлар санының күплегенә карап түгел, ә, һичшиксез, илгә нинди байлык тудыруыннан чыгып бәяләнергә тиеш. Хәзергә, кызганычка каршы, без аларның иҗат нәтиҗәсен, күп очракта, өем-өем кәгазьләргә таянып кына исәплибез.

Дөрес, соңгы елларда фәнни оешмалар һәм производство коллективлары арасында хуҗалык исәп-хисабы килешүе белән эшләү мөмкинлеге булдырылды, тик бу очракта да уртак тел табуы җиңел түгел. Ник? Чөнки галимнәр, үзләренә тапшырылган эшне башкару өчен заводның акчасын, материалын, фәләнен-төгәнен алалар, алалар да, эшне тизрәк тапшыру ягын карыйлар, төп нәтиҗә белән кызыксынмыйлар. Ашыгуларын аңлап була — табыштан аларга берни дә тими. Табыш бер миллионмы, әллә йөз миллионмы — аларга моның кызыгы юк. Яңа фикерләрен практик эштә файдаланырлык иттереп очлап чыккан галимнәр, ачышлары китергән байлыкның тәгаен билгеле бер өлеше, законга нигезләнгән рәвештә, фәннең үзенә бүленәчәгенә нык ышанырга тиешләр. Аларга күпме бирү-бирмәү кемнеңдер шәфкатенә яки кырыслыгына гына бәйле булмасын иде!— Әлбәттә, практиклар да галимнәрнең миеннән сыгылып чыккан отышлы фикерләрдән файдаланып ятучылар ролендә калмаска тиешләр! Бу ике як та бер үк изге бурычны үз күреп, ихластан эшләсә генә гомум уңыш киләчәк.

Дөрес, законда фәнни ачышка хак түләү каралган. Тик моңа да ачыклык кертү кирәк. Бүген фән белән зур-зур коллективлар, әйтергә мөмкин, массалар шөгыльләнә. Аларга исә гадәти премияләр генә бирелә. Ачышлардан алынган табышның бер өлеше фәнни институтлар карамагына, аларның җирлеген нығытуга махсус бүлеп куелсын иде. Хәзергә саклана торган кагыйдәләр фәннең тар чикләргә сыешмавын бөтенләй искә алмый. Әйтик, безне яңалыкның кайда тууы кызыксындырмый, файдасы күзгә ташланып тора икән, чат ябышабыз. Әмма фикер иясе башка, мисал өчен, корыч кою яки элемтәчеләр министрлыгыныкы булса, ачышыннан миллионлаган файда тапсак та, безнең аны бүләкләргә хакыбыз юк.

Бер мисал. Без Казан химия-технология институты, СССР фәннәр академиясе Казан филиалының А. Е. Арбузов исемендәге органик һәм физик химия институты галимнәре белән тыгыз элемтәдә яшибез. Монда йөзләрчә күренекле химиклар тупланган. Эзләргә, тикшеренергә яраталар, тынгысызлар һәм үзләре, халык әйтмешли, «шыр Тукайлар», акчага әллә ни исләре дә китми. Алар бит күпме файдага юл яралар! Эшне ихластан бирелеп, ачышлары ләззәтенә исереп, энтузиазм, патриотик хис белән канатланып башкаралар.

Бу галимнәрнең бер ярдәмен генә искә төшерәсем килә. Безнең полимерларга нигезләнгән эштә кирәкмәс реакцияләр дә чыгып тора, торбаларда, колонналарда, батареяларда үзгәрешләр барлыкка килә. Әйтик, аларның эченә юшкын утыра. Юшкын өстәлә, калыная бара һәм көннәрдән бер көнне җайланмаларны сафтан ук чыгара. Илнең бөтен нефтехимиклары бу бәладән уртак бер ысул белән котылалар: аппарат туктатыла, җайланмалар суытыла һәм юшкынны кыра башлыйлар. Шуның белән утыз-кырык кеше атна буе шөгыльләнергә мәҗбүр. Без исә, әлеге дус галимнәребез ярдәмендә безгә кирәк булмаган реакцияне тоткарлаучы реагент таптык. Мәһабәт

колонналарыбыз өзлексез эшләп утыралар. Шул реагенттан файдалану биш заводыбызга ел саен биш миллион экономия китерә. Табышның бер өлешен әлеге институтларга бүлеп кенә җибәрер идең — ярамый. Министрлыклар башка. Шик юк ки, фәнни оешмаларның эшен киңрәк җәелдерү өчен акча бик кирәк. Ачышларның матди файдасыннан аларга да билгеле бер өлеш өстәлә барса, галимнәрдә үз фикерләрен тормышка ашыру теләге, мөген, көчлерәк булыр иде. Социалистик җәмгыятьнең: «...һәркемгә — хезмәтенчә», дигән төп принцибы галимнәргә дә кагыла лабаса!

Казан дәүләт университеты, Мәскәү химия-технология институты, Әзербайҗан фәннәр академиясенең химик процессларны өйрәнү институты, Воронеж һәм Тольятти политехника институтлары галимнәре дә безнең белән кулга-кул тотынышып эшлиләр. Әлбәттә, мөнәсәбәтләребез төрлесе белән төрлечә. Заказларыбыз күп. Кызыклы, җитди мәсьәләләр. Производство калдыкларыннан тулырак файдалану, энергия чыгымнарын киметү, реакторларны тулы куәтенә эшләтү, чималдан отышлырак файдалану һәм башка проблемалар чишелеш көтеп ята.

Бөтен җитешсез-кимчелекле мәсьәләләрне галимнәрнең пассивлыгыннан чыгып кына аңлату җиңел, әлбәттә. Тик мондый аклanулар гына эшне алга җибәрми бит. Безгә галимнәрнең производствога бүгеннән үк кирәкле проблемаларга теләр-теләмәс кенә алынуларының тирәндәге сәбәпләрен ачарга иде. Ни өчен дөнья шаулатырдай яңалык эзләү өстендә баш ватып утырырга һәр галим мең риза, ә гадирәк, турыдан-туры практикага бәйле, бүгеннән кирәкле мәсьәләне чишәргә керәү дә атлыгып тормый?

Акчага күчертеп исәпләсәк, безнең берләшмә фәнни тикшеренүләргә ел саен өч миллион сум туздыра, производствоның тулаем чыгымнары исә сигез йөз миллионга баса. Шушы саннарны чагыштырудан гына да хезмәт коллективларының фән белән элемтәсен тагын да ныгыта төшәрдәй нинди мөмкинлекләре барын аңлап була.

**Мин.** Сез, фәнни ачышларга сарыф ителә торган хезмәтләрне дә, акчаны да кызганырга ярамый, дип табасыз. Шулаймы?

*Ул.* Алай гына да түгел. Мин фәнни ачышларны бәяләгәндә төп билгеләмә итеп отчетлар, диссертацияләр, мәкаләләр санын күрсәтүне хуплый алмыйм. Бәя фәнни ачышларның тормышка ашырылуыннан, халык хуҗалыгына күпме табыш китерүеннән чыгып бирелергә тиеш. Һәм галимнәр, хәтта бу очракта да, белеп торсыннар иде: әле яңа фикерләрен хуҗалыкларда файдалана башлау да — эшнең тәгамләнүе түгел, чөнки фән инде алга китәргә өлгергән, производство алардан тагын да кыюрак адым көтә!

**Мин.** КПСС Үзәк Комитеты Пленумнарында да бүгенге көннең иң зур бурычларыннан берсе итеп ил экономикасына этәргеч ясардай иҗади көчләргә ныграк таяну, аларга зуррак мөмкинлекләр тудыру хакында әйтеп торалар. Мондый чараларның социалистик экономиканың алга баруына юнәлдерелгән булуы да кисәтелә...

Безнең әңгәмә, күргәнегезчә, шактый тирәнгә кереп, илебезнең киң колачлы экономикасын да үз эченә алды. Фәнни ачышлар, уйлап табулар, яңа фикерләрне турыдан-туры эшкә җигү мәсьәләләре РСФСР Верховный Советы депутаты, Социалистик Хезмәт Герое, «Нижнекамскнефтехим» берләшмәсе генераль директоры Николай Васильевич Лемаевның бөтен күңелен биләп алганнар. Ул, бурычларын тирәннән аңлап, фәнни-техник прогрессны халык хуҗалыгы файдасына нирләүдә зур җаваплылык тоеп яши, эшли, иҗат итә.

Мөхәммәт Мәһдиев

# МӘҢГЕЛЕК ЯЗ

РОМАН



Жалобаның монысы да булган эшкә нигезләнгән иде. Монысы да хуҗалык эшенә кагылмый...

...Мең тугыз йөз кырык бишенче елның җәендә авылга әллә каян әллә кая баручы бер сукбай карт килеп керде. Кемгәдер тукталып, мосафир буларак чәй эчте, ул арада кемдәдер кунып калды. Үзе белән шул көнне үк мәшәкатьле хәбәр дә алып килде. Имештер, шушы елның урталарында, ягъни июньнең соңгы көне белән июльнең беренче көне тирәсендә җир шарына бик зур йолдыз бәрелүе мөмкин. Имештер, бу турыда галимнәр, халык курыкмасын дип, әйтмиләр, ә үзләре әллә кайчан инде бөтен булган алтын-көмешләрне базарга чыгарып сатып, бөтен булганны ашауга тоталар, бал да май эчендә йөзәләр, ди. Казанда яшәүче зур бер галим әнә көн саен базардан бер тавык (!) алып кайтып ашый, ди...

Соң, нишләргә? Әмәл бар, имеш. Җиргә шушы көннәрдә генә Хөзер Ильяс иңгән, ди. Һәм ул әйткән ди: бу сугышта мөэмин-мөселман балалары бик күп шәһит китте, аллаһе тәгаләнең шуларны кырган дошманнарга каһәре төште, шуңа күрә җир өстенә зур бер йолдызны юнәлтте. Әмма ул йолдыз килеп җиткәнче әле бөтен халыкның да кылган гөнаһларыннан тәүбә итәргә, алланы искә төшереп, аның бирлеген танырга вакытлары һәм мөмкинлекләре бар. Шуңа күрә, менә монда язылганнарны һәр кеше тугыз данә күчереп язып, тугыз кешегә таратсын. Ул тугыз кеше тагын тугыз кешегә. Әгәр дә кем дә булса шуны үз кулында йомып калса, ул кешенең тугыз көн эчендә аяк-куллары тартышыр.

Авыл гөж килде. Фронтовиклар гына көлеште. Әмма сугыш дәһшәте кеше йөрәген бәла-казага, хәсрәткә чыныктырып кына калмаган, бәлки тетрәнеп алырга да өйрәткән иде. Карт-коры, диндар кешеләр тетрәнеп алдылар. Язу тарату китте. Шул язуларның берсе Сәкинә кулына килеп кермәгән булса, нәрсә белән тәгәлләнер иде бу язышу...

— Ах, контра, Колымага сөрдерим әле мин аны,— дип, Сәкинә җигүле сиртмәсенә утырып теге карт туктаган тол хатын йортына чатыр чабып килеп тә җитте. Дилбегәне йәлт кенә ат сыртына ыргытып, чыбыркысын тотып өйалдына бәреп керде, өйгә үк узды. Узды һәм... телсез калды. Идән уртасындагы зур лаканда су эчендә иске кәрзин кебек

---

*Ахыры. Башы 5 нче санда.*

таралырга торган кабыргалы бер гәүдә утыра. Лакан эченнән пар чыга, идәндә, лаканда пешекләгән, пешекләмәгән кычыткан көлтәләре, әрекмәннәр, тагын әллә ниләр... Картның чыкмаган җаны гына бар иде, Сәкинә сугыш вакытында Хәйбулла картны трактор плугына утыртып бер мәртәбә авызы пешкән булганлыктан, монда саграк булды.

— Син...— дип буылып кычкырды ул хуҗа хатынга.— Син! Нинди контраны оялаттың монда? Лично үзең килеп документларын күрсәтерсең иртәгә! Аңлашылдымы? Бирермен мин...

Июль керде, теге йолдыз бәрелмәде, ул арада, яши торгач, тернәкләнеп, карт үзенә шөгыль дә тапты: халыкка мәет күмәргә, тегесен-монысын башкарырга ниндидер бер кеше кирәклеге сизелде, ә теге Хөббетдин агай шундыйны булдыра торган кеше булып чыкты.

Шулай яшәде дә калды, вак-төяк, кирәк яракка тотарга акча гел кереп торды. Авыл халкы аңа ияләнде, бик үз итеп бетермәсәләр дә, чит тә итмәделәр.

Җалобаны укыганда Ахиярның күз алдына шул карт килеп басты. Бичара... Ерак җирләрдән кайткан булган ул, ә хатыны сугышка кадәр үк әллә кай якка кияүгә чыккан икән. Үз авылларына кайтып төшәргә ирлек горурлыгы рөхсәт итмәгән, шуңа күрә авылдан-авылга җылы түшәк эзләп йөргән. Ахияр аны соңгы тапкыр ветсанитар Закирҗан өендә күрде. Кыш иде, әле узган кышның салкын февраль киче иде. Егерме өченче февраль. Идарәдән кайтышлый Ахиярның нигәдер эче пошып калды: солдат бәйрәме көне бүген, ә алар идарә утырышы уздырып яталар. Бәйрәм онытылган. Ахиярлар буыны өчен изге бәйрәм көн бүген. Моны сугыш вакытында да билгелиләр иде. Анда да вакыт, игътибар, бер чәркә зәм-зәм суы табыла иде. Ахиярның үз өенә кайтасы килмәде. Аңда ни ирләрчә сөйләшерлек кеше юк, ни эчемлеге юк. Закирҗан мөгаен өйдәдер! Төп-төгәл генә итеп, салып утырадыр. Солдат бәйрәмен ул билгеләмичә калмас. Калмас...

Закирҗаннарның тәрәзәсеннән кар өстенә куәтле өч көлтә төшкән, түрдәге биек рәшәткәләр аркылы ул көлтә юл-юл булып урам аркылы сузылган. Яңа чолан сайгаклары Ахиярның авыр гәүдәсеннән чатнап таза салкын тавыш биреп алдылар. Күлмәк изүләрен чишкән Закирҗан өйалдына чыгып каушап калды.

— Бәр-рәч... Бәлеш-күмәч-пәрәмәч, дигәндәй. Ничек болай керәсе иттең, иптәш Гарәфиев? Әйдүк, әле мунчадан чыгып кына утырадырыек. Әйдүк...

Үзе каушады, үзе шатланды. Ишек келәсен чак эләктерде. Көтелмәгән кунактан хатыны да каушады. Яңа йортта председательнең беренче булуы иде.

Чишенеп өстәл янындагы йомшак урындыкка килеп сеңгәч, Ахияр беравык күзләрен учы белән каплап уйга калды. Закирҗан белән хатыны йөгерешәләр иде. Йортка пилмән исе чыккан. Ахияр дөньяны онытты. Пилмән... Бу ризык — аерым бер ризык. Бу — тамак туклыгы гына түгел. (Ахияр, гомумән, ашау темасына сөйләшергә, аны кайгыртып мәшәкатьләнергә яратмый иде һәм әдәбият укыганда да хәзерге кайбер язучыларның үз әсәрләрендә бик тә авыз суларын кортып ашау-эчү процессларын тасвирлауларына каны катып, китапны читкә алып куя иде.) Юк, ашау турында язарга ярамый. Әзерләү турында дисәң — анысы икенче мәсьәлә. Мәсәлән, пилмән әзерләү. Ахияр бала вакытын хәтерли. Көндезен әнисе чапкыда ит чаба. Тук-тук... Суган турый. Борыч сибә. Менә кышның киче җитә. Әнисе келәткә чыгып кәрҗингә утыртылган чирекле ике (өчәр литрлы) шешә алып керә. Шешәләр салкын, алар өйгә кергәч тирләп китәләр. Бераздан өйгә керосин исе чыга. Салкын, хуш ис: бу ис матур озын кич вәгъдә итә. Авызыннан пар өрә-өрә әнисе лампа пыялаларын чистарта. Аннары лампага керо-

син салалар. Ахияр — кечкенә ярдәмче — бүрәнкәне тотып тора. Зәңгәр сыман керосин голт-голт итеп чирекле шешәдән бүрәнкәгә коела. Әнисе әйтә: керосинның иң әйбәте зәңгәр сыман була, ди. Сарысы — корымны күп ясый, сасы була, ди. Аннан өйгә гөлт итеп нур тула. Аннан әнисе озаклап кер сабыны белән кулларын юа. Ара-тирә:

— Я алла, эстәгъфирулла,— дип куя.

Аннан пилмән ясарга утыралар. Моңа ике-өч яшьлек Айзәрә дә кушыла, әмма ул әле пилмән ясый белми, ул ара-тирә камыр каба, әнисе күрмәгәндә чи ит тә кабып куя. Әниләре әйтә, борыч, тоз салгач, пилмән ите яртылаш пешкән була инде ул, ди. Балачак... Керосин лампасы, кышкы озын кичле, әтиле-әниле, казан өстеннән пар бөркелеп торган итле шулпа исле балачак...

...— Әйдә, иптәш Гарәфиев: без солдатлар бит. Бүгенге көн хөрмәтенә берәрне тотыйк. Безгә ярый ул. Хәзер пилмән килә.

Тоттылар. Ахияр дәшмәде, тозлы кыяр умырды. Закирҗанның сөйләшергә исәбе юк түгел иде.

— Безнең бит, иптәш Гарәфиев, тормыш юллары уртак. Син — солдат, мин — солдат. Бу булдымы бер. Син — колхозчы, мин — колхозчы. Бу булдымы ике. Ә теге якка китсәк? Син үги ана кулында үстеңме? Мин дә шулай. Әле мин хәтерлим: әнине күмгәч елап утырабыз. Әти — җиңел сөйләшә торган кеше иде мәрхүм, баштан сыйпап миңа әйтә: әни үлде, дип кайгырма, улым, яшь әни алып бирермен. Менә бит ничек ди? Миңа нәрсәгә ул яшь әни? Әйдә, гөмбәсен авыз ит әле. Мин үзем бу сыеклыкны яратмыйм, ну да, әмма ләкин, егерме өченче февраль көнне шуны тотмыйча калмыйм. Яшьлек искә төшә, автомат тотып Көнбатышка таба шуышкан, үрмәләгән, йөгергән яшьлек искә төшә, парин... Әйдә, тагын аз гына...

Чолан ишеген кактылар. Кухня ягында тәлинкәләр белән мәж килеп яткан хуҗа хатын Закирҗанга дәште:

— Син дим, бар әле, Хөббетдин абзыйдыр ул, мунчадан чыгышыдыр,— диде.

Закирҗан йәлт кенә урыныннан торып чоланга чыгып китте. Сайгаклар шартлады, ыгы-зыгы булды, ишек ачылды. Ишектән салкын һава бәреп керде, салкын һава катламы түргә узып тәрәзә тупсасы астындагы кайнар трубага бәрелде дә, җиңелеп өстәл артына борылды. Закирҗанның шау иткән тавышы ишетелде.

— Әйдә, әйдә, Хөббетдин абзый, аз гына хәл алырсың, монда читят кеше юк,— диде.

Картның мунчадан чыгышы һәм, гадәт буенча, хуҗаларга рәхмәт әйтеп узышы икән. Ахиярның бу картны күптән күргәне юк иде, бичара, пенсиясе юк, туган-тумачасы юк, кешегә зыяны тими, мәет булса — шунда барып карап күмешә дә, шул көенчә яши бирә, теге карчык та аннан зарланмады...

— Әс-сәламе галәйкем,— диде юллы тышлы тун кигән карт, Ахиярны күргәч бераз каушап китеп.— Мин рәхмәт әйтергә генә кактым чоланны, мунчагыз бик парлы, сулары бик мул булды. Ходай тәгалә сезгә байлык-дәүләт бирсен...

— Әйдә, әйдә, Хөббетдин абзый,— дип Закирҗан мәж килде,— әйдә, иптәш Гарәфиевнең безнең бу яңа өйдә беренче булуы әле, әйдә, түрдән уз. Бүген — безнең бәйрәм.

Карт, кыенсынып кына бүреген салды, бүреккә ияреп чыккан түбәтәен төзәтеп киде, тунын салып Закирҗанга тоттырды, ябык муеннары тирләгән, арык йөзе, сөякчел башы гел судан гына тора иде, шулай да сынаулы елмаеп өстәл янына килеп утырды.

— Син, дим, карале, Хөббетдин абзыйга чәй чыгар,— диде хатын кухня ягыннан.— Минем кулым камырлы.

Закиржан шунда Ахиярга да, Хөббетдин абзыйга да сынаулы, елмаюлы караш ташлады. Шкафтан, үрелеп кенә стакан алды да, күз кысып елмайды һәм Хөббетдин абзыйга ярты стакан салып та бирде.

— Әйдә, бүген ирләр бәйрәме,— диде.

Ахияр картка күтәрелеп карады. Нишләр икән? Әмма карт үзен егетләрчә тотты һәм шыпырт кына чәкештереп:

— Сихәт булсын, амин,— диде дә, әйләндереп тә куйды. Ахияр шаккатты. Ул арада парын бөркеп пилмән килде, серкә, борыч килде, хуҗа хатын шат, бәхетле иде.

— Бәйрәм булгач, аны запаска алыбрак куярга иде,— диде ул, бушаган шешәгә карап.— Безнекеннән юк инде, елына берне мин алып кайтсам кайтам, булмаса — юк. Әле монысын да август аенда ук пенсия акчасы алган көнне алып кайткан идем. Я, хәзер нишлисең инде? Өендә ике кунак...

Ахияр туарылып калды, бу сүзләр аның колагына әллә керде, әллә кермәде, тәмле пилмәнгә тотынды.

Тешләре төшкән, яңаклары утырган карт исә рәхәтләнеп шопырдата, йомшак пилмәнне ура иде. Хуҗа хатын аларның алдына тастымал куеп чыкты. Ахияр бер сүз әйтмәде, түбән карап уйланып утырды. Менә бу карт та кеше, ул да адәм баласы, ул да ир кеше. Бу авылда аның беркеме юк, ул җиде ят, әмма ул да яши, ул да — кеше. Бу кояш астында аның да яшәргә хакы бар. Колхозга аннан бер тиен дә файда юк, ләкин аннан кешелек җәмгыятенә зыян да юк, зыян салучылар да бар бит әле, ләкин карт яши, үлгәнне күмә, кешеләр янына кыен вакытта килә, йоласын үти. Урламый, кеше таламый. Муен-маңгай тирләрен тастымал белән сөртеп алгач, карт сүз катты:

— Энем Закиржан! Мунчагыз бик һәйбәт булды, рәхмәт,— диде.— Инде, чолан каккан җирдән мине шулай зурлап өйгә алып керделәр, анысы өчен тагын бер рәхмәт. Инде, энем, монда авылның зур хуҗасы да утыра, менә миннән бер игътибар булсын — карт чалбарының арт кесәсенә кереп китте, үзенең битеннән-башыннан тир ага иде,— миннән дә бер игътибар булсын: мә, энем Закиржан, акча,— карт сигезгә бөкләнгән егермебишлекне Закирҗанга тоттырды.— Юк, юк,— дип ашыкты ул,— шушы, минем акчага алдыртсаң гына монда утырам мин, әтү — чыктым-киттем.

Карт тәмам кызган иде, Закиржан көлмәк өстенә йөлт кенә туның салып тиз генә кибетче Гаделниса өенә барып килде. Гаделнисаның шундый көтелмәгән саякъ-сандыракка төнгә өенә алып кайтып тотканын бөтен авыл белә иде. Өстәлгә бөкеле шешә килеп утыргач, карт җырлап ук җибәрде.

Сәмавәти, сәмавәти
Фәрештәләр мәкамәти [1],
Сиңа яздым сәлам хати,
Сагынмаклык галәмәти...

...Ахияр ул төнне начар йоклады. Березлексез саташты. Төшенә гел сугыш керде, гел автомат тотып бер бина эчендә йөрде, кая гына килеп керсә дә, бер дә чыгу юлын тапмады, әллә ниткән карнизларда, сәндерәләрдә гел фашист снайперы утыра, үзе сугыш вакыты икән, үзе — сугыштан соң, Колан Кырда икән, фашистларның чолганышта калган бер отряды колхоз фермасына урнашып оборона тота икән... Каяндыр березлексез аталар, Ахиярга пуля да тими, әмма, ул йөргән бүлмәләрдә, чорма-карниз такталарына березлексез тукылдап пулямы, ярчыкмы эләгеп, чукып тора икән, бу — үзе төш кенә икән, менә хәзер уянсаң моннан котылып та буласы, иртән иртүк районга «Межрайбаза»га ба-

[1] Югарыда, күктә фәрештәләр авазы, дигән мәгънәдә.

расы иде, уянсаң, шуны тормышка ашырып булыр иде, юлда ат дугасына божра бәргәнне тыңлап баруы бик тә рәхәт буласы иде, әмма — фашистлар... Һаман аталар, һаман аталар, кабәхәтләр... Тыкъ-тыкъ-тыкъ! Тукъ-тукъ-тукъ!

Ниһаять, газаплы төш аны ычкындырды. Ахияр уянды, газаплы киерелде һәм будильникка үрелде: фосфорлы сәгать дүрт тулып фәлән минутны күрсәтеп тук-тук килеп корпусына бәрә иде. Ахияр күзен ачты һәм караваты янында сукно шәл бөркәнгән бер хатынны күрде. Танымады. Күзләрен уды.

— Карале, Ахияр энем,— диде сукно шәл.— Ни бит... Син чыгып киткәч, тегеләр кыза калды бит. Ни бит... Тегене бетергәч Хөббетдин безнең идәнгә ятты да йоклады, бит, Закирҗан да шунда гына тәгәрәгәние. Ни бит... Хатыны да кереп карады. Йоклаган йокласын инде, диде дә, чыкты да китте. Менә шул. Дүрт туларга чиректә торсам — теге суламый. Закирҗан телсез-авызсыз калды. Менә әле генә памытына килде дә, әйтә. Ахиярга кереп хәбәр ит, ди. Нишлибез? Кичтән үк җан тәслим кылган бит ходай бәндәсе...

...Ахияр анда кереп тормады. Таң алдыннан Хөббетдин абзыйны паласка төреп, кул чанасына салып үз өенә алып чыкканнар. Әлбәттә, кемнәрдер, иртәнге караңгыда бер капкадан икенче капкага таба шуышкан бу сәер йөкне күреп алганнар һәм көн яктыруга кабер казырга барган кешеләрнең берсе әйтә дә куйган:

— Председатель шәп сыйлаган, күрәсең,— дигән.

Дүртме-бишме көннән соң районнан, шәһәрдән әллә кемнәр килеп каберне казытмакчы да булганнар иде, әмма, һич тә көтелмәгәнчә, Хөббетдин абзыйның карчыгы нык булып чыкты.

— Йөрәге бик начарые, мунчадан чыгышлый хәле китеп Закирҗаннарга кергән, ике-өч тапкыр алмага кердем, кузгатмагыз, дип ялынды,— диде.— Шулай да,— диде,— Закирҗан белән күтәреп, чанага салып алып чыктым, ара ерак түгел, әмма ләкин, өйгә кереп җиткәндә иртән таңда үз кулымда җан бирде...

Карчык җавабында нык торды, каберне актартмадылар, ә менә ничә елдан соң... Ахияр хәтерли әле теге үткен карчыкны. Тикшерүче, врачларны шаккатырды ул әби.

— Нинди ул кабер куптару? — дип җикеренде ул тикшерүчегә. Тегесе татар егете иде, әмма карчык русчалап сипте.

— Аның,— диде,— узган ел гына Ташлытау бульнисендә җепселен кистеләр, гел тамак белән җәфаланды аңарчы. Аннары әйттеләр: синең авыруың нервный почкада, диделәр. Синдә имфарык булырга мужыт, диделәр. Менә имфарык бәреп салды инде аны... Моны,— диде,— дошманнар жалу иткән. Ике карга сугышканда саесканга ит була дигәндәй. Моны — юри язганнар.

— Ни өчен шундый йолаларны башкаручыга халык игътибарлы, ихтирамлы? Бүгенге телевизор, радио, космос заманында? Нигә?

Нургалиев бу сорауны Ахияр белән Байгильдеевкә генә түгел, үзенә дә бирә иде, ахрысы. Ләкин бу сорауга берәү дә җавап бирмәде. Чибәр егет исә акрын гына болай сөйләп китте:

— Ата-баба йоласын башкаручы кеше механизатор, сыер савучы, кибетче, тегермәнче, ветеринар янына ул кешенең иң авыр вакытында килә. Игътибар итегез: берәр кешегә авыр булса — ул кеше сезнең янга килә. Ярдәм сорый. Транспорт кирәк, ссуда кирәк, рәтсез малаен судтан йолып алырга кирәк, сыерын алыштырырга, өй түбәсен ябарга, урманнан бүрәнә алып кайтырга, больницага барырга... Әнә ул сезгә үзе килә, аңа авыр. Сез аңа бармыйсыз, ул килә. Монысы аңлашыла. Әмма кешенең иң авыр вакыты болар түгел, ә — үлем. Йортта — үлем. Картлар «үлем-җитем» диләрме? (Нургалиев, тәгаен генә я Әтнә я Мөслим тирәсеннән чыккандыр, телне шактый нечкәләп тоя икән). Ме-

нә шул иң авыр вакытта аңа кем килә? Әнә теге абзыйлар нәкъ менә шунда — теге кешенең иң авыр минутында аның янында инде. Ул картлар теге, үлгән кешегә бөтенләй кирәк түгел. Тегенә, исән калган кешегә кирәк алар. Әнә шул кеше мохтаҗ андый рухи ярдәмгә. Һәм кеше ахырдан аны онытмый. Әһә, бу абзый минем карт әтинең гәүдәсен юды. Әйе, бу кеше аны карап күмеште. Ул булмаса нишләр идең? Менә шулай уйлый ул. Ә без — андый вакытта, читтә. Без материаль ярдәм күрсәтәбез, тегесе-бусы белән булышлык итәбез, әмма иң нечкәсе — рухи ягына вакыт тапмыйбыз. Болар бит дин түгел, ә яшәешнең бер формасы, дөресрәге — финалы.

Сүзгә Ахияр катнашты.

— Иптәш Нургалиев,— диде ул, гаепле кеше сыман.— Менә мин сезне аңладым. Чыннан да, колхозчы семьясында кеше үлгән вакытта минем алар йортына кереп караганым юк. Ләкин безнең колхозда ике төрле милләт яши. Кечкенә генә бер авыл бар — Поник, менә мин шунда яшим. Рус авылы. Руслар кеше күмү вакыйгасына безгә караганда зуррак карыйлар. Менә аларда хәлләр... Бала туган көнне, туй көнне, кеше үлгәч керми кара син аларга. Бер тиенлек авторитетың калмый. Бервакыт бәби алып кайткан йортка керми калган идем. Карыйм, эти кеше — тракторист, иртәгесен эшкә чыкмаган. Идарәгә чакыртам.

— А шту,— ди бу,— син мине кешегә санамыйсың? Киттем бардым колхоздан, ди. Тракторист, ди, кайда да кирәк.— Менә шулай, чын күңелдән рәнҗегән. Машинага утыртып үзен, авылга кайтып яшь, бәхетле ананы өч тапкыр үбеп, иртә баштан котлап чыгарга туры килде. Трактористның ул көнне ике ярым норма бирде.

Байгильдеев тә тирән уйга чумган иде.

— Чыннан да, кешегә бик кайгылы вакытында без килмибез шул, әнә шундый бер Хөббетдин килә,— диде.— Безгә халыктан өйрәнергә дә өйрәнергә әле...

Аерылышыр алдыннан яшь егет Ахиярга тагын бер киңәш әйтте.

— Кешеләргә карата сак мөнәсәбәттә булыгыз,— диде.— Бу — стратегия. Ә сез тактик кына тоеласыз миңа. Сез, күрәм, гел алга карыйсыз. Бу — әйбәт. Әмма, вакыт-вакыт артка да борылып карап алырга кирәк. Жалоба язалар — димәк, кемнедер читләтәсез, кем беләндер ачыктан-ачык сөйләшмисез, кемдер сезгә рәнҗи...

Ахиярның председатель булып килгәннән бирле Сәкинә белән бер авыз сүз сөйләшкәне юк иде шул...

## VIII

Беренче сезонда язгы чәчүгә чыккан көнне Ахияр кырда була алмады: тиктомалга төнлә авырып китеп, манма тиргә батты. Тамак бакасы чыккан иде. Беренче килеп чыккан, җитмәсә. Туп-туры өенә керде, әллә исәнләште — әллә юк.

— Беренче сезонны шулай башлыйсызмы? — диде ул кырыс тавыш белән.— Алдан ук әйтеп куйыйм: җитәкче кешегә өч сыйфат кирәк. Болар: эшлеклелек, гаделлек һәм таләпчәнлек. Шул сыйфатларның берсе юк икән, ул кеше — җитәкче түгел. Әмма колхоз председателенә тагын дүртенче сыйфат та кирәк: сәламәт булу. Төннең теләсә кайсы сәгатендә, теләсә нинди хәлдә дә син сәламәт һәм үз эшеңне башкарырлык булырга тиешсең.

Ахияр шунда ниндидер җайсыз сүз әйтте. Аңлапмы, аңламыйчамы? Үзенең фронтта булганы, Беренченең сугыш күрмәгәне тирәсендәрәк булды ахрысы ул сүз. Беренче төксе саубуллашып чыгып китте, шун-

нан мөнәсәбәтләр киеренке төс алды. Тик бу хәл озакка бармады. Дөньяда Беренчедән дә зур кешеләр бар бит әле. Әйтик, өлкә комитеты.

Ташлытау райкомына бер көнне өлкә комитеты секретаре киләсе итте. Килеренә нибары өч сәгать кала хәбәр салды һәм әйткәненнән бер сәгатькә алда килеп тә төште. Районның картасын сорап алды, соңгы атнадагы савым белән кызыксынды.

— Киттек минә бу колхозга,— дип секретарь «Яңа юл»ны күрсәтте һәм ак фуражкасын киеп тә куйды.

Райком секретаре тамагын кырды.

— Ни бит, иптәш... Ул колхозның председателе бик начар холыклы бит. Сүз җаен белми...

— Аның сөт, ит буенча күрсәткечләре әйбәт,— диде өлкә секретаре,— характеры — сиңа. Ә миңа бүгенге көндә тегеләре әһәмиятлерәк әле аның.

Егерме чакрым араны сөйләшмичә генә селкенеп бардылар. Райком машинасы артта бара иде, алда ГАИныкы чайкалды.

— Юлларың шәп түгел,— диде өлкә секретаре.

— Аларны кайгыртырга бер дә вакыт калмый шул,— диде райком секретаре.— Гел кукуруз, икмәк, ит-сөт дип чабулыйбыз...

— Стратегия кирәк,— диде өлкә секретаре.— Стратегия. Алдагы көнгә карау. Менә син юл төземисең, күпме машина ватасың, запчасть эзлисең. Кышларын-көзләрен райүзәк, шәһәр белән элемтәң өзелә. Син ит-сөт өчен көрәшәсең. Янәсе, тегесе икенче планда. Юк шул, туганкай. Владимир Ильич әйткән: кем дә кем диган, төп, генераль мәсьәләләрне хәл итми торып икенче дәрәҗәдәге эшләр белән шөгыльләнә, ул кеше котылгысыз рәвештә әнә теге төп мәсьәләгә килеп төртеләчәк, дигән.

Шуннан ары сүз булмады.

«Яңа юл» колхозының чигендә колхоз исеме һәм «Хуш киләсез!» дип язылган такталар кагылган ике багана күренеп калды.

Председательнең кайда икәнен идарәдә әйтә алмадылар. Озак уйламыйча туп-туры терлекчелек фермасына — Поник авылына таба юл тоттылар. Фермадан читтәрәк, Кесмәс елгасының төбе кәкрәеп-бөгелгәләп беткән каеннары арасында председательнең тузган, какшаган мотоциклы күренде. Сүзсез дип әйтерлек күрештеләр. Ахияр өлкә секретарен таныды, шуңа күрә сүз башламады. Ул елганың теге ягындагы куаклыктан бозау көтүе кайтканны карап тора иде. Бозаулар аклы-каралы чуар дулкын булып куаклы тау буеннан аска — Кесмәскә таба төшәләр дә, кеше булса «ике дә уйлап тормыйча» дияр идең, ә болар — хайван бит — бөтенләй туктап та тормыйча Кесмәскә кереп китәләр. Кесмәснең ул урыны тирән түгел, әмма киң — утыз метрлар булыр. Аклы-каралы чуар корама дулкын шунда керә тора, сыртлары гына күренерлек тирәнлектән күн танауларын өскә күтәреп, колакларын торгызып бу якка — фермага таба чыга тора. Чыккан берсе кагына-кагына ашыкмыйча гына тауга, фермага таба атлый тора. Юылып, тоякларын ахакландырып чыккан бу мәхлүкъларга карап өлкә секретаре бераз тын торды һәм сорап куйды:

— Юри оештырдыңмы бу спектакльне, Гарәфиев? — диде.

Ахиярга тел керде.

— Юк, сез нәрсә... Яздан бирле шулай. Башта суга кертеп булмады. Сыер көтүе белән йөрттек берәр атна. Үгез кереп китә, аннан сыерлар. Алар артыннан бозаулар. Шулай өйрәттек. Безнең сыерлар да ул як басуда йөргәндә шулай юынып кайталар.

Өлкә секретаре балаларча шатланды. Райком секретаре да гадәттән тыш канәгатьлек чырае белән Ахиярга карады.

Ул арада кузгала да башладылар. Өлкә секретаре флотта хезмәт иткән кеше икән.

— Корабльдә,— диде ул,— берәр җирдән комиссия килсә, иң элек гальюнны (бәдрәф) карый. Шунда тәртип булса — корабльнең барлык урынында да тәртип була һәм инспектор тикшереп тормый. Без болай итик: син шәһәргә килгәндә туры үземә кер. Ярдәмчегә әйт: чиратсыз керергә кушты, диген. Аннан соң, бу драндулетыңны черметка илтеп аудар,— секретарь кәкре каен төбенә караш ташлады,— берәр нәрсә табарбыз. Дүрт тәгәрмәчле... Дөресен әйтим, син миңа ошадың, Гарәфиев. Молодец! Онытма, мин бу сүзне елга бер-ике генә әйтәм...

Машиналар китте, Ахияр һаман шул урында басып торды. Бозаулар инде аранга кереп тулган иде.

Бу — беренче визит — Ахиярның бөтен гомерен, председательлек юлын хәл итте. Дөрес, Ахияр эрсезләнмәде. Бер генә тапкыр да өлкә комитеты секретареның бүлмәсенә чиратсыз кермәде. Әмма белеп яшәде: «Яңа юл» колхозы гел игътибар үзәгендә булды. Моны сизде, тойды.

Язмыш Ахиярны өлкә секретаре белән әле тагын ике тапкыр очраштырды. Болары — еллар узгач, байтак тәҗрибә туплагач. Ике очрашу арасында байтак ара белән.

Әмма һәр икесе — тарихи очрашу булды. Бу очрашулар — Ахиярның гына түгел, «Яңа юл» колхозының, хәтта Ташлытау районының да тарихыдыр. Тарихтан бер кисәктер. Болар турында, ихтимал, аерым сөйләргә кирәктер. Шулайдыр... Кирәктер...

## IX

Ахияр өлкә комитеты оештырган активта гаҗәпкә калып утырды. Трибунага чыккан секретарь авыл хуҗалыгына кагылышлы иң үзәк мәсьәләләрне уртага алды да, берни дә яшермичә сөйләп китте.

Партиянең көче кайда? Бердәмлектә, дибез. Алдан күрүчәнлектә, дибез. һәм башкалар. Ахияр бүген үзе өчен тагын бер ачыш ясады: партиянең көче — кимчелекләрне ачыктан-ачык әйтеп бирә белүдә дә. Моның шулай икәнен заманында XX съезд раслаган иде. Әмма, бүген... Өлкә секретаре, әйтерсең лә «Яңа юл» колхозын өйрәнгән дә, шуны мисал итеп, шул турыда гына сөйли.

— Без соңгы елларда колхозчылар өчен типовой йортлар салу белән мавыктык,— дип сөйләп китте гомуми бурычлардан соң секретарь.— Бу өлкәдә без хата эшләдек. Әйе, мин борғаланмыйча әйтәм — хата. Без колхозчы өчен дүртәр, сигезәр квартиралы икешәр катлы йортлар төзедек, шуның белән мактандык. Нәрсә килеп чыкты соң? Колхозчы шәп квартирага кереп урнашты, суы, газы, ваннасы бар, колхозчы сыерын, сарыгын, дуңгызын сатып, мебель, палас алды, төсле телевизор, «Жигули» алды. Әнә шул «Жигули»ена утырып колхозчы район үзәгеннән, шәһәрдән үзенә продукты ташый башлады. Кәбестә — шәһәрдән, бәрәңге — шәһәрдән. Инде эш шуңа барып җитте ки, колхозчы район яки шәһәр кибетеннән машина багажнигына салып сөт, кефир, катык ташый башлады. Димәк, колхозчы авыл хуҗалыгы продуктларын тудыручыдан аны үзләштерүчегә әйләнде. Мондый йортлар төзү киләчәктә туктатыла. Колхозчы шәһәрдән продуктны ташымаска тиеш кенә түгел, ул әле шәһәр базарына продуктны үзе чыгарырга тиеш. Хәзергә без шәһәр халкын гастроном белән генә тәэмин итә алмыйбыз, бу — факт, хәзергә шәһәр халкына Камәр апай белән тетя Мотяның да базарда булуы кирәк. Алар алып килгән продуктсыз әлегә шәһәр яши алмый.

Тагын бер мәсьәләгә тукталмый мөмкин түгел. Соңгы елларда без колхозларда зур-зур терлекчелек комплекслары төзедек. Юеш иденле, авышкан стеналы иске фермалардан котылдык. Төзүен төзедек, әмма

бу комплексларда дуңгыз үрчетү кыенлашты. Күз алдына китерегез: коры бетон идәннәр, автомат линиядән азык килә, конвейер тиресне алып чыгып китә, шунда ук суы килгән — ә дуңгыз баласы үлә. Без галимнәр белән ачуланышып беттек: сәбәбен табыгыз, дибез. Галимнәр әллә нинди лабораторияләр ачтылар, әллә ниткән штатлар алып бетерделәр, өйрәнепме-өйрәнәләр, ә дуңгыз балалары кырыла бирә. Бу сорауга кем җавап бирде, дисезме? (секретарь трибунадагы кәгазьләрен актарды. Ахияр комач кебек кызарды: бу сорауга җавап эзләп секретарь Поник бригадасына килеп чыккан иде, шунда ул ферма каравылчысы Аксентий агай белән сөйләшкән иде).— Бу сорауга җавапны Ташлытау районы «Яңа юл» колхозы ферма каравылчысы Аксентий Савельев бирде. Дуңгыз баласы, диде ул, терлек-туар арасында иң нәзберәге. Башка бер хайван да алай иркә түгел. Әнә шул иң нәзберәк бала тугач та тимер-бетонга баса. Бу — дөрес түгел. Табигатьнеке табигатьчә булырга тиеш. Ул я җиргә, яки тактага басарга тиеш. Цементка баскан дуңгыз баласы яши алмый, диде. Һәм нәрсә дип уйлыйсыз? Хәзер без дуңгызчылык комплексларына тактадан идән җәйдертәбез. Ә «Яңа юл» җитәкчеләре — хәйләкәр эгоистлар. Шуны белгәннәр, проектны бозып ук салганнар комплексны, идәннәре — такта. Дуңгыз балалары үлми. Үзем барып чыкмасам, һаман шулай сер итеп сакласылар (зал җиңел генә гөжләп алды).

Секретарь сәгатьтән артык сөйләде. Сүзнең ахырында ул колхоз авылының культурасы турында һич тә көтелмәгәнчә сөйләп китте. Соңгы елларда колхозлар культура учаклары төзүгә зур игътибар күрсәткәннәр: сарайлар салу, оркестр, рояльләр алу, биллиардлар дисеңме... Секретарь мисал китерде: бер колхоз культура сараеның алгы бүлмәсенә кечерәк ындыр табагы кадәр биллиард кайтарткан (12 мең сумлык), шарлары кечерәк карбыз кадәр ди, ә уйнаучылардан берәү икенче көнне үк кий белән төртеп тегенең сукносын ерткан. Хәзер биллиард өстәле иске газета, иске журналлар саклау өчен хезмәт итә икән. Республика буенча нәрсә ачыкланган соң? Сарайлар салынган, пианинолар алынган, ә ул сарайларда эшләргә кадрлар әзерләнмәгән. Культура буенча әзерләнгән кадрлар күбрәк шәһәр тирәсендә калу ягын карыйлар. Димәк, нишләргә? Культура-агарту уку йортларына колхоз стипендиясе белән кеше җибәрергә. Бу — бердәнбер юл.

Секретарь кызып китте, трибунадан читкә чыкты.

— Без,— диде,— моңарчы тарихта булмаганча, зур бер экономик сикереш ясадык. Андый һәлакәтле сугыштан соң бер генә илнең дә 25—30 ел эчендә экономикасын торгыза алганы юк. Ә без торгызып кына калмадык, сугышка кадәрге дәрәҗәне әллә кайчан инде узып киттек. Без инде икенче якка сикердек: безгә бир син киенергә польский костюм, югославский плащ. Безгә бир син хәзер японский транзистор, финский пальто. Без хәзер шулай. Менә мин бик күп илләрдә булдым, бер генә капиталист та безнең кебек кыйммәт киенми. Капиталистның өстендә гап-гади күлмәк, гап-гади пиджак. Ә без сикердек. Бу байлыкка без мораль яктан әзер түгел икәнбез.

Секретарь елмайды һәм сәгатенә карап алды.

— Менә мин авылда үскән кеше, сугыш вакытының һәм сугыштан соңгы елларның бөтен авырлыгын кичкән кеше,— дип сөйләп китте ул, нәрсәнедер, бик кызыклы бер хәлне хәтеренә төшергәндәй, тукталып.— Хәтерлим: безнең авылда сугышка кадәр мир көтүен көткән абзый бар иде. Үзегез беләсез, ул елларда мир көтүен көткән кешенең бер дә дәрәҗәсе булмый иде һәм көтүче булып иң фәкыйрь, абруйсыз бер әтрәк-әләм яллана иде. Кеше өстеннән ашау, кеше өстеннән чабата, чиләк белән он, бәрәңге җыеп йөрү — үзегез беләсез. Менә шул надан, фәкыйрь Сәхаб абзый кырык беренче елда сугышка китә һәм интендант частенда обозчы булып Германиягә хәтле барып җитә. Хәтерлим

кырык бишенче елның җәен. Безнең авыл,— базарлы авыл, ул вакытта базар бик калын була иде. Эссе көн, кырык градус бардыр, базар өстендә утлы кайнар һава. Сәхаб абзый кайткан, шәп киенеп кайткан, диләр. Малай-шалай аны эзләп йөгерешәбез. Әле дә күз алдымда: базар уртасында Сәхаб абзый тора. Тройка костюм өстеннән хром пальто кигән, башында өр-яңа зәңгәр велюр эшләпә, авызында гавана сигарасы. Пальтосын чишеп җибәргән дә ике кулын чалбар кесәсенә тыккан, вакыт-вакыт белэгендәге сәгатенә карап ала, үзеннән пар чыга. Хром исе, сигара исе. Бөтен кешенең күзе анда. Һәм нәрсә булып бетте дисез? Күрше станция кешеләре бу юләрне эчертәләр, исертәләр. Таң алдыннан теге мескен үрмәләп өенә кайта — бөтен булганы — солдат кальсоны. Майкасы да калмаган. Менә мин шул кешене гел хәтерлим, иптәшләр...

Киная көчле иде һәм зал моны аңлады.

Авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре өчен шәп концерт бирелде, буфетлар гөрләп эшли иде. Киенеп ятканда Ахияр бер читтә басып торган Байгильдеев һәм күрше колхоз председателе Митрий янына килде.

— Сезнең планнар ничек, иптәшләр,— диде ул,—гостиницада кунасыздыр бит?

— Барыбыз да шунда инде. Әйдә, шунда кайтып тәлинкә тотырып аш ашыйк әле...

...Күп катлы гостиницаның беренче катындагы ресторан гөж килә иде. Агай-эне эшне тиз тоткан, Опера театрыннан трамвайга төялеп төшкән. Байгильдеев, Митрий, Ахияр кергәндә буш өстәлләр инде юк, республиканың хуҗалык токтасы булган райком секретарьлары, башкарма комитет председательләре, колхоз председательләре бүгенге активта күтәрелгән мәсьәләләрне гөжләтеп тикшерәләр, бәхәсләшәләр, официантлар ыгы-зыгы килеп аквариумдагы балык кебек өстәлгә дә, кешегә дә кагылмыйча шул тыгызлыкта шуып кына чабышалар иде. Ахияр белән Митрий бөтен залны йөренеп килделәр. «Стол для гостей» дип язылган бөтен өстәлләр дә кешеле иде. Ишек янында уңайсызланып кына Байгильдеев басып тора, районда аның даны бар иде: Байгильдеев гомере буе ресторанны яратмады. Сәбәбен дә беләләр иде: расчет ясаганда официант белән ваклашасы түгел, сдачаны алып маташасы түгел, имеш. Байгильдеев үзе ятимлек белән, нужа чигеп үсте, шуңа күрә хезмәт кермәгән көе кесәгә килеп керүче бер генә тиенне дә гафу итми иде. Аннан соң (монысын Ахиярга әйткәне бар), дөньяның бер гүзәле булган яшь бер кызга «мә, мин сиңа илле тиен калдырам» дип әйтү Байгильдеевнең намусын, хатын-кыз матурлыгына карата соклану, бәяләү хисен дә рәнҗетә иде. Байгильдеев шуңа күрә тимер-пыяла авыр ишек янында боегып кына басып тора (әйтерсең, ул бөтен бер районның иң зур житәкчесе түгел! Шәһәргә килсә, малай була да кала!), Ахияр исә, шәһәр кияве буларак, әрсезләнеп инде бер өстәл дә тапкан. Ул өстәлгә ,бастырып куелган «Стол для гостей» дигән табличканы арт ягына борганнар да, ике яшь кыз, ике чибәр егет кереп утырганнар. Ахияр (тәҗрибәле кеше!) чамалап алды: егетләр — шәһәрнеке, кызлар — авылдан килеп техникумгамы, берәр институткамы кергән студенткалар. Чәч — бөтен җилкәгә таралган, тырнаклар — озын, кызыл, керфекләр — авыр, майлы, саллы, авызда — сигарет. Төтенен дә йотмыйлар, ә болай гына суыралар. Вәт чукынчыклар...' Озак басып торырга шулай ук килешеп бетми инде, Ахияр әлеге өстәл янына килде:

— Сеңелләр, бу бит безнең өчен, сез бәлки инде бу өстәлне бушатырсыз,— диде. Аңа Митрий кушылды:

— Әйе, бу өстәлләр бүген вапше безнеке,— диде.

Сеңелкәшләр башта эндәшеп маташмадылар. Ахияр кабат дәште.

— Сеңелкәшләр, бәлки бу өстәлгә колхоз председательләрен утыртырсыз,— диде. Ахияр өстәлдәге блюдоларга күз ташлады: сарык итеннән рагу! «Яңа юл» колхозы әле өченче көн генә ике машина сарык озаткан иде ит комбинатына. Өчме-дүртме шешә сыра. Узган сезонда «Яңа юл» колхозы дәүләткә ике мең центнер арпа тапшырды. Ул арпаның һәр бөртегендә Ахиярның нервасы, күзәнәге. Тагын бер шешә «Пшеничная...» Әгәр ул эчемлек, чыннан да, бодайдан ясала торган булса... «Яңа юл» колхозы сигез йөз гектар чәчә аны! Ул бодайның җыеп алынганы гына түгел, чәчелгән бөртеге дә Ахиярның канында, йокы минутларында...

Әмма Ахиярны мондый тирән экономик уйларыннан тиз айныттылар. Теге кызлар, дуңгызлар, татар кызлары икән. Озын сигарет тотканы (чибәр, каһәр) чыркылдаган купшы тавыш белән Ахиярга карап ымсындырырлык елмайды һәм әйтте:

— И, абый, колхоз председателе булсаң, бар инде, колхозыңа кайт та, сыерларыңның... кашы,— диде.— Бәлки, сөтләрен арттырырлар.

Калган өчесе боларга күтәрелеп тә карамады. Номерга менеп, «кипятильник» дигән ике җеплекәле могҗиза белән су кайнаттылар да тәрәзә арасына, суыткыч шүрлегенә куелган итләр, сырлар, сыралар белән иркенләп мәҗлес башладылар.

Иң бәхетле кеше, әлбәттә, Байгильдеев иде, Ахияр моны сизде, әмма теге, авыр керфекле авыл кызының оятсыз сүзе аның йөрәген әле дә кискәләп, борчып тора иде. Шәһәр кызы болай әйтә алмас иде. Авылныкы, авылныкы бит, юньсез...

Митрий ул арада телефоннан эзләп энесе Константинны тапты. Гостиницага якын гына яшәгән энесе ярты сәгать дигәндә дипломат тотып килеп тә җитте. Шәһәрчә модалы киенгән — джинсы чалбар, калын табанлы ботинкалар, кара футболка өстеннән хром пиджак кигән, чәчләр арысландай, бармакта калын алтын балдак, кулда коточкыч модалы— бөтенләй цифрасыз сәгать иде. Дипломат эченнән ул бер шешә суырып чыгарды, лимон турады. Өстәл рәтен белә малай, бөтен кеше дә мин түгел шул, дип уйлап куйды Митрий.

Костя шәһәр, сәнгать, гастрольләр турында, узган җәйдә ничек итеп Мальтада, Италиядә концерт бирүләре турында сөйләде. Утыра торгач кыздылар. Митрий гел өстәлне җыешыргалап, ризыкны рәтләбрәк торды.

Байгильдеев егеткә байтак карап торгач үзенең яратып куллана торган әйтеме белән дәште:

— Я, әтәч булып кычкырдың, таңын да аттыр инде,— диде. Ахияр да, Митрий дә моны аңламадылар, әмма Костя тиз тотып алды.

— Монда инструмент юк бит,— диде.

— Инструмент — үз тамагың,— диде Байгильдеев.

Костя тамагын кырды. Итальянча ария җырламакчы булды. Әмма Митрий каршы төште.

— Син, Күстәнтин, андый җыр җырлама безгә,— диде.— Я әле, үзебезнең «Әкрен кирәк»не сиптер әле.— Ул бәхетле елмаю белән энесенә карады. Митрийнең авызы, колагы, күзләре тулы горурлык иде. Күстәнтин ялындырмады, урыныннан торып басты, тамагын кырды. Һәм менә гостиницаның бер бүлмәсенә көмеш моң тулды:

Суда балык йөзәдер лә,
Су салкынын сизәдер шул, сизәдер...

Шул урында Костяның тавышы көчәергә тиеш иде һәм өстәл янындагылар барысы да аңа кушылырга да маташканнар иде, әмма Костя ике кулы белән дә дирижерлык итеп тавышны кысарга дигән ишарә ясады һәм бик акрын гына тавыш белән моң агызды.

Әкрен кирәк, иплəп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын...

Байгильдеев — детдом баласы — тиз нечкәрде. Костя үзәккә үткәреп җырлый иде. Байгильдеев аның күзләренә игътибар итте: ачык зәңгәр күзләрдә «Әкрен кирәк, иплəп кирәк» дигән урынны әйткәндә эчке бер сагыш чагылып китә иде. Дөресрәге, тарих. Байгильдеев партшколага кадәр университетның тарих бүлеген тәмамлаган иде. Костяның сагышлы зәңгәр күзләрендә шуңа күрә ул тарихны күрде...

Әкрен кирәк, иплəп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Әйе, тарихыңның төбендә патшалар, урядниклар, поплар булганда әкрен кирәк. Һәрвакыт шулай иплəп кирәк булган.

— Син нигә безнең районга, туган ягыңа кайтып бер концерт бирмисең соң? — диде Байгильдеев.— Мондый тавыш белән... Әллә мин белми каламмы? — Ул сорау катыш караш белән Митрийгә, Ахиярга борылды. Митрий куңелсезләнеп китте. Авыр сулады.

— Юк, юк, Кустәнтиннең институт бетергәннән бирле вапше авылга аяк басканы юк,— диде ул. Аннан энесенә кызганычлы караш ташлап әйтте:

— Катын шундый туры килде аның. Көнче. Үзе дә кайтмый, Кустәнтинне дә җибәрми. Вапше шулай...

Бу тарих Митрийгә бик яхшы, Ахиярга якынча таныш иде — дүрт ир тынып калдылар.

Бөтен хикмәт шунда — Костяның яшьли сөйгән кызы Зоя — авылда калды. Костя белән аларның унынчы классны тәмамлаганда кайнар мәхәббәте булып алган иде. Алар бергә укырга да килделәр. Зоя балл буенча университетка узмады, Костя — талант буенча культура институтына үтте. Аерым тормыш шуннан башланды. Очрашулар сирәгәйде. Зоя мәктәпкә лаборантка булып урнашты, аннан читтән торып укырга пединститутка керде. Костяның исә тормыш бөтенләй шома юлдан китте: тулай торак буфетында эшләүче апа сары тузгак чәчле, зәңгәр гәрәбә күзле, буйлы авыл егетен ошатты куйды. Костя кайчан кайтса да, буфетның әллә кай төшләрендә аның өчен калдырган өчпочмак, каймак, тавык боты табыла иде. Ә бер ял көнне буфетчы апай Костяны өенә чакырды. Кызым белән таныштырам, дип ачыктан-ачык әйтте. Пластинкалар тыңларсыз, бездә магнитофонга язылган Высоцкий бар, диде. Высоцкий дигәч, Костя чыдамады — китте. Паласлар белән түрелгән ялгыз бүлмәдә буфетчы апайның кызы Даимә (Дина) белән алар музыка тыңладылар. Буфетчы апай журнал өстәленә кайнар өчпочмак кертте, салкынга тирләгән «Шифалы су» шешәләре, бер-ике шешә әллә ниткән чит ил эчемлекләре куйды. Үзе зал якка чыгып («Язның унҗиде мизгеле» бара иде) телевизор каршына сеңде. Даимә бердәнбер кыз; әтиләре ташлап киткән (эчкән), өч бүлмәле квартира кооперативныкы, әнисенең элемтәләреннән башка да кызый медицинскийга урнашып шунда фармакологиядә укып йөри икән. Йөргән егете? Берәү булган, әмма салу ягын бик яраткан. Болар семьясында ул мәсьәлә төп күрсәткеч: кеше үз урынында сала белсен, нормасын белсен һәм ахырдан аның салганын беркем дә сизәрлек булмасын. Костя бу таләпләргә тулысынча җавап бирә иде, менә ничә ел инде студент булып йөри, ә тулай торакта һәркөнне берәүнең туган көне, Костя — җырчы, күп мәҗлеснең түрендә була, әмма әлегә кадәр бер генә эчемлекне дә ике рюмка эчкәне юк: ник әллә нинди патшалар эчә торган шәраб булмый шунда — бер рюмка. Шуның белән бетте. Костя шулай сөйләде. Ләкин белмәде: бу хикәя аның язмышын хәл иткән иде инде.

Бу семьяда эчмәүче кешенең бәясе валютага тора иде. Дөрес, шул ук көнне Костя зур бер стратегик хата да җибәрде: Зоя белән ике арадагы кайнар мәхәббәтне, тормыш шартлары үзгәрү аркасында ул мәхәббәттә кечкенә генә бер ярык барлыкка килгәнне һәм башкалар...

Костя шулай паласлы бүлмәгә һәр ял саен килеп йөри башлады, юаш беркатлы авыл малаена каршы исә паласлы бүлмә «Операция Зоя» дигән яшерен план төзеде. Бу планда беренче пункт итеп теге кечкенә генә ярыкка шартлаткыч салырга, икенче пункт итеп егетне авылына кайтарып йөрүдән туктатырга, биздерергә дигән бурычлар куелган иде.

Болар барысы да шундый оста эшләнде ки, шул елның май аенда Костя белән Даимә инде «Бүләкләр» кибетенә кереп җитмеш тәңкәлек туй күлмәге алдылар.

Костя — шуннан бирле капкында. Әлбәттә, ул үз авылын, җәй башындагы яфрак бәйрәмнәрен, шул көнге болынны, елгадагы каен агачы агыздыру йолаларын, беркатлы абыйсы Петрны сагына (Митрий аңа кергәләп йөри) — балачагын сагына. Әмма характер буенча Даимә көчлерәк булып чыкты. Костя юкә агачы, Даимә — имән иде. Юкә агачы ике-өч ел яшәүгә имәнгә таба сыгылды да төште.

Митрийгә конкрет аерым очраклар да таныш. Күстәнтин гастрольдән — Мальтаданмы шунда, Африкаданмы кайткан көннәр иде, Митрий, гадәт буенча, шәһәргә килгәч бер буй казылык күтәреп аларга керде. Ерак гастрольдән кайту уңае белән мәҗлес икән, унлап-уникеләп кунак килгән, күпмеседер артист халкы, юлдашлар, тагын Даимәнең дус-ишеннән ике-өч кешеме, ике-өч пармы бар иде. Артистлар утырган мәҗлестә кайчан тәртип булганы бар? Ул бит авылда гына, авыл интеллигенциясе катнашкан мәҗлестә генә шулай: менә монысы ир, монысы — хатын; ире колхоз председателе, димәк, түрдә, хатыны белән бергә. Ә болар? Стоп! Мәктәп директоры, шулай ук хатыны белән, хатыны — мәктәптә королева... Боларны менә бу якка... Алай. Тагын кем? Колхозның завхозы. Кайвакытта аннан тавык аласы була. Тавыкның төрлесе бар: йолыккач кәрәз кебек була кайберсе, ә кайберләрен йолыкканда бармак башларың зәңгәрләнә: гел бала йон, каурый. Димәк, завхозны юантык хатыны белән менә бу төшкә. Аннан...

Инде! Артистлар мәҗлесен күрсәң! Эт — баш, сыер — аяк! Ата — улны, ана кызны белми. Болар ахырдан ничек кайтып бергә яши? Митрий шуларны аңламый утырды. Менә ирек! Болардагы эчкерсезлек, саф күңеллелек! Кеше хатыны белән янәшә кеше ире утыра. Җитмәсә, әле уен-көлке сөйләшеп, бер-берсенә әллә ниткән хикмәтле сүзләр әйтеп утыралар, барысы да рәхәтләнеп көлә. Митрийнең гаҗәпләнгәне шул булды: теге хатынның ире бу ирнең бу хатынга кул салуына ачуланмый гына түгел, рәхәтләнеп авыз ерып утыра. Митрий бу ситуациядә үзен ялгыз хис итте. Аның Марфасынамы? Берәү җилкәсенә кул салсамы? Да, вы шту? Бу мәсьәләдә, бу мәҗлестә Митрий — берүзе. Һәм ул үзендә бөтен мәҗлескә бу мәсьәләдә каршы торырлык көч сизде. Әмма ялгышты: бу мәсьәләдә Митрийдән дә куәтлерәк бер шәхес бар иде дөньяда, Митрий әле аны алай ук дип белми иде, ул — бәхеткә каршы, Даимә икән. Даимә озак җыелды, озак чыдады. Мондый мәҗлесләрдә утыргалый иде. Әмма монда! Кыздылар да, илленче еллар репертуарына тотындылар. Кемдер җыр башлады, кайсыдыр баянда тартты, бөтен кеше шул искергән, Даимә бәяләве буенча «противный» бер җырга тотынды. Җитмәсә, барысы да Костяга — мәҗлес хуҗасына карап җырладылар. Мәҗлестә солистка Зоя утыра иде, аның гүзәллегенә, тавышына күпләр гашыйк иде, һәм, гаҗәпкә каршы, Зоя — ирле, ике бала үстерүче «нормаль» бер артистка иде, әмма — гүзәл! Теге,

илленче еллар җырын башлаган мокыт, берни дә уйламастан, бер ялгышлык җибәрде. Ул иптәшләре белән бергәләп болай җырлады:

И дускаем, килденмени,
Күрмәдем килгәненне;
Зөһрә йолдызга охшатам
Елмаеп көлгәненне...

Иптәшләр күтәреп алды:

Ачма тәрәзәңне мин килмичә...

Шул вакыт Зояга карап кайсыдыр ачы тавыш белән ярды:

Костяны кертерсең, белмичә...

Шунда бөтенесе шау итеп көлде, Зояның ире чит илдә озак командировкада иде, кичә генә Костя ничектер гадәттәгедән соңга калып кайткан иде, һәм, гомумән, бу йортта «Зоя» исеме химик бомба белән бер — теге, авылдагысы да шул исемле бит әле аның...

Мәҗлес күңелсез генә тәмамланды, тәҗрибәле артист халкы хуҗа хатынның чырае үзгәргәнне тиз сизеп алды. Соң иде инде, Митрийне гостиницага җибәрмичә, кунарга калдырдылар. Митрий кечкенә бүлмәдә төн буе ишетеп ятты: Даимә ваклап-тәякләп ирен эшкәртә, метекләнә, елый, бәйләнә иде.

— Юк, син әйт: нигә синең белән аны телгә алып җырлыйлар алар?

— Туктале, ни бит...

— Юк, син дөресен әйт: кичә нишләп уникедә кайттың син? Мин бит телевизордан карап утырдым: сезнең концерт ун тулып ун минутта бетте.

— Ни бит...

— Юк, син дөресен әйт... Ул теге солистыгыз нигә сезнең исемне кушып җырлый? Тинтәк! Үз хатынын белсен.

Төне буе шулай. Ну, капкан икән энекәш вапше, дип уйлады шул чакны Митрий һәм юрган белән башын томалап стенага таба борылып ятты.

...Төн уртасында сәгатенә карап алып, Костя тагын бер җырлады. Монысында Байгильдеев тәмәке кабызды, Митрий исә ванна бүлмәсенә өстәлдәге тәлинкәләрне ташыган булды, юган булды, әмма Ахияр сизде: Митрий елый иде. Хәер, Костяның да тавышы елады.

— Әйдә, әйдә!

— Кая, кая?

— Әйдә барыйк урманга...

...Ахияр төн буе йоклый алмады. Нигәдер аның төшенә гел Фира керде, Фира озын ак күлмәктән, ак яулыктан, кулларына ак чәчәк бәйләмә тоткан да, каен агачы артыннан торып урман аланында җырлый. «Әйдә, әйдә!» дип Ахиярны чакыра иде...

## X

Иген ишелеп уңасы иде, печән өсте башлануга явымнар китте. Керәшен авылларын берләштергән Емельянов исемендәге колхоз председателе, какча гәүдәле кызыл сипкелле Митрий Евдокимов узышлый гына Ахиярга сугылды. Авыр сулады.

— Быел планнар бик зур иде, мине харап итте бу,— диде,— Бөтенесе черәчәк, Нәчтүк әбинең сынамышы буенча бу яңгыр нәкъ ай ярымга,— диде. Ахияр моңа шатланмады. Гаҗәпләнмәде дә: күршедәге ке-

рәшеннәр утызынчы елдан бирле урта мәктәп, клуб тотсалар да, Нәчтүк әби, Әүдәки бабай кебекләрнең сынамышына ышанып рәхәтләнеп яши бирәләр иде. Гаҗәбе шунда: боларның сынамышына председатель һәрвакыт колак сала, исәпкә ала иде. Партшкола тәмамлаган, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган Митрий шуларны санга суга иде. Митрийне белмәссең: аларның нәселе әллә нинди: биш малай үскәннәр алар, бишесендә биш язмыш, биш характер. Митрийнең бер абыйсы Мәскәүдә, отставкадагы генерал. Ике-өч елга бер ялга кайта, шәһәргә кайтып төшә дә, такси-фәлән алмый, ат яллап, арба астына чалгы тыктырып, яңа чабылган печәнгә ятып кайта. Ике көн буе! Кайткач бөтен авылның карты-карчыгына үз кулы белән күчтәнәч өләшеп йөри, ул көнне орден-медаль тулы мундирын кия. Шул бер генә көн. Аннан ай буе болында балык тота, бер грамм эчми, печәнлектә йоклый, яланаяк йөри. Сугыш күргән яшьтәшләре белән гәп кора, Мәскәүдәге адресы басылган визит карточкасын өләшә, кунакка чакыра. Ай—ай ярым үткәч Митрий аны колхоз атына утыртып, шулай ук чалгы кыстырып, печән өстенә палас җәйдереп шәһәргә озата. Бу булдымы бер абый. Икенчесе — Новосибирск шәһәрендә Академгородокта, математика фәннәре докторы, дәүләт премиясе лауреаты. Анысы кайтмый, әмма һәр елны эти белән әнинең каберен карагыз, дип Митрийгә җәй башында биш йөз сум акча сала. Ял итәргә я Италиягә, я Кырымга йөриләр. Акча килгән көнне, генерал кайткан көнне өлкәннәр бер шаккатып сөйләшеп алалар.

— Менәтерәк укытучы Афанасий балалары берсе дә югалып калмады. Этиләре бик талкауай иде шул. Бакча үстерде, умарта тотты, кеше малына кызыкмады шул.

Митрәй дүртенчесе иде — гел укыды, гел гыйлем юлында булды. Партшкола тәмамлаган елны райком секретаре аны үз авылына китереп колхоз җыелышына куйды: яңа председатель кирәк иде. Керәшеннәр шаулаштылар:

— Бик тощай күренә бит, калхузны аббара алырмы?— диделәр.

— Абыйсы мешәйть итәр аңа, бер дә тәртибе юк бит Питрның,— диештеләр.

Петр — семьяда өченче малай. Тимерчелектә эшли. Алтын куллы. Бервакыт дөм караңгыда бәхәсләшеп бер сәгатьне (куен сәгате) сүтте һәм җыйды. Сәгать йөри иде. Петр янып эштән чыккан электр лампасын яңадан рәткә кертә ала. Әмма сәер гадәте бар: һәр көнне кичкә таба эчеп исерә. Кешегә зыяны тими, үз акчасына эчә. Тагын шунысы бар: Петр теләсә нәрсә эчә. Теләсә нинди маркалыны — тик градусы гына көчле булсын. Печән өсте, урак өсте көннәрендә авылга аракы кайтмый тора. Әмма Петр андый көннәрдә аптырап калмый, одеколон эчә. Бераздан одеколон да бетә. Андый көннәрдә Петр кибеткә килеп керә, житез караш белән шүрлекләрне тикшереп ала да, авыр сулап әйтә:

— Һай-һай, сеңлем, парфюмерия бүлегенең рәте калмаган...

Шулай да, Петр өч йөз алтмыш биш көннең икесендә каты ук эчә. Үзе ул моны «капитально» дип сөйли. Моның беренчесе — яз көне тимерче алачыгы янындагы тау битенә яшел үлән төртеп чыккач. Ул көнне Петр алачыкны яба, чиста киенә, кибеттән мул гына итеп (әгәр булса — көчлесен генә) эчемлек алып кайта һәм көне буе тау битендәге шул беренче чирәмгә ятып аунап эчә. Бу инде — язгы чәчүгә чыгарга ярый, туфрак җылынган дигән сигнал. Һәм авыл халкы моңа шулкадәр күнеккән, көннәрнең ни язга, ни җәйгә туры килмәгән чагында үзара хәл белешеп болай сөйләшүчеләр була:

— Афанасий малае аунап эчтеме икән инде? Бигрәк сузылды быелгы яз...

Менә бер көнне хәбәр тарала: бүген Афанасий мглае аунап эчкән. Ул көнне тәрәзәләрнең эчке каты алына, халык өй юарга әзерләнә, йортларда җиллек тишекләрен ачалар. Председатель дә агрономын алып кичке яктан басуны махсус бер әйләнә: Петр аунап эчкән, димәк, иртәгә чәчүне башлап җибәрергә. Ә кич кояш батканда тау битеннән Петрны җитәкләп алып кайталар. Петр шунда бер җыр җырлый да, кычкырып җылый. Аның бу дөньяда иң рәнҗегәне — төпчек энекәше Константин. Константин шәһәрдә культура институтын тәмамлады да, хәзер җырчы артист булып китте. Кайтмый да, хат та язмый. Петр шуңа бик рәнҗи. Югыйсә, генерал абыйсы Иван, доктор абыйсы Степан гел элемтәдә торалар. Ә теге төпчек, иркә малай — юк. Тау битеннән төшкәндә Петр үксеп-үксеп җырлый, җылый...

Ибан белән Ычтапанның
Килеп тора хатлары;
Күстәнтиннең юк кабәре,
Катканмаллә кагәре?

Икенче көнне, берни дә булмагандай, алачыкта чүкеч тавышы чыңлый. Ул көнне Петр аеруча дәрт белән эшли, чөнки инде авыл җәйге режимга күчкән...

Өч йөз алтмыш биш көннең икенчесе — сабантуй көнне. Ул көнне Петр иртән иртүк матур киенеп энесе өенә — Митрийгә китә. Митрий — ни гаҗәп — үз гомерендә аракы, тәмәкенең ни икәнен белми. Кешеләр ышанмыйлар: үз гомерендә авызына да алмаганмы? Юктыр, булмастыр... Әмма, шулай. Петр килә, Митрийнең идән тулы, өстәл асты тулы бала, ишек катында яшел эмаль тышлы саплы «чүлмәк» кенә дә икеөч. Петр килә, керә, хәл-әхвәл сораша, шунда Марфа килен кухня ягында гына аңа бирәр стакан эчемлек бирә (Митрий үзе эчмәсә дә, килгән кунак өчен алып торалар). Петр ат казылыгын чәйни-чәйни рәхмәт әйтеп чыгып китә. Бу — һәр елны эшләнә торган мәҗбүри бер эш сыман визит. Марфа исә Петрны бик ихтирам итә, аның килгәнен көтеп үк тора. Әле менә быел килгәнендә кухня якта өстәлгә ике шешә чыгарды да, Петрдан сорады.

— Кайсын эчәсең, Питр?— диде.

Петр шешәләрне әйләндереп, кәгазен укыды. Берсенә «Эрети» дип язылган, «сухое, 8—10°» дип күрсәтелгән, икенчесенә «Коньяк» диелгән һәм муен төбенә биш йолдыз тезелгән иде. Петр стакан тутырып коньяк салды да, «Эрети»не кире бирде:

— Монысы белән кич эштән кайткач председатель аягын юсын,— диде.

Сабантуйга Петр бик нык кызып килә. Килеп әйләнә тирәсенә бастымы — бетте! Петр — юк! Кая китә? Ник юк? Дөресе, Петр бар, әмма инде ул шушы минуттан башлап татарча сөйләшүне туктата. Петр... немесчәгә күчә. Халык көлә, әмма мыскыл итми. Немесчә ике-өч сүз белгән кеше аңа юри эндәшеп тә карый, Петр аларны сүз белән күмеп ташлый. Халык белә: Петр кырык икенче елда үзенең яшен арттырып документ эшләтә һәм унҗиде яшьлек көе сугышка барып керә. Бәхетсезлеккә каршы, унсигез яше тулганда әсирлеккә эләгә. Менә шуннан лагерьларда була, кыйнала, ачыга, кыскасы, фашист кулындагы әсир күпме түбәнлек, газап күрсә — унсигез яшьлек егет боларны күрә. Әмма ун ай тулганда алар бер иптәше белән качалар һәм үзебезнең якка чыгалар. Фронт сызыгын узганда, хәтта немецларның бер пулеметын элэктереп чыгалар (моның өчен Кызыл Йолдыз орденын Петр сугыш бетеп нәкъ утыз ел узгач алды). Әнә шулай, сабантуй көнне Петр немецчә сөйләшә. Ник алай? Моны берәү дә белми. Тик бер елны, Петрны кызык итик әле дип, шәһәрдән берәүләргә кунак булып кайткан, нин-

дидер институтның чит тел кафедрасында аспирантурада укучы бер шома егетне аның янына китереп караганнар иде — шома егетне ай күрде, кояш алды.

— Син исерекме?— диде егет Петрга мыскыллы караш ташлап. Петр җанланып китте.

— Әйе, мин исерек,— диде ул, немецчә сөйләшергә иптәш табылуына шатланып.— Мин ике йөз грамм коньяк эчтем. Син кем буласың? Исемең ничек?

Әмма аспирант, эшнең тирәнгә киткәнлеген белеп шылган иде инде...

...Шулай, Митрий Ахияр янына килеп керде һәм авыр сулап әйтте:

— Кеше төсле бер киерелеп алмакчы иде минем колхоз быел,— диде.— Бу — бетерде инде, бөтен җәйгә бу,— диде.— Хәтерлисеңме? Илленче елны нәкъ шулай булды. Мин партшколада идем. Каникулда идем. Печән өсте башлануга тотынды. Сентябрь башына кадәр.

...Ахияр төшке аштан соң үзенә урын тапмыйча нервланып верандада гәзит-журнал караштырып ята иде, Митрийне нишләтәсен белмәде. Бераз шаяра торган кеше булса шалт итеп бер ярты чыгарып куяр иде дә, йөрәк ярасын шуның белән юар иде. Юк бит, кунагы андый түгел. Ә яңгыр коя да коя. Чапкан печән болында каралып ята, люцерна инде егылып җиргә сыланды. Ахияр суыткычтан тирләгән кара шешәле сыра алып куйды, ике стакан куйган булды.

— Йөрәк яна, парин, ничек кышларбыз?— диде.— Нигә, нигә азынды бу табигать? Нигә ел саен авыл хуҗалыгыннан үч ала ул? Әгәр болай яуса тагын бер атна — кара җәяүгә калачакбыз бит. Я, әйт, мин нишлим? Мин хәзер идарәгә барып нишлим? Болынга чыгып мин нишлим? Нәрсә дип планерка уздырыйм мин бүген? Колхозчы каршына нәрсә дип чыгыйм, ничек күреним мин?

Митрий йөгереп кенә чыгып машина эченнән бер төргәк алып керде. Ахияр аның гадәтен белә иде: үзе грамм эчмәсә дә, дус-иш өчен машина артында калын кәгазьгә төргән ат казылыгы йөртә. Митрий ел саен мари ягыннан ат сатып ала, симертә, еллык ит запасы булдыра, чорма киштәсе тутырып казылык ясап элә, балалары да ана сөтеннән аерылуга казылык ашый башлыйлар, көндез ашарга пешерү аларда бөтенләй юк, Марфа медпунктта эшли, көндез кайтып йөри алмый.

Ахияр башкасын да белә: Митрий үз авылларындагы иң гүзәл — калын ике толымлы, озынча биек матур аяклы, ай кашлы, сөлектәй сылу беләкле, бәрхет тавышлы Марфаны әләктергән, председатель булып ике ел эшләүгә Марфага шәп путевка алып аны Кара диңгезгә җибәргән кеше. Марфа диңгездән тагы да сылуланып, тагы да назлыланып кайткан иде, Митрий бәхетле иде, әмма сылукай кайтып атна-ун көн узуга Гагра штемпеле сугылган бер хат килеп төште «Председателю колхоза» дип язылган. Конверт эчендә песи теле кадәр бер кәгазь «Хатының безгә бик ошады, киләсе елга тагын җибәр, яме?». Митрий шул көнне Марфаны ике чәч толымыннан чорнап тотып, утын лапасына алып кереп эт итеп кыйный, иртәгесен Марфаның өч айлык баласы төшә... Марфа бюллетень алып ай буе өендә ятты, кеше-карага берни сөйләмәде. Шуннан соң Митрий дә белде: хатын-кыз Кара диңгезгә йөрер өчен түгел, бала табар өчен яратылган бу дөньяга.

— Давай,— диде Митрий,— мин аракы эчмим, тәмәке тартмыйм, минем балалар сәламәт булырга тиеш, бала тап, мин туйдырам,— диде.

Марфаның күп балалы ана булуга юл тотуы авырлык белән барды. Сылу кыз иде Марфа. Сипкелле Митрийга карармын дип башына да китерми иде ул. Марфаның яшьлеге сугыштан соңгы елларга туры килде. Тормыш алай җиңел түгел иде, әмма халык инде чабатадан котылды. Алабута, кычытканнан котылды. Бераздан тамак та туйды.

Тамак шулай бит ул: ачса туяр күк түгел, туйса ачар күк түгел. Барысы да онытылды. Кичке уеннарда кызлар арасында ул елларда бер генә шәхес бар иде: Марфа. Сәхнәдә Галиябануны ул уйнады, «Ак калфак»та Хәмдияне, «Зәңгәр шәл»дә Мәйсәрәне. Ул кич чыгулар... Аңа әзерләнүләр. Моның ләззәтен, ихтимал, авыл кызы ныграк тоядыр. Шәһәр кызы ул бизәнеп таш сарайга бара, ярым караңгы залларга бара. Авыл кызы исә бизәнеп табигатькә чыга. Яз житсә, синең помада, пудра исеңә — балчыклы боз, тал каерысы, балык исе кушыла, җәй килсә — мәтрүшкә, кырлык үләне, билчән чәчәге исе кушыла, көз булса — юкә чикләвеге, имән яфрагы исе кушыла. Шундый баш әйләндергеч дөньяда яшь кыз булып кара, шул исерткеч диңгездә үзеңне саклап кара.

Һәм Марфа үзен саклый алмады... Аннан — сипкелле, таләпчән, эш турында гына сөйләшә торган Митрий.

Марфа бу язмышка күнде. Ике елга берне я малай, я кыз алып кайта торды, бераздан болар белән идән тулды, башта, балалар аз вакытта, кыен иде, биш, алты, җидегә җиткәч бер кыенлыгы калмады: өй кичләрен филармония яки консерваториянең берәр классына охшап кала иде. Митрий — ректор, Марфа — кафедра мөдире, имеш. Ә нәселдә тавыш бар, Митрийнең энесе — Константин, ни әйтсәң дә, шәһәрдә җырчы. Каннар әйбәт...

Митрий бик гаиләчел кеше: район үзәгенә барганда, рәсми оешмалар белән эшен тәмамлауга, промтоварлар кибетенә керә һәм бала-чага өчен кием сайлый. Кайсы кызына ничәнче размерлы колготки, кайсы малаена ничәнче размерлы зәңгәр ыштан, Марфага нинди кофта аласын ул яттан белә. Митрий семьяны кайгырта, тик бер шарт белән: Марфа ялгыз барырга дип көньякка путевка гына сорамасын.

...Дәшмичә генә верандада утырдылар. Күк, түбә тишелгәнсыман, койды да койды. Ахияр сыра эчте, Митрий казылык ашады. Боларга күп сөйләшеп торуның кирәге дә юк иде, районда болар иң зур стажлы ике генә председатель иде. Аракы эчмәгән аркасында Митрий беренче елында харап булды. Ул вакытта райком секретаре әллә каян — Волгоградтагы трактор заводында цех парткомында эшләгән кырыс бер кеше иде. Печәнгә төшәсе көннәрдә генә кинәт кенә телефоннан чылтыратты.

— Бүген көндезге берләр тирәсендә синең территориядән узам, мине күр,— диде.

Митрий тегенең-моның гына рәтен белә иде, үз өеннән гадәттәге казылыгын, яшел суган, пироглар төяп, яхшы эчемлекләр, пешкән тавык алып Ташлытау юлына чыкты. Шофер белән икесе юлдан читтәге зур куаклык төбенә (картлар бу куаклыкны Ташлытау белән ике арада юл уртасы дип билгеләп йөртәләр иде) дорба җәеп табын әзерләделәр. Партком секретаре да мотоциклын җан-фәрманга куып килеп җитте. Озак та үтмәде, Ташлытау ягыннан килгән секретарь машинасы күренде. Юлга чыгып каршы алдылар, тегеләй-болай иткән булып, әйдәгез, әйдәгез, менә бу куаклыкта сандугачлар оя кора безнең, дигән булып шунда алып керделәр. Керсәләр — кара битле, кара куллы шофер шыпа-шыпа табынга кечкенә стаканнар тезеп, «Шифалы су»лар куеп йөри иде, секретарь барысын да аңлады. Секретарь шешә мәсьәләсендә бик каты, кырыс кеше иде, Митрий башын юләргә салып табыннан урын тәкъдим итте. Батырланырга бер генә терәге бар иде — партком секретаре Пәви (Павел) райкомда инструктор булып эшләгән егет. Шуңа таянды. Секретарь кырыс булды.

— Мин монда кунак булырга чыкмадым, Евдокимов,— диде. Аннан бераз йомшады.— Я, ярар, нишлисең инде, бу территориянең хуҗасы син, ә мин узып баручы,— диде.— Минем «Яңа юл»га, Гарәфиевкә барыш. Я, ярар, кайда да булса ашап алырга кирәк бит инде безгә дә,—

дип секретарь сырлы бәләкәй стаканны тотып ук куйды да, казылыкка ябышты.— Ишеткәнем бар, ашаганым юк иде, күзен миңа да өйрәтерсең әле,— диде ул Митрийгә карап.— Синең белән әле аерым сөйләшәсе бар: таналар симертү буенча беренче зур комплекс төзүне синнән башларга дигән тәкъдим булды бюрода. Шул мәсьәләдә син бүген алтыларга райкомга килеп чык әле. Мин «Яңа юл»ны да шул максаттан чыгып карап алмакчы. Кич килеп чык әле...

Секретарь бик тәмләп казылык ашый иде, шунда нидер булгандай кинәт туктап калды:

— Ә?— диде ул.— Нәрсә бу?

Митрийнең бәләкәй стаканы шул көе, кагылмаган көе мөлдерәп утыра иде. Митрийнең гадәтен элеккеге цех парткомы секретаре каян белсен?

— Ә-ә,— диде секретарь, авызын кәгазь белән сөрткәләп.— Аңлашылды. Монда минем янда анонимщик утыра икән. Киттек!— Ул сикереп торды, әллә каян гына аның шоферы килеп чыкты һәм газ да бирде. Секретарь машина эченә керә-керә кычкырды:

— Терлекләрне юнәлешле симертү пункты дип аталачак! Синнән башлыйбыз! Ә анонимщиклар белән минем сөйләшү каты булачак! Без бүген кич барысын да ачыкларбыз. Син әле мине белмисең икән...

Митрий шаккатып, авыз ачып, аякларын ерып теге сандугачлы куак төбендә басып тора иде. Секретарь машинасы инде газ бирде...

Митрийнең бу секретарь белән колхоз территориясендә икенче очрашуы да катлаулы булды. Тик кенә торганда бер көнне идарә янына райком машинасы килеп туктады. Тиз танадылар: бу машинада беренче секретарь гына йөри. Митрий киндер кепкасын элеп тиз генә кабинетыннан чыгып йөгерде, кунакны каршы алды. Ярый әле комплексны төзүнең бик җанлы вакыты иде, дип уйлап алды Митрий, хәзер мөгаен генә шунда барырга туры килер. Ләкин ялгышты.

— Колхозчыларга ничә квартира салдың? Шуларны карыйк әле,— диде секретарь.

Митрийнең квартира салу түгел, бу турыда уйлап та караганы юк иде,— югалып калды. Секретарь ул көнне кырыс иде, шул хуттан «Яңа юл»га китте. «Яңа юл»да да теге «Юнәлешле симертү комплексын» салып яткан көннәр иде, Ахияр секретарь машинасын еректан ук таныды. Ярый әле эшнең кайнаган чорына туры килде, дип, тимер-бетон балкалар аша сикерә-сикерә машина янына ашыкты.

— Утыр әле машинага,— диде секретарь исәнләшү урынына.— Синең колхозда ничә авыл? Дүртме? Әйдә шуларның кибетләрен карап чыгыйк әле.

Кибет ике генә авылда бар иде. Башта Колан Кырныкына керделәр. Кибет — егерме тугызынчы елны кулакка чыгарылган берәүнең келәте иде. Урыннан-урынга күчереп сала-сала аның бүрәнәләре балта белән дә, яшел, кызыл, зәңгәр буяу белән дә нумерланып чуарланган. Кибетнең эче тулы буш шешә тутырылган ящиклар, ул ящикларның почмакларыннан өзелгән калай лента башлары төртеп тора, шүрлекләрдә хәлвә, такта чәй, одеколон, гөл чүлмәге, балта, ефәк оеклар, теш щеткалары, вакса — бөтенесе бергә. Идән сайгагының бер башы бөтенләй чергән, ул тишеккә ялт кына итеп бер мәче кереп китте, һәм идән астыннан эт ырлаган тавыш ишетелде.

— Теге кибетегез дә шушы хәлдәме?— диде секретарь сүс баулар арасыннан тузанлы, саргайган ике-өч китап тартып алып.— Китаплар сугыш беткән елны чыгарылганнар икән — тегесе дә шулаймы?

Тегесе аннан да фәкыйрьрәк иде.

Ул көнне Ахияр күршесе Митрийне очратты. Бу гадәти булмаган визит икесен дә гаҗәпләндергән иде.

Ун-унбиш көннән аңладылар. Районның партия активы җыелышы булды. Анда көн тәртибе буенча «Колхозчыларның тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту мәсьәләләре» дигән темага райком секретаре доклад белән чыкты. Ахияр белән Митрийгә эләккән кадәр берәүгә дә эләкмәде. Секретарьның эш стилендә завод, цех, эшчеләр сыйныфы йогынтысы көчле генә сизелгәнен шул көнне аңладылар.

Бераздан ул секретарьны шәһәр райкомына күчерделәр, аның урынына Байгильдеев килде. Әмма элеккеге секретарь Ахияр белән Митрийгә күп елларга җитәрлек сабак биреп китте.

...Яңгыр койды да койды.

— Бу, ахрысы, бүген вапше туктамас,— диде Митрий, урыныннан торып.— Курмысыз калсак тагын Кустанай ягын таптыйсы була инде...



## XI

Нәчтүк әбинең юраганы юш килде. Печәнне каралтып, кыздырып, җир каны ясап, ничек кирәк алай җыеп бетерделәр. Шулай, печән өсте бер елда да булмаганча сузылды: ярты җәйне алды. Ул арада арыш башаклары тулып, дымга авыраеп ласылдап салындылар. Куе арыш арасында аста җир, камыл күксебашлаган иде. Яңгыр һәр ходай бирмеш көнне килде дә яуды, килде дә яуды. Бөтен район тынып калды, киңәшмәләр, җыелышлар тукталды, телефон аппаратлары дәшмәде. Ул арада каяндыр хәбәр ишетелде: Байгильдеевкә инфаркт булган, аны шәһәр больницасына салганнар. Район шулай итеп ятим калды.

Райкомның икенче секретаре Халидә Әхмәтовна югалып калды: Байгильдеев канаты астында эшләү — ял йорты булган икән. Җитмәсә җәе нинди килде! Халидәнең мондый «авыл хуҗалыгы» җәен беренче күрүе иде.

Ул һәркөн иртән алтыда кабинетына килә дә басуга карый. Райкомның бинасы район үзәгенең иң калку урынына салынган. Икенче катның тәрәзәсеннән карасаң, еракка-еракка сузылып җәйрәп яткан иген басуларын күрәсең. Әнә ул саргаеп беткән дәрья — дулкын-дулкын булып ишелеп егылган, ә яңгыр сибәли дә сибәли. Һәркөн иртән сәгать җиделәрдә өлкә комитетыннан телефон:

— Я, ни хәлләр анда?

Халидә Әхмәтовна һәркөнне бер мәртәбә үзенең йөрәге типкәнне ишетә:

— Бездә... бездә һаман ява.

— Димәк, чыга алмыйсыз?

— Бу көе торса... әлегә юк.

Һәркөн шулай, бер үк яңгыр, бер үк кабинет, шул ук ишелгән басу (райком бинасы район үзәгенең бер читенә салынганлыктан, арыш басуы кабинет тәрәзәсеннән йөз метрларда ук башлана), шул ук телефон, шул ук сүзләр. Тик өлкә комитеты секретареның гына тавышы көннән-көн кырыслана бара.

Арыш урагы нәкъ уникe көнгә тоткарланган иде. Менә тагын бер көн өстәлә. Бүген дә ява. Кара-кургаш болытлар явыз ишелеп иген басуы өстендә шуышалар, өелеп-өелеп галәм киңлегендә йөзәләр, кушылалар, аерылышалар, әмма берөзлексез тамчы коялар. Бүген Халидә Әхмәтовна телефон күтәреп тәрәзәгә карап озак торды. Бүген, никтер, телефон чылтырамады. Сөйләшүе авыр булса да, ул бер иптәш ичмасам, үзенең ялгызлыгыңны тоймыйсың.

Озак карап торды ул иген дәрьясына. Лачкылдап ятып беткән иген басуы аннан ярдәм сорый кебек иде. Халидәнең күзләрен яшь алды.

Фу, шайтан. Райком секретаре — күз яше! Нинди мәгънәсезлек! Әмма күз яшьләре ургылып килде һәм Халидә тәрәзәгә маңгаен терәп иркенләп елады. Бу — секретарь булып эшли башлаганнан бирле икенче мәртәбә иде. Беренчесе моннан өч ел элек «Актив» колхозына жалоба тикшерергә баргач булган иде. Бер төркем колхозчылар председательнең фермада бөтенләй булмавы, гел культура эшләре белән генә шөгыльләнеп, сәхнә тирәсендә йөрергә яратуы, ферма малларының ач ятуы турында язганнар иде. Ул вакытта Халидә Әхмәтовна туп-туры фермага барып чыккан иде. Ярый әле сыер абзарына берүзе керде. Сыерлар ябык, янбаш сөякләренә чиләк эләрлек, сыртларын укра баскан, барысы да башларын салындырган, әйтерсең, хәлсез гәүдәнең сыер башы кебек авыр йөкне күтәреп торырлык егәре калмаган. Ферма коридорыннан чыгып барганда Халидә Әхмәтовна кинәт туктап калды: идәнгә яткан бер ала сыер мөлдерәтеп аңа карый иде. Ярдәм ит! Тамагымны туйдыр! Мин сөт бирәчәкмен! Шунда Халидә Әхмәтовна елап җибәрде, сыерның маңгаеннан, муеныннан сөйде һәм шушы малларның тамагын туйдырырга ант итте. Жалобаны тикшереп тормады, райкомга чапты, Байгильдеев янына кереп хәлне аңлатты. Беренче секретарьның резервыннан шул көнне үк йөз тонна фураж алуга иреште, ике көннән соң колхозның гомуми җыелышын җыеп «культура работнигын» эшеннән азат иттеләр.

Менә тагын күз яшьләре... Иген басуының да, күрәсең, нинди дер үзенә генә хас күз карашы бар иде, һәм ул мөлдерәтеп ярдәм сорый иде. Уйлап тап бер әмәл! Мин тулдым! Уйлап тап!

Халидә Әхмәтовна кнопкага басты — ярдәмче килеп керде.

— Көндезге унга барлык совхоз директорларын, колхоз председательләрен чакыртыгыз,— диде ул яшьле күзләрен тәрәзәдән алмыйча гына.— Конференц-залга, нәкъ сәгать унга. Сельхозтехника җитәкчелеген дә онытмагыз.

Нәрсә эшләргә? Халидә Әхмәтовнаның сынап караганы бар. Кеше баш миен бервакытта да бөтен нагрузкасына эшләтми. Баш миен эшләргә өйрәтергә, мәҗбүр итәргә кирәк. Авыр вакытта фикер дә килә. Менә бүген өлкәдән дәшмәделәр. Димәк, авыр икәнен аңладылар. Сәгать унга кадәр Халидә кабинетында тик утырды. Ник кенә бер телефон чылтырасын, әйтерсең бу яңгырга җебеп дөнья үлгән иде. Халидә берөзлексез кәгазьгә рәсем ясады. Тегене ясап карады, моны ясады, нәрсә ясаса да берәр урынында кәкре урак барлыкка килә иде. Туктале, бу урак элек бөтен Россияне икмәк белән тәэмин иткән бит! Комбайннар әле булмаган. Комбайн — социализм җимеше. Халидә хәтерли: ул беренче класста укыганда аларның уку китабында бер табышмак бар иде: «Ура, суга, җилгәрә, симез орлыклар бирә». Җаяләр эчендә җавабы: «К......». Комбайн. Бик нәзберек машина бит. Һава коры торганда бер комбайн уртача 300—500 кешене алмаштыра. Яңгыр булганда комбайн — нуль. Нишләргә? Рәсемнән тагын кәкре урак килеп чыкты. Я, ярар... Кәкре урак. Аны хәзер каян табасың? Чормаданмы? Авылдагы музейлардан мы? Хәтерли Халидә Әхмәтовна, барын да хәтерли. Сугышка кадәрге авылда (июнь ахырларында) бик матур бер гадәт бар иде. Авылда хәбәр тарала: бүген урак җыялар. Менә ишегалдына ике-өч кеше килеп тә керә. Гадәттә, язып баручысы кыз бала була. Фәлән Фәләневләр. Ничә урак? Ике ир кеше чырымта белән бәйләп уракны беләкләренә эләләр. Ә монысы? Агач сабы верстакта кырылып ясалган кызгылт буяу сеңдерелгән урак, монысын алмыйбыз. Ник? Нигә? Чөнки монысы — Мәкәрҗә урагы, ягъни, Мәкәрҗә ярминкәсендә сатып алынган урак, ул — корыч, аны инде бер тапкыр тешәгәннәр, шул — гомерлек. Аннан тимерче алачыгы янында атналар буе

кайрак тавышы. Зур тәгәрмәч ташны ике яшүсмер көне буе әйләндерә, тәгәрмәч таш аста су салынган тагарактан чыланып уза, көннәр буе урак кайрыйлар. Аннан урак тешәү башлана. Тимерче һәм ярдәмче... Беренче бригада, икенче, өченче... Ярдәмче тимер сандал өстенә кайралган, кайракка ышкылудан бераз гына зәңгәрләнеп янып, хуҗасына рәнҗеп калган тешсез уракларны бер-бер артлы куеп тора. Хәер, алай тиз түгел. Ярдәмче егет уракны төптән очка таба этеп тора, ә тәҗрибәле тимерче зубило белән уракка теш ясап бара: тек! Бер теш. Тек! Ике теш! Тек! Өч теш...

Аннан урак өләшү көне. Уракның агач сабында һәркемнең тамгасы. Тагын кенәгә белән теге кыз, тагын теге ике агай. Фәткуллиннар! Баскыч тамга? (Урак сабында киртләгән баскыч рәсеме, ягъни, ике вертикальгә ике горизонталь). Өч урак? Мәгез, Гали пәкесе булган. Бераздан: Зәйнуллиннар? Тавык тәпие? (Ягъни, бер ноктадан чыккан, өч якка таралган сызык). Җиде урак? Алла! Җиде! Менә, алыгыз. Бераздан: Шәймуллиннар? Бер урак? Ә, сезнең бит калганнары Мәкәрҗәдән. Сәнәк? (ягъни, тамга — сәнәк рәвеше). Менә булды.

Ул көн авыл яңа коралга карап хезмәт дәрте белән тула иде. Сугыш елларында ул уракларны рәтләп тешәүче дә булмады, әмма шул кәкре урак белән урып, барысын җыеп, эшкәртеп баралар иде. «Кечкенә генә бөкере, бөтен кырны бетерде». Халидә укыган «уку китабы»нда мондый табышмак та бар иде. Кәкре урак... Аны каян табарга, аның белән эш итә белергә ничек өйрәтергә? Тиктәскә генә бүгенге яшьләргә аны тоттырсаң, алар бер-ике учма алганчы ук бармакларын турап бетерәчәкләр бит! Халидә дымлы күзләре белән елмаеп куйды: ел саен сентябрь аенда ул көньякта диңгездә була, әллә ниткән кешеләр белән аралаша, таныша (генерал, академик, лауреат, дипломат һ. б.), ә үзенең чәнчи бармагы (француз лагы белән буялган) икегә аерылган сыман җөйле: бала вакытта аны әнисе үзе белән уракка алып чыккан иде. Ике учма әйләндереп салуга, өченчесендә учмага билчән эләкте һәм урак шуып китеп Халидәнең чәнчи бармагын тырнак өстеннән урталай ярды. Тирән үк китмәде китүен, әмма гомерлек эз булып калды. Тырнак үсә тора, кисә торасың, ләкин гел җөйле булып үсә. Гаҗәп...

Инде шуңа кайтыргамы? Туктале, бу районда иң тәҗрибәле председательләр кем? Гарәфиев, Евдокимов... Аларның мондый җәй күргәннәре бардыр бит инде. Андый җәйдә нишлисе икән? Нишлисе?

...Конференц-залга керер алдыннан Халидә Әхмәтовна күз төпләрен, керфекләрен бераз рәтләде, көзге каршында бераз торып алды. Башын-чәчен рәтләде дә, түбән карап кына залга узды, беренче рәттә бюро членнары урнашкан иде. Халидә залга караш ташлады: председательләрнең йөзе борчулы, әмма барысы да диярлек бәйрәмчә киенгән, райкомга ничек килергә аларны Байгильдеев өйрәтте шул. Сүзне башлар алдыннан секретарь зал буйлап күз йөртеп чыкты, арттагы рәтләрнең берсендә болай гына, узышлый гына кергәнсыман сөйләшеп утыручы Евдокимов белән Гарәфиевне күреп алды. Тә-ә-к... Боларны алып калырга. Районда болар — иң зур стажлы председательләр. Болар бер ни әйтер. Әйтми калмас.

— Иптәшләр, нишлибез?— дип башлады сүзен Халидә Әхмәтовна.— Нишлибез? — Ул тәрәзәгә карады. Яңгыр тәрәзәгә сылап сибәли иде.— Я, нишлибез?

Зал гөрләп алды, үзара сөйләшү китте.

— Мин доклад сөйләргә җыенмыйм, иптәшләр. Просто, киңәшергә кирәк: бу хәлдә без нишли алабыз?

— Берни дә эшләп булмый!— Алгы рәттән бер председатель тавыш бирде.

— Әй-йе! Туктамаса, берни дә эшләп булмый...

— Бер генә конкрет тәкъдим юкмы?

Хуҗалык җитәкчеләре гөрләште:
— Болай явып торганда нинди тәкъдим инде?
Халидә Әхмәтовна берәм-берәм сайлап аерым колхоз председательләренә мөрәҗәгать итте.
— «Жданов» колхозы?
— Нинди тәкъдим булсын инде, иптәш Әхмәтшина...
— «Авангард» колхозы?
— Тәкъдим дип... Кул ураклары булдырсаң гына инде.
Халидә Әхмәтовна җанланып китте:
— Менә-менә... Бу турыда без уйларга тиеш бүген. Ә «Актив» нәрсә уйлый?
— Булмый, иптәш секретарь, берни дә булмый...
Секретарь ачуына буылды. Нәрсә әйткәнен үзе дә сизми калды:
— Алайсә, чалбарыгызны юбкага алыштырыгыз. Без сезне монда «булмый»ны ишетер өчен түгел, нәрсә эшләргә була — шуны ишетер өчен чакырдык.
Зал белән бәхәс кыза төште. Инде Халидә Әхмәтовна үзенең ике әзер тәкъдименең берсен куеп карарга булды. Икенчесен ул әлегә резервта калдырды.
— Болай, иптәшләр. Дөресен генә әйткәндә мин сездән конкрет тәкъдимнәр көткән идем. Сез минем ышанычымны акламадыгыз. Сезнең арада күпме фронтовиклар бар? Сез менә, иптәш Гарәфиев өлкән сержант бит! Ә сез, Николай Васильевич, гвардия офицеры бит! Сез, иптәш Евдокимов — сугыш узган солдат бит! Сез сугыш вакытында да шулай булдыгызмы? Днепрны кичәргә — булмый! Варшаваны азат итәргә — булмый! Берлинны алырга — булмый! Алайса, без ничек җиңдек? Дошман бит аларның берсен дә «мәгез, рәхим итегез» дип бирмәде! Сез сугыштыгызмы, әллә обозда ат җигеп солдатларга күлмәкыштан, сабын ташып кына йөрдегезме? Ә, иптәш Гарәфиев? Ә, Николай Васильевич? Я, ничек? Нигә берни дә тәкъдим итмисез? Ә бүген чын сугыш башланса? Сугыш бит кырык беренче елны да шул уракка төшәр алдыннан һына башланды. Ә бүген башланса? Булмый дип торабызмы? Ә? Торабызмы? Я, нигә тәкъдим кертмисез? Кул белән уруга ничек карыйсыз? Бер кеше көненә күпме ура ала?
Арттан Евдокимов торып басты:
— Вапше, тәҗрибәле, элек урак тоткан хатын 20—23 сутый ура ала. Тик менә урак каян табарга?
— Менә, менә... Димәк, биш хатын-кыз көненә бер гектар ура ала. Ярыймы бу? Кул кушырып утыруга караганда, ярый. Димәк болай: бүген бөтен хуҗалыкларда булган уракны барлыйсыз. Һәр бригада ничә урак, ничә чалгы куя ала — ачыклыйсыз. Тәҗрибәле уракчыларны яшьләргә өстәмә итеп билгелисез. Бүген — әзерлек көне, иртәгәдән эшкә. Аннан соң, нигә борын салындырасыз әле, иптәшләр? Сез игътибар итәсезме быелгы яңгырның характерына? Көннең беренче яртысында ява да, төштән соң туктый, җилли, һәр төнне аяза? Игътибар иттегезме? Менә сезгә уйлау өчен бер юнәлеш. Сораулар бармы?
Зал шыгырдап, мыгырдап алды, сораулар юк иде.
— Сораулар булмаса, хәзер үз объектларга таралабыз. Иртәгә мин көне буе телефонда сездән мәгълүмат җыеп утырачакмын. Ә хәзер таралыгыз, Гарәфиев белән Евдокимов минем янга керәләр.
...Халидә Әхмәтовна кабинетында озак утырдылар. Төш вакыты узган, күк йөзе ертылгалаган, яңгыр туктаган, дөнья җилли иде. Кабинетта бераз яктыра төште. Шул сәгатьтә өч кеше әлегә беркемгә дә мәгълүм булмаган карар кабул иттеләр: бүген комбайннар белән төнге сменага чыгарга. Һәркөнне төштән соң җилли икән, төнен чалт аяз икән, димәк, эш вакытын күчерергә. «Яңа юл» белән Емельянов исемендәге

колхозның уртак межасына оператив штаб урнаша. Уртак ашханә. Вагонеткалар. Телефон аппараты. Медпункт. Ремонт машиналары. Бүген төнгә чыгып сәгать бергә кадәр эшләп карарга. Әгәр эш барып чыкса, иртәгүк бөтен районга шул режимны кертергә. Килештек? Әйдәгез, иптәшләр, шуның инициаторы булыгыз әле...

Ташлытаудан кайтканда юл бераз җилләгән иде. Ай, бер-ике генә көн кояш! Ике генә көн! Ахияр кайтуга ашыгыч рәвештә бөтен механизаторларны җыйды. Механизаторларның кәефе начар, җәй буе техниканы әзерләделәр, әзерләделәр дә, менә инде буылып тик яталар. Ахиярның тәкъдименә, аның гаҗәпләнүенә каршы, берәү дә шик белдермәде, киресенчә, барысы да иркен сулап куйдылар. Бер киерелеп, көчне сынап карыйсы килгән иде. Механизаторларга бурыч куелды: бүгенгә ун комбайн белән кырга чыгарга. Бер комбайнга ике тяга бирергә. Эшләп карарга. Калганын колхоз идарәсе үзе кайгырта.

Ахияр идарә членнарына аерым-аерым эш йөкләде: берәүләр ашханә ягын хәл итәргә, икенчеләр вагонеткалар китерергә, өченчеләр күчмә ремонт машинасын шунда илтү өчен җаваплы булдылар. «Яңа юл»да әле беренче генә елын эшләп, үз функцияләрен таба алмыйча җафаланган партком секретаре, яшь егет Рәиф Шәймиев кош toткандай йөгереп йөрде: югыйсә, моңарчы бөтен авыр мәсьәләне Ахияр үзе хәл итә, дәрәҗәсе, олы гәүдәсе белән гел яшь секретарьны күләгәләп килә иде. Бүген Рәиф Шәймиев штаб начальнигы итеп билгеләнде...

Кичкә таба байтак җилләде, авыл җанланды. Авыл тутырып техника гөрләде, тыз-быз чабыштылар. Хәсән карт әйтә куйды:

— Теге елны, егерме икенче июнь шулай чабышкан иде халык... Кыямәт көнемени? Һаваны бозып бетерделәр инде. Гел ракета да ракета, айга очумы дисең, кояшкамы? Күк ничек чыдасын аңа? Менә тишеп бетерделәр дә, хәзер бик ямыйсы...

— Белмим шул, төнлә урак урып булырмы икән?

Кич ике басу арасында шәһәрчек барлыкка килде. Егермедән артык комбайн, дистәләгән трактор, механизаторлар межаны тутырдылар. Ике-өч урында вагонетка, бер урында палатка да корылган иде. Башта межага утырып керәшеннәр белән бергә тәмәке тарттылар, уенкөлке сөйләштеләр. Нәчтүк әбинең әйтүенчә симән көненә ике атна кала гына (Семенов день — 14 сентябрь) аязасы икән. Әмма төннәрен гел аяз буласы, ди. Ахияр яхшы күнитекләр кигән, өстендә сырган бишмәт, Митрий исә яшел брезент куртка киеп куйган, шулай ук күнитектән иде. Вагонеткаларның берсеннән токмачлы, итле, суганлы шулпа исе борынга бәрелде. Ул арада район үзәгеннән «Уазик» килеп туктады, бортында кызыл хач рәсеме бар иде. Эченнән ак халатлы ике-өч хатынкыз, бер ир чыкты.

Нәкъ сәгать тугызда Ахияр, Митрий, ике агроном, ике партком секретаре (яшь Рәиф, көмеш чәчле йомры Пәви) арыш арасына кереп киттеләр, механизаторлар һаман әле сүз уйнаталар иде. Межа буенда йөргәндә Ахияр гел колагына аларның сүзен эләктереп барды. Сөйләгәннәре — бер дә авыл хуҗалыгы турында түгел, гел семья-көнкүреш мәсьәләсенә кагылышлы мәзәк, мәкаль иде. Гаҗәп! Берсе дә дулкынланмый, борчылмый.

— Әй, сөйләп торган булма инде. Вапше. Аны кем дә белә. Үз катының янында бер дә әлләкем булып булмый. Чөнки ул синең бөтен кимчелегеңне белә... Әнә безнең тимерче Питр. Нәрсә генә килми кулыннан? Ну, кимчелек зур — катын белә.

— Шулай инде ул. Әнә безнең Колан Кырда Габдерахим нинди номер күрсәтте. Ирләр илледә котыра, ди. Дөрес инде ул.

— Әйтәләрме: карт гыйшык кала ватар, дип? Нилар күрсәтмәде балаларына, хатыны үлгәч. Һи-и-и... Белгән инде, ир кеше, ата чыпчык,

этэч — өчесе бер. Момент — әйдә, ник шунда кырык чөең кырылып ятмый...

Арыш җилләгән, җир сурыккан иде. Күк йөзенең офыкка төшкән көнбатыш ягында кара карганың кауры кебек зәңгәр-караланып хәтәр, хәвефле болытлар туктаган, дөнья тынып калган иде. Җитәкче иптәшләр вагонеткалар янына килгәндә ике колхозның механизаторлары межага басканнар, чырайлар җитдиләнгән һәм барысы да авызларын ярым ачып әмер көтеп торалар иде.

— Башлыйк,— диде Ахияр.

— Вапше, арыш җилләгән, егетләр,— диде Митрий,— әйдә, бер тарихка кереп калыйк әле.

Комбайнерлар таралыштылар, тракторлар инде гөрелдәп утыра иде, шлемнар киелде, күзлек киюнең кирәге юк иде: тузан булмаячак, кояш — юк. Һәм дөнья икегә аерылды. Межадан, горизонттан, ике якка, түбәнгә таба, ике колхоз басуына таба гөрләп комбайннар кереп китте. Районның авыл хуҗалыгы тарихына моңарчы булмаган эш — комбайннарны төнлә эшләтү дигән яңа бер бит язылып ята иде. Ул арада автомашиналар бункердан орлык кабул итәргә камылга кереп киттеләр. Халидә Әхмәтовна дөрес әйткән: межа буендагы шәһәрчек сугыш штабына, ә ике басу — фронтка охшап калган иде.

Берәр сәгать буе берөзлексез эшләделәр. Автомашиналар, озак-озак көтеп булса да, орлык тутырып авылга таба шуыштылар, бераздан офыкны әкияттәгедәй серләндереп, сәерләндереп зур кызыл табак булып ай калыкты. Шәһәрчектәге движок эшли башлады, урман полосасындагы ике каен башына фара эленгән иде, алар басуга яктылык көлтәсе сипте. Ул арада басудан, рәттән чыгып бер комбайн килеп җитте: барабанга ташмы, агачмы эләккән, нәрсәдер булган. «Емельянов» колхозыныкы. Вагонеткадан берәүме-икәүме йөгереп чыктылар, фараны шуңа юнәлттеләр, ыгы-зыгы башланды. Берсе — Петр икән.

— Ну-ка, ну-ка,— дип өтәләнде ул.— Кабыз әле! Эшләт әле бөтен узелларыңны! Тавышланмагыз әле! Мин тыңлыйм әле. Стоп!

Ярты сәгатьләр матавыклангач комбайн яңадан басуга кереп китте.

Төн караңгы, офыктан күтәрелгән кызыл ай, бераздан яшелләнсә дә кырны яктырта алмады, нииндидер бер озынча зәңгәр корыч болыт аны каплап алды да тик тора. Әмма ике як басуны да комбайн фаралары ялый, ике якта да тигез гөрелте ишетелә иде.

Уникедә туктарга тиешләр иде, җитәкчеләр берөзлексез сәгатьләренә карадылар. Унике. Унике тулып егерме минут. Вәгъдәсезлек бит бу! Егетләргә шулай әйтелгән иде. Беренче ярты. Туктатыйкмы? Бер туларга унбиш минут...

— Вапше...

— Әнә, олы юлдан бер машина борылды. Мөгаен, безгәдер...

Газик ут көлтәсен селки-селки шәһәрчеккә килеп туктады. Җиңел хәрәкәт белән машина эченнән Халидә Әхмәтовна сикереп төште: өстендә плащ, аякларында резин итекләр иде.

— Я, ничек? — диде ул җитәкчеләр янына килеп.— Ничек, иптәшләр? — Үзенең тавышы калтырый иде.

— Менә сигез йөк орлыкны колхоз көшеленә озаттык,— диде Ахияр.

— Без, вапше, унике машина озаттык,— диде Митрий.

Халидә Әхмәтовна кинәт йомшап китеп, Ахиярны кочаклады. Аннан Митрийне. Тагын йомшады.

— Бу, иптәшләр, беләсезме? Бу — беләсезме? Мин сезгә әйттем бит! Мин сезгә ышана идем бит! Ә иртәгә — бөтен районга! Бөтен бюро әгъзаларын колхозларга! Рәхмәт сезгә!— Ул сәгатенә карады.— Иптәшләр, сез нәрсә? Бер тулып киткән бит! Беренче көнгә җитәр! Туктатыгыз!

Аннан ике партком секретареннан ике председательне аерып читкә алып китте дә, пышылдап болай диде:

— Ашыгыз пешкәнме? Аш алды бармы механизаторларга? Аң булыгыз, моны мин әйтергә тиеш түгел, ләкин фронт паегы булсын...

Ахияр моны алдан күргән икән, Митрий исә тиз генә шоферын авылга чаптырды.

— Вапше, йокысыннан уят, кибетен ачсын и күп сөйләшеп тормасын, мин кушты дип әйт...

...Аш әзерләгән такта өстәлгә ике фараны да борып куйдылар. Фронт паегын караңгыда, җитәкчелек күрмәгән җирдә хәл итеп килделәр. Гөлдерәп килеп утырып (комбайнерлар тышкы өстәлдә, тракторист-шофер вагонеткада иде) итле ашны ак күмәч белән сыпыра башлагач, өстәл башына Халидә Әхмәтовна килеп басты.

— Иптәшләр,— диде ул,— кадерле иптәшләр. Сез әле бүген үзегезнең нәрсә эшләгәнегезне белмисез. Бу — иптәшләр, икмәкне коткару дигән сүз! Ватан алдында үзебезнең бурычны үтәү дигән сүз! Иптәшләр! Кемнең нинди гозере бар! Булдыра алмаганны эшләргә тырышачакбыз! Менә сезгә врачлар! Иртәгә вагонеткада бормашина торачак. Кемнең тешен дәваларга кирәк?

Ахияр елмаеп Кәшфигә карады: авыз тулы яңа тешле, битләр-чырайлар тазарып киткән Кәшфи өстәлнең түрендә утыра иде, бүген аның комбайны иң зур «күрсәткеч»кә иреште.

— Кем мотоциклга, машинага чиратта тора? Кем мебельгә, паласка? Минем сүзем — райком сүзе! Эшләгез генә!

Халидә Әхмәтовнаның тавышы калтырый иде. Төнге аш күңелле генә тәмамланды. Офык ягындагы кара болыт сыр-сыр булып өзгәләнгән, ай бераз гына тоныкланган, аның тирәсен ефәк шәлсыман болыт чорнап алган иде. Халидә Әхмәтовна китәр алдыннан трактористлар, шоферлар ашаган вагонеткага керде: фронт паегыннан шоферлар мәхрүм ителгән, әмма трактористлар шау-гөр килеп сөяк кимерәләр, аш ашыйлар, тәмәке тарталар, уен-көлке сөйлиләр иде. Митрий килеп секретарьга аңлатты:

— Вапше, бик аптырадым әле мин; фронт паегыннан минем старший брат баш тартты. Утыз ел шуның белән дус булган кеше. Бер трактор чылбырының палецы чыккан. Нинди ул, шуны эшләмәгән көе, ди.

Вагонетка түрендә Колан Кыр тракторисгы, үзенең олы гәүдәсе белән бөтен районга билгеле, зур битле, чабата калыбы кадәр борынлы Сәйяф утыра иде, «старший брат»ның өлешен аңа биргәннәр, ике өлеш исә аның кәефен үк ачкан...

Халидә Әхмәтовнаны машинага утыртып озатканда бөтен шәһәрчек кузгалды, фара көлтәләре уйнады.

— Иртәгә мин сәгать төнге бергә киләм,— диде ул җитәкчеләргә,— рәхмәт, егетләр. Бүген больницадан иптәш Байгильдеев чылтыратты, сезгә сәлам әйтте, бер атнадан чыгаралар, диде. Район буенча утыз гектар — бу инде әйбәт башлангыч! Мин хәзер өлкә комитетына сводка бирәм. Иртәгә, юк, бүген икән, сезнең тәҗрибәне — бөтен районга!

...Иртәнге алтыда аны өлкә комитетының авыл хуҗалыгы буенча җаваплы секретаре телефон белән уятты.

— Сез нәрсә, күз буйыйсызмы?

— Ә нигә күз буярга?

— Ә соң утыз гектар?

— Әйе, әлегә утыз. Бүген күбрәк тә булыр.

— Нәрсә, сездә явым туктадымыни?

— Туктамады, без төнлә урабыз.

— Ничек — төнлә?

— Менә әлегә тәҗрибә эшләп карыйбыз.

— Димәк, утыз гектар — дөрес?

— Дөрес, ләкин бүген арттырырбыз дип уйлыйм.

— Ну, карагыз. Ә болай — бик кызык...

Ул көнне төнге кампанияне ачарга колхозларга бюро членнары таралды. Секретарь сүзендә торды: кампанияне башлаучы ике колхоз межасына кичке сигезгә раймаг машиналары килеп туктады, берсендә промтовар, икенчесендә гастроном иде. Кызыл Хачлы машина килеп туктады: машина тулы врачлар иде. Райпо председателе халыкны җыеп сөйләшеп алды: кемгәдер түбә калае, кемгәдер мотоцикл кирәк икән. Палас сораучы булмады.

— Бөтен сорауларыгызны канәгатьләндерәм,— диде райпо председателе.— Акчагыз гына булсын.— Шаяртып та алды: — Бельгиядә тегелгән хром курткалар кирәкмиме? Бәясе — нибары дүрт йөз сиксән сум...

Көлештеләр. Тик Кәшфи генә бу мәсьәләгә җитди карады:

— Аның өчен чөнки, шулай ул, иптәшләр. Аны бер аласың и һәм дә гомер буе киясең. Ул чөнки арзанга төшә...

Тиздән район газетасында «Яңа юл»-«Емельянов» тәҗрибәсе» дигән мәкалә күренде. Төнге уруга инде бөтен колхозлар да керешкән иде. Бюро членнары һәр төнне колхоз кырында булдылар, ул арада Байгильдеев тә кайтып җитте. Әмма аңа әле эшкә чыгарга рөхсәт итмиләр иде, районның бөтен дилбегәсе Халидә Әхмәтовна кулында кала бирде. Бер төнне секретарь «Яңа юл»-«Емельянов» кыр станында иртәнгә кадәр калды, ул төн явымга тартым иде, барысы да борчылдылар. Халидә Әхмәтовна иртән туп-туры райкомга кайтып кабинетына керсә, кемнеңдер өстәлдәге кәгазьләргә кагылганын сизде. Өстәл календаре бөтенләй борылып куелган. Халидә Әхмәтовна сискәнеп китте: календарь битенә кызыл фломастер белән язганнар иде. «Халидә! Молодец! Звони!» Имза — өлкә секретареныкы иде.

Ул төнне өлкә секретаре төнлә килеп ярты районны йөреп чыккан икән.

Арыш урагы тәмамланганчы сабан өлгерде. Төнге уру шулай сентябрьгәчә сузылды. Ахияр да палатка эчендәге бал исле арыш саламында йоклап рәхәтләнде. Ул нәкъ иртәнге өчтә ятып җидегә кадәр сабый бала йокысын йоклый иде.

Шундый төннәрнең берсе узганда Ахияр баллы салам исенә рәхәтләнеп киерелеп уянды. Уянды — аңыша алмыйча торды: күк йөзенә саргылт кояш күтәрелеп килә иде. Кояшның чырае авырудан терелеп килгән кешенеке кебек газаплы, сагышлы, йончулы булып күренде аңа. Эскерт инде кояш нурына җылына башлаган, түбәндә, үзәндә җәйрәп яткан авыл зәңгәр рәшә эчендә тирбәлә иде. Ахияр шатлыклы киерелеп торды, машина ишеген ачып радиоалгычны көйләде. Бәхетенә — һава хәлен әйтеп яталар икән. Дикторның мөлаем тавышы бүген генә түгел, алдагы ике көндә дә явымсыз, температура 23—28 градус булачак дип хәбәр итте.

Монысына ук Ахияр түзә алмады, машинасын кабызып җир ярып Митрий колхозына чапты. Исәбе — аны да ияртеп районга килеп чыгу иде. Әгәр мөмкинлек булса, Ахияр туп-туры кабинетында ук райком секретаре Халидә Әхмәтовнаны кочаклап, яңагыннан үбәчәк. Әгәр мөмкинлек булса, ул Байгильдеев кабинетына да кереп шатлыгын уртаклашачак. Байгильдеевнең бүген беренче эш көне буласы дигәннәр иде.

Юк, кайгыны үзең генә күтәреп була, әмма шатлыкны — булмый. Алай ярамый...

«Емельянов» колхозына якынлашкан саен кояш җетеләнә бара, бөтен дөнья зәңгәр рәшәгә тирбәлә иде.

Адәм баласын нәрсә яшәтә? Борчулар, җиңү шатлыгы яшәтә. Әйе, шул ике көч...

Мәгыйзь колхоз экономикасының бөтен тәрәге иде. Күрше колхозларда аның замандаш хисапчылары инде әллә кайчан «тиражга чыктылар», әмма, Мәгыйзь гел заман дәрәҗәсендә булды. Кирәге чыккач, арифмометрны өйрәнде, авыл хуҗалыгы буенча кеше әйтеп кеше ышанмаслык махсус әдәбият укып барды. Башы, хәтере — колхоз архивы. Ничәнче елда, кайсы басуга нинди культура чәчелеп, күпме уңыш алынуы турында бөтен мәгълүматны бернинди кәгазь актармыйча, Мәгыйзь генә әйтеп бирә ала. Тик шул мәгълүматын әйләндереп чыгарып салу өчен бер генә шарт кирәк: аның ике ирене арасында сүнгәнме, пыскып торганмы, бер төпчек кисәге булсын.

— Кырык тугызынчы елны,— ди ул Ахиярга карап.— Торна урманы буендагы клинга арыш чәчтек. (Сүнгән төпчеген суырып ала). Андый кечкенә клинга чәчмик, дип бәйләнәләр. Кәрделе-чыктылы басу. Мәшәкате зур, борылуы кыен. Мин әйтәм, яңа җир бу, чәчеп карыйк. Әйдә, мин әйтәм, йөз гектар гына. И һәм дә шуннан күпме уңыш алдык? (Пыс-пыс, инде тәмам сүнгән икән.) Шуның гектарыннан егерме сигезәр центнер алдык. Ә уртача валовой җыем — алты да сиксән. Белдеңме? Менә сиңа клин. И һәм шул елны мин өйләндем. Колхоз шул елны — сугыш башланганнан бирле сигез елдан соң! — беренче тапкыр ашарга ипи бирде. Ничек бирде? Теге клин элек көтүлек иде. Ышна басуы. Чәчү мәйданына кертмәдек тегене. Сәкинә белми исәп-хисапны. Менә көз җитте, уңыш бүлдек, Сәкинә кара көеп йөри: бу ни хәл бу, сабатажник? — ди миңа. Ә мин — кәләш алып кайтып йөрим... Чирәм җир — вәт нәрсә хәл итә ипине!

Ахияр аның тәҗрибәсенә гел таянды.

Аны «Яңа юл»га председатель итеп җибәргәндә үк авыл хуҗалыгы бүлегендә әйттеләр: колхозның исәп-хисабын, экономикасын яттан белүче хисапчы бар, шуңа таян, диделәр. Һәм Ахияр шуңа таянды. Мәгыйзь исә прогнозларны бирә торды, аның саен Ахияр каршында дәрәҗәсе үсә торды. Шуңа күрә председатель аның бер сәер гадәтен гел гафу итте.

...Райпо кибетләрендә ревизия ясарга кирәк булса, иң беренче чиратта Мәгыйзьгә хәбәр кылә иде. Шул хәбәр килгән көнне Мәгыйзь яшәреп, рухланып китә, ничектер аеруча чистарак итеп кырына, күлмәкнең яңасын кия һәм урынына утырып бер эш эшли алмый. Керә, чыга, телефонны бора, райпо белән сөйләшә.

— Кайсы кибеттән башлыйбыз? Ничә көнгә? Миңа бит иптәш Гарәфиевтән рөхсәт кирәк. Миңа көн сорарга кирәк...

Кичке якта тагын:

— Ачыкладыгызмы? Бригадада мин старшиймы? Ике көнгәме?

Ахияр болай да белә иде. Ике түгел, дүрт, биш көн. Ике көннән кайтса Мәгыйзь буламыни ул? Әйдә бер җилләнеп, мамык коеп кайтсын инде.

Кичен исә ул кышын булса — идарә коридорында, җәен булса — урамда, капка төбендә, финанс эшенең чисталыгы, намуслылыгы турында әллә ниләр сөйләп халыкны таң калдыра.

— Менә мине — җиде класс белемле кешене бүгенгесе көнне иптәш Гарәфиев ник тота? Птамушты — мин намуслы. Колхозның бөтен байлыгы менә ничә ел инде минем баш миемнән, кулымнан уза. Сез ач булганда — мин дә ач, сез тук булганда — мин дә тук. Ә бит — шаярам дисәң мог бы! Миңа нәрсә? И так — яхшы, и эдак — начар түгел.

Аннан мәзәк сөйләп китә. Хәсән карт колак яфрагын турайтыбрак тыңлый.

— Шулай бер байның хезмәтчесе булган. Авылдан килеп, үзенең яшь, чибәр хатыны белән байның кара өендә торалар икән. Хатыны

кер юа, үзе — ишегалдын себерә, кар көри, утын яра. Бай һәр көн иртә белән ишетә: теге хезмәтче ишегалдын себергәндә гел үзенчә сөйләнә икән. Себеркене бер якка селтәгәндә:

— Миңа болай да начар түгел,— дип, икенче якка селтәгәндә:

— Миңа болай тагын да яхшы,— дип.

Көннәрдән бер көнне бай сорый моннан:

— Нәрсә дигән сүз соң ул? — ди. Хезмәтче әйтә:

— Мене син мине базарга йомышка җибәргән арада кара өйгә кереп минем хатынны кымтырыклыйсың, аңа күлмәклек-яулыклык акча бирәсең — бу минем өчен начар түгел. Ә син ярминкәгә киткәндә мин хатынымны авылга әтиләренә кунакка җибәрәм дә, синең хатын янына кереп йоклыйм, ул да миңа һәр төн өчен көмеш бер сум биреп чыгара. Миңа монысы тагын да яхшырак,— ди.

Хәсән карт — дөньяны күп гизгән, мәдрәсә күргән, сугыш узган кеше, колхозга гомер буе умарта, умарта рамы ясаган оста, Мәгыйзь сөйләгәннәрне рәхәтләнеп тыңлый. Чөнки белә: Мәгыйзь — кеше арасында иркен яши. Өендә хатыны кырыс, бераз көйсезрәк. Характерлары туры килеп бетмәгән. Кырык тугызның ипиле көзендә алып кайтты аны Мәгыйзь. Унбиш чакрым ераклыктагы Күпербаштан. Матур итеп туй уздырдылар, кабартма, коймак, каз ите, бәлешнең иге-чиге булмады. Әмма хатын — кеше белән аралашмый яшәгән семьядан булып чыкты. Мәгыйзьләрнең исә бөтен тормыш ачык, бөтенесе күрше-күлән белән уртак иде. Өч-дүрт атна дигәндә өйдә низагъ чыгып, килен әтиәнисе янына кайтып китте. Сәкинәдән ул җигеп йөри торган атны тагын бер кат сорап, Мәгыйзь аны барып алды. Атна-ун көн әйбәт кенә яшәделәр. Тагын тавыш чыкты. Яшь килен тагын Күпербаш ягына юл тотты. Бу юлы инде Мәгыйзь председатель Сәкинәдән оялды. Бригадир атын җигеп, гади арбага утырып Күпербашка барды һәм көйсез киленне алып кайтты. Аннан көйсез килен тагын биш-алты тапкыр асрылып китте. Мәгыйзь унбиш чакрымны җәяү йөри башлады. Авыл халкы елмаеп кына аны Күпербаш юлына озатты, елмаеп кына аларның икесен каршы алды. Ә бер көнне килен чираттагы үпкәсен белдереп Күпербашка китеп баргач, анда гадәттәге бер кичен кунгач, һәм Мәгыйзь иртән таңда аны алып кайтырга дип юлга чыгарга җыенганда, урамда очраклы рәвештә Хәсән карт туры килде.

— Тагын... шундамы? — диде Хәсән карт. Хәер, ул вакытта Хәсән картны әле Хәсән абзый дип кенә йөртәләр иде.— Тагын шундамы?

Мәгыйзь сүзне уенга борды:

— Иртә торсаң — ит пешә, соңга калсаң — бит пешә,— дигән булды ул.

— Ай-һай, улым, ит пешәрме икән сиңа,— диде Хәсән абзый шунда.— Әйдә, менә мондарак кил әле...

Һәм ул Мәгыйзьгә киңәш бирде. Тормышың көйләнсен дисәң, хатыныңны барып алма, диде. Үзе килер, диде. Капка төбенә Мәгыйзьнең әнисе Вагыйзәттәй дә чыккан иде. Сүзгә ул да кушылды. Үзәгенә үткәнне әйтте.

— Улым,— диде,— мин курыкмыйча сөйләшәм. Мин — синең төсле егетне үстергән надан бер карчык. Шулай да әйтим әле: мин — ул анасы. Ул анасы — гөбернатыр, кыз анасы — посып ятыр, дигән бабайлар. Бәяңне төшермә. Кодагыйга да әйттем: шикәр шикелле кызымны сезгә бирдем, дип бик борнайланма, кодагый, дидем. Яшьләрне бозма. Ир-ир инде ул, дидем. Үз урыныңны бел, улым.

...Мәгыйзь ул көнне Күпербашка бармады, идарәгә китте, икенче көнне дә бармады, кичен уку йортында яшүсмер Рәиф белән кроссворд чишеп утырды. Рәифнең шул вакытта ук баш әйбәт эшли иде шул, партком секретаре итеп юк-бар кешене куймыйлар.

— Авыл хуҗалыгы машинасы,— ди Рәиф карандаш белән шакмак санап.

Мәгыйзь әле бүген үз гомерендә беренче тапкыр кроссворд чишүгә катнаша, тәртибенә әле өйрәнеп килә.

Ләкин шунда ук үзенекен сөйләп алырга да онытмый. Авызда тәмәкесе булганда ул гел сөйли.

— Ызначит, болай,— ди ул Рәиф баш катырып утырганда.— Кешегә бер замечание ясарга кирәк. Шуңа колак салып, шуны башкача кабатламаса — ул кеше өметле. Бер үк замечаниене ике тапкыр ясаткан кешедә өмет юк. Менә болай: бераү чәчен тарый да, мин, кәнишне, кыз баланы күздә тотам, чәчле тарагын өстәлгә — ашау өстәленә куя. Син әйтәсең. Әнә шуны бүтән кабатламаса — ул кызга өйләнергә ярый. Кабатласа — өмет юк. Авыл хуҗалыгы машинасы дисеңме? Ничә хәреф? — дип сорый ул тәҗрибәле кеше сыман.

— Алты хәреф. «С» белән башлана.

— Трактор! — дип шатлана Мәгыйзь. Рәиф көлә. Алга таба да шулай.

— Уку-язу әсбабы... Беренче хәрефе «К», ахыргысы «ш». Бу була...

— Күпербаш! — дип кычкыра Мәгыйзь һәм оялып китә. Үзе кроссворд чишә, үзенең күңеле гел Күпербашта икән бит!

Ике кичтән соң хатын, әлбәттә, кайтты, Мәгыйзьне бер почмакка кысып сорау алды:

— Мине ник килеп алмадың? Ник? — дип сөлекләр булыпябышты. Мәгыйзь каты торган булды, Хәсән карт агитациясе икәнен әйтмәде. Үткен килен сиздe: Мәгыйзьгә кемдер тәэсир ясаган. Моны ачыклау өчен аңа көянтә-чиләк белән бер тапкыр чишмәгә төшеп менү житте. Чыбыксыз телефон бик төгәл эшләде: кырынып, яңа хром итекләрен киеп Күпербашка чыгып барган Мәгыйзьне иртә таңда Хәсән карт туктаткан...

Килен, йомыш тапкан булып, Камиләтти янына керде. Бәхетенә Камиләтти үзенең сөяккә әйләнгән таягы белән сөйләшә-сөйләшә кибеткә киткән, Хәсән абзый ялгыз иде.

— Ник котыртасың син кешене? Ник кеше арасына керәсең син? — дип яшь килен авызыннан ут чәчте. Үзгенә үтеп сорашты: Мәгыйзь кайчан капкадан чыккан, чыккач кем белән очрашкан, кая барам диган, ник кире борылган...

Кичен Хәсән абзый идарәдән кайтып килүче Мәгыйзь белән исәнләшкәч әйтә куйды:

— Иллә дә метеклэп сорашты инде. Җон төбенә төшмичә туктый торган кеше түгел икән...

Мәгыйзь кәефсез иде.

— Аптыраган инде, Хәсән абзый,— диде.— Уйлап та куям: аллә аерылышыйкмы икән? Характерлар бер дә туры килми бит...

Хәсән абзый тамагын кырды.

— Ашыкма, энекәш. Хәзер инде аерылышу турында телеңә дә алма. Бодаен алгач, саламына ут төрт, дигәннәр. Хәзер инде нинди сүз ул — характер? Битенә тут төшкән бит инде аның.

Менә шулай торып калдылар. Идарә эше, исәп-хисап, экономик фаразлар буенча сөйләшеп Ахияр аның белән күп төннәр уздырды. Мәгыйзь колхоз идарәсенең рухы, җаны иде. Аның кыш кия торган карага каккан туныңа идарә исе сеңгән, ул ис берничә еллык тәмәке исе белән кәгазь, кара, счет, шкаф исләреннән оешып аерым бер «Мәгыйзь исе» ясаган иде. Мәгыйзь бигрәк тә идарә бүлмәсендә төн утыруны ярата. Янында булган кешегә төне буе кызыклы хәлләр, авыл, колхоз тарихын сөйләргә ярата. Ахияр бөтен колхозчының нәсел-нәсәбен, холык-фигылен шуннан өйрәнде, колхоз тарихын шуннан сеңдерде. Боларны белү аның эшен шактый җиңеләйтә иде.

Менә Мәгыйзьне райпога сорыйлар бит әле. Ташлытауның үзәк кибетендә ревизия ясарга.

— Иптәш Гарәфиев, рөхсәт итәсезме? — ди Мәгыйзь итагать белән генә.— Ике көнгә...

Ахияр белә: алай гына булмаячак. Рөхсәт итә. Икенче көнне иртүк Мәгыйзьне районга озаталар. Зур бер хәл бу: идарә генә түгел, колхоз ятим кала. Яшисе килми бу авылда. Бер ямь юк монда!

Әмма Мәгыйзь үзе алай уйламый. Раймагның эчке бүлмәсендә төтен эчендә ул чалт та чолт төймә тарта, кибетчеләргә, ревизорларга төрле хәлләр сөйли.

— Ишеткәнегез бармы? Бер тиен җитмәүчелек аркасында бер бухгалтер асылынып үлгән?

— Нигә үз кесәсеннән салмаган?

— Кая салсын ул аны?

— Ник, кассага!

— Юләрләр! Бухгалтер бит ул касса белән эш итми. Касса — кассирда. Бухгалтер акча тотмый бит ул! Ул бит финанс системасының аристократы! Интеллигенция...

Кибетнең йөк ташучысы шаяртып ала:

— Иң тиле ак сөяк...

Мәгыйзь аңа рәнҗеп карый. Сүз катмый.

— Юк инде, бер тиен өчен үзеңне-үзең харап иту — эш түгел.— Моны сатучы яшь кыз әйтә.

Мәгыйзь квалификацияле анализ ясый.

— Ә ул бер тиен чутның аскы чыбыгында җитмәгән.

Яшь кызлар аңламыйлар. Мәгыйзь кырыслана:

— Унынчы төймә булган ул.

Һаман аңламыйлар. Мәгыйзь сүнгән төпчеген яңарта, счет чалтырата башлый.

— Менә карагыз.— Ул счетның бөтен чыбыкларындагы төймәләрнең тугызарын сул якка күчерә. Уң якта һәр чыбыкта — берәр төймә утырып кала.— Менә карагыз! Иң астагы рәттә — тиенлекләр. Тәк. (Пыс-пыс.) Менә бер тиен бу якта, уң рәттә калган. Шул юк. Аңладыгызмы?

Кемдер һаман каршы килә.

— И, инде бер тиен дип үләргә! Бигрәк тагы! Сумашушный булгандыр ул!

Мәгыйзь тагын рәнҗи. Шырпы сызып авыз тирәсенә менеп төшә.

— Менә,— ди ул.— Бер тиен табылды: кулда түгел, дукәмиттә. Әмма ки аны бухгалтер үлгәч табалар. Бер җирдә хата киткән. Менә карагыз: өске рәтләр нәрсә бирә? Тугыз миллион тугыз йөз туксан тугыз мең тугыз йөз туксан тугыз тәңкә и һәм дә туксан тугыз тиен. Ә бухгалтер белә: ун миллион чыгарга тиеш. Ә ул өске рәткә карый: нәкъ бер миллион җитми. Өч көн, өч төн утыра бичара. Шуннан үзен-үзе бетерә. Дукәмиттә бер тиенне тапкач санныйлар: астагы рәттәге бер тиен өстәлгәч, аның өстендәге ун тиенгә, анысы тулгач, өстәгесе бер сумга, анысы тулгач өстәгесе ун сумга җыела. Шулай менеп киткәч — барысында да бер генә төймә җитми бит! — өскә төп-төгәл ун миллион чыга. Әмма инде егет харап булган була.

Ревизия әнә шулай бара. Яшь кызлар, әле генә финанс-кредит-учет техникумын тәмамлап кайткан кызлар Мәгыйзьгә сокланып карыйлар: нибары җиде класс белем һәм Лаешта үткән алты айлык курслар! Мәгыйзь исә чутлый бирә, сөйли бирә:

— Акча эше намус сорый торган эш. Намус дигән нәрсә иң беренче шушында кирәк. Бер бай булган: кибеттә эшләү өчен йомышчы малай эзли икән. Килә бер малай. Бай тегеңә ун тиен акча бирә дә, урам

читендә комда уйнап утырган бер сабыйны күрсәтә. Бар, ди, бу акчаны шуңа биреп кайт. Малай әйләнеп кайта.

— Бирдеңме?

— Бирдем, бай абзый.

— Акчаны нишләтте?

— Учына йомарлап калды.

— Ярый, бар, энекәш, кирәк булгач, мин сине үзем табармын.

Шулай ике-өч малайны сыный бу. Берсе әйтә, күлмәк эченә салды, икенчесе, комга куйды, ди. Ниһаять берсе әйтә:

— Авызына капты,— ди. Бай әнә шунысын эшкә ала.

Яшь кызлар авыз ачып тыңлыйлар. Кемдер электр плитәсе өстендәге ашка лавр яфрагы сала, кемдер чут сала — әбәд вакыты килеп җитә. Әбәд вакытында кибет мөдире бер шешә ак, ике шешә кызыл китереп куя. Әмма, Мәгыйзь «категорически» каршы тора.

— Ахырдан,— дип кырт кисә ул.— Дебет-кредитларың, сальдо-мальдоларың әйбәт чыкса — шунда гына,— ди.

Аш ашаганда тагын сөйли.

— Сәүдәгәр үзенә ышанычлы сатучыны ничек сайлый? Беренче көнне идәнгә юри бер тәңкә акча ташлый. Китәр алдыннан яшь приказчикка идән себерергә куша. Үзе чыгып китә. Кайтарып бирәме теге егет тапкан акчасын, юкмы? Әнә шуннан чыгып бәя бирелә.

...Ревизия тәмамланып, актларга кул куеп бетерелгәч Мәгыйзь нәкъ ике көн-төн (бер сәгать тә ял итмичә) күңел ача. Колан Кырдан район үзәгенә йомыш белән барган кешеләр аны күреп кайтып сөйлиләр: Мәгыйзь — чәйханәдә, алдында — шешә, янында — дуслары. Тагын хәбәр: Мәгыйзь — станция буфетында, алдында — шешә, янында — әллә кемнәр. Бишенче көнне Ахияр кушуы буенча аны бензовозга утыртып авылга алып кайталар, ул көнне Мәгыйзь идарәгә килми. Бу — елына уртача ике тапкыр була. Хәер, кайбер елны өч тапкыр да була. Мәгыйзь, финансист буларак, үз заемын үзе тикшерергә ярата. Таблица килгәнне өзелеп көтә. Таблица елына җиде тапкыр (алты төп, бер өстәмә тираж) килә. Облигацияне калай белән тышланган агач сандыкта (колхоз сейфы) саклый. Ара-тирә откалап куя. Аның облигацияләре бик күп, күпмегә кыстасалар, шуңа языла килде. Менә бер көнне «Мәгыйзь заем откан» дигән хәбәр тарала. Нигә гел Мәгыйзь? Нигә башка кеше откапы ишетелми? Мәгыйзь чамалый: гади халык — карт-карчык облигацияләрен бөтен еллыгын бергә чүпрәккә төреп тота. Таблица килгән дигән хәбәр чыгуга, шуны күтәреп финагент янына килә. Бәгъдә идарәнең бер бүлмәсендә үзе өчен биек барьерлы бер почмак эшләтте, карт-коры төргәкне аңа шул биек коймa артына бирә дә көтеп утыра. Бераздан төргәк кире чыга: юк, отмаган. Нәрсә отмаган, кайсы елгы заем, ничә сум облигация бар — колхозчы моны белми дә, уйлап та карамый. Тик күрәләр: Бәгъдәнең кыйммәтле әллә ничә мамык шәле, әллә ничә пальтосы бар, үзе ничә карасаң кибет тирәсендә, учлап акча тота, базар саен берәр сарык алып кайтып суя, шәһәр юлын да таптый, әллә нихикмәт ботинкалар, итекләр, күлмәкләр сатып алып кайта... Мәгыйзь моны белә һәм отышын алырга Ташлытауга үзе китә. Кайвакытта болай да була: егерме биш тәңкәлек отыш алырга барган җиреннән Мәгыйзь ике-өч көн кеше сыйлап әҗәткә кереп, кайта алмыйча ята. Андый вакытта район үзәгенә Ахияр үзе китә, бухгалтерны «сатып ала». Юлда Мәгыйзь сөйләшми, председательдән курка да, оялa да.

...Мәгыйзь диндар ата-ана кулында үсте. Әле ШКМда укыганда — утызынчы елларда да, әтисе-әнисе белән бергә ураза тота иде. Утызынчы елда Мәгыйзьгә инде уникe яшь, ул инде пионер, әмма ураза тота, гарәфә кичендә, гает көнне, мәүлет бәйрәмендә әтисе белән бер-

гә утырып, бөтен җиренә җиткереп тәһарәт ала, дога укый иде. Балалыгы аңа тик бер генә нәрсәгә комачау итте, авыл егетләре рамазан аеның соңгы кичендә манарага менеп «Әльвидагъ» әйтәләр, вак-төяк малайларны анда менгермиләр иде. Мәгыйзь рамазан аеның салкын кышка туры килгән моңсу-дини кичләрен, китап сүзләрен, сыйнфый көрәш, коллективлашу, кулакларны сөрү, налог, самообложение, культсбор, үзара салым, заем дигән төшенчәләр белән бергә буталган кичләрен хәтерли. Әти-әнисенең салкын тын кичтә манарадан ишетелгән «Әльвидагъ»ны тыңлап ишегалдында елап торганнарын хәтерли. Авыл ирләре, җиткән егетләр тигез хор белән, әллә ниткән кабер асты моңнары белән бөтен тирә-якны тетрәтеп күктән җырлыйлар иде.

Мәгыйзьләр буыны кызык хәлләр күреп үсте. Аларны пионерга алдылар, мәктәпкә быргы, барабан кайтты. Боларны күргәч тын буыла, күзгә яшь тыгыла иде. Болар — яңалык, мәһабәтлек, киләчәк тормышның матур бизәкләре иде, болар — маяк иде. Әмма укытучы апа дини ата-аналарга карата бик рәхимсез булып чыкты. Беренче дәрестә үк динне, алланы сүкте, йортта булган коръән, намазлык, гарәп хәрефле бөтен китапларны мәктәпкә алып килеп мичкә ташларга кушты. Сентябрь аенда ук зиратка ике тапкыр экскурсия оештырылды. Пионер отрядын стройга тезеп, флаг күтәреп, быргы кычкырттырып, барабан суктыртып зиратка алып барды, анда каберлек араларында үскән чәчәкләр, яфраклардан коллекция җыйдырды. Шунда Мәгыйзь һәм тагын берничә малай галстукларын салып кесәләренә тыктылар. Әмма юкка гына: укытучы апа аларны әти-әниләре белән бергә кичен кәнсәләргә чакыртты.

Ул кышны балалар мәчетнең алгы бүлмәсендә сәхнә ясап әллә ничә концерт куйдылар. Мәгыйзь гел «пирамида» дигән номерда катнаша, үзеннән бер яшькә олы таза Габдерәхим аның эченнән тотып өскә күтәрә дә, Мәгыйзь горизонталь хәлдә катып кала иде. Ул концертлардагы җырлар, декламацияләр әле хәтердә.

Җир казыйбыз, таш ватабыз
Эшче куллар!
Яңа тормыш кайнатабыз
Комсомоллар.
Безнең техника —
кулда чүкеч,
Бездә — зур көч.
Ясарбыз машина,
Менәрбез башына,
Җимерербез барсын да,
Тауны да, ташны да,
Көч белән сугарбыз,
Корычны бөгәрбез
Сукаларга ясарбыз тракторлар!

Әмма рамазан аенда уздырылган ул кичәләрдән кайткан балаларның күбесе төнлә торып әти-әнисе белән сәхәр ашый, уразага керә иде. Укытучы апа моны белә һәм иртәгесен дәресен өзеп, яралы юлбарыстай классны кырыштыра башлый иде. Шулай бер көнне Мәгыйзь дә эләкте.

— Яле, Хәмитев, авызыңны ач әле,— диде укытучы аның янына килеп. Мәгыйзь ул көнне соңга калып килгән иде, белмәде: аңарчы инде класста яңача ысул белән погром узган иде. Авызын ачты да куйды: тешләрен карый дип уйлады. Бу — гадәти хәл иде, «санпост» дигән укучылар иртән күлмәк якасыннан бет, бармак арасыннан корчаңгы, тырнак, колак тирәсеннән балчык эзлиләр иде — Мәгыйзь авызын ачты. Зәңгәр блузалы укытучы апа исә шап итеп учы белән Мәгыйзьнең авызын каплады. Каушап калган малай аңлады: авызының иң төбенә укытучы апа ипи кисәге ыргыткан иде, малай тиз айныды, партаны шы-

гырдатып торып басты, укытучының кулыннан шуып чыкты, ипине учына кире чыгарды да, класс идәненә тәкеренде. Ураза кануннары таләп иткәнчә, ризык тәме үңәчкә үтәргә тиеш түгел иде. Аннан сүзсез, рәхимсез, ямьсез көрәш башланды. Укытучы апа кемнәрнедер ярдәмгә чакырды. Мәгыйзьне идәнгә егып салдылар, авызын ике яктан каты бармаклар белән кысып ачтылар, кемнендер җылы уч төбеннән хуш исле ипи уалчыкларын тамак төбенә койдылар, аны йотканчы башын як-якка селкеттеләр, малай тончыкты, йотты, шуннан соң аны ычкындырдылар. Шулай берничә малай-кызны, шулай ураза ае беткәнче...

Ахырдан мондый бәрелешүләр врачлар белән дә булды. Мәктәпкә ак халатлы апалар килеп йөри торган булды, авыз эчен, колак тишеген, күз төпләрен тикшерәләр, ялангач күкрәккә дөп-дөп итеп ике бармак белән сугып карыйлар. Кызлар ояла: ямаулы, сидрәгән зәңгәр ыштаннарын малайларга күрсәтәселәре килми, ә укытучы апа — усал. Ак халатлы апалар әллә ниткән сүзләр белән фикер алышалар, «коньюктивит», «трахома», «чесотка», «дистрофия» дигән булалар, әмма барысына да бер генә дару тәкъдим итәләр:

— Күкәй, май, сөт...

Алар киткәч атна буе малай-шалай тәнәфестә гөрли:

— Күкәй, май, сөт...

Ә җайвакытта ак халатлы апалар килеп беләккә җәрәхәт ясыйлар— Мәгыйзьләр анысында инде нишләсен яхшы беләләр: ак халатлыападан ычкынуга йөгереп чыгасың да беләк җәрәхәтен кан чыкканчы суырасың! Бу бәладан бөтен бала-чага шулай котыла иде...

Ахырдан күпмедер еллар үткәч Мәгыйзь-солдатның тәнең госпитальләрдә шыгырдатып кистеләр, пычкы-өтергә белән, чүкеч белән балтыр сөякләрен ялгадылар, ямадылар, ләкин теге чактагы беләк суырулар, уколдан качып сыер абзарындагы тагарак асларында ярты-шар көн ятулар истән чыкмады.

Мәгыйзьгә инде быел пенсия яше килеп җитте, ул инде пенсиягә чыгып, өендә утырып колхоз тарихын яза башламакчы иде. Тик председатель Ахияр катгый әйтте:

— Пенсиягә,— диде,— икебез бер көнне. Синнән башка мин нишлим? Синнән башка мин кем? Үзең уйлап кара...

Мәгыйзь уйлап карады да — риза булды. Югыйсә, бу көн — архив кәгазьләрен өстәлгә җәеп салып колхоз тарихын яза башлау көнен — ул күптән, бик күптән көтә иде. Инде бик картайган, күзләре күрмәс булган әнисе Вагыйзәттәй исә, моны ишеткәч, әйтә куйды:

— Кадерең барда кадерлән,— диде,— кадерең беткәч — кабереңә әзерлән.

Мәгыйзь ниндидер эчке зур ләззәт, рухи бөтенлек белән диванга утырды: өйдәгеләрнең барысы да диярлек җыелган, өстәлгә аш килгән, озын чәчле егет (өченче малай) дыкыр-дыкыр китереп телевизорны көйли, анда кайсыдыр программада — Казаннанмы, Мәскәүдәнме — «Освобождение» дигән фильмның беренче сериясе башланачак иде. Мәгыйзь бу фильмны ике-өч тапкыр караган һәм кайбер урыннарын күңелдән дә белә, шулай да һәрвакыт күңеле янарып, яшьлегенә кире кайтып ала иде.

## XIII

Ахияр килеп кергәндә Нәчтүк әби иске күзлеген киеп ниндидер бер таушалган калын дәфтәр актарып утыра иде. Нәчтүк әби чит кеше килеп кергәнне сиздеме, юкмы, әллә юри шулай белмәмешкә салыштымы, дәфтәргә карамыйча гына укып китте. Дөресе — җырлады:

— Минем Ибаным бу дөньяда иң акыллы бала иде; ул шул кадәр

акыллы иде, кечкенә вакытында җокларга җаткырыр алдыннан, мин аннан сорый идем: матурым, Ибаным, иртәгә җаңгыр җавармы, җукмы, дип сорый идем; шул сорауга, җөрәгем минем, Ибаным минем, болай дип җавап бирер иде; син, әни, җаңгыр җавармы, җукмы дип сорыйсың; мин әни болай әйтәм: я җавар, я җук... Икенче көнне, җөрәгем минем, нәкъ ул әйткәнчә булып чыга иде. Иа, җазмыш бәндәләреңне бу афәттән коткар, безнең җиребезгә җаңгыр бир, безнекенә генә түгел, күрше калхузларының да басуына җаңгыр бир...

Ахияр тирләгән маңгаен сөртеп урындыкка утырды. Өйдә салкынча, ярым караңгы, куркыныч та иде. Ничектер, якында гына үлем кебек тоелды. Нәчтүк карчык исә бу бүлмәдә һаман да ялгызы гына яшәде, көтмәгәндә килеп кергән олы гәүдәле ирне байтак вакыт күрмәмешкә салышты.

— Ә-ә, Әрәпи малае,— диде ул, күтәрелеп карагач, бер дә гаҗәпләнмичә.— Эчең пошамы? Игеннәр янамы? Янар шул... Кодай каршында гөнаһларыгыз күп шул.

Ахияр — райком әгъзасы — Нәчтүк әби янында утыра. Ник килде ул бу авылга? Митрий янынамы? Юк, Митрий белән алар бүген басуда очраштылар. Митрий кояшта янган, кипкән, авызы казныкы кебек ачык, ирен төпләре ак, битләре кубалакланган иде. Юк, Ахияр аның янына килмәде. Шулай булгач? Кемгә, нигә? Әллә узышлый болай гынамы, җанына урын тапмагангамы? Кем белсен?

— Минем Ибаным белән бер яшьтә идең бит син,— дип тезеп китте карчык, почмаклары таушалган калын дәфтәрне ябып.— Син кайттың, ул — кайтмады. Мин синең кайчан, ничек кайтканыңны белдем. Сез бит бер көнне киттегез сугышка. Ташлытау военкоматына мин Ибанны озата бардым. Мин бит сезне күрдем, мин барында сыра эчтегез. Дурт шешә сыра алдыгыз. Ибан, син, авылдашың Кәшфи, Колан Кырдан Гыйльфан. Мин күреп тордым, акчаны тракторист Кәшфи түләде. Аннан үксеп-үксеп елады. Ә сез тәмәке кабыздыгыз. Ә минеке — Ибаным гел көлеп торды. Мин барында тартмый иде ул. Бездә, керәшеннәрдә, ана хакы — таңре хакы. Сездә дә шулайдыр ул. Менә сез кайттыгыз, минеке — ятып калды. Безгә сугыштан соң кайсыгыз килде? Я әйт, кайсыгыз Ибан анасының, атасының хәлен белде? Синең бу нигезгә беренче тапкыр аяк басуыңмы? Мин бит барысын да беләм. Нигә тынгылык тапмыйсыз сез бу тормышта? Сез бит кайттыгыз, сез бит барыгыз да эш кешеләре. Сезне начар кеше дип кем әйтер? Ә тормышыгызда тынгылык юк. Кәшфи — төн йокламый. Бөтен хөкүмәткә билгеле кеше. Гыйльфаныгыз — ниләр генә күрмәде. Төн йокылары юк. Бөтен илгә данлыклы кеше. Ә син — шушы якның иң зур кешесе. Бармы синең бер төн тоташ йоклаганың? Нигә алай?

Карчык күзлеген күтәреп күзләрен бармак өсте белән сөртеп алды, тагын төшерде. Авыр сулады.

— Ә минем Ибаным, җөрәгем минем, тыныч йоклый. Ул тыныч йоклый. Аның каберс Мәскәүдән илле ике чакрымда. Ул борчылмый... Ә син... Их, сезне...

Ахиярның тамагы кибеп китте, Нәчтүк әби кызларча җинел торып аның алдына самавыр китереп утыртты, җитез хәрәкәт белән штепселен бүрәнәдәге розеткага кертте.

— Ни бит, Нәчтүк әби... Дөнья куабыз бит. Мин Иванны хәтерлим, ләкин сине — юк. Мин ничә еллар буе сине ул Иванның әнисе дип тә белми йөрдем. Дөнья авыр бит. Белгәнемә әле нибары ике ел. Митрий сөйләде. Менә син бу корылыкны безнең начарлыктан дисең... Бүген мин Иванны искә алып синең янга кердем.— Ул пиджак кесәсеннән бер пачка һинд чәе алып куйды.

— Шулай, шулай...

— Көн-төн колхоз өчен йөгереп йөрим. Мин нинди әшәке булыйм?

Әгәр колхоз амбарыннан законсыз рәвештә бер кило бодай, ярты кило ит алган булсам — мине менә хәзер шунда җир йотсын! Ипи белән, кояш белән ант итәм! Партия билетым белән ант итәм!

— Син алай тиз генә ант итмә,— диде карчык.— Минем Ибаным беренче хатында язды: әти, әни диген, инде ант кабул иттек, анда әйтелгән, диген, әгәренки мин илемә хыянәт итсәм, мине халкымның каһәре суксын, диген. Бу, диген, кеше гомерендә бер генә тапкыр була. Антны бер генә тапкыр бирәләр, диген.

Ахиярның маңгай җыерчыклары тирәнәйде.

— Нәчтүк әби! Мин дә бит кан коеп кайттым. Теге антны мин дә бит Иван белән бергә бирдем. Минем гөнаһ нәрсәдә соң? Мин — намуссыз сугышчымыни инде?

— Син сугышчы буларак намуслыдыр, анысына әйбер әйтер хәлем юк. Ә монда ниләр эшләдең? Колхоз дип кенә булмый ул. Ә монда?

Ахияр сүзнең кая таба киреп киткәнен аңышмаган көе сорап куйды:

— Ник мин монда нишләгән ул хәтле? Эчеп, азып-тузып йөргәнме? Кеше семьясын бозганмы?

Нәчтүк карчык явыз елмайды:

— Һи-и-и...— Ул тамагын кырды.— Монда иркен болынга эләктең инде син. Дүрт авыл — синеке. Яшь, таза. Гәүдәле. Күпме тол хатын.— Әбинең тавышы кырысланды.— Ә үзеңнекен ник рәнҗеттең? Ник айрым яшисең? Ник хатының килеп торып карый да, яңадан китә? Теге бырач кызны ник юлдан җаздырдың? Бөтен халык белеп торды. Катерина кызы Уляны ник үзеңә караттың? Үзеңнән җегерме яшькә кечене? Менә син иркендә йөреп шулай булдың. Күңел — дәрья, күз — марҗа, диләр. Синең тирәдә йөргән берәү дә бәхетле булмады. Менә ник җаумый ул җаңгыр...

— Ни бит, Нәчтүк әби... Кырык җиденче елны да шул хәл иде бит. Мин районда, семьям — бөтен, бер гөнаһым юк. Ул вакытта кем көйдерде соң дөньяны?

Карчык монда да югалып калмады.

— Халыкка ул елны да кеше рәнҗеше төште. Ишеткәнсеңдер? Безнең укытучы Афанасий срогын тутырып авылга кайтышы иде. Ни өчен ун ел читтә йөргән ул, аны шайтан да белмәде. Кырык җиденче елның апрель числосы иде, яз кисәк килде. Үзәннәр бүртте. Бер хәбәрсез кайтып төште. Утыз җиденең декабрь аенда, декабрьның унтугызы төнендә юкка чыккан иде. Әнә шул кеше сезнең Колан Кыр үзәнен чыга алмый кар-боз өстендә йөргән. Сезнең авыллар күргән бит аны каланча башыннан! Әйткәннәр бит, берәү үзән буенда йөри дип! Ник бармаганнар алар шунда? Үземә килеп әйткән булсалар, кодай белән ант итеп әйтәм, таяк тотып шунда киткән булыр идем. Афанасий шунда кырда, язгы төндә ялгыз калган. Иртәгесен аның каткан мәетен алып кайттылар. Шул елны ничек сиңа яңгыр булсын? Кодай ник каһәрләмәсен бәндәләрен?

Карчык Ахияр алдына чәй чынаягын этәрде.

— Әле,— диде,— киләсе җәйгә дә бик ышанмагыз. Бәндәләрнең явызлануы шул хәтлегә җитте, әнә безнең авылда ниләр булды: кайнанаңың чәенә «дуст» дигән агу салып эчерделәр. Килен амбарда эшли, агу — үз кулында... Менә күрерсез: киләсе җәйдә бер көне җәй, бер көне кыш булыр. Безнең Афанасий әйтерие: ни күп — тиле күп; ни туа— тиле туа. Шул карчыкны карап җай гына яшәсәләр булмаганмы? Баедылар шул, катын амбарда булгач. Икесе дә нинди җүк җирдән чыккан кешеләр. Малай гомере буе чабатадан арынмады. Менәтерәк колхоз берсен амбарга куйды, икенчесен такта яруга старший итеп. Доход зур. Әни — артык. Борынгылар әйткән: ярлы баемасын, исерек айнымасын. Кайвакытта әнә шундый мәкаль дә туры килеп куя.

мәңгелек яз ◆ Мөхәммәт Мәһдиев ◆

...Нәчтүк әбинең йортыннан Ахияр газаплы хисләр белән чыгып китте. Баш түбәсен ак кояш кайната, көйдерә, дөнья үле, бөтен урамга кояш эсселегендә кызган такта, шифер исе таралган, кемнеңдер ачык тәрәзәсеннән радио концерты ишетелеп тора иде. Ахиярга бервакыт Митрий сөйләгән иде: керәшеннәр үз халкыннан чыккан талантлар белән башка бер халык та булдыра алмаганча горурлана беләләр. Бүген — ял көне — төш вакыты концерты икән. Һәм урамнан ялгыз барганда Ахияр күрде: күп кешенең тәрәзәсе ачык, радио актык көченә кадәр куелган. Анда керәшеннәрнең горурлыгы булган җырчы Анфиса тавышы.

Суда, суда, суда йөзаласыңмы?..

Ак кояш каш өстеннән кереп баш миен кайната, күз алмаларын сызлата иде. Суда йөзә аласыңмы, имеш... Елгалар кипте бит инде! Ах, Анфиса, нигә бу көнне шул җырны җырлыйсың? Менә гастрольгә кайтмассыңмы әле... Митрийгә әйтеп...

## XIV

Партком секретаре Рәиф Шәймиев авырлык белән үсте. Шуңадырмы — властьлы, каты куллы Ахияр Гарәфиев белән уртак телне тиз таптылар. Райкомнан аны бу урынга тәкъдим иткәндә әйттеләр: Гарәфиевнең дәрәҗә бик зур, син яшь кеше, менә синең партшколада алган белемең шунда сыналачак. Килешеп эшли алырсызмы? Уртак тел таба алырсызмы? Әллә председатель күзенә карап тора торган йомышчы бер малай булырсыңмы? Кайбер председательләр шундыйны яраталар...

Ләкин председатель белән партком секретаре уртак тел турында уйлап та тормадылар: эшне алга алып барырга кирәк иде. Тагын бер мәсьәлә боларны якынайтты: Рәифнең гаилә тормышы авыр, Ахиярныкыннан да авыррак иде. Ахиярның нәрсә? Хатыны шәһәрдә яши, квартирасы бар, малай авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап шушы якка кайтырга тиеш, кыз — медицинскийда укый. Хатын авылны яратмады, нихәл итәсең? Кайта—китә. Ахияр шәһәргә барган саен аларга авыл күчтәнәче алып бара: ит, суган, кәбестә, авыл каймагы, күл балыгы... Хатын белән талашмыйлар, сугышмыйлар, үпкә сүзе әйтешмиләр. Бик гади: мәхәббәт юк. Юк, вәссәлам! Моны икесе дә беләләр, моны балалар да белә — ни хәл итәсең? Кала бер генә чара — үзара тыныч яшәү. Дөрес, Сольма ханым балаларын әтиләренә каршы тәрбияләмәде, балалар әтиләренә карата бик үк кайнар булмаса да, шактый җылы ярату хисләре саклап үстеләр.

Рәифнең исә — бөтенләй башкача. Анықын сөйләсәң — сөйләп, язсаң — язып бетерә торган түгел. Үзара сөйләшкәндә карчык-коры да, боларга барып җиткәч, сүзне кыскарту ягын карый:

— Әйтмә дә, Хәмит, сөйләмә дә Сәгыйть,— дип кенә сүзне түгәрәкләп куялар.

Рәифнең бу дөньядагы бөтен күргәне — мәшәкате, ихтимал, әнә шул — Ахияр гаиләсендә җитмәгән мәхәббәт аркасында булгандыр. Ике кешедән корылган гаиләгә табигать тарафыннан йөз процент мәхәббәт бирелә. Хисапчы Мәгыйзь әнә шулай аңлата. Әнә шул йөз процент мәхәббәт гаиләдә төрле пропорциядә бүленә. Әлбәттә, идеаль варианты — иллегә илле. Ләкин тормышта алай төгәл бүленеш була алмый. Алтмышка кырык, җитмешкә утыз, хәтта туксанга ун белән яшәп ятучылар теләсәң никадәр. Әмма тагын бер ягы бар, ди Мәгыйзь. Процентның зур өлеше хатын-кыз ягында булса, ул гаилә ныграк була. Чурт с ним, ди Мәгыйзь, алтмышка кырык булсын, ләкин теге алтмыш хатын ягында булсын... Киресенчә булганда яшәве, тормыш итүе авыр, бик авыр, имеш. Мәгыйзь кызган баштан Рәифкә дә исәплап бирде

бервакыт: синең, диде, туксан да ун чыга, туксаны синеке, унысы — теге йомрынықы (Дания бик тулы тәнле, мул күкрәкле, матур муенлы, җирдә ышаныч белән басып торучы таза аяклы, калын коңгырт толымлы иде). Ие, теге йомры унны гына бирә — Мәгыйзь чалт итеп чут төймәсен салды, төпчеген ысылдатып суырды.— Сиңа авыр булыр, ну, зату, бу тирәдәге иң матур хатынны кочаклап ятасың. Кешеләр шуны бер сыпырып кararга әллә ни бирерләр иде, ә син — бисплат! — көн саен шуны кочаклап ятасың. Менә баланс шулай чыга! — Мәгыйзь чут төймәсен чалтыратып кире кайтарды.— Балта осталары йортны ничек тигез бурый? Һечкә башка юан башны саласың да, бура тип-тигез күтәрелә. Менә семья тормышы да шулай, энекәш...

...Рәиф яшьтәшләре кебек үк ятим үсте, әтисез калган балалар авылда байтак иде. Әмма балачакта бер рәнҗеш күрде: әтисенең хәбәре туктагач, Колан Кырга районнан бер иптәш килде һәм боларның нәсел-нәсәбен тикшерде. Авыр, шомлы булды. Рәиф шул көннәрдә әнисенең башында ак чәчләр күрде. Әнисенә авыр сүз әйткәләүчеләр дә табылды: финагент Бәгъдә белән председатель Сәкинә аның әнисен еш елаттылар. Малай боларның барысын да авыр кичерде, йөрәгенә кан укмашты. Кырык дүртенче елның июнендә Рәиф җиденче классны тәмамлады. Таныклык бирергә «тантаналы җыелышка» чакырдылар. Җәйнең менә дигән бал кортлы, бөҗәкле, сандугачлы, яфраклы бер көне иде. Әгәр термометр дигән әйбер булса, һичшиксез, утызны бирер иде. Тантана мәктәп бакчасында быргылар кычкыртып, барабаннар кагып алып барылды. Малайлар, кызлар чирәмгә аяк бөкләп утырганнар, барысы да шатланасы урынга җитдиләнеп калганнар иде. Бу таныклыкны алгач нишлисе? Кая барырга? Әле мәктәптә вакытта, ичмаса, барысы да билгеле иде: иртән укырга киләсең, озын тәнәфестә — мәктәп подвалында кабыклы бәрәңге белән пешерелгән бер савыт умач бирәләр, хәл кереп китә. Рәиф үзенең гел «биш»тән генә торган таныклыгын һәм Мактау кәгазен алырга чыкканда язмышыннан оялды: күлмәге юклыктан өстенә иске бишмәт киеп куйган иде. Хихылдап, мыскыл итмичә, рәнҗетмичә генә көлеп алучылар булды. Рәифнең сөялле ябык кулын кыстылар, кояш эссесендә барабан, быргы тавышы ишетелде. Җыелыш беткәндә генә директор белдерү ясады: җидене бетергән малайларга иртәгә сәгать сигездә военкоматта булырга. Сугыш булмаса, бу көннәрдә район үзәгендә сабантуй үткәрелер иде. Иртәгә шуның урынына район буенча хәрби кросс икән...

Ташлытаудан унбиш чакрым ераклыктагы урманда военкомат көне буе хәрби кросс уздырды. Утыз, егерме тугыз, егерме сигез, егерме җиденче елгылар белән. Соңгыларының инде армиягә китәр вакыты җиткән иде. Көне буе кояш астында йөгереп, шуышып иза чиккән малайларны кич кенә стройга тезеп Ташлытауга алып кайттылар. Кем кайда — берәүләр туганнарында, берәүләр вокзал идәнендә кунарга калдылар. Рәифләрнең Ташлытауда беркеме дә юк иде, ул үзеннән өч яшькә өлкән Сәйяфкә иярде. Капчык төпләре буш, алабута күмәчләре ашалып беткән иде. Сәйяф озак уйлап тормады, тыкрыкларның берсенә абзардан чыгарып өелгән, өсте кипкән тирескә барып ятайды. Тирес җылы иде, бераздан Рәиф тә шунда урнашты, тегене-моны сөйләшеп утыра торгач, төн дә җитте. Егетләр ничек йокыга киткәннәрен дә сизми калдылар. Озак, тәмле йокланган. Кояш кыздыра башлагач кына аслы-өсле пешеп уянып киттеләр. Йокы туйганлыкны раслап сөякләр шартлаганчы киерелеп алдылар, тик бер-берсенә карагач кына сәерсенеп киттеләр: Сәйяфнең аскы ирене бияләй кадәр булган, болай да куәтле борыны тукмак кебек зураеп калыккан иде. Рәиф тә бер күз кабагын күтәрә алмый азапланды: балтырны талый торган сукыр черки кичтән үк шактый борчыган иде шул... Ашказанында бөртек ризык юк. Җәяүле, эссе тузанлы егерме чакрымлы юлга чыктылар. Рәиф

җыйнак гәүдәле бер малай иде, юл буендагы сыек арыш башакларын уып капкалады, башак та әле сөт кенә иде, аннан бер-ике урында кузгалак очрады. Әмма эре сөякле Сәйяф азап чикте дә инде... Бераздан Поникка килеп керделәр. Сәйяф җанланып китте: Поникта аларның якын туганы финагент Бәгъдә яши иде, һәм сугыш елларында «Бәгъдәләр ипи сала» дигән шаккатыргыч, кеше шикләнеп тә, сокланып та, дәһшәт катыш курку белән кабул итә торган бер хәбәр йөри иде. «Бәгъдәләр бал белән май эчендә йөзәләр»,— дигәнне дә Рәиф еш ишетеп үсте. Ул аны нәкъ шулай күз алдына китерә иде: Бәгъдә зур бер ишегалдында портфелен өскә чыгарып сыңар кул белән ишеп йөзә, ә йөзгәне — яңа суырткан бал күле, күл өстендә йомарлам-йомарлам май кисәкләре бар...

— Киттек, Бәгъдә апаларга,— диде Сәйяф, авырайган аскы иренен ялап.— Бер бөтен ипиләрен урлап булса да ашыйм... Чукынып үлсәм үләм...

Рәиф киртә буендагы куе чирәмлеккә лып итеп барып утырды.

— Мин... кермим...— диде. Кипкән иреннәрен ул да ялап алды. Бәгъдәләрнең өе моннан ике бакча аркылы гына күренеп тора, һәм июньнең эссе күгенә морҗаларыннан сыек кына төтен күтәрелә иде.

— Ник? Дурак? — Сәйяф бияләй иренен күтәреп яба алмый азапланды.

— Син кер. Мин монда көтеп торам. Бар, кер...

Сәйяф, ачлыктан малайның акылына зыян килгән икән дип белеп, авыр атлап теге йортка таба китте. Әмма Рәифнең акылы бик-бик ачык иде ул вакытта...

...Кырык өченче елның май бәйрәме бик былчырак вакытка туры килде. Урамда адәм аякланмаслык, өстән кар катыш яңгыр ява, яз буе ләйсән күренмәде, өшегән балчык һаман шул черексез көе изелеп ятты. Салкын, карлы былчыракны күгәрчен тәпие кебек алсуланган аяклары белән изеп, Рәиф мәктәпкә барды. Дәресләр булмаса да, бәйрәм көн итеп берәр савыт умачлы аш биреләчәк иде. Аяк инде карлы былчыракны тоймый ук башлаган иде. Шунда мәктәп белән идарә арасында аңа ике хатын очрады. Аякларында бик һәйбәт резин итекләр, өсләрендә кыек кисә кырыйларына күн тасма куеп тегелгән өр-яңа зәңгәр телогрейка, башларында затлы мамык шәл. Битләре пәрәмәч булып ялтырап тора, туклык, күңел бөтенлеге, бәйрәм кәефе әллә каян сизелеп, тышка бәреп тора иде. Шунда берсе юл пычрагын яланаяк изеп мәктәпкә таба атлаган сәләмә киемле Рәифне күреп, ихахайлап көлде:

— И-и, кара инде моны, бер савыт умачлы аш ашар өчен ни тикле җәфа чигә бит,— диде.

Икенчесе көлмәде, малайга нәфрәт белән карап алды да, калын тавыш чыгарып әйтте:

— Әтисенең теге якка чыкканы дөрес булса, аңа әле бер савыт аш та бирерлек түгел,— диде.

Ихахайлап көлгәне финагент Бәгъдә, монысы — Сәкинә иде.

Малайның йөрәгенә кан урнашты. Шул көннән соң ай үттеме-юкмы, әтисеннән хат килде: чолганыштан чыктык, исән кайтсам, гомер буе сөйләп бетерерлек түгел мин күргәнне, дип язган иде. Әмма шатлык бик кыска гомерле булды: кырык өченче елның көзендә ике көн эчендә Рәифләргә ике хәрби хат килде. Беренчесе — әнисе, Рәиф исеменә, әтисенең командирларынан мактау хаты иде. «Сез үзегезнең ирегез, әтиегез белән горурлана аласыз. Безнең батальонда ул иң батыр сугышчыларның берсе...» Икенче көнне исә кыска хат, әнисе исеменә: «Сезнең ирегез Ватан өчен көрәштә геройларча һәлак булды».

...Рәиф Поник авылы читендәге киртә буенда ярты сәгатьләп утырды. Менә йомшак җил исеп куйды, ул җил Бәгъдәләр морҗасыннан

чыккан төтен белән майлы таба ризыгы исен бу якка алып килде дә Рәифнең башын әйләндерде, күз алларын томалады. Таба ипие исе! Ипи пешергәндә ачы камырдан майлы табага салып башта шундый көлчә пешереп алалар иде! Рәифнең күзләрен яшь басты, берничә секундка ул аңын җуйган сыман булды. Әллә кирәргә кирәк булдымы икән? Ә? Әллә кереп түйганчы ашарга кирәк булдымы икән? Ә? Мин кем? Бу кайсы авыл? Мин нигә монда утырам әле?

Малай, чыннан да, саташа башлаган иде.

Сәйяф күзен тәгәрәтеп киртә буенда аңсыз яткан малайның авызын каерып кайнар таба ипие тыкты. Үзе сөйләнде:

— Керүгә берсен бөкләп кесәгә тыктым. Тукта, мәйтәм, бу малай тәпиен суза бит...

Рәиф берни аңламаган көе кайнар ризыкны чәйнәмичә генә йотты.

Менә берчак Рәиф тә үсеп җитте. Еллар рәтләнә башлады, авыр иде, налоглы, Бәгъдәле-Сәкинәле еллар иде, әмма алабута күмәче, кычыткан ашыннан инде арынылган иде. Рәифнең солдатка каралыр көне җитте. Тәтештә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап кайткан елда ул комиссиягә йөри башлады. Һәм шул елны... гашыйк та булды. Үзеннән байтак яшь — әле сигезенчедә генә укып йөргән шомырт кара күзле, калын толымлы Дания исемле кызга. Сәкинәнең каяндыр балалыкка алып кайтып үстергән кызына... Дания мут иде, кыю иде. Аның артыннан, ул әле алтынчыда укыганда ук яшүсмерләр чаптылар: капкакойма тирәсендә җәйге төннәрдә гел малай-шалай шаярышты. Дания берәүгә дә авыр сүз әйтмәде. Якын да җибәрмәде. Рәиф ул вакытта Тәтештә укуда, Дания аның күңеленә ике кереп бер дә чыкканы юк иде әле...

Кайтты Рәиф техникум таныклыгы белән, чыкты кич йөрергә, ничектер барып чыкты. Сәкинәләр тыкрыгына. Ниндидер бер кич иде ул, нәрсәдер эшлисе килә, өйгә кайтмыйча төне буе йөрисе килә иде. Сәкинәләр тыкрыгындагы яшьләр дә шулайрак уйлыйлар иде булса кирәк, кичке караңгылыкта, күз күрмәсә дә туп уйныйлар, уртага басып туп алып торучысы калку гәүдәле, хәрәкәтчән кыз Дания икән. Рәиф бу уенга катнашмады, Дания тирәсендә болай да бөтен егет-малай бөтерелә иде. Төн уртасына таба авышкач, урыс капканы шыңгырдатып ачып Сәкинә чыгып кычкырды:

— Хәзер үк таралыгыз, бу нинди бака туе? — диде.— Дания, кер әйдә...

Әмма, кызына карата әйтелгәне йомшаграк чыкты, уен дәвам итте. Яшьлек председатель сүзеннән курыкмый икән. Төнге уникеләр узганда да чыркылдау, көлешү дәвам итте. Таза урыс капка тагын зыңгылдап ачылды.

— Бу нинди безобразие, понимаетели? Дания, кер йокларга, чисти мәче тулгагы ясадыгыз, бит...

Бу юлы уен тынды. Егетләр игътибарыннан бәхете ташыган Дания шул вакытта гына тыйнак басып торган Рәифне күреп алды. Аның үзенә эндәшмәгәнен, игътибар сорамаганын, янында бөтерелмәгәнен гафу итә алмады, чыркылдап көлеп тупны бөтен көченә аның битенә бәрде дә, йөгереп кереп тә китте. Рәифнең таныклык алып кайтуы, егет булып җитүенең шатлыгы шуның белән бетте. Егет өчен газаплы көннәр башланды...

Шулай да июнь аеның иң кыска бер төнендә кичке уеннан кайтышлый ул бер кыю хәрәкәт ясады. Аны Сәйяф гел әйтә иде:

— Кызлар янында никадәр кыю булсаң, шул кадәр җиңел... Син не думай. Алар фәрештә булып кыланалар гына. Ә...

— Ә нахал дип уйласалар? — Рәиф шуннан курка иде.

Сәйяф көлде. Андый сүз вакытында гел көлде.

— Юл-ләр... Уйласыннар! Нахальный булсаң, кызлар арасында дәрәҗәң генә арта...

Рәиф алай ук нахал була алмый иде, әмма шул төнне Сәйяф теориясен эшкә җикте: кыз белән бергә атлап кайтты да, кызый шәп капканың keләсен басам гына дигәндә, кулын капкага аркылы салды. Йөрәге дөп-дөп итте. Әмма юкка гына! Кыз, берсүзсез, калды куйды! Теориянең кайбер пунктлары белән мең яшә, Сәйяр! (Сәйяр үзе бу вакытта армиядә хезмәт итә иде.)

Аннан кыскача гына аңлашу булды. Аннан бакча эченә кереп утырулар булды. Әтәч икенчеме, өченчеме тапкыр кычкырды. Рәиф белән Дания суган түтәленең ике ягына әрекмән җәеп кара-каршы утырдылар. Күп сүз сөйләнде. Дания унынчыны тәмамлаган, гәүдәсе тулган, авыр чәч толымын кая куярга белми, лас-лос шуны әйләндереп сала, хәер, чәч толымын гына түгел, алга ыргылган мул, куәтле күкрәкләрен дә, гомумән, үзен дә кая куярга белми иде.

Бераздан ул озын суган кыягын өзеп алды да авызына капты. Икенче очын мут елмаеп Рәифкә каптырды. Аннан акрынлап суган кыягын авызына бөтәрли башлады. Рәиф тә шулай итте. Түтәл бик тар иде, күп тә үтми, мәшәкатьсез генә бер-берсенә якынлаштылар. Рәхәт, бик рәхәт булып китте суганны уртак ашау.

Рәифнең берөзлексез тамак төбе кипте, башы әйләнде. Шундый рәхәт, ләззәтле әйләнә иде ул баш!

Кояш чыгар алдыннан гына айнысылар: түтәлнең бер квадрат метр җирендә кара балчык кына калган иде!

...Рәиф температура белән нәкъ ике тәүлек ятты. Аның авыз эчләре, иреннәре туналып беткән иде. Нормадан артканда һәр ризыкның зыянлы икәнен ул белә иде. Бераз җиңеләйгәч, чәй эчергәндә әнисе рәнҗеп болай диде:

— И, улым, улым! Шул Сәкинәне кодагый итеп түремдә утыртыйммы инде мин? Атаңның сөякләре рәнҗер...

Рәифкә бик тә, бик тә авыр иде.

Аннан солдат тормышы башланды. Дания хатны сирәк язды, күңеле һаман алак-шалак булды. Рәифкә исә хатлар дус-ишләреннән күбрәк килде. Барысы да бер нәрсә тукыдылар: Дания сине көтеп ятучылардан түгел, тегенең белән дә, моның белән дә йөри. Солдат ут йотып нәкъ дүрт ел хезмәт итте. Уртада бер тапкыр кыска гына ялга да кайтты, әмма, алдан сөйләшенгән булса да, Данияне очрата алмады. Рәифнең әнисе моңа шат булды, ләкин солдат шатланмады. Дания, юри иткәндәй, шул көннәрдә генә Урта Азиягә, үзенең кардәшләренә кунакка киткән иде. Рәиф ул эшли торган мәктәп ишегалларында озак йөрде, җәйге каникул вакыты иде. Аны күзәттеләр, берәүләр кызганды, икенчеләр авыз ерды. Солдат шул көе китеп барды.

Ә бераздан хәбәр килде: Дания бала тапкан. Сәп-сәламәт кыз бала. Әтисен дә әйттеләр: Сәйяф. Кайткан хезмәт итеп, күкрәгендә бер медаль, әллә ни тикле значок ди, бөтен авылны таңга калдырып, идарә алдында җигүле атны ал яктан кереп күтәреп күрсәткән, ике потлы герне бөтен кеше карап торганда сигез тапкыр күтәргән, бәхәсләшеп ике яртыны бер юлы эчеп бетергән һәм тагын әллә ниләр... Буе метр да туксан булган кешегә, имеш, армиядә ике порция ашаталар... Сәйяф беренче кичтә үк клуб янындагы олайган яшьтәш кызлары арасыннан бер йомры яшьне тотып алган. Бөтен кеше карап калган, уйлаганнар, әйткәннәр: ну, бу кызый сикеренгәләп караган иде, әләкте дә соң инде... Яшь бит әле бу!

Рәиф хезмәтен тутырып кайтканда, Дания бала үстереп килүче яшь бер хатын иде. Мәктәптә пионервожатый, тагын ярты штатка хисапчы, имеш.

Алар беренче көнне үк авыл советы янындагы ат бәйли торган урында очрашып күрештеләр. Өлкән сержант погоннары таккан юаш Рәиф сүзне кыска тотты:

— Бер түгел, биш балаң булса да, мин сине алам, синнән башка миңа берәү дә кирәк түгел,— диде.

Дания чын күңелдән елап җибәрде һәм өенә таба йөгерде.

Озак та үтмичә Сәкинәләр өенә ыштанының бер балагын чыгарып, таягы белән сөйләшә-сөйләшә Камиләтти килеп керде.

— Әйдәле, әйдәле, Камиләне шушы гөнаһлы баланы бәхетле итәргә алып бар әле... Әйдәле, теге май бәйрәмен апрельдә уздырган бәхетсезне бер юньле бәндәгә сылап куйыйк әле. Әйдәле, кыз бала умырзая кебек инде ул, иртә шытып чыга, иртә шиңә. Әйдәле, ходайның бер юньле бәндәсенә сылап карыйк әле шуны. Савaплы эш эшлик әле...

Берничә көннән Рәифнең әнисе түр башына утыртып Сәкинә кодагыйга хөрмәт күрсәтте. Сәкинәнең таләбе буенча түр башына, аның кырына, финагент Бәгъдә дә утыртылган иде. Ни дә булса булды, әмма бу көнне Рәиф кадәр бәхетле кеше планетада юк иде. Чын...

Рәифнең күргәннәреме? Даниянең аңа күрсәткәннәреме? Партшкола тәмамлап кайтып, «Яңа юл»га тәкъдим ителгәндә Рәифнең бөтен курыкканы шул булды: син нинди җитәкче безгә, үз хатыныңа да баш була алмыйсың, дип сүз чыгарсалар нишләрсең? Син ничек безгә акыл өйрәтәсең, әнә үз әниең ни хәлдә яшәде? — дисәләр...

...Рәифнең әнисе озак авырды, каты авырды. Зур нарат бүрәнәле өйнең кояшлы бүлмәсе аныкы иде. Авыру шунда ятты. Дания иртәнге килгән бәләкәй кызына гел әйтә килде: әнә, кызым, ул бүлмә — синеке инде. Әнә, кызым, син укырга кергәч, шул бүлмәдә дәрес әзерләрсең. Әнә, кызым... Рәифнең йөрәгенә кан сауды. Горькийда партшколада укып йөргән вакыты иде. Ана дәшмәде, ыңгырашты гына.

Менә бер көнне ананың хәле авырайды. Янында инде үсеп килә торган үги кыз көннәр буе утырды. Дәү әнисен ул бик ярата иде. Карчык өч-дүрт көн телсез-авызсыз булып ятты да, бер кичне өзелде. Рәифнең каникулда вакыты иде — башын иеп Ахияр янына килде. Ахияр бөтен эшен ташлап күмүне оештыруга катнашты. Рәифкә әйтмичә генә комсомол райкомына хәбәр бирде:

— Сезнең элеккеге беренченең әнисе үлде, тиешле игътибарны күрсәтегез,— диде. Тегеләр автобус, «Бобик»ка төяләп веноклар оештырып килделәр. Моны көтмәгән Рәиф кинәт сынып калды, абзар артына чыгып елап керде.

Авылдагы гадәткә каршы килмәделәр: зиратка хатын-кыз кермәде, комсомол комитетыннан килгән егетләр карт солдатканың кабере өстенә венок китереп куйдылар. Килгән кешеләр зират яныннан ук таралыштылар. Рәифне үз машинасына утыртып Ахияр кайтарып куйды.

— Түз,— диде,— бу — котылгысыз хәл. Ата-ананы карап җирләү — баланың бурычы. Мин сугышта бик күп кеше җирләгән... Актык елың бара, туры үзебезгә сора. Монда секретарь картайды, үземә генә авыр. Комиссар кирәк! Шушы җирнеке кирәк...

Рәифкә бераз җиңел булып китте. Өенә керде, анда әле гел хатын-кыз иде. Үги кызына карады: күзләре шешенгән, тораташ булып каткан. Ишегалдында таягы белән сөйләшеп Камилә карчык йөри иде:

— Менә ничек зурладылар Рәифне... Камсамуллар килде. Шулай ул, юньле кешегә шулай ул. Шулай ул, кеше — кеше белән, Иләбәр — Шекше белән, диләр [1]. Я, алла, каберләрен нурлы ит... Рәиф улым, ба-

---

[1] Саба ягындагы мәкаль. Иләбәр, Шекше — шул яктагы авыллар. Мәкальнең нигезендә нәрсә ята? Пугачев явына бергәләп бару түгелме? Моны фольклорчылар әйтер.

баң крәчинкә өстенә аш куеп калды, ашарга безгә кер. Ике баланны да алып кер, килен инде ул үз әнисенә китәр...

Рәиф ду-чат килеп өй җыештырып йөргән хатын-кыз арасына килеп керде. Өйдән олы мәет чыккан... Зур кубып, зурдан алдырып эшлиләр. Кер юалар, идән юалар, кер кайнаталар. Тик түргә узгач кына Рәиф бераз аптырап торды: түр бүлмәдән әнисе яткан караватт чыгарылган, ул яраткан гөлләр тәрәзә төбендә инде юк, Дания зур дәрт белән бүлмәне үзгәртеп йөри иде (ахырдан, Камилә карчык сөйләве буенча, аны Хәсән карт бер көнне Мәгыйзьгә тапшырган, пачти, җырлап, дигән).

Дания яшьләр бүлмәсе ясап йөри икән. Рәиф аның күзләрендә шатлык очкыннары күрде — йөрәге телгәләнде. Дания мут елмаеп, үзенең йомры тәне белән аңа бәрелгәләп узды, сыпырынгалады, әйтте:

— Үлгән артыннан үлеп булмый, безнең әле яшисе бар,— диде.— Әнкәй,— диде,— кадерсез ятмады. Ярый инде, кеше кулыннан узмады— үзебезнең кулдан.— Ул тагын йомры күкрәкләре белән Рәифкә юри бәрелеп узды...— Мин,— диде,— әнкәйне шикәр шикелле мунчада гомер буе үз кулым белән юындырдым, чиста урын-җирдә тоттым...

Рәиф каршы килмәде: Дания чисталыкны ярата иде — сүз әйтер хәл юк. Шулай да, Рәифнең күңеле рәнҗеде, җаны катты: әле өченче көн генә әнисе яткан бүлмәне Дания ду кучереп яшьләр бүлмәсе итеп үзгәртеп йөри иде. Нигә ашыгырга? Карфаген шәһәрен җимереп, урынын сөргән римлылар кебек — кешелексезлек бит инде бу? Йортта Камиләтти кереп-чыгып йөри иде.

— Мин,— диде карчык, Даниягә карап,— инде бөтенләй кайтып киткәнием. Картның чәй эчәр вакыты җитте. Әле кире килдем: таягыма әйттем: әйдәле Мәгыйзьләргә алып бар әле, дидем. Мәгыйзьнең әнисе авырып тора икән. Шуларга барышым. Инде сезнең капка төбеннән узганда таягыма әйттем:

> Юл өстендә юкәләр,
> Өйдәме икән бикәләр?
> Өйдә булса бикәләр,
> Керми китсәң, үпкәләр.

Ник кердем мин? Менә нәрсә өчен... Син, килен, алай бик каударланма. Ашыкма. Мәетнең җаны тынычлансын. Менә боерган булса, өчесен уздырырбыз, шул көнне аның җаны күбәләк булып тәрәзәгә килер. Очып йөрер. Карар. Минем яткан урыннарым нинди хәлдә икән, дияр. Син ашыкма әле, яме... Күбәләк булып, мамык булып очып йөрер, ди китап. Өчесен, җидесен уздырыгыз, йәме? Алай мәгънәсез булмагыз. Тол хатын булды, менә дигән егет үстерде, йорт-җир җиткерде малае укыганда. Нигез игелекле булсын. Уздырыгыз! Дуга кермәсә дә, дога керсен нигезгә...

Әмма Дания ашыкты. Мәет озаткан көнне үк инде кечкенә бүлмәнең стенасына кыз яраткан паласны (ике олы болан янында бала болан агач төбенә басып тора) элде, кызның китапларын шунда кертте. Рәиф теш кысып түзде. Камилә карчык таягы белән сөйләшә-сөйләшә әле кайтышлый да кереп чыкты:

— Әйдәле, әйдәле, тагын бер сүз әйтсен әле Камилә карчык боларга. Син, килен, кара аны, мәетне зурлау — ата-бабадан калган эш. Син аны дин генә дип уйлый күрмә тагын. Мәетне олылау — Нух заманыннан килә. Яшьләр шуны күреп үсәргә тиеш. Әнә хөкүмәттән өйрәнегез, ирең фартейный бит. Әнә хөкүмәт ничек олылый үлгән кешеләрне. Әнә кичә тилизырдан күрсәттеләр, бер зур әфисәрне күмделәр. Ничә мендәр урдиннары гына бар. Кабере янында нинди генә олы кешеләр тормады. Барысы да фартейный. Шуларның иң зурысы үзе басып торды...

Әмма килен ашыкты. Кызый шул кечне үк инде юылган, чистартылган, үзгәртелгән бүлмәдә кунды. Дания әчке, яшерен шатлык белән бәхетле иде. Атналар үтте. Өчесе дә, җидесе дә тыйнак кына уздырылды. Өчесен хатыннар белән, җидесен ирләр белән уздырдылар. Камилә карчык әйтеп китте, өчесен уздырганда. Рәиф белән Даниягә генә әйтте:

— Олы мәет артыннан йортка зур зыян килә торган була,— мал-туарыгызны карап йөртегез. Сыер-фәлән зыянлый торган була. Тагарагына инә-фәлән төшә күрмәсен. Ут-фәләннән сак булыгыз...

Дания бәхетле, болардан шикләнерлек, боларны уйларлык дәрәҗәдә түгел иде. Ә шулай да йортка бәхетсезлек килде: Ташлытаудан җыр бәйрәменнән кайтканда яңгырга очраган машина тау менгәндә ауды. Рульдә Сәйяф малае иде. Егермеләгән яшь кыз-егет арасыннан борт астына бер кыз кысылды. Калганнары чәчелеп-коелып исән калдылар, кемнең бер кабыргасы сынган, кемнеңдер кулы тайган иде.

...Үги кызны күмгәндә кабер янында Рәиф үксеп-үксеп елады. Сәкинә белән Дания йортта башларын бәйләп ятып калганнар иде. Бигрәк акыллы, бигрәк сылу, юньле бер бала иде, үзенең «незаконный» апасы икәнен искә алып, Сәйяф малае аңа кабинага утырырга кушкан. Теге, бичара, әйткән:

— Минем плащым әйбәт, менә моны утырт,— дип кабинага Мәгыйзьнең кече кызын, үзенең классташын утырткан. Тегесе плащсыз, бер генә кат күлмәктән икән. Кузовка менгәч тә Дания кызына уртадан урын биргәннәр.

— Юк, мин кырыйга басам,— дигән юка киемле иптәшләренә карап.— Бер-берегезне җылытып кайтыгыз.— Шулай дигән дә, кузов кырыена урнашкан. Шулай, яшь җан дөньядан китеп барды.

Рәиф каникулдан әллә ниткән авыр уйлар белән китте, саташулы төннәр уздырды, шулай да партшколаны әйбәт тәмамлады. Диплом эшенә комиссия «биш»ле куйды, кафедра мөдире хәтта аспирантурага тәкъдим итәргә тырышып карады. Әмма яралы йөрәк авылга — газиз ана белән сөйкемле үги кыз каберенә таба тартты. Ахияр өлкә комитетының бүлек мөдире белән әллә кайчан сөйләшеп куйган иде инде. Рәифкә туп-туры шул юлны өйрәттеләр.

— Хатыныгыз белән ничек яшисез? — дип сорады Рәифне сайлау җыелышында трактористлардан берәү.— Ату, болай булмасын: вендә бизабразы, ә үзең монда килеп миңа акыл өйрәтәсең. Алай бармас, энекәш. Без, кара халык булсак та, ишетмибез-аңламыйбыз түгел, колакка мамык тыгылмаган. Әнием — карт солдатканы рәнҗетмәдеңме? Менә бит безгә нәрсә турында сөйләргә кирәк. Характеристика укып кына булмый. Анда гел әйбәт язалар. Ә менә үз өеңдә...

Рәифнең кандидатурасын яклап чыккан кешеләр арасында иң куәтле чыгыш, ихтимал, Ахиярныкы булгандыр.

— Безгә шушы җир кешесе кирәк,— диде ул.— Семья хәле буенча ышаныч күрсәтергә теләмисез икән, менә иң беренче чиратта, мине колхоздан куыгыз. Берегезгә дә үпкәләмим. Куыгыз. Турыдан-туры әйтегез: иптәш Гарәфиев, диегез, син безгә бу яктан үрнәк була алмадың, син мондый постка лаек түгел, диегез. Ә Рәифне сайлыйк. Шушы җир кешесе — үкенмәссез. Ә миңа — балык күлендә каравылчы штатын бирегез...

Ахиярның тавышы калтырап куйды, коммунистлар гөжләделәр, райкомнан килгән Халидә Әхмәтовна авторучка белән графинга какты.

— Ышту син, иптәш Гарәфиев,— дип Мәгыйзь күтәрелде.— Юрагангa — юш, койрыгы белән биш, ди. Ышту син! Рәзе моңарчы сиңа

риза булмаган кеше бар? Безгә башка председательнең упшым да кирәге юк. Әле Рәиф мәсьәләсендә дә болай гына сөйләшү бу. Юри сөйләшү, җыелыш формально булмасын дип, егетне сынап карау. Аңа кем каршы килсен? Үзебезнең егет, солдат малае. Дөньяны күреп үскән. Безнең секретарь инде ул, давай, иптәш Халидә, кул күтәртегез! Ыштусез? Хатын ягын тикшерә башласаң монда!.. Гайбәт тыңлап утыра торган урынмыни бу? Бу бит — партҗыелыш. Хатын белән минниләр күрмәдем? Хатын күрсәткән номерлардан чыгып эш итсәң монда, бик күбебез бу җыелышта утырырга тиеш түгел. Белдегезме шуны? Рәиф иптәш булырлыкмы секретарь? Булырлык. Хатынына лично үзе әйбәт торамы? Тора. Малай үстерәләрме? Үстерәләр. Хатынының тегендимондый яклары элек булганмы? Монысы безнең эш түгел. Әнә шундый хатын белән менә дигән итеп яшәп кара син... Мәхәббәт, ярату дигән әйбер бармы? Бар, диләр әнә язучылар. Партком секретаре ярата аламы? Не только ала, ә шуның өстенә — әбәзен. Давайте, иптәш коммунистлар, гайбәтче хатыннар дәрәҗәсенә төшмик. Мин аңламыйм, җыен эт арасында бер этнең койрыгы бот арасында дигән шикелле була бит инде бу! Нигә әле, әйтик, минем хатынны тикшермибез? Нигә Рәифнеке? Ә?

Гәр Хутор бригадасы исеменнән Кәшфи күтәрелде.

— Аның өчен чөнки, болай иптәшләр. Рәиф и һәм дә аның тормыш юлы — безнең күз алдыбызда. И һәм аның хатыны Дания турындагы мәсьәлә бу җыелышка керергә тиеш түгел. Аның өчен чөнки, хатынкыз — матур булмасын. Инде дә син, бәхетсезлегеңә каршы, матур булып, и һәм дә ирләрнең күзе төшәрлек булып тугансың икән, будь дубыр, синең ирең чыдам бирсен. Аңа Дания гаеплемени? Аңа Рәиф иптәш гаеплемени? Менә мин үзем андый борчудан бөтенләй азат булдым. Аның өчен чөнки, мин уртачаны алдым. Мин — тракторист, мин уртачага кучереп исәпләп өйрәнгән. Ә Рәиф — яшьләр комиссары, ул — матурлык командиры. Районда комсомолның беренче секретаре булып эшләде, гел безнең белән булды. Ә хатын — матур, аңа теләсә кем карый. Аның өчен болай ул, иптәшләр: әйдәгез, бертавыштан сайлап куйыйк. Үкенмәбез. Әле мин чыгыш ясыйсы түгел идем: менә монда безнең бригада трактористы сорау бирде, шуңа күрә генә сөйләвем. Җавап бирүем. И һәм мин кулымны күтәрәм, иптәшләр... Безгә дә бер яхшы партком секретаре белән эшләп карарга кирәк. Шундый егетне шик астына алырга ярыймы? — Кәшфи теге трактористка таба борылды.— Эт корсагына сары май килешми, диләр. Аның өчен чөнки безгә менә нинди секретарь кирәк: ул безгә давай-давай дип кычкырынып йөрмәсен; ул председательнең юлына аркылы төшеп наряд бирүгә борынын тыкмасын; эш бүлеп утырмасын. И һәм дә администратор булмасын. Безнең башка ягыбызны кайгыртсын ул. Авылга яхшы китапханә кирәк. Гәр Хуторга бер финский йорт кирәк.— уку йорты булсын. Тегесе бик иске хәзер. Аның өчен чөнки хәзер халык күп укый. Мәктәп балаларын, укып бетергәч, авылда калдыру буенча эш алып барырга кирәк. Әнә мин берни эшли алмыйм. Авылга, өйгә аю мае сипкәндәй булды. Китеп кенә торалар. И һәм дә авыл белән шәһәр арасын кайгыртсын ул: китерсен күчмә театр, китерсен филармония, чакырсын язучыларны, лекторларны. Менә болар барысы да партком эше. Музей ачтырсын, ветераннарны истә тотсын, Колан Кырның мәчетен ремонтлатсын — халык хезмәтенең истәлеге бит ул! Анда менә дигән музей корып була. Аның өчен чөнки, әнә Емельянов исемендәге колхозда чиркәүне ялт итеп куйдылар. И һәм эчендә колхоз музее. Менә безгә нинди партком кирәк. И һәм, минемчә, Рәиф мондый эшләр өчен аккурат үзе булачак. Аның өчен чөнки, иптәшләр, әйдәгез кул күтәрик.

Рәиф бер тавыштан сайланды...

## XV

Хәсән карт — авыл тарихының сакчысы. Авыл тарихын Мәгыйзь дә начар белми, ләкин ул утыз дүртенче еллардан гына алып китә. Тарих исә һәрвакытта тирәнлеге белән ота. Тирәнлек — Хәсән картта.

— Сине партком секретаре итеп сайлап куйган көнне тракторист Габделбарыев нинди наказ бирде? — дип елмайды Халидә Әхмәтовна «Яңа юл» секретаре Рәиф белән күрешкәч. Рәифнең йөрәге селкенеп алды: семья мәсьәләсе иде, бугай. Ну, ярый, семья хәзер тыныч. Йомры Даниянең еллар узган саен каны тынычланды, малай да тәрбиялисе бар иде, шуның өстенә, әнисе Сәкинә склероз белән газап чигә башлады. Саташа, адаша, бутап сөйли... Тормыш Данияне дә үз урынына утыртты.

Сүз — авыл тарихы, колхоз музее оештыру турында бара икән. Рәиф җиңел сулап куйды. Шуның өстенә Ахияр да әйтте:

— Әйдә, төп эш итеп шуны ал. Тарихын яздыр, музей оештыр, хуҗалык эшләрен мин әлегә алып бара алам.— Аннан йомшап китте.— Шул музейда... Үзем... үлгәнче эшләр идем...

Халидә моны ишетмәмешкә салышты, Рәифкә дә уңайсыз иде. Колхоз күптән инде районда беренче булып рентабельлеккә чыкты, Ахияр да, Рәиф тә районкүләм җыелышларда моны артык купайтмаска тырыштылар, эчтән генә шатландылар. Ахияр тормышында да үзгәрешләр булды: үзләрендә үскән Резеданы — Фәхразый кызын колхоз хисабына укытып финансовыйны тәмамлатты, кызы Фрадия медицинскийны тәмамлап институтта калды, улы Рамильне һич тә көтмәгәндә күрше «Көрәш» колхозына председательлеккә тәкъдим иттеләр. Бу — райондагы иң авыр хуҗалыкларның берсе, дөресрәге — иң арттагысы иде. Ахиярның болай да бик исәпле булган төн йокысы качты, бала — нигә яшьтә генә булмасын — үзәкне өзә иде. Ләкин иң гаҗәбе шул булды: шәһәрдән Сольма кайтып төште һәм китмәскә дип. Олайган, кызгылт-кара чәч төпләрендә урылган басудагы камыл кебек ап-ак катлам, муенында бер-ике хыянәтчел җыерчык, күзләре һаман да матур, һаман да сагышлы караш. Олайган, әмма мөлаемлеген югалтмаган. Бернинди аңлашусыз, бернинди үпкә-сапкысыз яши башладылар. Ахияр, ниһаять, оҗмахка эләкте: ашау-эчү, яту-тору, вакытында мунча керү, кием алыштыру дисеңме — Сольма боларны вакытында искиткеч зур таләп һәм өлгерлек белән хәл итте. Рәтсез яшәүнең тәмен белгән Ахияр беренче атналарда бераз ыңгырашып караган иде дә, җиңелде. Буйсынды. Сыкранып буйсынды һәм күп тә үтми, аңлады: әйбәт, тәртипле, эшчән хатынга буйсыну бик рәхәт икән! Шуны белмичә узган гомерен кызганды. Сольма исә алай уйлап тормады, ике көннең берендә межа буйлап җәяүләп «Көрәш» колхозына йөрде. Кулында я банка белән варенье, я үзе тозлаган гөмбә, я бүген генә пешкән йорт ризыгы була иде. Рамильнең хатынын ул белә: бүгенге яхшы шартларда, житкелекле гаиләдә (әтисе районда нефтебаза директоры) үскән кыз, әлбәттә, варенье да кайнатмаячак, гөмбә дә тозламаячак, ул — менә дигән культуралы (университет тәмамлаган), менә дигән чибәр кыз, ә ир кешегә тулы тормыш белән яшәү өчен әнә тегеләре дә кирәк...

Ахияр инде пенсиягә кадәрге гомерен саный иде, әмма эшсез ятуны күз алдына китерә алмый газапланды. Йокысыз күп төннәрдән соң уйлап тапты: колхоз, авыл тарихын язарга! Гомеренең калган санаулы көннәрен шуңа багышларга!

Халидә Әхмәтовна, Рәиф — өчесе бергә колхозның балык күле янындагы шалашта чәй янында алар шул турыда гәп кордылар. Колхоз тарихын язып булыр кебек, аны әле Мәгыйзь, Мәсгуть, пенсионер Рәхмәт хәтерли. Ә авыл тарихын? Кала ике кеше — Хәсән карт белән аның әллә кайчан акылы сидрәгән карчыгы — Камиләтти. Хәсән картка

быел туксан тула, имеш. Ну, гомерне бирсә дә бирә ходай. Хәер, керәшеннәрнең Нәчтүк әби дә әле исән. Аннан соң туган күпме кеше кырылды инде, ә Нәчтүк әби яшь бирә.

«Үткән тормышка ихтирам саклау — менә бу инде кешене кыргыйлыктан аеручы сыйфат»,— диде Халидә Әхмәтовна, калай кружкадан чәй авыз итеп.— Моны Пушкин әйткән. Әйдәгез, шул юнәлештә бер талпынып карыйк әле. Югыйсә, без гел ит, сөт, икмәк турында гына сөйләшергә өйрәнеп беткән. Әйдәгез, яшь буынны сынап карыйк әле: үз ата-бабаларының үткәненә алар ничек карар, нинди реакция булыр? Яшьләрне тәрбияләүнең бик мул бер чыганагын балчык астында яткырмыйбызмы икән без?

Партком секретаре зур дәрт белән колхоз музее оештыру эшенә керешә. Моңа мәктәп коллективын тарттылар: Мәгыйзь исә эшне туп-туры Хәсән карттан башлады.

...Крестьян Хәсән заманында җирне күп чәчмәде, ни гаҗәп — бөтен шөгыле җимеш бакчасы һәм яшелчә бакчасында чокчыну булды. Колан Кырда берәү дә бәрәңгедән башка нәрсә утыртмый, шомырт белән миләштән башка агач үстерми иде. Шуңа күрә Хәсәннең бу шөгыленә сәерсенеп караучылар булды. Шуның өстенә ул әле өч-дүрт баш бага-на умарта тота һәм авыруы булган йорттан чынаяк чокыры тотып кыш буе моның капкасына киләләр иде. Бу шөгыльләр барысы да ярады, әмма тагын бер шөгыле мәшәкатьле, борчулы булып чыкты. Хәсән абзый абзарында нәсел үгезе тотты. Үгез үзенең рәвеш-кыяфәте, иләмсез зур гәүдәсе белән бөтен бер волостька берәү генә иде. Киң маңгае тоташ сөяк булып бәрәңге тукмагы сыман таза өчлы ике мөгез белән янга киңәйгән. Маңгай уртасында уҗәтләнеп, бөтеркәләнеп беткән йон арасыннан ак кашкасы күренеп тора. Кара елтыр тиресе муен тирәсендә (хәер, муен бөтенләй юк, баштан соң тоташ коридор китеп, мунча кадәр гәүдә ясалган) җыерылып-җыерылып тора, дүрт ак бәкәле өстендәге йоннар көлтә-көлтә булып җиргә ышкылып йөри. Үзенең холкы алай начар түгел, әмма бөтен кешене котчыккыч дәһшәт астында тота. Сыер шикелле бугаз ярып кычкырмый, әллә ниткән эчке, ашказаны тавышы белән генә үзен сиздереп ала:

— Ы-ы-һһһ! — ди.

Колан Кырдагы бөтен тереклек иясе шул тавышка сискәнеп куя иде. Көтүдән кайтканда да тәртипле булды, туры кайтты. Инде дә иртәнге якта берәр сыерга яки танага үгезләрчә күңеле төшсә, көне буе шуңа турылыклы булды, бүтән берсенә дә эндәшмәде. Үзенең шул көнге мәхәббәтен ул җиренә җиткереп үтәде, тегене үз капкасына кадәр озатып куйды һәм хуҗалар капка янында үз сыерларын каршы алгач, Көлтәаяк куәтле эчке тавыш белән аларга тапшырып кайтып китә иде:

— У-у-ыһһ!

Тик кайбер көннәрдә, көтүчедән берәр гаделсезлек күргәндә генә, Көлтәаяк, зур гәүдәле тереклек ияләренә хас булганча, чын күңелдән, үгез йөрәге белән рәнҗеп, урамга кайта һәм Хәсәннең капкасына карап та тормыйча, Колан Кырның ике урамын да уртадан ярып әйләнеп чыга иде. Бу вакытта аның тавышы бөтенләй икенче — үпкәләү нота-ларында яңгырый:

— Бум-бум-бум! Бум-бум-бум!

Бу инде, бер дә шиксез, көтүче Ибәт карт миңа бер гөнаһсызга чыбыркы белән сукты, яки бүген иртән гыйшкым төшкән Акбаш белән миңа көтү читендә ялгыз калырга комачау итте, дигән кебегрәк үпкә сүзләре булгандыр....

Үгез үзенең хуҗасы Хәсән крестьянга күпмедер дәрәҗәдә доход та китерә иде, сыерлы кешеләр кайсы бер чиләк солы, яки берәр пот арыш,

берәр капчык бәрәңге китереп бушаталар иде. Кыскасы, үгез үзен-үзе дә, Хәсән крестьян гаиләсен дә шулай өч-дүрт ел туйдырды.

Мең тугыз йөз егерме тугызынчы елның мартында Колан Кырда колхоз оеша башлады. Колхозның беренче әгъзалары (алар арасында Хәсән дә бар иде) иң беренче эш итеп ашыгыч рәвештә ат абзарлары салдылар. Ат абзарының бер башына ябык стеналы бер бүлмә эшләделәр: атлар тапшырган көнне Хәсән крестьян да аты белән бергә үзенең Көлтәаягын шунда җитәкләп илтте, дүрт ягы да томаланган бүлмәгә кертеп япты. Үгез бер карулыксыз тагаракка борынын тыкты да, шабырдатып башак ашарга кереште.

Шулай да төнгә таба борчылды. Хәсәннекеләр ул төнне йокы аралаш ишетеп яттылар. Яңа салынган ат абзары тирәсеннән бәгыреңне өзәрлек тавыш авыл өстендәге һава катламын дерелдәтте:

— Ы-һ! Ы-ы-һ! — дип төне буе Көлтәаяк ыңгырашты.

Ә апрель аеның җылы бер төнендә аның тавышы аеруча куәт белән ишетелеп торды. Хәсән абзый, инде көннәр җылыга таба китте, иртән торгач өйнең саламнан өелгән нигезен сүтәсе булыр, дип план корып ята иде, колагында гел үгез тавышы булды. Иртәгесен исә нигез сүтеп мәшәкатьләнәсе булмады: урамнан бер тавыш килә, һәм тавыш якынайганнан-якыная бара иде. Хәсән абзый эшне тиз аңлады: абзарын ватып Көлтәаяк качкан. Хәер әлегә болай ук төгәл фикергә дә килеп җитә алмады ул — капка төбендә үгез күренде. Юыртып кына килгән хуттан Көлтәаяк капканың ябык икәнен күрде дә, капкага сылап тотылган бер торык койманы җиңелдән генә мөгезләренә утыртып, читкә алып та куйды. Торыкның бер башына балчыгы-бозы белән суырылып чыккан багана да ияргән иде. Хәсән абзый каушый калды, чолан баскычына менеп китте, Көлтәаяк исә ишегалды уртасына аякларын җәеп басты да, киң танавын җиргә терәде. Күзләре акайган, өске якка яртылаш кереп беткән, аскы якта чәй чокыры зурлыгында аксыл-кызгылт күз алмалары җаныңны өшетерлек куркыныч иде. Көлтәаякның мышнавыннан аяк астындагы апрель суы дулкын-дулкын булып дерелдәде. Ләкин бу халәт озакка бармады, Көлтәаяк башын күтәрмәгән көе генә өй буена килде дә, каты маңгаен өй стенасына китереп төртте: өй эчендә чылтыраган, шалтыраган тавышлар ишетелде, Хәсән абзыйның кырыну әсбаплары тәрәзә өстендә саклана иде, күрәсең, идәнгә шулар тәгәрәде.

Көлтәаяк күз ачып йомганчы өйнең өч ягына салынган нигезне сүтеп бирде, казык каккан урыннарда аеруча рәхәтлек белән маңгаен ышкыды, пошкырды, үкерде. Ике-өч минут эчендә ишегалды иске салам, сынган казык, такта кисәкләре белән тулды. Шуларны таратып бетергәч, Көлтәаяк әле дә телсез-авызсыз чолан баскычында басып торган Хәсән абзыйга күзләрен алартып бер карап алды да, урамга чыгып ук китте. Ярты сәгатьләр буе Көлтәаяк капка-киртәләр җимереп урамда йөрде, үзе гел үкерде:

— Бом-бом-бом, — килде.

Әйтерсең, үзеннән күпме игелек күргән кешеләрнең аны дүрт ягы да тоташ итеп ябылган бүлмәгә илтеп бикләүләренә ул рәнҗегән, үпкәләгән иде.

... Ахияр бик яшь иде әле, үз әнисе исән вакыт иде, әтисе Гарәфи абзый аны атка утыртып Колан Кыр сабантуена алып килде. Әнисе кечкенә Айзәрә белән өйдә утырып калды. Сабантуй авылдан бер чакрым чамасы читтә, инешле болында иде. Җыелган халык атларын тау битенә туарып, аста барган көрәшне, уенны карап чирәмгә урнашкан, ашыйлар-эчәләр, гармунга җырлыйлар. Сабантуй кызып килгәндә генә басудан әллә ниткән хәвефле аваз ишетелде. Баштарак моңа игътибар итмәделәр, дисталәгән тальян тавышы берсен-берсе аркылы кистереп тоташ музыка тудырган, чебен-кигәвенгә башларын чайкый-чай-

кый арт арбага бәйләнеп куелган клевер ашаучы атларның шөлдер, тамак асты кыңгырау тавышлары су буен тутырган иде. Әйе, баштарак игътибар итмәделәр. Әмма бер мизгелдә тау битендә кинәт калкып җир астыннан чыккан җил тегермәнедәй бер нәрсә барлыкка килде. Аңышмый тордылар. Хәер, Көлтәаяк та аңышмый торды: бу ни бу? Нәрсәгә дип барысы да монда җыелган? Кырда йөрергә тиешле сыер көтүе кайда? Әйтегез, кайда, кайда? Ә? Ә?

— У-у-у-һ! О-о-о-һ!

Халык сискәнеп китте. Гарәфи агай ярый әле атын теге як тау битенә туарган иде. Дөресрәге, ярый әле аркалык, йөгән тезгенен генә бушатып, алды арбаны кендектән алып атын борып кына куйган иде. Теге як халкы инешкә коелды: чыр-чу, елаш-кычкырыш. Көлтәаяк инде инеш буена төшеп, куәтле маңгаен инеш ярына терәгән иде. Өлкәннәр инеш буендагы чаш* үләне эченнән берөзлексез балаларны бу якка озатып тордылар. Батып, пычранып беттеләр, ул арада Көлтәаяк җиңелдән генә бер-ике ат арбасын әйләндереп атты, исәбе мәйдан уртасына керү иде. Көрәш туктады, йөгереш-кычкырыш башланды. Гарәфи агай Ахиярны клеверлы арбасына утыртты, атны җайлап борып куйды. Үгез бу якка бәлки чыга да алмас — ике арада сазлык. Кыскасы, сабантуй таралды. Мәйдан уртасындагы колга төбенә маңгаен терәп Көлтәаяк ялгыз калды. Шул чак тау битендәге халык арасыннан күлмәген салган, таза тәнле берәү үгез каршына чыкты. Кулында сәнәк иде. Гарәфи агай улына әйтте:

— Ну, бу бирә инде, — диде. — Ел саен батыр кала торган Колан Кырның Гыйззәт бу—Ахиярның бу батыр турында ишеткәне бар. Гәр Хутор малайлары сөйли иде: имеш, җиде-сигез яшьлек Сәйяф исемле малае бар, унбиш-уналты яшьлекләрне тотып кыйный ала икән.

Халык тынсыз калды. Сәнәк дигәннәре — каян табылгандыр, кибән башына көлтә бирә торган ике япьле чәнечке икән. Үгез һаман күзен алартып маңгаен колга төбенә терәп тора иде, Гыйззәт аңа якынлашты. Килеп җитәргә өч-дүрт адым кала кинәт хәрәкәт белән чәнечкенең озын сабын тез башына куеп шартлатып сындырды да, ярты сыныкны читкә ыргытты. Аннан үгез каршына килеп үк басты. Берничә секундка икесе дә исәп җыеп тордылар. Таралган халык шым калды. Ахияр малай да этисенә тотынып арба өстеннән астагы көрәшне карап торды. Менә ялан тән Гыйззәт, куәтле беләкләрен күпертеп, теге япьлекә белән үгез каршына килде һәм кинәт алга таба сикереп, япьлекәне үгезнең киң, юеш, алсу тишекле күн танавына тыгып та алды. Халык аһ итте.

— Кан күрсә котыра бу, бөтен халыкны харап итә! Гыйззәт! Гыйззәт! — дип кычкырындылар.

— Тукта! Чиген! Кадама!

Әмма көрәшче Гыйззәт кызган иде, үгезнең чирәмгә терәгән танавына ул тагын ике-өч тапкыр кадап алды. Ни хикмәт, кан чыкмады. Ниндидер сеçләгәй-фәлән акты, кан чыкмады. Көлтәаяк яман үкереп алгы аягына хут бирде: күз ачып йомганчы ашъяулык кадәр бер урында чирәм бөтереп тузан оча башлады. Ни сәбәптәндер, үгез һөҗүм итү турында уйламады, ду күчереп балчык очыртты да, бум-бум килеп үкереп авылга таба чапты. Ниндидер бер мизгелдә аның колагына авылдан сыер тавышы ишетелде, сабантуй көнне көтү чыгармаска дип яз көне көтү биргәндә үк Ибәт картның халык ризалыгын алганын Көлтәаяк белми иде. Әйе, Колан Кырда гомернең-гомер буе шулай: көтүче кеше сабантуй бәйрәменнән мәхрүм ителми.

Көлтәаяк җир селкетеп авылга таба китте, мәйдан яңадан оешты. Көрәшне яңарткanчы таза ирләр җыелып, Гыйззәткә бер дистә чи йомырка эчерттеләр, тау битләренә тагын халык җыелды.

[1] Казан арты сөйләшендә камышсыман үләнне шулай диләр.

Сабантуйның иртәгесен сөйләделәр: Көлтәаяк су буйлап кайтышлый урам башында яшәүче Хәбри картның капка-киртәсен, читәннәрен көл иткән, Хәсән абзыйның хатыны таяклы Камилә, имеш, болай дигән:

— Егерме тугызынчы елның мартында Көлтәаякны илтергә дип иң беренче Хәбри карт килеп әйтте. — Сезнең, — диде, — ат кына түгел, үгез дә бар. Бичара, шул картны хәтерләп калган, диген...

Тагын сөйләделәр: председатель ат караучыларга сабантуйга килергә рөхсәт итмәгән икән. Алар шуңа үч итеп көпә-көндез Көлтәаякны чыгарганнар. Ат караучыларга бишәр көн хезмәт көне белән штраф салганнар.

Көлтәаякның соңгы «чыгышы» печән өстендә булды. Болын тулы ирләр иде. Төшке аш алдыннан су кереп алдылар, зур казанда питрау тәкәсен [1] турап салган аш кайный иде, киң киндер паласларга ипи туралган, аш тәлинкәләре багана булып өелгән иде. Һәр паласның бер почмагы мәгънәле генә күтәрелеп, ул күтәренке почмаклар астында печән арасында зың-зың иткән пыяла тавышлары ишетелгәләп куя. Куәтле эштән, кушаяк тибеп йөзүдән тән бераз гына рәхәтлек кичереп алҗыган, ял сорый, ашказаны ризык сорый иде. Менә кайнар токмач бүленде, уртага табагы белән җелекле-сөякле ит килде, стаканнар хәрәкәтләнде. Кибеп килгән печән покосы исе дөньяны баскан, колхоз ирләре таза, шат, бәхетле... Стаканнар тиз генә җиңеләйде, кайнар токмач, яшел суган туралган шулпа, бүген иртән генә суелган питрау тәкәләренең ләззәтле ите, чикерткәләр тавышы, җылы җил башны әйләндергән вакыт иде, тау башында — нәкъ сабантуйдагы кебек — бөтен болын һавасын селкетеп бер тавыш ишетелде. Карасалар — Көлтәаяк икән. Ат караучы Габдерәхим — яшь егет — печән өмәсенә барасы килгән икән дә, бригадир рөхсәт итмәгән. Сабантуй көнне өлкән ат караучылар алымын ул да шулай кулланган... Бу юлы көрәшче Гыйззәт палас янынннан чалгы күтәреп кузгалды. Ләкин ирләр каршы төштеләр:

— Син нәрсә, Гыйззәт! Кәтер китәсең киләмени? Пеләмә үгезе бит ул! Моны үтерсәң, башың өтермәдә чери бит синең!

Көлтәаякның хәтере яхшы икән: бу юлы ул борынын җиргә терәп тормады, туп-туры Гыйззәт өстенә китте. Ирләр сибелештеләр. Гыйззәт яман сүгенеп гайрәт белән чалгысының очын үгезнең маңгай уртасына селтәп утыртты. Ирләр «ах» дип артка чигенделәр, ләкин үгезгә шәйтан да булмады, чалгының очы үгезнең маңгай катысына туры килде дә, чалгы сабы чартлап сынды, Гыйззәт коралсыз калды. Ул арада үгез сыңар аягы белән тау битендәге чирәмлектән бер-ике кәс актарып атты да кинәт һөҗүм итте: тирләгән майкалы Гыйззәтне (Гыйззәтне нәкъ алты пот дип сөйлиләр иде) куәтле маңгаена алды да тау астына таба күтәреп ыргытты. Аннан үкерә-үкерә авылга таба чапты. Көрәшче Гыйззәт ул елны җәй буе Ташлытау больницасында ятты, шуннан соң ничә еллар көрәшергә җыенып та, көрәшкә керергә кыюлыгы җитмәде, ул арада сугыш чыкты, һәм шунда Гыйззәт хәбәрсез югалды.

Көлтәаякның исә бу шуклыгын инде гафу итмәделәр...

Икенче көнне иртән Ташлытау юлында гадәттән тышрак бер йөк күренде: пар ат җигелгән арбага тегермән ташы салганнар, арба артына чылбыр белән Көлтәаякны бәйләгәннәр. Чылбырның бер очы арбадагы тегермән ташының уртасыннан алдырып төйнәлгән иде. Күп кеше Көлтәаякны ит заданиесенә тапшырдылар дип ышанып, берәүләр кыз-

---

[1] Питрау тәкәсе — татар халкының ышануынча, яз көне туган сарык бәтиенең итенә шул көннән соң гына тәм керә. Питрау — Петров день, (изге апостоллар Петр һәм Павел көне) христианнар бәйрәме, искечә 29 июньгә туры килә. Татар халкы Питрау көн җитмичә печәнгә төшмәгән, печән шул вакытка гына туклыклы булып өлгереп җитә, дип исәпләгән. «Питрау җиткәч печән арасына ут керә»,— дигән мәкаль шуннан. Печән өстендә, гадәттә, тәкәләр суелган, шуларны Питрау тәкәсе дип йөргәннәр.



Т. Хажиәхмәтов рәсеме.

ганып, берәүләр шатланып карап озаттылар. Шулай да авыл ятим калды, тын калды.

Ләкин ике-өч көн узгач күрделәр: Ташлытау юлыннан ат җигелгән җиңел арба килә, артыннан күндәм генә Көлтәаяк атлый. Ат та берәү генә, арбада да тегермән ташы юк, үгезнең дә муенында чылбыр түгел. Көлтәаякны нәзек кенә сүс бау белән арба артына бәйләгәннәр. Тик, мөгезеннән түгел, ә ... борын тишегенә киертелгән боҗрадан. Көлтәаякны каршы алырга бөтен халык җыелды. Абзарга япканчы тышта байтак тоттылар: Хәсән абзый белән Камиләтти елап та алдылар. Теге, бичара, кешеләргә рәнҗүенең актык чиген белдергәндәй, танавын җиргә төртте дә нәкъ сыерча:

— Өм-м-м, — дип эндәште.

Халык шаулашты:

— Ничек тишкәннәр аны? Ничек?

— Әллә бөтенләй харап иткәннәрме?

— Юктыр ич, юктыр ич? — дип сораулы караш ташладылар. Ветфельдшер ат туарып маташа иде, иренеп кенә мыгырданды:

— Иттеләр ди, менә, иттеләр. Янына берәр тана китереп карагыз... Иттеләр, ди...

Көлтәаяк турындагы сүзләр, куркыныч хикәяләр шуның белән бетте. Бераздан аның абзардагы бүлмәсенә кечкенә малайлар да керен йөри башлады. Кергән берсе танаудагы боҗрадан ике мөгезгә күтәреп бәйләгән нәзек сүс бауны тартып карый иде.

Бау тартып карарга бер көнне Гәр Хутор малайлары да килде. Моны оештыручылар — кызу канлы, җитез хәрәкәтле, һәрвакыт ашыгып сөйләүче Кәшфи исемле һәм бөтен Гәр Хутор малайларының атаманы, таза беләкле, урамда гел яланаяк йөри торган Ахияр исемле малай иде.

Колхоз тарихы, авыл тарихы дигәч, ничектер, бүген шул вакыйга Ахиярның хәтеренә килде.

## XVI

Авыл, колхоз тарихын язу дигән фикер ялгыз йөргәндә Ахиярга иптәш булды. Чыннан да, бик кирәкле эш икән бит: Колан Кырда сугышка кадәр ике йөз утыз бер хуҗалык булган. Сугыш алды елларында башка чыгучылар исәбенә яңа урам ясалган. Димәк, гел артуга... Ә менә хәзер — кимүгә. Моның сәбәпләре бик күптер, бик тирәндер. Моны Ахиярга бер генә дәреслек тә аңлата алмады. Галимнәр бу процессны бик өстән генә шудыртып аңлаталар. Пенсиягә чыгуга Ахияр, мәсәлән, Гәр Хутор тарихын яза башлаячак. Монысы — кимеми торганы — бик кызыклы...

Сентябрь башындагы яңгырлы ике көн үлеп барган табигатьне терелтте. Сентябрь искиткеч җылы, парлы, кояшлы килде. Кукуруз басулары каракучкыл-яшькелт диңгез булып тыгызланып китте, август эссеннән көйгән бәрәңге яңадан чәчәк атты. Хәтерләре исән калган, заманның төрле елларын исләрендә тота ала торган картлар әйттеләр: менә алтмыш ел яшим... Менә җитмеш биш ел яшәдем... Мондый кояшлы, җәй кебек җылы, парлы сентябрьнең булганы юк иде әле...

Ахияр иртәдән кичкә кадәр гел басуда булды. Бәрәңге быел күбрәк утыртылган, халык көченә туры килми иде. Үзе күп, үзе вак. Эссе харап иткән. Бу турыда, бәрәңгене күпләп утыртып та җыеп ала алмау куркынычы турында, Ахияр күп уйланды. Хәзер аның башында моңа карата аерым фикер дә тупланып килә. Тик бу фикерен ул тегендәмонда кычкырып әйтерлек җаен тапмый әле. Дөресрәге — нинди трибунадан торып әйтәсен белми. Ә перспектива болай: авылда кеше кими, бу инде котылгысыз хәл. Кеше кимегәнгә карап чәчүлек мәйданна-

ры кимеми, шул көенчә кала. Җыеп алу өчен иң авыры — бәрәңге. Монда кул көче сорала. Шәһәрдән тегеләй-болай гына кайтып, шаляй-валяй гына эшләп йөрүчеләр дә мәсьәләне хәл итми. Димәк, нишләргә? Димәк, шәһәрдә булган барлык оешмаларга җир бүлеп бирергә. Әйтик, конфет фабрикасы эшчеләре. Аларга кышлык бәрәңге кирәкме? Кирәк. Сездә күпме эшче бар? Менә сезгә шуның кадәр гектар бәрәңге, фәлән районның фәлән колхозыннан. Эшчеләрне колхозга бер айга түгел, яки колхоз бәрәңге алып бетергәнче түгел, бәлки конкрет фәлән гектарны алу өчен җибәрергә кирәк. Әнә шул фәлән гектарны ничек-ничек оештыра предприятие? Анысы — предприятие өстендә. Колхоз нишли? Эшчеләрне торак, ашау белән тәэмин итә. Бер атна эчендә хәл итәләр икән — рәхим итегез, кайтып китегез. Мондый шартларда эшчедә инициатива туачак, стимул булачак. Ә хәзерге кебек беренче октябрьны, яки кайтырга гомуми команданы көтеп йөргән кешеләр белән бәрәңге проблемасын хәл итеп булмый.

Кояшлы көндә бәрәңге алу, шулай да, күңелле эш. Ахияр бигрәк тә Гәр Хутор бригадасын ярата. Туган авылы бит... Быел аларда студентлар тора, ун йортта йөз ун студент. Кәшфиләргә генә кеше кертмәгәннәр: Тавис булгангадыр инде, бригадир алдан күрүчән кеше шул анда.

Урман эчендәге кояшлы басуда халык бәрәңге ала. Гәр Хутор... Кайчандыр бер заманда бу урынга француз кампаниясендә батырлык күрсәткән солдат кайтып төшә. Үзе мишәрләр ягыннан — Сызраньнан икән. Патша хәзрәтләре аңа сугышта күрсәткән батырлыгы өчен морза титулын биргән. Мишәр морзасына патша хәзрәтләренең күрсәтмәсе буенча Казан губернаторы җир бүлеп биргән, бу якларга землемер килгән. Землемер урманны, җирне үлчәгән һәм акт язган. Землемер актын Ахияр үзе эзләп тапты, архивтан копиясен алдырды. Авыл ул заманнарда ук Колан Кыр дип аталган икән. Димәк, бу якларда колан яшәгән. Землемер исә болай язган: «Владенная запись Казанской губернии Мамадышского уезда деревни Кулан Кыр.

I

К 1 январю 1815 года в селении числится ревизских 7 — народной переписи мужского пола душ крестьян 126.

II

Означенное селение находится в общей генерального межевания дачи деревни Поник — Айман, с деревнями под № 1113.

III

Во владении этого селения имеется земли под угодиями, составляющими крестьянский надел:

| | |
|---|---|
| удобной | 636,6 десятин |
| неудобной | 10,7 десятин |

Всего во владении крестьян шестьсот сорок семь и три десятых (647,3) десятин».

Актта тагын мондый юллар бар:

«1816 года, Август 23 дня, на сельском сходе государственных крестьян Казанской губернии, Мамадышского уезда деревни Кулан Кыр господином Производителям Работ по состоянию и выдаче владельных записей Вериго в присутствии госп. Мирового Посредника 3-го участка Мамадышского уезда Гоппсон, Запасного Лесничего Макарова и сторонних добросовестных крестьян означенного селения была предъявлена владенная запись со всеми к ней приложениями, объяснен смысл всех статей ея и значения передачи их в распоряжение дворянина г. Аязкули Сергея Альмухамедовича, кавалера солдатского ордена Знак отличия, причем крестьяне никаких возражений не делали, поэтому запись признана окончательно проверенною, о чем составлен на месте настоящий АКТ. Подлинное за надлежащим подписом.

С подлинным верно:
Августа 29 дня 1816 года.
И. О. Губернского землемера инженер Вериго».

Яшь алпавыт Сәетҗан Аязколый зур дәрт белән эшкә тотынган: иң беренче эш итеп ул Казанга килгән һәм оставкадагы генерал-майор Оппельбаумның кызына өйләнгән, чиркәүгә барып никах укыткан. Аннан Колан Кырга кайткан да үзенә йорт салдырган, балык күле, тополь аллеясы, тегермән эшләткән, ат заводы, кирпеч сугу цехы ачкан. Акт буенча бирелгән урманны күзәтеп чыккач, урманның фәкыйрь генә бер аланын дүрт яктан ут төртеп чистарткан да, Колан Кыр крестьяннарыннан биш семьяны хуторга чыгарган. Борынгы славяннар гадәтенчә бу хуторны ул «Гарь» (яндырылган җир мәгънәсендә) дип атаган һәм Гәр Хутор дигән русча исемле татар авылы барлыкка килгән.

Гәр Хутор элек үз гомерендә мәктәп, мәдрәсә, мәчет, мулла, хәлфә күрмәгән, шулай да ат асрап, ямщик куып, шәһәр белән ике арада элемтәне ныгыткан һәм бала-чагасын күрше-тирәдәге мәктәп-мәдрәсәгә, школага биреп укытырга тырышкан.

Сәетҗан Аязколый яки Сергей Альмухамедович нәселеннән Гәр Хуторда бер кеше дә калмаган иде.

Кечкенә авылларны бетерәләр дигән хәбәр йөргән иде шул... Имеш, Гәр Хутор бетә икән. Киресенчә булды: күрше авылларда колхоз оешканда аерым-аерым хуторлар ясадылар, әллә ниткән исемнәр биреп бетерделәр: «Күчтем», «Кызыл Көч» һәм башкалар.

Хәсән карт яшь вакытында теге морзаларның өченче буыны Габдрахман Әлмөхәммәтовта эшләде. Аны яхшы хәтерли.

Бу арада Хәсән карт янына көн аралаш Мәгыйзь килә, калын дәфтәргә барысын да яза. Дөрес, Хәсән карт Мәгыйзь сораганнарга туры җавап бирми, хәтере ялгышмасын өчен үзе салган бер эздән бара да бара. Сораулар аны бу эздән чыгара алмый...

Габдрахман Әлмөхәммәтов чибәр, мәһабәт гәүдәле, шакмак мыеклы, көләч йөзле укымышлы кеше иде. Кешеләргә гел елмаеп карый, әмма шул вакытта күзләре көлми иде. Гел хәрәкәттә, гел эштә булды. Якынтирә авыллардагы крестьяннарны ничек кулга аласын белә иде: өч ташлы тегермененең бер ташын гадигә, икенчесен ярмага, өченчесен ак онга көйләтте. Көрәк оны[1] әйбәт кенә алына иде, әмма тегермәндә чират көтеп яткан мужикларга чәй эчерү өчен бер бүлмә тотты. Монда тәүлек буе өч чиләк керешле зур самавыр кайнап тора, озын өстәлдә ашъяулык өстендә ипи, чәй һәм — шаккатырлык хәл! — шикәр була иде. Үз өендә шикәрне «керт» итеп тешләп кенә чәй эчкән крестьян монда рәхәтләнә иде.

Габдрахман бай турында әллә ниләр сөйләделәр ул заманда: имеш, аның улы Казанда ветеринар институтында укый икән, имеш, патшага каршы сүзләр сөйләгәне өчен бер елга аны авылга этисе янына сөргәннәр икән, имеш, җәй көне аның янына озын чәчле, ак йөзле, юка пыяла күзлекле бер «студин» кайткан икән дә, икенче көнне үк Ташлытаудан «палисмистер» килеп тикшерү ясаган икән.

Габдрахман байның кирпеч заводы бөтен Казан артында дан тоткандыр: халык арасында әле дә морҗа чыгарганда, морҗа сүткәндә шундый сүз йөри:

— Һи-и, Әлмөхәммәтов кирпече инде ул! Аңа нәрсә булсын!

Морҗачылар әле дә шул кирпечне аерып куялар: ул бераз калынрак, морҗачы балтасы белән аны, гомумән, китеп тә, ватып та булмый.

Хәсән карт сөйли Мәгыйзьгә:

---

[1] Көрәк оны — тегермәндә ашлык тарттырган өчен түләнә торган өлеш. Моның нормасын һәр тегермәнче үзе билгели. Уртача нормасы — бер поттан өч-дүрт кадак.

— Чакыра бу авыллардан малайларны. Акчага кызыгып барасың. Үз атың белән килсәң, ике өлеш артык түли. Синең эш — ат өстендә йөрү. Зур гына чокыр. Тирән түгел, бер аршын[1] гына булыр. Зурлыкка — зур, әнә мактәп бар бит әле, шуның урыны шайы[2] булыр. Олылар теге чокырга кызыл балчык ташый, мичкә белән су ташый. Ә син ат аягы белән шуны изәсең. Көне буе. Лач та лоч. Көндез — ипи белән шикәрле чәй. Кичен—биш тиен. Җәй буе шулай. Ул инде кайбер көнне унар ат була, изелгән балчыкны кичен учыңа алып карыйсың— каймак! Билләһи! Менә кирпеч нйчек ясала ул!

Мәгыйзь язып өлгерә алмый. Тик шунысы бар, олы кеше янында тәмәке тартырга йөрәге җитми. Колан Кыр авылында бу — әдәпсезлек санала.

— Әлмөхәммәтов якын-тирәдә ат нәселен яхшыртты. Безнең халык нәрсә? Авылына бер айгыр була, еллар буе бияне шуңа каплаталар. Менә бер заман ат нәселе корый башлый. Юк, теге алай итми. Ат заводы тотты. Яңа нәсел чыгарды. Крәстиян биясен чаптырырга[3] шунда алып бара башлады. Бәясе — ике чиләк солы. Бервакыт бөтен халык шуңа йөри башлады. Аннары... Теге авылга мәчет кирәк, бу авылга чиркәү кирәк. Бөтенесе моның аркылы. Инде шуны салдырып куйдымы? Измәгә ничә меň тавык йомыркасы сытканга үзе ышандымы? Шуннан инде мулланы, попны үзеннән башка куя алмыйсың. Килә бирәү мулла булырга. Авылда приговор җыелган, тегенең указы кулында. Ну әле моның белән генә эш бетми. Моны үз янына Әлмөхәммәтов чакырта. Иң беренче эш — русча белүен сынап карый. Беләме теге, юкмы? Яхшы белмәсә — приговор юкка чыгарыла. Аннан тегене дин, шәригать буенча сынап карый. Колан Кырга приговор җыеп килгән бер мулланы тәки куйдырмады: теге мескен, җир кит балыгы өстендә тора, дип ышанып...

Хәсән карт сөйли торгач сүзеннән айнып китә:

— Сиңа, — ди, — калхуз турында кирәктер, ә мин гел теге заманны сөйлим. Калхуз турында шул: бер генә хәл булды — син аны хәтерләмисеңдер инде, — малай гына бит. Габдрәхим юньсез бар иде бит. Шуның әнисе — Бәдрикамал — егерме тугызынчы елда кызып китеп, влач безнең кулда, безгә бер әйбер дә нипачум дип зур юрган алып каравыл өенә килде. Янәсе, колхоз булгач, бөтен кеше бер юрган астында йоклый. Кулакларның болай да җырлары бар иде: хатын-кызлар — уртак, маңгайларга — пичәт... Туктаттым, ярамый, дидем. Тыңламады, авызын ерып каравыл өенә китте. Надан, нәселләре белән надан. Шуннан, нәрсә булды соң? Икенче көнне калхуз таралды. Бөтен картлар гариза язып кәнсәләргә китерделәр. — Син яздыңмы? Син дә чыгасыңмы? — диләр миңа. — Юк, — мин әйтәм, — юләр хатынның бер ахмаклыгына карап, кире гариза яза алмыйм. Олы улы Шәймәрдәнне хәтерлисеңме? Әнисе иргә чыкканчы ук тумакчы булган ул бала. Ул вакытта андый эшләр ярамый — зур ыстырам. Егете баш тарткан. Шуннан бу нишләгән? — Хәсән карт тагын сүзеннән айнып китә. — Болары калхуз тарихы түгел инде аның. Шулай да бит— халык тарихы. Болар бит бөтенесе безнең шушында булган хәлләр. Тарих дигәнең шул түгелмени? Шул түгелмени? Һәм теге юньсез Бәдрикамал нишли? Мунча кергәндә үзенең эченә ике-өч тапкыр бияләй инәсен тыгып ала. Ике-өч тапкыр! Янәсе, гөнаһтан котылмакчы.

---

[1] Аршын (аршин) — Россия, Болгария, Төркия, Афганстан һ. б. илләрдә кулланылган озынлык үлчәве — 71,12 см. Әле безнең гасырның кырыгынчы елларында да балта осталары бүрәнәләрне аршынлап үлчиләр иде.

[2] Шайы — кадәр, хәтле мәгънәсендә. Арча якларына унтугызынчы гасырда Лаешка урман эшенә барган кешеләр алып кайткан сүз. Моны кайбер гаиләләрдә генә кулланалар.

[3] Чаптыру — каплату дигәнне аңлата. Казан арты сөйләме.

һәм нәрсә була? Шул гөнаһлы көе кала, староста белән карт хәзрәт килеп егетне күндерәләр. Дүрт айдан бала таба бу. Никахтан соң дүрт айдан. Менә шул. Ике күзе дөм сукыр. Шәймәрдән, бичара, гармунга өйрәнде, якын тирә авыллардан килеп аны туйга, сабантуйга чакыралар иде. Менә шул сукыр малае белән юрган күтәреп ике-өч көн каравыл өенә йөрде. Колаклар түләгән тегеңә. Алай ярамый бит. Шуннан, шәһәрдән килгән бер коммунист бар иде, халыкны җыеп сөйләште:

— Гаризаларыгызны кире алып ялгышкансыз, колхоз ул — күмәк хуҗалык дигән сүз, аның, диде, гаилә бетерү, аны күмәкләштерү дигән статьясы юк.

— Ирдәй ирнең эчендә иярләнгән ат ятыр, хатындай хатынның эчендә биләүләгән бала ятыр, ди. Менә шулай, энем Мәгыйзь. Теге сукыр Шәймәрдәнне әйтәм. Үсте, энисен ташлап чыгып китте. Хәтерлисеңме?

Мәгыйзьләр буыны сукыр Шәймәрдәнне хәтерли. Утыз алтынчы елларда «Сукырлар җәмгыяте» авылларга килеп концерт куеп йөри иде. Шәймәрдән бер-ике тапкыр Колан Кыр клубында җырлады. Зур шадра битле, кара күзлек кигән киң җилкәле ир сәхнәгә чыгып төймәле гармунда уйнады. Төймәсе өч рәт иде. Үзе уйнаганга үзе җырлады. Малайлар озак вакытлар аның сүзләрен кычкырып җырлап йөрделәр, бер куплетын отып калганнар иде.

Каховка, Каховка, иркәм син, винтовка,
Кайнар ядрәдәй очып бар.
Иркутск, Варшава, Орел һәм Каховка —
Безнең үтелгән зур юллар...

Хәер, тагын бер җырның ниндидер бер ертык кисәген отып калганнар икән:

Херсон буенда
Үләннәр бик биек,
Херсон буенда бар курган.
Кылган басып киткән
Шул курган астында
Йоклый Железняк-партизан...

Теге вакытта, Шәймәрдәнне тыңлаганда, бөтен Колан Кыр халкы шыпырт кына елады.

— Ә такта яру заводы? Такта яру заводы?— Мәгыйзь, тәмәке тартасы килүдән иңрәп, озын сүзле Хәсән картка ачу катыш карады.

Монысын Хәсән карт турыдан башлады.

— Алпавыт тугызынчы елны салды такта заводын. Башта якын-тирә авыллардан утызлап егет җыйды. Аңлатты: шулай-шулай, диде. Кул белән такта ярып чиләнәсез. Дөньяда, диде, шундый көчләр бар: җил, пар, су, кояш. Алдынгы халыклар, диде, әнә шуннан файдаланалар. Әнгличәннәрне әйтте, урысларны, немесләрне. Менә шулай аңлаткач әйтте, такта яру заводы салам, диде, әмма ликин аңа пар казаны кирәк. Шәһәрдә, диде, мин килешеп кайттым, акчасын түләдем, миңа пар казаны эшләделәр. Аны алып кайтырга кирәк. Кемнәр риза?

Пар казанын тәгәрәтеп нәкъ бер ай да унике көн алып кайттык. Шәһәрдән генә бер атна чыктык. Уч төпләребез, тез башларыбыз чиләнеп, сөялләнеп бетте. Пар казанын алып кайттык, әмма бай вәгъдәсен үтәмәде: эшләгәнегез юлда ашауга беткән, диде. Бер елдан завод эшли дә башлады. Беренче көнне бөтен өяз халкы җыелгандыр: алты пычкылы гыйфритнең бер башыннан бүрәнәне биреп торалар, икенче ягыннан шалтырап такталар килеп чыга. Пила чүбен ашап эшли. Кирәк белән пила чүбен мичкә ыргытып торалар, теге янып тора, казанда пар ясала тора.

Мәгыйзь бу хикмәтле заводны хәтерли иде әле. Аны гына түгел, Колан Кыр белән Гәр Хутор уртасындагы «алпавыт дачасын» да, Кесмәс елгасының уйсуланып аккан тугаен да, наратлы тау башын да — барысы да тарих. Нарат бүрәнәдән салып, нарат такта белән тышланган бер

катлы, чардаклы өй, әйләнә-тирәдә сирень бакчасы. Бакча уртасында беседка, корган, какшаган инде, ләкин буяулы такталар матур, затлы. Сирень, гел сирень иде ул тирәдә. Әле ул елларда җыр да бар иде.

Тәрәзә төбем гөлсирин,
Гөлсирингә су сибим...

— Бай, бай үзе нишләде? Совет властена ничек булды? Авыл тарихын язганда моны без яктыртырга тиешбез...— Мәгыйзь тәмәке тарта алмаган вакытта гел нервлы була иде, монда өй бит, урам булса, ул түзмәс иде, кабызыр иде. Урамда Хәсән карт барында гына учка яшереп тарткалаган бар, анысы. Хәсән карт арган иде, Мәгыйзьнең сорауларына туры җавап бирә башлады.

— Нишләсен? Колчак армиясе килгәч, алпавыт шулар белән Малмыжга китте. Халык, бәлки, тимәгән дә булыр иде. Дөрес, Түнтәрдәге Ишми ишан белән дуслашып, унберенче елда Казан артындагы бөтен мөгаллимне, яңача яшәргә өндәп йөргән күп кенә муллаларны өтермәгә озаттырды. Алай ярамый бит. Шуннан куркып китеп барды да. Аның пәйгамбәр урынына күргән Ишми ишаны сәвиткә каршы чыкты. Аңа зур суд булды, җәзасын алды. Ә безнең алпавыт Колчак белән китте, китте. Кытайга барып чыккан. Кытайда син кемгә кирәк? Аннан Төркиягә күчеп килгән. Анда кем көтеп тора сине? Анда бит эшләтер өчен без юк. Төрекнең үз байлары бар. Менәтерәк, үзе шунда үлгән, балалары исән, ди. Истамбулда. Кайтып шул бакчаларны бер генә карап, шул сиреньнәрне бер генә тапкыр иснәр идем, аннары шунда үләр идем, дип елый ди, бер малае. Килгән бер парахутны каршы ала икән Истамбулда. Янәсе, безнең яклардан кемнәр бар? Безнең илдән килгән парахутларны әйтәм. Казан ягыннан кем бар? Менә бит, әтиләренең эчке күңеле начарлыкта булгач, безнең гади халыкны кешегә дә санамагач — балаларына нинди җәза... Кеше яшәгәндә балаларын да уйларга тиеш. Китте — Колчак әрмиясе белән китте. Дворяннар юлыннан китте ул да. Ә теге заманда бит дворяннарнең патшага каршы чыгып себер киткәннәре дә булган. Кешенең күңеленә карап эш итәргә кирәк, Мәгыйзь энем. Әнә шул әфисәрләр — дворяннар — безнең кебек мужикны яклаган бит инде. Үзләре, дөрес, бал-май эчендә йөзгән. Шуларны безнең авыл янындагы юлдан Себергә куганнар бит инде! Шуңа күрә безнең яннан уза торган таш юлны «Әбизәр юлы» дип йөртәләр бит инде!— Хәсән карт, шуны да белмисеңмени дип рәнҗегән сыман, Мәгыйзьгә карады. Аннан, борын эченнән генә җырлап күрсәтте:

Өсталләрең бизәр-бизәр,
Бизәр саен әбизәр [1],
Әбизәрләр дөнья гизәр,
Сез дуслардан кем бизәр?

Хәсән карт халыкара хәлләр белән бик кызыксына, әмма газит-фәлән укый алмый, күзләре бик начар. Шуңа күрә, кичке тугызда телевизордан «Время» тапшыруын бер дә калдырмый. Мәгыйзь исә күп укый. Үзенең авыл тарихын язганда тәмәке тартмыйча утырып иза чигүенең ачуын икенче вакытта ул Хәсән карттан ала. Урамда, яки үз оясы — идарәдә. Мәгыйзьнең карт янында тәмәке тартуының бер системасы бар. Хәсән карт өендә ул тартмый, түзә; урамда, капка төбендә утырганда җиң эченә яшереп, башын читкә борып тарта; идарәдә исә — ник әлл кемнәрең килми! Монда Мәгыйзь — абсолют монарх. Бызгытып тарта.

Халыкара хәлләр бик катлауланып киткән көннәрдә Хәсән карт яр ты сәгатьлек «Время» тапшыруына гына риза булмыйча, идарәгә кил. Җаен көтә, Израиль, Хөмәйни, Ясир Арафат, Ливан мәсьәләләре, Италиядәге мафия, Америкадагы эшсезлек мәсьәләләре аны бик нык бор чый, бик кызыксындыра. Шунда инде Мәгыйзь рәхәтләнә.

[1] Әбизәр — офицер. Казан арты диалекты. Халык теленә унтугызынчы гасырд кергән булса кирәк.

— Хөмәйнинең кичәге белдерүен тыңладыңмы?— дип башлый ул үзенең сүзен.— Нәрсә ди бит, ә? Вәт картлач! Нишли бит, ә?— Хәсән карт якынрак килеп утыра, Мәгыйзь моны сизә, юри суза.— Ну, бу инде нәкъ теге хикәяттәге шикелле: ызначит, тәмәке тартуга каршы көрәшәбез, дип галимнәр симпозиумга җыелганнар (кабызып ала, тирән итеп суыра). Сөйләгәннәр болар, бер сәгать, ике сәгать. Ызначит, тарту зарарлы, тартмаска кирәк. Ярый. Тәнәфес ясаганнар. И һәм нәрсә булган дип уйлыйсың?— Мәгыйзь тирән елмаеп Хәсән картка таба борыла, тегесенең исә тәмәкене үз гомерендә авызына алганы булмаган кебек, бу турыда тыңларга да теләми, ул тагын шуышып утыра, мөлдерәтеп Мәгыйзьгә карый: Хөмәйни нәрсә дигән? «Правда» ни яза? Ә?— Мәгыйзь — явыз артист.— Ызначит, болар, зур коридорга чыгып авызларына бөтенесе папирос капканнар. И һәм җиңел сулап куйганнар. Тагын ничә доклад калды?— дип сорый икән иң галауный учуный.

— Шуннан, шуннан? Хөмәйни нәрсә дигән?

Мәгыйзь ашыкмый, тәтенгә рәхәтләнеп чумып сөйли:

— Ә... Хөмәйни... Ул әйткән: безгә дигән ни тульке шаһның үзен генә кайтарып бирәсез, шуның өстенә әле аның дәүләт казнасыннан талап чит ил банкыларына күчергән акчасын да кайтарасыз. Без, ди, картлач, сорамыйбыз, ә таләп итәбез,— Мәгыйзь чалт-чолт китереп чут төймәсен сала.— Ызначит, менә булдымы егерме биш миллиард америка доллары. Ә теге якта бөтенесе долларга корылган...

Хәсән карт активлаша:

— Бирәләрме икән? Кайтаралармы икән?

Мәгыйзь исә халыкара хәлләрне тәмәке темасы белән бергә бутап алып бара.

— Ә менә тагын ничек булган: Советлар Союзының бөтен тәмәке фабрикаларының директорларын семинарга җыйганнар. Трибунага чыккан берсе үз продукциясен мактый икән. Тәнәфескә чыкканнар, тартып җибәргәннәр. Шунда безнең министр болар янына килгән дә, сораган: нинди марка тартасың? Карасалар, бөтенесе дә Ленинградның Урицкий фабрикасыныкын тарталар икән. Министр кычкырып көлгән...

— Шуннан, тегене сөйләп бетермәдең әле, Мәгыйзь энем. Акчаны кайтаралармы икән?

Бүген Хәсән картка үзе теләгән информацияне алырга насыйп булмаган икән. Идарә янына дөбер-шатыр трактор килеп туктады, ул арада бухгалтерия бүлмәсенә өтәләнеп Кәшфи килеп керде:

— Ишеттегезме? Аның өчен чөнки, әле генә хәбәр иттеләр: ике космонавт очкан. Хәлләре яхшы ди. Берсе — полковник, икенчесе — гражданский галим. Аның өчен чөнки, шулай итмичә ярамый: берәү — командир, ә икенчесе дизельләр, карбюраторлар, поршеньнәрне яхшы белергә тиеш. И һәм дә горючийне...

Хәсән карт ашыгып радио тыңларга кайтып китте, Мәгыйзь исә төтенен тәмләп суырып арифмометр әйләндерә башлады...

— Әле менә син кергәндә генә уйлап куйдым,— диде ул Кәшфигә карап.— Колхоз ничә ел рәттән инде рентабельле булып килә. Ә бит районда җитмеш биш процент колхоз шул турыда хыялланып яши. Менә без ник алда? Син уйлыйсың инде, син яхшы эшләгән аркасында гына дип. Юк шул, энекәем, малны тота белергә кирәк. Ә ул мәсьәлә безнең кулда. Хәзер — исәп заманы. Шуңа кормасаң, ачка кырылып бетәсең. Менә мин әле генә документка имза салдым: симертүгә куелган унсигез баш тана иртәгә шәһәргә озатылырга тиеш. Ни өчен? Культпоходкамы? Юк, ит комбинатына. Ни өчен иртәгә?— Мәгыйзь елмая.— План шулай. Бүген ундүрт башны Емельянов колхозы озата. Ә берсекөнгә күрше «Марс» колхозы. Менә без — хисапчылар, экономистлар шулай планлаштырып утырабыз инде. Шәһәрдә күпме халык бар? (Чут төймәсе — чалт! Бераз гына әле бөтерелеп тора.) Мин круглый алам,

пускай булсын бер миллион. Һәркемнең тамагы бармы? Авызы? Бар. Мин круглый алам — бер авызның буе — биш сантиметр (чут төймәсе — чалт! Мәгыйзь авыз кырыендагы төпчектән чыккан сыек төтеннең күтәрелеп бер күзенә бәйләнүенә чыдый алмыйча, башын янтайта, бер күзен кыса.) Миллионны бишкә тапкырласаң, (чалт-чолт), ул буладыр — биш миллион сантиметр. Тәк, метрлар, (чалт-чолт), ул буладыр... илле мең метр. Хәзер без аны (ачы төтенне суырып алгач) әйләндерәбез километрга. Тә-ә-к... (чалт-чолт). Ул буладыр нәкъ илле километр озынлыктагы авыз. Әнә шуны күз алдына китерәсеңме? Әнә шул авыз көненә өч мәртәбә (чалт!) ачылып ризык сорый! Илле километрлы авыз! Дөрес, ул да безгә машина, кием-салым, газ, электр, аяк киеме бирә. Папирос, сигарет бирә. Шырпы, зажигалка. Машинага бензин. Ул да тик ятмый, ну син дә инде, будь дубыр, әнә теге авызга сала бир. Көненә өч тапкыр, дим...

Кәшфи балаларча каршы килеп маташты:

— Юк, туган, алай дөрес чыкмый ул. Менә син авыз дисең. Аның өчен чөнки, минеке дә биш сантиметр бар ул. Ну бит минем тешләр юк. Мин бит бәрәңге боламыгы гына ашыйм. Сөткә изеп. И һәм дә...

— Ә-ә, юк, туганкай. Аны круглый аласың инде. Тигезлисең. Өй бураганда ничек? Нечкә башка юан башны салгач, теп-тигез чыга ул. Шылт та итми... Син теге, үзең ашамагач та. Теге мәзәкне беләсеңме?— Мәгыйзь тәмләп яңа «Беломор» кабызды, ике-өч бөжра очырды.

— Килеп чыгыгыз әле бер,— дип кода үзенең икенче авылдагы кодасын чакыра икән. Бер чакырган, ике. Бер көнне теге кода үзе генә килеп тә чыккан. Монысы чапкыда тәмәке турый икән.— Тарт, кода, хуш исле чия яфрагын кушып чаптым,— дип төрдертә икән. Әлегә бер дә самавыр-фәлән кыймылдатучы юк, ди. Тарталар болар. Бераздан кода икенче бер кучне күрсәтә: монысын тартып кара, монысының өстенә ширбәт суы бөркеп киптердем, ди. Моны да тарталар. Тагын берничә тапкыр. Кунак кода зәңгәрләнеп бетә. Самавыр тавышы тәки юк. Шуннан кунак кода тора да, кайтырга җыена башлый. Ә теге хуҗа кеше әйтә:

— Икенче килгәндә кодагый белән килегез,— ди. Кунак кода да югалып калмый:

— Кодагый тартмый шул,— дип капкадан чыгып китә.

Кәшфинең килүе Ахияр янына икән. Кабинет бушаганны гына көтеп торды да председатель янына ашыкты. Мәгыйзь исә әле чут салып, әле арифмометр әйләндереп эшли калды. Хәер, күбрәк чут салып: иләнелгән, ышанычлы, бөтен операцияне төгәл башкара инде ул агач төймә. Ә иң дөресе — агач чут төймәләре яшьлекне хәтерләтә иде. Арифмометр — чалбар кигән кызыл тырнаклы кызларныкы. Әнә алар күрше бүлмәдә исәпләп утыралар. Алар ишеге яныннан узганда Кәшфи дә сискәнеп куйды: двигателен сүндермәгән иде ул. Трактор лепелдәп эшләп утырды, бу бит — байлык. Материаль байлыкны исраф итү дигән сүз. Шуңа күрә кабинеттан Кәшфи тиз чыкты. Кабаланып сөйләп бетерде.

— Кайтам дигән. Семьюм. Алдагы елга пенсиягә чыгам дигән. Йорт урыным исәнме, дигән. Аның өчен чөнки... Кешегә үз нигезе кирәк. Ни өчен дисәң, шулай әйбәт була. Давай, иптәш Гарәфиев (кабинетта вакытта ул Ахиярга гел шулай дәшә), без моны уйлашыйк. Материалны үзем ташыйм. Бушка. Бер тиен язмагыз. Чүтеки, без өчәү бергә чыгып киттек сугышка. Япь-яшь көе.

— Дүртәү икәнбез,— диде Ахияр авыр сулап.— Күрше Иванны кая куясың? Ятып калды? Әнисе янына кергәнең бармы? Ә Гыйльфанга хат яз: биш куллап каршы алабыз, нигезе исән, материал булыр...

## XVII

Йорт капкасы, квартира ишеге төнен кеше тыныч йокласын өчен ябыла. Төн — ял өчен, йокы өчен. Төнен кем йокламый? Ил сакчысы солдат, дежур милиционер, ашыгыч ярдәм станциясе, телефон-телеграф кешеләре, ипи-күмәч пешерүчеләр. Кайвакытта — гашыйклар, еш кына — хәсрәтлеләр. Төн — йокы өчен, моны бозарга ярамый. Авылда, мәсәлән, барысы да йоклый. Ферма каравылчысы да, идарә дежуры да — барысы да, барысы да төнен йоклый. Авылда төн уртасында берәү дә, берәүнең дә ишеген какмый. Гадәт шулай, тарих шулай. Әмма бу гадәт бер кешегә кагылмый: ул — председатель. Аның капкасын теләсә ни вакытта кагалар, теләсә ни вакытта аны уяталар. Ахияр соңгы вакытта, Сольма кайткач, кеше төсле йоклый башлаган иде. Я хода! Адәм баласына — председательгә — мондый кадер дә була ала икән: кайтып керешенә — кайнар аш. Салат ясалган, өстәлгә катык куелган. Аштан соң зал бүлмәсендә телевизор кабызылган. Журнал өстәлендә бүгенге почта. Идәндә йомшак палас. Ятар алдыннан эмальле табак белән җылы су, тәбәнәк урындык, аяк сөрткече. Чытыр ак урын-җир, укып яту өчен көйләнгән лампа. Нигә гомер буе килеп-китеп яшәде бу Сольма? Әнә бит, Мәгыйзь әйтә, аныкы ике ел гына шулай тулгаклаган. Сольма исә — гомер буе. Ярый әле, малай авылны сайлады... Адәм баласы болай да яши ала икән. Ахияр вакыт-вакыт шикләнеп куя башлады: мондый идеаль шартларда яшәп колхоз белән җитәкчелек итеп булырмы? Иөрәкне май басмасмы? Ләкин кеше төсле итеп кадерле урыннарда йоклый башлагач, анда бер сәер гадәт барлыкка килде: ул төшендә сугышны күрә иде. Һәрвакыт иң авыр вакытын, һәрвакыт — чигенү вакытын. Ахияр газаплана, шуыша, автоматын югалта, элемтә аппаратының батареясын тартмага кертә алмый, кабель аягына чорнала, ул шуыша алмый, инде ыңгыраша гына, ә кабель һаман аякны ычкындырмый, җитмәсә батарея тыгылмаган телефон тартмасындагы зуммер эшли! Батареясыз эшли!

— Зың-ң! Зың-ң! Зың-ң!— килә, үзәкне өзә. Тагын шуышырга, тагын кабельдән аякны алырга дип тыпырчынырга...

— Зың-ң! Зың-ң!

— Ахияр, дим! Ахияр! Уян әле, ишектәме, капкадамы кеше бар!

Монысы Сольма тавышы, ни гаҗәп, сугыш вакытында алар таныш түгелләр иде бит әле, Сольма да шушы взводта икән бит...

— Ахияр, дим! Капкада кемдер бар...

Фу-у... Ахияр уянды, саташып каранып алды: сугыш түгел, бүрәнәле авыл өенең эче икән. Әнә таныш палас. Әнә таныш сәгать. Тең! Тең! Авыр хәрәкәт белән гомер саный.

Электр кыңгыравы һаман зеңелди иде. Ахияр торды, киенде, ишек алдына ут бирде, чолан баскычларын март суыгында шартлатып, капкага килде. Сорамыйча гына ачты. Өй кыегыннан төшкән яктылыкта кара плюш жакет киеп, калын мамык шәл бөркәнгән Сәкинәне танып алды. Аны күрмәгәнгә ничә айлар инде! Сәкинә каушаган иде.

— Рәүф кияү шәһәрдә җыелышта бит, иптәш Гарәфиев (Ахияр игътибар итте: Сәкинәнең аңа беренче тапкыр шулай зурлап эндәшүе иде). Сезне борчымас та идем: ни бит... колхозда бик зур бәхетсезлек чыкты бит.— Сәкинә тыны буылудан тотлыга иде.— Ни бит... Бәгъдә апаң ялгышкан. Сручны озатырга кирәк...

— Ничек ялгышкан? Нишләгән?

— Ничек дип... Акылына зыян килгән. Кычкыра, ут белән уйный. Бөтен авылны хәл итәм, ди. Берүзе бит, берүзе! Бич чишенеп ташлап ишегалдында йөгереп йөри! Ялан тән! Кар өстендә... Карарга ыстырам...

Ахияр бер мәлгә тын калды. Нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Фу, шайтан, бу төн бетте инде. Иртәгә, юк инде, бүген — райком пленумы бу-

ласы иде. Ахиярның анда чыгыш ясыйсы бар. Ун-унбиш минут, диделәр. Чыгыш әле язылмаган. Өстәл өсте тулы мәгълүмат. Иртәнге дүрттә торып утырмакчы иде ул...

— Бар шоферны уят,— диде ул Сәкинәгә.— Колан Кырдан Мәгыйзь белән Рәхмәтне алып килсен. Үзең дә әзерлән юлга. Районга кереп тормагыз, туп-туры шәһәргә. Мәгыйзь андыйның рәтен белә...

Сәкинә төн караңгылыгына кереп югалды.— Ничә яшь икән инде моңа?— дип уйлап калды Ахияр. Алтмыш бишме? Юктыр, күбрәктер. Инде җитмешкә таба барышыдыр... Чын сүз әйттеме икән? Сәкинәнең үзенең дә бит акылы сидери башлаган дигәннәрие. Ни чакырып кияве-кызы янына күчеп килми, ялгыз яши. Ялгыз яшәүченең эше яман! Аңа бернинди телевизор, радио, китап ярдәм итә алмый. Чын хәбәр әйттеме икән?

Ул көнне машина шәһәрдән кич кенә кайтты. Ахияр да арып кайткан иде, кичке аш алдыннан бер рюмка коньяк эчте. Чыгышын бик ошатып бетермәде кебек Беренче. Өлкә комитетыннан да инструктор бар иде. Анысы пленум беткәч Ахияр белән җылы гына сөйләште. Кечкенә авылларны саклау мәсьәләсендә Ахияр эчкәрерәк кереп китте дә, экономик мәсьәләләрне күмеп ташлый язды. Беренче шуны ошатмады. Әмма инструктор кызыксынды, Ахияр яшьләрне тәрбияләү мәсьәләсендә әллә нинди прогнозлар биреп бетерде. Арадан берсе — буаз атларны кечкенә малае булган йортларга биреп асрату. Колхоз фураж җибәрә, хезмәт хакы түли, малай бәхетле була — колын үстерә. Бер ел бүе шулай... Мондый тәҗрибә әлегә «Яңа юл»да гына һәм әлегә гел уңай нәтиҗә бирә. Малайлар авылны яраталар. Аннан соң СПТУ мәсьәләсен күтәрде Ахияр. СПТУга диде, сигез классны өчкә-көчкә бетергән малайларны җыю дөрес түгел. Мисал да китерде: бер колхозның председателе мәктәпкә кергән икән дә, дәрес бара ди, укытучы дәресен бүлеп әйткән:

— И, иптәш председатель, менә шушылар белән иза чигәм инде мин,— дип, күзлек киеп теге дөньяга карап утыра торган ике-өч малайны күрсәткән.— Менә укытып кара син аларны: әлегә кадәр яшел төс белән сарыны аера алмыйлар...

Теге председатель шунда әлеге күзлеклеләр янына килеп, аркаларыннан сөйгән:

— И, җаннарым, болар — минекеләр инде,— дигән...

— СПТУга сигезне, унны отличнога тәмамлаганнарны гына җибәрергә кирәк,— диде Ахияр трибунадан торып.— Авыл хуҗалыгы машиналары елдан-ел катлаулана. Мин теге өчле-көчлеләрне күп укытып карадым. Кайта — зур комбайнны күреп мөстәкыйль үзенә урдырырга кушкач, югалып кала. Аннан бөтенләй ташлый...

— Ә теге отличникның институтка китәсе килсә?— дип бүлдерде аны Байгильдеев.

— Анысын да уйларга кирәк,— диде Ахияр. Җитмәсә, шул мәсьәлә буенча пленумда, һич тә көтелмәгәндә, мыеклы, таза тавышлы бер иптәш чыгыш ясап, Ахиярга бәйләнде: шагыйрь икән, авыл темасына яза торган әсәренә материал туплап йөри икән һәм беренче секретарьдан пленумда катнашырга рөхсәт сораган. Мыек туп-туры Ахиярга һөҗүм итте:

— Менә сез, иптәш,— диде ул,— кадрларны авылда калдыру турында кайгыртасыз. Урта мәктәпне тәмамлаганнарны авылда калдыру буенча эш алып барасыз икән. Әмма уйлап карадыгызмы? Сезнең агитация буенча авылда калдырган егетләр-кызлар арасында күпме-күпме талантлар һәлак була? Бәлки, алар арасында киләчәкнең менә дигән рәссамы, музыканты, язучысы, артисты, галиме, архитекторы бардыр? Сез шул турыда — милли культурабызның киләчәге турында уйлап караганыгыз бармы? Гел доярка-доярка дип булмый бит! Дояркаларга укыр өчен кем шигырь язар, кем телеспектакль күрсәтер, кем рухи азык

бирер? Минемчә, сез уй-фикерләрегез белән бүгенге көн таләпләреннән байтак артта калгансыз...

Мыеклы шагыйрь залны үзенә аударды да бетерде. Тавыш та кирәк шул. Бугаз шәп булганда, рәвеш-кыяфәт булганда ни әйтсәң дә — шәп чыга. Ахияр шулай уйлап утырды конференц-залда. Әмма кайтып яткач, башкасын да уйлады: чыннан да, бөтен идеологик эш савымчы белән механизатор үстерүгә кайтып калмыймы соң? Теге, мыеклы, бәлки, хаклыдыр?

Бәгъдә апаң, Бәгъдә апаң... Ахияр ул елны әлемтә бүлеге начальнигы булып эшли иде. Хәтерли, хәтерли аны Ахияр. Бәгъдә — җир җимереп, ирләрчә сүгенеп йөри торган хатын — ул елны саклык кассасы мөдире булып эшләп алды. Түбәннән — авылдан күтәргәннәр иде. Кырык җиденче елның калын, йомшак карлы кышы. Кибетләр рәтләнергә торган бер чак, карточка системасы бетерелә икән, ипи-шикәр теләгәнчә булачак икән, дип сөйләгән сүзләр куерды. Халыкта өмет, өмет... Көтүләр, ышанулар. Шикләнү, булмаска сәкеннәүләр... Халык кулында акча — бигрәк тә сугышта кешесе булган — аз балалы таза солдаткалар, налогсыз яшәгән ялгыз карт-карчык баеды. Бәрәңгенең чиләге егерме-утыз сум. Бәрәнге мул булды, сугыш башланганнан алып беткәнче бәрәңге-иген ишелеп уңып килде. Налогтан азат ителгән льготалы кызыләрмис семьялары бәрәңгедән зур доход алдылар. Базарлар мул, калын булды, сарык, бозау, таналар печәнле чана янында үзләренең озын юлда бөкләп килеп оеган аякларын язып, көйшәп торалар, ял көне Ташлытау хезмәткәрләре базарга чыгып сарык, бозау, тана-үгез сатулашалар, каз-тавык түшкәсе сайлыйлар. Акчалар бик эре: утызлык — озын, кызгылт-алсу сурәтле, йөзлек — тастымал буе, унлык — кара-көмеш сурәтле. Өчлек-бишлекне малга да санаган кеше юк: алар яшькелт кәгазьдән, бишлегендә парашют капчыгы киеп елмаеп торган кеше, өчлегендә — каска киеп, шахтер лампасы тоткан егет. Берлекне күргән дә юк, аңа берни дә алып та булмый. Бакча тәмәкесенең стаканы егерме биш тәңкә, ләкин егерме бишлек акча юк, күп вакытта тулы стаканга бер аш кашыгы өстиләр дә, кызыл утызлыктан кайтарып биреп мәшәкатьләнмиләр. Нindидер бер көнне район үзәгендә кемнендер авызыннан «акча алышыначак икән» дигән хәбәр чыкты. Бу хәбәр яшен тизлегендә Ташлытауның бөтен кибетләренә таралып өлгерде. Халыкка таралды. Ахияр сизеп утырды: коммутатор янындагы телефонисткалар арып-талып эштән чыктылар, клеммалар берөзлексез лепелдәп ычкынып торды, тоташтыру шнурлары шың-шың килеп шуды, өзелде, кайсыдыр линия стройдан чыгып торды — бөтенесендә бер генә сорау иде:

— Акча алышына диләр, шул сүз дөресме?

Бу сорауга беркем дә, берни дип тә җавап бирә алмады, шик-шөбһә аның саен артты. Халыкта акча күп иде — моны кеше белә иде.

Менә шимбә көн килеп житте, район үзәге хезмәткәрләре иртүк алтыда стенадагы кара картон тәлинкәләрен көйләделәр. Кызыл Мәйдан тавышы ишетелде, мәһабәт гимн яңгырады. Соңгы хәбәрләр китте: төрле өлкәләрдән, крайлардан, автономияле республикалардан Сталинга хәбәр итәләр иде: мөмкинлекләрен чамалаганнан соң фәлән-фәлән өлкәләр, крайлар, республикалар яңадан шуның хәтле ашлык чыгарырга булдылар, фәлән-фәлән җирдә Сталинга музей ачылган, фәлән композитор аңа багышлап кантата язган, фәлән художник аның образын киндергә төшергән һәм башкалар... Акча алмашынуы турында — ләм-мим. Туктале, нәрсә соң бу? Нәрсә бу? Моңарчы бит бер дә буш сүз булганы юк иде. Теге елны сугыш башланырга мөмкин дип сөйләде халык, Молотовның чыгышы да бу хәбәрне бастыра алмады — сугыш башланды. Ике ел элек — кырык биштә, сугыш бетә икән, диделәр — бетте. Гитлер үзен-үзе үтергән дип сөйләделәр — шулай булып чыкты. Сталин —

бөек диделәр — шулай булды, фашизмны җиңдек бит. Ә бу хәбәр? Нүжәли юкка гына? Халык шулай уйлый иде.

Әмма халык бу очракта да дөрес сиземли иде. Шимбә көн иртән район җитәкчеләренең сейфларында инде махсус күрсәтмәле конвертлар ята һәм аларны бары тик шул көннең икенче яртысында гына ачасы иде. Бу конверт килгәнен белгән хезмәткәрләр инде райүзәк буенча йөгерешкән, пышын-шашын килгән, акча тулы сумкалар белән кибетләрне, складларны сөреп чыккан иде. Әмма сейфлардагы теге хатны ачарга әлегә иртә: моның эчтәлеген райүзәктә әлегә нибары бер кеше генә белә иде. Дөрес, якынча белүчеләр дә булды: район башкарма комитеты председателе, банк управляющие, финанс бүлеге мөдире, Дәүләт куркынычсызлыгы Министрлыгының (ул вакытта — Министрлык) район бүлеге начальнигы һәм... Бәгъдә. Саклык кассасы мөдире. Бәгъдә шул вакытта үзен Кремльдә дип хис итте. Тыны буылды. Үз гомерендә беренче тапкыр ул Дәүләт Серенә якын килгән иде.

Бәгъдә шимбә көнне шул Сергә бик якын килде. Дөресен әйтергә кирәк, ул Сер элемтә бүлеге мөдире Ахияр Гарәфиевкә дә килеп җитте: саклык кассасына салынган акча сумга-сум исән калачак икән. Шөкер, Ахиярның андый «юләр» акчасы юк, бар тапкан ашау-эчүгә, йорт кирәгенә бетеп бара иде. Әмма саклык кассасындагы «өч меңгә кадәр акча сумга-сум түләнә» дигән хәбәр райүзәк буйлап яшендәй узды, күп кешене урынга екты, егылганны торгызды, урамга куды. Саклык кассасы тирәсендә кара мәйдан барлыкка килде. Бәгъдә шәп утырды, такта кабинетның ишеген кагып керүчеләр арасында сумкалылар, саквояжлылар, хәтта капчыклылар бар иде. Бәгъдә каты торды:

— Сәгать алты тулды, вкладларны бары тик дүшәмбедән генә алабыз, бөтен счетлар ябылды, бүген бернинди операция башкармыйбыз,— диде. Һәм кассаны яптылар. Ә иртәнге сәгать алтыда, Кремль курантларының мәһабәт тавышыннан соң Кызыл Мәйданның салкын ташларыннан чакылдап чыккан кебек Левитан авазы яңгырады: «От Советского правительства...» Бу тавышны, мондый мәһабәтлекне 1945 елның 3 августыннан бирле — Япония империализмын җиңгән көннән бирле ишеткән юк иде әле. Левитан хәбәр итте: Совет хөкүмәте халык интересыннан чыгып акча реформасы уздыра; бүгеннән башлап азык-төлек, киң куллану товарларына карточка системасы бетерелә... Радионың картон тәлинкәләре шулай сөйләде. Халыкның шатлыктан тыны кысылды.

Ыгы-зыгылы дүшәмбе башланды. Нәрсә ул реформа? Яңа акча — ул нинди? Кибеттә ниләр бар?

Әмма район үзәге хезмәткәрләре алай баш ватып тормады. Сумка, портфельләр күтәреп саклык кассасына җыелдылар. Карарда әйтелгән иде: саклык кассасындагы акчаның өч мең сумына кадәр сумга-сум, калганы унга бер исәбеннән түләнә, дип. Күп кешене шул харап итте. Һәркемнең Бәгъдәгә үтенече бер генә:

— Шимбә көн белән салып булмасмы?

— Өченче көн белән оформить итик! Бер-беребезгә... түгел.

— Әйдә, слушай, вакланмыйк: минем хатынның матрац астында унбиш мең яткан. Юләр, миңа әйтмәгән. Шуны шимбә көн ордеры белән хәл итик... Бездән эш калмас. Бергә яшисе бар. Бергә эшлисе бар...

Һәм кайбер кешеләргә Бәгъдә эшләде. Күп тә үтмәде, ул яңабаштан киенде, Ташлытау урамыннан боярыня Морозова булып узып йөрде, ага-эне (авыл халкы) аңа юл сабып кала иде. Әмма, бу хәл бер айдан да ары бармады: партия контроле дигән оешма эшкә тотынды. Райүзәк дер селкенде: райком бюросында персональ эшләр иртәнге дүрткә кадәр каралды. Ә бюролар өч көн саен җыелды. Бәгъдәне, нәданлыгын исәпкә алып, эшеннән күчерделәр, яңадан Колан Кыр участогына финагент булып кайтты. Башкалар бу хәлне авыр кичерде:

банк управляющие, егерме меңне шимбә көн белән дүшәмбедә салган кеше, үзен-үзе хәл итте. РайФО мөдире Бәгъдәнең өенә килеп, бер яртыны ачып (бәхетсез хатыны да ияреп килгән иде), үкереп елады:

— Мин сугыштан исән-сау кайттым, минем ике медалем, бер орденым бар, мине нигә партиядән чыгардылар? Нигә мин бүгенге көндә партиясез, эшсез? Ник син шул вакытта минем үтенечемне кире какмадың? Мин нишлим ул өч мең тәңкә белән,— диде.

Шулай, атналар буе еладылар. Кемнәрдер каядыр китте, кемнәрнедер хәтта каядыр озаттылар. Бәгъдә дә шым калып бер-ике атна райүзәктә яшәде дә, әле үзенең нәрсәдән, нидән исән калганын аңламаган көе, нәрсәгәдер шатланып, авылына күчеп кайтты...

...Ул вакытта Ахияр, кайчан да булса бу хатын белән бер колхоз территориясендә яшәрмен, вакыт-вакыт аңа, пенсионеркага, утын-печән китертү өчен йөк машинасы бирермен дип, әлбәттә, башына да китермәгән иде. Ул авырып шундый хәлдә калыр, мине төн уятып транспорт сорарлар дип тә... И, бу дөнья! Кем, кайчан нәрсә буласын алдан әйтә ала соң? Астрономнар да йолдызлар юлын гына беләләр. Тарихчылар — җәмгыятьнең үткәнен, экономистлар — киләчәген әйтәләр. Ә менә аерым кешенең киләчәген кем әйтә? Бәгъдәнекен кем шулай булыр дип уйлаган иде? Теге, шәп йөргән елларда бит, бу дөньяда Бәгъдәдән дә властьлы, мәңгелек кеше юк сыман иде. Шул кайчангыдыр куәтле хатын инде бүген ялангач калып кар өстенә чыгып йөгереп йөриме? Менә адәм баласының ахыр көне!

Ә синең үзеңнеке ничек булачак? Соңгы көнең? Моны сиңа кем әйтә ала? Син дә бит бүген, әлегә бик шәп, синең кулда — ил байлыгы, икмәк, ит, май, сөт, бал... Синең кулда — кешеләр, куәтле техника. Колхоз председателенең дәрәҗәсе хәзер моңарчы беркайчан да булмаганча күтәрелде. Хәзер районнан килеп төшкәннәрдән өч-дүрт кенә кеше белән кепка салып сөйләшә председатель. Чөнки — барысы да колхозда. Бөтен байлыкка колхоз хуҗа. Әнә шул зур, дәрәҗәле посттан китеп пенсиягә чыккач, ничек яшисе булыр икән? Ничек?

Төн йокысы шулай качты. Ничәнче төн? Гомере буе Ахиярның төн йокысын качыра торган хәлләр булып тора. Сугышта бер төн йокламады. Кайткач — элемтәдә. Анда эшләгән кеше, гомумән, бөтен бер төн дигән төшенчәне оныта. Аннан — председатель. Колхоз председателе — ул кем? Төннең теләсә кайсы бер сәгатендә кинәт уятып, аякка бастырып эшкә кушарга мөмкин булган шәхес. Ахиярның бөтен гомере әнә шулай үтте. Булды! Җитте!

...Колхозның отчет-сайлау җыелышына нәкъ ун көн вакыт калган иде — шул төндә, март башының салкын бер төнендә үзенең чолан баганасына сөялеп председатель Ахияр үз-үзенә вәгъдә бирде:

— Җитте. Ил алдында мин үз бурычымны үтәдем кебек. Җыелышта, яңадан сайларга уйласалар, баш тартам. Пенсиягә чыгам да, улым Рамильгә консультация биреп, тыныч кына тик яшим. Мин дә кеше. Мин дә...— Әнә, машина кабызган тавыш ишетелде, әнә, фара яктысы кибет янындагы карт нарат башын ялап алды, әнә, кузгалдылар. Кайчандыр, сугыш елларында җиде-сигез авылны дер селкетеп торган Бәгъдәне шәһәргә — больницага алып китәләр. Ул да бит дәүләт эшен эшләгән теге заманда. Менә иң авыры бу дөньяда шул: дөрес эш белән ялгыш эшне аера белү. Чөнки алар арасында кинәт уздырылган сызык юк. Дөрестән ялгышка күчкәндә ике арада ниндидер томанлыклар була, анда күбрәк дөреслек чаткылары ялтырап ала да, кеше ышана: әйе, мин дөрес эшлим, ди. Ахияр да шулай хәзер: тузган, арган, үзе һаман эшли. Дилбегәне әллә кайчан Рәнфкә бирәсе инде, бирәсе инде...

Ләкин райком алай дими. Әллә хәтер саклыйлармы? Белмәссең.

Әмма унсигезенче март — Ахияр тормышында хәлиткеч бер көн булачак. Ул шунда өч дистәгә якын еллар күтәреп килгән авыр йөген иплэп кенә җилкәсеннән төшереп, кызыл комач җәелгән өстәлгә — президиумга — китереп салачак:

— Иптәшләр, мә, алыгыз... Миннән исән-сау, мин ардым. Йөкне күтәрүчеләр бар...— Ул шулай диячәк.

## XVIII

Шәһәрдә Бәгъдә белән күпме мәшәкать күргәннәрен Мәгыйзь дә, Мәсгуть тә, Рәхмәт тә бер кешегә дә сөйләмәделәр. Алай ярамый, алай ирләрчә булмый. Мәшәкать күрелде, Бәгъдәне ышанычлы кулларга — врачларга тапшырдылар. Алар инде нишләтәсен белә. Әмма йөрәк тетрәткече ул булмады. Мәгыйзьне ул хәл тетрәтмәде. Кот очарлыгы шунда булды ки, «Беломор» алырга гастрономга кергән җирендә Мәгыйзь яшь, чибәр бер хатын-кыз белән кара-каршы очрашып, телсез калды. Яланбаш, инена төймәләмичә генә, яшькелт көзге пальто элгән, пальто астында йомшак йорт халаты, аякларында өйдә кия торган сукно тапочкалар. Кулында бер шешә «Алабашлы», ике пачка «Прима». Ачык муенында күптән ямалган, тарттырылган җөй. Пычак эзе булыр. Чибәр, шайтан. Кара-каршы килделәр дә, туктап калдылар. Мәгыйзь авызын ачарга җыенганда, теге чибәр ачык пальтосын яба төшеп муенын җыйды да, танымамышка салышып, юкка да чыкты.

Машина эченә кереп утырган Мәгыйзь гүя гастрономда телен калдырган иде: ничекләр итеп инде Мәсгутькә, синең югалган кызыңны очраттым, дип әйтәсең? Моны Ахияр белән киңәшмичә ата кешегә ничек әйтәсең? Юк, Мәгыйзьдә андый йөрәк, андый тәвәккәллек юк. Ахияр кирәк. Һәм ул юл буе йоклаган сыман итеп кайтты. Мәсгуть белән Рәхмәт исә юлда рәхәт чиктеләр: икеме-өчме тапкыр «Бобик»ны туктатып, шофердан стакан, пәке сорап алдылар. Гади колхозчыга еш эләгәмени алай «персонально» йөрү? Бу рәхәтлеккә Мәгыйзьнең катнашмавы алар өчен һич кеше аңламаслык бер сер булып калды.

Иртәгесен идарәгә тегеләй-болай кереп чыгучылар, утырып торучылар булды. Бәгъдә язмышы белән кызыксынучылар булды. Әмма Мәгыйзь сүзне икенче якка борды. Шунда ук Рәхмәт белән Мәсгуть тә утыралар иде. Мәгыйзь үзәк газетаның бер мәкаләсе уңае белән гәп корды. Ул мәкаләдә колхозчыларның, шәһәр тирәсендә яшәүчеләрнең шәхси хуҗалыкларына, шәхси терлек асрауга ярдәм итү кирәклеге турында сүз бара иде.

— Күрдегезме, безнең партия, хөкүмәтнең зирәклеген?— диде Мәгыйзь.— Шәхси хуҗалыкларга ярдәм, дигән. Әнә бит теге елларны кайбер иптәшләр нинди хата ясап ташладылар.— Һәм ул тәмләп «Беломор» кабызды. Аннан җай белән сөйләп китте:

— Анекдотка кадәр барып җиттеләр: участковый милиционер шәһәр читендәге бистәдә кисәтеп чыга. Дүрт аяклы терлекләрегезне суегыз, сатыгыз, ди. Берничә көннән җыелышып тикшереп йөриләр: әмер үтәлгәнме, юкмы. Керәләр «Нахаловка»дагы Хәмдениса апайга.

— Тәк, тәк,— ди участковый, планшеттан блокнотын чыгарып.— Сезнең сикс͡эн өч кош-корт, бер кәҗә. Кош-корты безне кызыксындырмый, ә менә теге сакалбайны исемлектән сызабыз. Әмер үтәлгәндер бит?

— Үтәлде, үтәлде, энекәем,— ди Хәмдениса апай,— өченче көн үк Хәмидулла абыең чалып ташлады. Базарга чыгарып саттык, кәҗә итен алучы да юк, арзанга гына бирдек инде. Би-би-ик сөтле иде, җаныкаем,—дип Хәмдениса апай алъяпкыч итәге белән күз яшьләрен дә сөртеп ала.

Тегеләр «для порядка» абзар-кураны күзәтеп чыгалар һәм күрәләр: кәҗә абзары буш, ятим, ишеге шыр ачык. Блокнотка билге куеп

ишегалдыннан чыгып барганда гына өй астыннанмы, базданмы, сәер бер тавыш ишетеп тукталалар:

— Мә-ә-ә-ә!

Бичара, гомере беткән кәҗә, шунда өй астында тагы бер минут түзсә ни була инде? Алып чыгып, акыртып суялар. Хәмдениса апай нишли? Урамның теге башына торып йөгерә. Анда әле быел гына бер төн эчендә йорт салып килеп урнашкан энесе бар аның. Киленнәре мәктәптә җыештыручы булып эшли. Алар ике баш сарык тоталар. Алар да сарыкларын өй астына яшерәселәре иде. Хәмдениса апай тегеләрдән берәр сәгать алдан килеп китә. Килен исә шул бер сәгатьне әйбәт файдалана, мәктәптән ике противогаз алып тора да, йөгереп кайтып сарыкларына киертә. Сарыкка була — аның мөгезе юк. Сарыклар шулай исән кала...

Мәгыйзь борчылып тәрәзә аша урамга күз ташлый. Сүз сеңдерүче Хәсән карт килеп җитмәгәнгә борчыла ул. Ә карт — һаман юк. Урамнан инде таягы белән гәпләшеп Камилә карчык ике тапкыр гына узды, иң кирәге — карт юк. Мәгыйзь газаплана, ыңгыраша — сөйлисе сүз күп, бутала, теләсә нәрсә сөйли. Күнитек башы шактый ук былчыракка каткан Мәсгутькә карап ала, җирәнгеч кыяфәт белән сөйләп китә.

— Ызначит, болай: аяк киеме әйтә икән хуҗасына, әйдә, ди икән, син мине кичтән матурлап куй, и һәм мин сине иртәгесен матурлыйм.— Мәсгуть моны аңламый, авызын ерып утыра бирә.

Ул арада идарәгә Хәсән карт килеп керә. Керә туры Мәгыйзь бүлмәсенә. Теге бүлмәләргә кереп йөреп булмый. Дөресрәге — уңай түгел. Анда кызлар утыра, исәплиләр, тегесендә партком, монысында бөртекләп бодай санйыйлар, эллә ниткән вак үлчәүләр. Мәгыйзь бүлмәсендә исә — элекке заман рухы көчле: иске счет һәм... сүз.

— Ызначит, болай: Ленин бабайдагы кешелекне әйтәм әле. Күзенә дару тамызырга бер профессор килеп йөргән моның.— Мәгыйзь юри пауза ясый, чөнки Ленин, Тухачевский, Фрунзе, Блюхер, Дзержинскийлар турында сөйләгәнне тыңлаганда Хәсән карт тын да алмый: бу темалар аның өчен изге.— Учуныйлар әйтәләр аны, ызначит үз гомерендә (чут төймәсен чартлатып Мәгыйзь бер чыбыктан биш, икенчесеннән дүртне сала) беләсезме күпме китап актарган, укыган Ленин? Беләсезме? (Чутның өскерәк чыбыкларыннан өч төймәне чартлатып сала). Өч йөз меңнән артыгракǃ Белдегезме? Аңа нинди күз чыдасын!

Бу минутта Хәсән карттан да бәхетле кеше юк. Тик аның теге вакыйганы — күзгә дару тамызу турындагысын беләсе килә.

— Шуннан?— ди ул, ябык ияген Мәгыйзьгә таба сузып.— Шуннан?— Хәсән карт, колаклары бик үк ышанычлы булмаганлыктан, сүзне ияге белән тыңлый.— Күз даруы, дим...

— Ә-ә, аны әйтәсең икән. Менә бер кичне профессор Ильичның фатирына килгән, калошларын салган, чишенгән, бүлмәгә узган. Ильичның күзләренә дару тамызган, китә башлаган. Ишек янында бераз караңгырак икән, калошларын таба алмый ди бу. Шунда — ялт! — Ильич бөкрәйгән дә калошларын тегенең аяк очына китереп тә куйган.

— Ышту сез, ышту сез,— ди икән профессор. Каушаган теге. Ленин үзе и һәм бөкрәеп калош элли.

Мәгыйзь тәмәке суыра, үрелеп кенә метрлы линейка белән форточканы этеп ача, линейка утызынчы еллардан бирле идарәдә, ул инде сөяккә әйләнеп беткән, әйтерсең, үтә күренмәле.

Шул вакыт Мәгыйзьне телефон бүлдерә һәм ул озак кына итеп райпланмы, сельхозтехникамы — бер оешма белән сөйләшә. Хәсән карт чыдый алмый, рәнҗеп чыгып китә. Бухгалтер кнәгәләрен озак актарып, чутта нәрсәдер исәпләп алгач кына Мәгыйзь сөйләп бетерә. Хәсән картның моңа кабат кайтарачагын белеп сөйләп бетерә:

— Теге профессор уңайсызланып, каушап калган. Каушаудан һич кенә аягын калошка туры китерә алмый икән. Ул арада булмый, Ильич бөкрәя дә, тегенең калошын җайлап киертеп тә куя. Профессор тагын «ышту сезләп» маташкан арада — икенчесен дә. Профессор телсез калган. Ә Ильич — киноларда күрсәтәләр бит әле — хәйләкәр елмаеп баш бармакларын жилетына кыстырып тора — Ильич шулай итеп баскан да, елмая ди. Тегесе һаман:

— Ышту сез... — ди икән. Шунда Ильич әйткән:

— Ә мин балачактан семьяда шулай тәрбияләнгән,— дигән.— Бездә,— дигән,— шулай тәрбияләделәр: укытучыга, врачка аеруча ихтирамлы и һәм дә игътибарлы булырга.— Менә ничек дигән ул.— Укытучыга и һәм дә врачка, дигән... Әле менә искә төште,— дип Мәгыйзь үзенең яраткан фәлсәфәсенә кереп китә.— Партиянең көче кайда? Халык белән киңәшеп эш итүдә. Киңәшле эш таркалмас, диме халык? Ә теге вакытта кайбер иптәшләр киңәшмәде. Партия моны волюнтаризм дип атады. Ул бит сиңа булмый теге замандагыча. Менә, мәсәлән, мин үзем...

Шул вакыт идарәгә бер кәгазь тотып Хәсән карт килеп керә, Мәгыйзь сизеп тора инде, аны карчыгы җибәргән, бар әле, тыңлап бетермәгән көе ник кайттың, дигән. Һәм Мәгыйзь сүнгән төпчегенә ут яңартып сүз башлый:

— Тәмәкенең иң затлы сорты икәү генә. Икесе дә Төркиядән чыккан. «Трапезунд» һәм «Самсон». Безнең илдә бу сорт Абхазиядә генә үсә. Инде шуның яфрагын киптереп өстенә бераз гына юкә чәчәгеннән яки карабодайдан җыелган сыек бал да сиптерсәң — шуны тартканда тутырган тавыкларың, каклаган казларың, алма-хөрмәләрең бер якта торсын. Менә быел әле шуны үзем үстерәм...

Хәсән карт явыз карап аның өстәле янына килеп утыра. Кәгазен суза. Мәгыйзь укып та тормаган кыяфәт белән тиз генә кул куеп кәгазьне кайтарып бирә: ике кило бал сатып бирүләрен сорый икән карт. Хәзер үзе умарта карый алмый — факт. Ә Мәгыйзь рәхәтләнә.

— Ә менә Кушма Штатларда ничек? Анда теләсә нинди кыз, егет — студентларны әйтәм,— тәнәфес вакытында килеп теләсә нинди профессордан сигарет сорап алып тарта. Һич тә гаеп ителми.

Мәгыйзь шулай өенә хәбәр алып кайтырга тиешле Хәсән картны газаплый. Теге вакытта, авыл тарихын язганда аның өендә тәмәке тарта алмыйча газапланып утырган сәгатьләре өчен газаплый.

— Әле менә кичәге газетаны укыдыгызмы? Кавказдагы йөз илле бер яшьлек карт турында язганнар?

Хәсән карт, колак яфрагын турайтып, ияген сузып Мәгыйзьгә таба шуышыбрак утыра, Мәгыйзь моны сизә, үзе кенәгә актара, үзе сүзен дәвам итә. Ләкин бөтенләй башка темага.

— Яшь чак — гайрәтле чак,— ди икән бер чуаш карты шулай җыелып гәп сатып утырганда. Бөтенесе шаккатып тыңлый, ди.— Яшь чак — гайрәтле чак,— ди икән бу.— Айлы төн, күзне йокы алмый.— Шул вакыт Мәгыйзь үз сүзен дә кыстыра:— Бүген иптәш Гарәфиев райпланга китте, идарәдә дисциплиния бераз йомшаграк, ну инде безь ул юк дип, үз эшебезгә зыян китерүчеләрдән түгел. Әле болай гына әйтүем — аулагөй, дип.— Яшь чак, гайрәтле чак,— ди икән әлеге чуаш.— Ай яктысы, күзне йокы алмый. Карап ятам, нәрсәдәндер күңел шикләнә. Ул арада капка-койма селкенгәндәй итте, сикереп тордым, тәрәзәдән карыйм — ике кеше ат абзарына таба шуыша. Һи-и-и, минем яшь чак, гайрәтле чак. Идәнгә карадым, ай яктысында ялтырап идәндә балта ята. Иртән урманга барасы бар, кичтән генә кайрап, Гали пәкесе итеп куйган идем. Ялтырый теге. Ә минем — тегеләр инде ат абзарының ишеген ачып яталар — миңа нәрсә — минем яшь чак, гайрәтле

чак. Теге ялтыравык балтаны кулга алам мин. Әти карт белән әни карчык берни белмичә йоклыйлар. Ә минем — гайрәтле чак. Шуннан... карыйм тегеләр безнең көрән айгырны йөгәнләп абзардан алып та чыктылар. Ай яктысы. Балтаны кысып тоттым. Чөнки минем — яшь чак, гайрәтле чак. Карыйм — тегеләр атны ишегалдыннан капкага ук алып киттеләр. Ай яктысы — минем кулдагы балта ялт та йолт килә. Чөнки — минем яшь чак, гайрәтле чак. Беләктәге куәттән балта дер-дер килә. Минә бервакыт капка ачыла, атны алып чыгалар болар. Ә минем бик хәтәр вакыт — яшь чак, гайрәтле чак...

Мәгыйзь эффектын тикшерер өчен Хәсән картка карый: Хәсән картка кирәк булган ник кенә бер информация чыксын! Ни халыкара хәл турында, ни Бәгъдә турында! Ә Мәгыйзь рәхәтләнә.

— Менә шулай атсыз калдык. Ә минем — яшь чак,— ди икән чуаш карты.

Хәсән карт, аңа рәнҗүле карап, өенә кайтып китә. Ике кило баланы — малмени ул, өйгә алып кайтырлык яңа хәбәрен булмаганда... Җитмәсә әле, чыгып киткәндә генә аны Мәгыйзь туктата:

— Амбарга бар да ал, Хәсән абзый, председательнең кулы юк монда, ну инде минем кул булгач, дукәминт безнең колхоз территориясендә зур көчкә ия. Ул бит болай түгел (яңа папирос кабызып):

— Ызначит, бер илдә зарланалар икән дә, студент-мазардыр инде, нигә бездә конституция юк дип. Ярар, дигән, боларның патшасы, булыр. И һәм гәзиттә бер көнне конституция басылып чыккан. Ике статьядан тора ди. Беренчесе: «Безнең мәмләкәттә бөтен власть патша кулында, ул нишләсә дә ирекле». Икенчесе: «Әгәр шуңа шикләнсәң, беренче статьяны укы». Менә шулай, Хәсән абзый. Камиләттигә бездән сәлам әйт...

## XIX

Унсигезенче март җыелышында, әлбәттә, Ахиярны яңадан сайлап куйдылар. Җыелыш гаугалы булды. Байгильдеев башта үзе килмәкче иде, планын үзгәртте: Халидә Әхмәтовнаны җибәргән. Кичтән райкомга чакырып, Ахиярга әйтте Байгильдеев:

— Я, нәрсә кыланасың? Синнән башка мин нишлим? Сез бит Евдокимов белән икәү генә. Сездән башка мин кем? Әле бит ярдәм итеп «Көрәш»не дә аякка бастырасың бар! Как-никак, газиз балаң бит! Әйдә, малай-шалай булма әле, иптәш Гарәфиев...

— Шулай да мин үземне азат итүләрен сорыйм. Кадр әзер — Рәиф өлгереп җитте. Дөресрәге — өлгерүдән узды. Халыкка мин шулай диячәкмен.

— Рәифкә тими тор. Заготзерно директоры картайды. Тузды. Рәифнең үзенә әлегә әйтмә, ләкин партия райкомында аны заготзерного алу турында фикер өлгерде инде. Тагын бер срок, иптәш Гарәфиев. Һәм отчет-сайлау җыелышында — концерт куйма! Кылануга охшамасын! Аңладыңмы? Пока! Ә гаризаңны укып кара! Шунда белерсең, китәргә ярыймы, ярамыймы. Пока!

Отчет җыелышында Ахияр авырлык белән үзенең гаризасын укыды. Укыды — Байгильдеевның сүзе искә төште: «Концерт куйма!» Концертны Кәшфи Габделбарыев башлады. Аңа инде теш куйганнар, ул, элеккечә, яшь вакытындагыча, әтәтерләнеп сөйләшә, ашыга, җөмләне вата, боза иде.

— Аның өчен чөнки, иптәш колхозчылар. Мин дулкынланам чөнки. Ни өчен дисәң, иптәшләр, алай бөтенләй ярамый. Ярамый и вчу! Чөнки, әгәр иптәш Гарәфиевне бүген председательлектән азат итсәк, мин инде моны болай гына әйтәм, мин иртәгә үк башка колхозга күчәм. Гариза язып. Дөрес, миңа да пенсия алыр вакыт житкән, минем шәп чыга, миң райсобес белән сөйләштем — йөз егерме чыга, диделәр. Ләкин

мин инде чөнки тик ятмыйм, аның өчен иптәш Гарәфиевне бүген сайламасак, яңадан шушы постка, мин инде чөнки, бу колхозда калмыйм. Миңа трактор булса, җир булса — шул җиткән. Мин — чөнки киң күңелле кеше. Безнең Советлар Союзында теләсә нинди колхоз туфрагы — минем туган җир. Ләкин инде шушы үзебез туган җирдән иптәш Гарәфиевне ычкындырабыз икән... ...Ычкындырабыз икән...— Шулчак Кәшфи чалбар кесәсеннән таушалган кулъяулык чыгарды. Күзләрен сөрткәндәй итте.— Ычкындырабыз икән...— Кинәт ул урындыкларны җимергәндәй итеп ду купты һәм кешеләрне бәрә-бәрә клуб артына — чыгу юлына таба китте. Зал бер мәлгә югалып калды. Арткы ишеккә барып җиткәч, Кәшфи кинәт борылды да президиумга кычкырды:

— Белегез, әгәренки шушы башбаштаклыкка юл куясыз икән, мин иртә таңда өлкә комитетына юлга чыгам,— диде. Аннан — тарихта булмаганча — борылып чыгышына үкереп елап җибәрде:— Аның өчен чөнки... Хәзерге яшьләр аңламый. Кадрлар мәсьәләсе... И һәм дә... Чөнки...

Халидә Әхмәтовна берөзлексез елмаеп утырды. Ник елмаям әле мин — райком секретаре? Аның башына шундый шөбһәле уй килде. Райком секретаре икәнсең — җитди бул, никадәр җитди булсаң, халык алдында шулкадәр дәрәҗәң, абруең зур булыр. Ник елмаям мин?— Ул шулай үзен-үзе каһәрләп утырды. Ләкин бу сорауга җавап тапмады. Аның өчен чөнки... Мондый җыелышны, председательне калдыру-калдырмау мәсьәләсендәге мондый мелодраманы беренче күрүе иде.

Ул арада амбар мөдире Мәсгуть кул күтәрде. Пенсиягә әллә кайчан вакыт инде, китми бит, көн-төн амбарда ята. Теге фаҗига аны каратайтты. Ахияр теге көнне Мәгыйзь сөйләгәнне тыңлагач, киңәш бирде: әлегә әйтми торыйк. Мәсгутьнең авыр вакыты. Сигез бала. Теге — чибәр, йомшак кызны, кара мыеклыларга ияреп харап булган кызны исәпләмәгәндә — җиде бала. Барысы да укый, кем институтта, кем техникумда. Мәсгутьнең тормышы авыр. Ул җыелышта да авыр шыгырдап басты. Сөйли белми иде, моны үзе дә, клубта утыручылар да яхшы аңлый иде. Ахияр каты, көчле, бирчәйгән учлары белән маңгаен кысты. Әле февраль ахырында гына бер көнне аңа халык контроле председателе Рәхмәт килеп әйтте: Мәсгуть, диде, көн аралаш, кул чанасы тартып басу түреннән, эскерттән арыш саламы ташый. Һәр таңда. Нишлибез?— диде Рәхмәт.— Кәнишне, мин эшне зурдан кубару ягында түгел, ләкин — колхоз милкен урлый. Нишлибез?

— Нишлибез?— Бу сорауны өенә кайтып, телевизордан «Время» тапшыруын карап бетергәч, урынына ятканда председатель Ахияр үзенең шәһәр тәрбиясе алган хатынына бирде.— Нишләргә? Ә?

Ахияр инде ул сорауны болай гына бирде — шәһәр хатыны нәрсә белә инде ул? Авыл кешесенең эчке дөньясын белүче шул булдымы? Болай гына инде ул... Ләкин Сольма кухнядан чыгып, алъяпкыч итәкләренә бармак очларын сөрткәләп (Ахияр белеп тора: Сольма ире яраткан винегрет ясый) болай диде:

— Син, җаныкаем, шуны онытма, аның бит баласы күп. Нишләсен инде ул? Күп бала белән...

Ахияр шунда айнып китте. Ие, монда әле нинди мөмкинлек, власть, байлык белән ике бала үстерүнең очына-кырыена чыгып булмый — гел проблема. Ә бу иптәшнең сигез бала. Фу-у, чурт... Хатын-кыз димә, югары белем шул, инженер башы шул...

Ахияр шунда яратып Сольмага карап алды. Сольма исә бу карашны әрәм итмәде, тиз тотып алды. Утыз еллар элек районның элемтә бүлеге начальнигы Ахияр Гарәфиев дигән егетнең йөзендә шундый кадерле, сөйкемле бер караш булып ала иде...

Мәсгуть күтәрелде. Бичара, сөйли белми иде. Дөнья әллә ничек корылган шунда: кемдер җыелышта-фәләндә сандугачлар булып сай-

рый, теле-телгә йокмый, халыкны әлләниләргә өйрәтеп бетерә. Ә бала үстерә алмый. Ә кемдер илгә, Ватанга сигез-тугыз кадр үстерә, җыелышта торып басса — ике бозауга кибәк аера белми. Тел юк. Мәсгуть тә шулай: басты, салган бүреген кул аралаш йөртте, йөртте дә башына киеп куйды. Тамак кырды. Сүз башлады.

— Иптәшләр, ни бит... Болай булмый. Болай ярамый.— Ул авыр сулады, үзенең әлегә әйбәт кенә сөйләп баруына шатланды булса кирәк, йөзенә елмаю чырае чыкты.— Болай булмый. Мин үзем — фәрештә түгел. Шушы җирдә тудым, шушы җирдә торам. Безнең колхоз миннән башка да яши ала. Мин — булдым ни, булмадым ни... Ну бит ләкин...— Ул тагын тамак кырды.— Ну бит тә ләкин, иптәшләр. Алай булмый. Алай һәм ярамый. Һәм дә мин, шушы колхоз члены буларак, каршы. Каршы мин, белдегезме? Алай ярамый. Нишләп без әле һәм алай эшләргә тиеш?

Халидә Әхмәтовна гел елмайды. Мәсгуть исә, аның чыраен тотып алып, тагын да кыза төште:

— Дөрес түгел бу, иптәшләр. Мин шулай уйлыйм. Нигә?— ул арткы рәтләргә борылды.— Ник кирәк? Тик торганда... Юк, мин риза түгел. Дөрес түгел бу...

Халидә Әхмәтовна инде рәхәтләнеп көлә иде. Кемне яклый бу кеше? Нинди принципны яклый? Нәрсә әйтергә тели? Нәрсәгә каршы бу? Белмәссең...

Әмма зал барысын да белә, аңлый иде.

— Дөрес! Молодец! Рәхмәт!

— Рәхмәт сиңа, рәхмәт,— дип ирләр шау итте.

Мәсгуть тә тирләгән маңгаен пальто җиңе белән сөртеп, авыр шыгырдап урынына утырды. Ахияр аңлады: Мәсгутьнең аны яклап сөйләве иде бу, тик әйтеп кенә бетерә алмады. И агай-не! Минме инде сине аңламыйм? Минме? Минме? Рәхмәт сиңа, туган!

Халидә Әхмәтовна председательне яңа срок белән котлады, чәйгә кереп тормады: — Мондый җыелышны үз гомеремдә беренче тапкыр күрдем, иптәш Гарәфиев,— диде.— Халыкның кадерен белә күрегез. Яңа партком секретаре турында уйлый башлагыз. Без дә уйлыйбыз. Я, тәбрик итәм сезне! Хатыныгызга миннән сәлам...

## XX

Ахияр тагын бер йокысыз төн уздырды. Борчулар байтак иде. Рәиф урынына кем булыр? Эшләү өчен бик җайлы малай иде. Табигать биргән сәләт — кешене тыңлый белә. Ахияр кешегә бу сыйфатны югары белем, дәрәҗәле урын бирә дип уйлап йөргән иде. Ялгыш фикер икән. Әле күптән түгел генә районга бер төркем язучылар килде: район активы берничә председатель (шул ук инде: Гарәфиев, Евдокимов — тагын бер-ике) белән сөйләштерер өчен актив ахырында бер мәҗлес оештырды. Ресторанның эчке бүлмәсендә — район җитәкчеләреннән өч-дүрт кеше, өч-дүрт председатель һәм дүртләп язучы — шаярышкан булып тостлар әйттеләр. Кунакларның Ахияр кырыена туры килгәне кырыкларны узган ир иде. Ахиярга авыз да ачтырмады. Беткәнче үзе сөйләде. Хәтта Ахиярның исемен дә, кайда, кем булып эшләвен дә сорамады, кызыксынмады. Үзе — авыл турында роман яза икән, Ахиярга гел шул романдагы геройлар, аларның язмышы турында сөйләде. Мәҗлес тәмамланганда Ахияр инде тәмам диванага әйләнгән, сугылган көлтә булган иде. Байгильдеев хәйләкәр карап, хәйләкәр елмайды. Бу караштан Ахияр менә нәрсә тотып алды: — Алаймы, иптәш Гарәфиев, авырмы? Син тегендә — кырда иялəнгән берүзең командующий булып. Менә син ике сәгатькә чыдый алмыйсың, ә мин атна буе кемнәрне генә кабул итмим? Шәһәр тирәсе райкомының секретаре булып кара әле

син. Ай-һай, сиңа кыен, ә? Ә мин — түз! Елмай, киң күңеллелек күрсәт, тыңла... Минем нервлар капроннанмыни? Нейлоннанмыни? Ә?

Ахияр шул көнне генә Байгильдеевның да, Халидә Әхмәтовнаның да, Рәифнең дә искиткеч бер әйбәт сыйфатка ия булганлыкларын аңлады: болар кешене тыңлый беләләр. Әйе, тыңлый беләләр. Ә теге иптәш... Ахияр бер-ике тапкыр авыз ачып караган иде. Юк, теге иптәшнең күзләре алмашынган, ул инде үзе турында гына уйлауның тәмен белгән һәм янында утырган йөз ун кило авырлыктагы Ахиярны һәр ике тапкырында пучтәк кенә җөмлә белән кисте дә куйды:

— Нәрсә дип әйтим... Тукта, болай... Менә минем егермеләп китап чыкты. Минем соңгы романда менә болай... Менә мин үзем. Нәрсә дип әйтим... Мин әле институтта укытам да. Доцент. Нәрсә дип әйтим...

Мең яшәгез, Байгильдеев иптәш, Халидә сеңел, Рәиф энекәш! Сезнең белән эшләү, билләһи, җиңел!

Әйе, Рәиф урынына кемне куясы?

Ләкин йокламас өчен сәбәпләр ул гына түгел иде. Кичә кичен генә идарәгә Камилә карчык килде. Керә-керешли үк җырлап-сөйләшеп узды.

— Ахияр энем. Ни бит... Бабаң начарланып китте бит. Үлем исереклеге керде. Кичә иртүк үк, чәй эчкәч, йөрәк бик леперди әле дип әйткән иде — кичкә таба алмашынып ук китте. Бүген төн чытлы йокы күрмәдем. Гел саташты, картны әйтәм. Гел кычкыра «бәтәлиун ысмирна» дип кычкыра. Нәрсә дигән сүздер инде ул. Ходай белсен. Аңарчы гел сөйләнеп ятты: кырык мең солдат күпмени ул, бер пулык ул, ди. Гел шуны әйтте. Әле бүген аңына килгәч әйтә: мин, ди үземнең тормышымны менә шушы дәфтәргә яздым, шуны персидәтелгә тапшырасым килә, безгә кереп чыксын, ди. Минәйтәм, аны сәламәт йөргәндә ник тапшырмадың? Үлармен дип башыма да китермәдем, ди. Белдеңме шуны? Вәт, минәйтәм, Исәкәй... Туксан дүртенче белән бара бит. Мин ди, моны ди, ун ел элек язганыем. Шуны кереп алсын, ди. Менә карт аңына килгән арада сиңа торып йөгердем. Таягыма әйттем: әйдәле, дидем, шул исәр картның йомышын персидәтелгә алып барып тапшырсын әле Камилә карчык, дидем. Әйдәле, дидем, әйдәле...

Камилә карчык ничек тиз керсә, шулай тиз чыгып та китте. Ишек яныннан борылып кире килде дә әйтте:

— Син инде иртәгә бер вакыт табып кереп чык. Бик чиста күңелле карт бит! Сине бик яратты шул. И-и-и... Кара инде, ул Сәйяфны бүген! Тагын туй итәләрме, ди? Шау итеп җырлый — урам уртасында! Безнең карт андый эчү-фәләнне, тәмәкене бер дә яратмады. И-и-и аллам...

Һәм идарәдән чыкканда Камилә карчык көйли-көйли атлады:

— Әйдәле, әйдәле, карт янына алып кайт әле мине. Әйдәле, тагын нинди бәтәлиюннар, пулыклар уйлап тапты икән Хәсән бабаең...

Ахияр әйләнде, әйләнде. Рамильнең ничек булды икән бу арада хәлләре? Аның бөтен кайгысы — Кустанайдан салам китерту. «Көрәш» колхозы терлекләргә азык базасы булдыру турында алай баш ватып тормаган, Кустанайга иялэнгән. Ел саен, кыш саен. Колхоз егетләре дә инде Казахстан совхозларына барып кыш уздыруга күнеккәннәр. «Көрәш»тә бик күп кешене алыштырырга кирәк. Рамиль әле яшь, тәҗрибә — юк. Бөтенесен берьюлы алыштырырга ярамый. Мәсәлән, элеккеге председательне йөрткән шоферны нишләтәсең? Колхозны тегеләй дә, болай да туздырганнар. Моның иң информацияле шаһите председательне йөрткән шофер. Аны нишләтергә? Унбиш ел бергә йөргәннәр элеккеге председатель белән. Унбиш ел... Әйтергә генә ансат. Күргәннәр, белгәннәр — кем күпме эшли, кем иза чигә, ә кем урлый, рәхәт күрә. Болар үзләре дә рәхәт күргәннәр. Рамиль сөйләде этисенә: килеп эшли башлаганның икенче көнендә аңа ашыгыч рәвештә Ташлытауга

барырга кирәк булган. Шимбә көн иртән. Чакырткан шоферны. Тегесе әйткән:

— Коробка передачиның бер дә рәте юк, ике-өч көнсез юлга чыгарлык түгел, ремонтта ятам,— дигән.

Рамиль таш юлга чыгып, «салют биреп» бер машина туктатып, Ташлытауга киткән. Йомышын йомышлап кайтырга чыккан — караңгы, пычрак, адәм аяк атламаслык икән. «Салют биреп» таш юлдан кайтучы «Бензовоз»га утырган, кичке караңгыда аннан төшеп калып, былчырак ерып «Көрәш» колхозы территориясенә кереп киткән. Шунда каршына ике фара якынайган. Рамиль юл биреп калган, әмма таныган: председатель машинасы. Эчендә — элеккеге председатель. Хатыны белән. Менә сиңа «ватык машина!» Рамиль юл сабып читтә калган. Иртәгесен шофер аның янына гариза тотып килгән: «Мин — гаепле, мине бу эштән азат итеп, йөк машинасына күчерүегезне үтенәм. Имзам: Хәммәтуллин».

Рамильгә әйтте Ахияр: калдыр, күчерми тор. Үз гаебен аңлаган кешедә өмет бар...

Ахияр авыр шыгырдап тагын әйләнде... Ә-ә... Кустанай бит әле. Рамиль сөйләде: Ташлытау станциясенә салам тюклары килә. Колхоз кешеләре шуны бушаталар, колхоз машиналарына төйиләр. Шундый кешеләр бар икән авыл юлларында: тюк төягән машина каршына чыгалар да «ярты» күрсәтәләр. Шунда «Көрәш» колхозының завхозы — салам ташу буенча иң җаваплы кеше — өч-дүрт тюкны «ярты»га алыштыра икән. Ә фермада сыерлар көтә. Бу — һәр елны шулай икән. Инде быел, Кустанайда эшләүче тәҗрибәле якташлар салам төргәгенең бавы астына кәгазь тыгып җибәрә башлаганнар: «Әй син (әшәке сүз), завхоз, әгәр сиңа... (әшәке сүзләр) булмаган булса, бу тюкны сатып эчмә. Исән-сау кайтсак... (ярамый торган сүзләр)». Рамиль әйтә: быел бераз тыелдылар, ди. Әмма завхозны да алыштырмыйча булмый...

Йокы шулай алмады. Ахияр торды, өстәл лампасын кабызды, Сольманың паласка шуып төшкән китап-журналларын җыештырды, кухняга чыгып салкын чәй йотып керде, сокланып-яратып Сольмага карап торды: рәхәтләнеп йоклый иде. Ахиярның теге — бик әллә кайчангы заманда — үз энисе исән вакытта, ун-унике яшьләрдә генә йоклаган йокысы Сольмада әле исән икән! Ул тумбочка өстендәге кыңгыраулы сәгатькә карады, бәрәч! — әле нибары беренче ярты гына икән... Һи-и, әле хәзер үк йокыга талсаң бик яхшы биш сәгать йокы бар икән. Болай булгач, әле ярый. Шулай да, дару эчәргәме? Камилә карчык әйткән иде әнә, Хәсән карт белән йокы алдыннан ишегалдына чыгып әйләнеп йөрибез, дип. Туксаннан узгач йокы кирәкме икәнни? Ахияр алай йөри алмый инде, ә менә кухня шкафында бер дару бар: исеме «Брэнди». Шуны бер рюмка салсаң, шәт, хәл итәр мәсьәләне. Ул үзенчә акрын йөрергә тырышып кухняга яңадан чыкты, шкафны ачты. Әмма нәкъ шул вакытта ишек янындагы тумбочкада телефон тавышы ишетелде. Өзек-өзек ашыгыч кыңгыраудан аңлады: авыл җире түгел, «междугородный»дан бу. Сольманы уятуына кыенсынып, трубканы учы белән каплап кына җавап бирде:

— Да, да...

— Иптәш Гарәфиевме? — Район элемтә бүлегендәге кызның тавышын Ахияр белә иде.— Өлкә комитетыннан. Хәзер... Ярты гына секунд.

Ахияр ә дип тә, җә дип тә әйтергә өлгерә алмады, телефон шелтмелт килде дә, кинәт тынып калды. Тын каналда, минем тавышны йөз проценты белән ишетәләр, дигән ышанычлы тавыш ишетелде.

— Гарәфиев, нихәл? Төн йокысын бүлдемме?

Ахияр бераз каушап калды. Беренче икән. Өлкәдән. Шактый аптырап кухня өстәленә карап алды: «Брэнди» дигән йокы даруы электр

лампасының яктылыгын сеңдереп алтын эретмәсыман мәгънәле елтырап утыра иде.

— Ие, тыңлыйм. Юк, әле нинди йоклау...

Беренченең көр тавышы яңгырады.

— Дөрес! Бу вакытта нинди йокы әле ул? Менә безнең бюро соң тәмамланды. Әле өйгә таралыш. Менә бюро членнары сиңа сәлам әйтәләр. Ярый бит? Ә?

Ахияр каушый ук калды. Бу сүзләр нигә? Ни әйтәсе бар моның? Ә Беренче сорау бирми — сөйли генә.

— Тагын бер срокка калгансың икән? Котлыйбыз! Китәсе килми, ә? А как же! Мин аңлыйм!

— Иптәш секретарь! Мин бит... мин бит гариза укыдым. Мин бит... Иптәш Байгильдеев шаһит. Әнә ул үзе...— Беренче аны бүлдерде.

— Гарәфиев! Малай-шалай булмыйк әле. Мин барысын да беләм! Син нәрсә? Шаяруны аңламыйсыңмы? Молодец! Пенсиягә ашыкма! Әле бергә-бергә эшлибез... Шатландырыйммы?

Ахияр бөтенләй каушады.

— Нәрсә белән? Нәрсәгә шатланыйм?

Беренченең елмайганы телефоннан сизелә иде.

— Слушай... Безнең монда шундый мөмкинлек бар. Бюро членнарының фикере бердәм: сине Алтын Йолдызга тәкъдим итәргә...

Ахиярның кинәт кенә бугазына төен утырды. Кинәт кенә күз алдына колхоз ветераннары Мәгыйзь, Рәхмәт, Мәсгуть, «Емельянов» колхозы председателе Митрий, Гәр Хутордан Кәшфи, туксан дүрт яшьлек Хәсән карт, таягы белән сөйләшеп гомер уздырган Камиләтти килеп басты. Телефон тын иде.

— Син нәрсә, Гарәфиев, шатлыктан инсульт булмагандыр бит? — Секретарь тагын шаярулы тонга күчкән иде.— Каш ясыйм дип, күз чыгармыйк тагын...

Әмма Ахияр айныган, бөтенесен дә аңлап үзе өчен тиешле карар кабул иткән иде инде. Ул кысып тоткан трубкасын авызына якын китерде. Ул тынычланып өлгергән иде инде.

— Иптәш секретарь! Иптәш секретарь! Сезнең белән шушы катлаулы заманда бергә атлап баруым белән мин бәхетле...— Ул тагын нидер әйтмәкче иде, секретарь аны бүлдерде:

— Бик кәҗүнни итеп әйттең әле. Мәгънәсе ни?

— Ни дип... Менә болай. Алтын Йолдызны я — механизатор Габделбарыевка, я — Евдокимовка! Только миңа түгел!

Телефоннан елмаю сизелде.

— Я инде, Гарәфиев. Ул хәтле тыйнак булам дигәч тә... Алай ук ярамый...

— Юк, юк, иптәш секретарь! Габделбарыевка!

— Ә соң аның моннан алты ай элек кенә тагын бер орден белән бүләкләнгәнен оныттыңмыни?

— Орден? Юк, онытмадым. Ләкин...

— Карале, Ахияр Гарәфиевич... Алай булмый бит. Килер бер вакыт, Габделбарыевка да характеристика тутырырбыз. Бик лаеклы кеше, беләбез. Бик тә кирәкле кеше. Ә менә бүген бюро членнары шундый фикергә килде: иң лаеклы бер председательне тәкъдим итәргә диләр. Шундый мөмкинлек бар, аңлыйсыңмы?

— Мин хәзер бөтенләй аңладым, иптәш секретарь! Ев-до-ки-мов! Быел аларда рентабельлек утыз алты процент!

— Ә синдә — начармы?

— Начар түгел, әмма бераз түбән... Миндә — егерме алты.

— Пәри башка, җен башка, диләр. Евдокимовны иң зур орденга тәкъдим итеп ятабыз. Без барысын да беләбез монда... Алтын Йолдызны бер ел өчен бирмиләр.

Ахияр авыр сулады.

— Аннан соң... ни бит, иптәш секретарь. Минем шәхси биографиям бик үк матур булмады. Хәзер ярый инде дә...

— Беләбез. Өлкә комитеты барысын да белә.

— Аннары. Мәскәүнең үзенә генә минем өстән ничә жалоба булды... Әйдәгез, Евдокимовны тәкъдим итик...

— Фу ты, ну ты, лапти гнуты... Бу кадәр үз кадереңне үзең белми торган кеше булырсың икән. Ә болай караганда бик кызык кеше син, Гарәфиев.— Секретарь тамагын кырды.— Кыланмый торгансыңдыр бит? Мине сынап каравыңмы?

Ахияр ашыкты, йөткерде:

— Кылансам — шушы урынымда җир йотсын, иптәш секретарь.

Секретарь көлде:

— Ну, коммунистларча ант иттең үзең дә,— диде.— Я, ярар мин иптәшләр белән киңәшермен. Уйлашырбыз. Шәһәргә килсәң, кереп чык. Байгильдеев зарланды: гел сорый Гарәфиев ди. Һич канәгатьләндереп бетереп булмый, ди.

— Гел төзибез бит, иптәш секретарь.

— Дөрес! Гел сорагыз, гел борчыгыз. Узган ел нәтиҗәләре белән канәгатьме?

— Юк, иптәш секретарь.

— Ни өчен?

— Һаман да әле үзем теләгәнчә үк барып чыкмый.

— Молодец, Гарәфиев! Мин монда туйган: нихәл?— дип сорыйсың. Күбесе: отлично!— дип кычкыра. Тикшереп карыйсың — отлично түгел. Я, ярый, хуш. Теге мәсьәләдә уйлашырбыз.

Трубка тирләгән икән. Ахияр аны чак ычкындырды. Бик кысып тоткан икән.

Ул кухняга күз салды — өстәл өстендә теге алтынсыман сыеклык түшәмнән электр яктысын сеңдергән дә әйләнә-тирәгә нур чәчеп утыра. Ахиярга җиңел, бик җиңел булып китте: өлкә комитетының бюросында бүген аның үзе, аның эше турында сүз алып барганнар. Уңай бәя биргәннәр. Димәк, гариза язып ашыккан ул беркөнне. Димәк, әле эшләргә мөмкинлек бар. Димәк, әле ышаналар, синнән эш, хезмәт көтәләр...

Беренче әтәчнең тоныкк тавышы тирән абзар эченнән — бик еракътан ишетелде. Бала вакытта Ахияр әнисеннән сорый иде:

— Әтәчнең иң беренчесе вакытны каян белә? Анда, абзарда караңгы бит?

Әнисе әйтә иде:

— Җир астында зур бер әтәч яши. Төн уртасы авышкач әнә шул әтәч канатын кагынып кычкыра. Моны җир өстендәге әтәчләр ишетеп алалар. Аннан соң инде алар да кычкыра башлый.

Бу төн уртасы авышканда, нигәдер, ерак балачакның шундый матур бер әкияте искә төште.

Балачак әкиятләре онытылмаган икән,— димәк, яшәргә дә, яшәргә әле. Әнә кичә Хәсән карт шул әкиятләрдән аерылган. Ахияр елмаеп куйды: бер полкта күпме солдат булганын Хәсән карт, Ахияр, Мәгъйзь, Рәхмәт, Кәшфи яхшы беләләр инде. Әле аны Сәйяф тә белә.

Әйе, бераз йоклап алырга да, Хәсән карт янына кереп хәлен белеп чыгарга кирәк булыр. Сугышмаса да, постта* тормаса да, Колан Кыр исемендәге «укчы полкның» бер солдаты иде әле ул...

## XXI

Зәңгәр март күге нигә шулай мәһабәт шаулый соң? Яшьлеге белән мактанамы? Күк гөмбәзе шулкадәр зәңгәрлеге белән кемнәрнең күңе-

лен жилкетә? Март күге — бу дөньяда әле беренчеме? Әллә быел гына-мы? Син әгәр шулай дип ышанып шауласаң, ялгышасың... Әнә яшьләр ышансын. Мондый язлар, мондый мартлар булды инде Ахияр гомерендә. Күп мартлар, күп язлар. Син мәңгелек, әмма кешеләр синә сокланып яшиләр, яшиләр дә сине калдырып китеп баралар. Кешеләрне кызган!

Әнә өч көн элек — март аеның соңгы якшәмбесендә зәңгәр күк белән мәңгегә хушлашып Хәсән карт китеп барды. Теге көнне ул Ахиярга ике калын дәфтәр биреп чыгарды. Хәер, биреп чыгарды дип үк әйтеп булмый. Хәсән карт караватына утырып ястыкка сөялгән һәм яшьлегенә кире кайткан да, шат чырай белән хәрби команда бирә иде.

— Бәтәль-ю-у-ун! Һир-ра! На кра... ул!

Шәйтан алгыры, дәфтәрләрен гарәп шрифтында язган. Язуы әйбәт үзенең, әмма Ахияр бер кич утырып ике-өч җөмлә укый алды. Беренче дәфтәрдә «минем солдат булуым, Австрия фронтында булуым, аннан Германиядә, Төркиядә, Иракта — Англия-Төркия фронтында булуым, шуннан качып Истамбул аркылы кайтып, Одессада аклар кулына төшүем һәм Самарага кайтып җиткәч кызылларга чыгып краснәармиес булуым тарихы» диелгән. Бу булды — бер кичлек. Ахияр игътибар итте: Хәсән карт моны озак язган, ике төрле кара кулланган. Бүлек башлары, абзац башлары, текстта очраган кеше исемнәре, шәһәр исемнәре — барысы да кызыл кара белән. Калган текст — каян тапкандыр, ялтыравыклы яшел кара белән. Калын дәфтәрнең беренчесендә Ахияр әллә ничә тапкыр язылган бер үк фамилияләргә, бер үк шәһәр исемнәренә игътибар итте: Зюссен лагере, Ташлытау өязе Кара Чыршы авылы егете Шәяхмәт Кәлимуллин. Икенче дәфтәр исә егерменче-утызынчы елларны яктырта булса кирәк, кызыл кара белән язылган ике-өч урынга күз салып, Ахияр тынсыз торды: Гәр Хуторның Гарәфи дигән сүзләр бар иде анда. Ахияр шунда үзенең иркенләп гарәп шрифтындагыны укый алмавына җан ачысы белән үкенде. Бу дәфтәрдә аның нәселе, аңа кагылышлы хәлләр турында байтак мәгълүмат бар иде!

Әнә кичә — бу дөньяда күргән ачы хәсрәтенә, Ватан сугышы кырларында алган җәрәхәтләренең сызлавына чыдый алмыйча безне калдырып дөньядан Мәсгуть китеп барды. Үлемен теге кыз тизләтте: Ахияр ни түзеп карады теге серне саклап, әмма Мәгыйзь, Рәиф өчәү бергә киңәштеләр дә, чакырып әйттеләр; кызың исән. Атна буе Мәсгуть күргән газаплар, борчулар! Кыз белән күрешү һәм коточкыч биографиянең шаһите булу! Мәсгуть тәмам кешелектән чыгып кайтты ул вакытта. Кайтты, егылды һәм дүрт-биш көн яттымы икән: врачлар инсульт диделәр. Колан Кырда мондый диагноз белән үлгән кеше булганы юк иде әле моңарчы.

Күк гөмбәзе бүген биек, бик биек. Мондый зәңгәр гөмбәз тагын кайчан булыр икән? Элек ул ешрак була иде сыман. Мәсәлән, Ахиярлар, Кәшфиләр бала чакта. Аларны урманга — нарат күркәсе җыярга алып кергәлиләр иде. Шул вакытта нарат шавының аһәңенә исереп күккә карап ятып торгалыйлар иде. Ул күк — Ахиярлар, Кәшфиләр балачагының күге шулай бик биек, бик зәңгәр була иде. Аннары кырык бишенче ел мартының күген хәтерли Ахияр. Карпат таулары арасында, ниндидер бер көнне шулай тынлык булды. Ахияр, ничек алай туры килгәндер, бер көнне ике сәгатьләп күк гөмбәзенә карап ятты. Анда да шулай күк җиле, зәңгәр тоташ һава агымы иде. Хәтерли: әле оялып та куйды. Менә анда, тылга кайткач, үзеңнең сугышта ниләр күргәнеңне сөйлисе булыр. Карпатка килеп җиткәч Ахияр инде исән кайтырмын, дип ышана ук башлаган иде. Ә менә бу рәхәтне сөйләсәң? Кешеләр гаеп итәр бит! Зәңгәр күккә карап ике сәгать яттым, дип сөйләсәң... Аннан соң... Тукта, шуннан соң — нәрсә? Нәрсә? Бәрәч, шуннан бирле күк йөзенә күтәрелеп каралмаган түгелме соң? Юктыр, каралгандыр. Ка-

ралгандыр. Әмма ул очракларда инде күк йөзенә бала Ахияр түгел, сержант Ахияр түгел, ә председатель Ахияр карый иде.

Ахияр урман буендагы юлдан авылга таба атлады. Агрономны, башка иптәшләрне борчымады, болай гына карлы басудан ялгыз әйләнеп кайтырга булды. Трактор ясаган эздә юка элпе инде зәңгәрләнеп кояшка тирләп утыра, иксез-чиксез басу күгелҗем-зәңгәр кар дәрьясыннан тора иде. Ахияр уйланып кайтты: соңгы елларда колхоз председательләре турында күпме фильм куелды, күпме очерк, хикәя язылды. Күпме, күпме әсәрләрдә колхоз председателе образы бар хәзер. Дөрес язалар, әйбәт язалар. Барысы да тормыштагыча. Әмма бер серне белмиләр, шәйтаннар! Хәер, аны кеше белмәсен дә инде! Председательнең иң бөек, иң рәхәт минутлары була. Ул минутлар (бик сирәк кенә — сәгатьләр) — анықы, бары тик анықы гына! Ул минут, сәгатьләр председатель, үз колхозының басу түренә чыгып ялгыз калганда була. Язмы ул? Көзме? Кышмы? Төрле вакыт булырга мөмкин, ләкин җәй генә түгел. Җәй көне андый сәгать була алмый.

Менә председатель Ахияр шундый рәхәт минутлар кичерә хәзер. Март җиле биткә бәреп исә, әмма карны күтәрә алмый, кар дингезенең өстен зәңгәр-күгелҗем элпе каплаган. Кар хәзер шул элпе аркылы кояш нурын сеңдерә генә ала. Бөтен күк шаулый, көньяктан шул зәңгәр шау белән яз килә, яз килә! Бу — Ахияр гомеренә бирелгән язларның алтмышынчысыдыр, өч-дүртен ул хәтерләми, әмма алары да анықы булган инде аның, һичшиксез, анықы. Менә күзне чагылдырган зәңгәр-күгелҗем кар дәрьясы офыкның теге ягына кереп сеңә, ул якта — «Көрәш» колхозы, анда — Рамиль. Ахияр бу басуларда тагын ике ел йөрер әле, ә Рамиль — гомер буена. Әтисе яшенә җиткәнче!

Механика мастерскойлары янына кайтып җиткәндә Ахиярның карга чагылган күзләре тәмам эштән чыгып авырта башлаган иде. Мастерской артындагы зур басуда тигез гөрләп йөргән дүртме-бишме тракторга карап ул шатланып куйды. Нинди игелекле чиста эш бу март кояшы астында чиста кар сөреп йөрү! Безнең кар, безнең җиргә табигать китереп салган кар, иген уңсын өчен салган кар!

Ярый әле, бу дөньяда шундый март көне бар, ярый әле шундый иксез-чиксез кар дингезе бар, ярый әле һәр елны шаулап килә торган яз бар. Ярый әле офык артындагы колхоз басуы, ул басуларның киләчәк язмышын үз кулына алып, йокысыз төннәр үткәрәчәк яшь председатель Рамиль Гарәфиев бар...

Менә бер ай үтәрме — юкмы, бу басуга кошлар кайтыр, ә бүген дөнья тулы саф һава! Көнбатыш Европаның промышленностьлы районнарына кертеп бер генә уздырырга иде бу җилне, зәңгәр һаваны...

Дөньяның бик күп кануннары үзгәрер иде шуны суласалар. Ахияр шул һава, шул кар, шул җил-җир хуҗасы буларак, үзен бик бәхетле тойды бу мизгелдә. Җир өстенә шаулап яз килгәндә нигә яшәмәскә, нигә эшләмәскә? Нигә борын салындырырга? Менә берничә атнадан тургайлар килер. Язлар бит кеше акылы кебек мәңгелек...

Гыйльфанга хат язарга кирәк: нигезеңә йорт салабыз, кайт та, яши башла. Әйдә, колхозга тәҗрибәле баш инженер да кирәк! Әйдә, яшьтәшләреңнең көчен-куәтен күрсәтик әле бер! Әйдә, гомер соңында матур итеп яшәп алыйк әле, күрсәтик әле безнең буынның кем икәнен яшьләргә! Алып китсеннәр әле безнең борчулы, мәшәкатьле, төн йокысыз эстафетаны яшьләр. Алар да шулай яз килгәнне ишетеп, кошлар кайтканын көтеп, илгә игелек китереп яшәсеннәр әле. Безнең кебек... Безне бит... Безне бит... Безне шул яшәтә бит — без бит язын кошлар кайтасын көтеп яшибез, эшлибез...

Яз җиле председатель Ахиярны тәмам исәрләткән иде...

*1982 ел, ноябрь*

## Фәнис Яруллин

### Галиҗәнап

Җыенды Ул бер дә ашыкмыйча,
Пешереп куйды өем-өем коймак:
«Кемнәр кермәс сиңа, кемнәр чыкмас —
Сабантуйда һәрбер кеше кунак».
Кычкырдылар Аңа капка кагып:
«Көрәшчеләр китте, әйдә, ашык».
«Мин килмичә барыбер башланмый ул,
Бәйрәмнәрдә мин бит иң зур башлык».
Киенде Ул көзге каршысында,
Киемнәрнең сайлап затлыларын:
Үз түсенә килешә торганнарын,
Бәйрәм кебек матур, яктыларын.
Тагын кемдер килеп тәрәз чиртте:
«Йөгерешчеләр китте, тизрәк җыен».
«Мин ашыкмыйм әле, чөнки минсез
Башланачак түгел һичбер уен».
Бетергәчтен өйдә барлык эшен,
Дәрәҗәсен үзенең саклап кына,—
Чыгып китте сабантуена Ул,
Урам буйлап, атлап вак-вак кына.
Һәм башланды шунда сабантуе...
Бу бәйрәмнең булып олы таҗы,
Иң күрекле җирдә утыра иде
Безнең галиҗәнап — Тамашачы.

### Көрәшче

Озак ятты инде Нуриман карт,
Үлә алмый шундый озак ятты.
Еракта улы хушлашырга
Быел менә өченче кат кайтты.
Аптырады авыл кешеләре:
Нәрсә тота картны, нәрсә шулай?
Тамагыннан күптән берни үтми,
Ризыгы да, ахры, беткән бугай.

Төннәр буе килене яки улы
Өзелер дип аны саклап чыкты.
Нуриман карт кара төн елгасын
Исән-имин һаман атлап чыкты.
Акты сулар, җитте сабантуе,
Тартты мәйдан абый-сеңелләрне.
Гармун моңы агылып керде өйгә,
Җилкендереп барлык күңелләрне.
Баш калкытып куйды Нуриман карт,
Гүя эчте әбелхәят суын:
Ярсып-ярсып типте арган йөрәк,
Кинәт кенә ныгып китте буын.
Нуриман карт торды урыныннан,
Чыгып китте аннан мәйданга ул.
Күкрәкләрен уды учы белән,
Түзә алмый йөрәк янганга ул.
Сабантуйның кызган чагы иде,
Көрәшәләр иде асыл ирләр.
Этә-төртә керде Нуриман карт:
— Батыр калыр икән быел кемнәр?
...Ул үзе дә көрәшче ир иде —
Йөрәк юкка шулай янамыни?
Көрәшчеләр, сабантуе күрми,
Бу дөньядан китә аламыни?!

❁

Кызлар ярыша.
Нинди гүзәл күренеш!
Мөлдерәмә тулы чиләкләре.
Ал көянтә өсләренә яткан
Аккош муены кебек беләкләре.
Сыгыла билләр. Уйный гәүдәләре,
Балериналарың көнләшерлек.
Кайсын гына алма — дөньяның иң
Гүзәлләре белән тиңләшерлек.
Адымнары нинди сак һәм күркәм!
Түкми алар суның тамчысын да.
Әйтерсең лә үз сафлыгын саклап
Бара һәркем язмыш каршысына.

❁

Әтиләр дә, әниләр дә,
Бәбиләр дә, әбиләр дә,
Малайлар да, бабайлар да,
Салпы колак маэмайлар да
Китте сабантуена...
Тик авылда бердәнбер ат
Чабышкан чакларын уйлап,
Ярышкан чакларын уйлап
Абзарда калды елап.

Сабантуе бара. Ә бер читтә,
Төп мәйданнан шактый еракта,
Дуга биеклеге ике малай
Җан-фәрманга көрәшеп ята.
Әле берсе, әле икенчесе
Өскә калкып чыга аларның.
Тик көрәшне туктатмыйлар һаман,
Басмаганнар әле каннарын.
Судья да юк, тамашачы да юк —
Ике малай монда ни бары.
Туктап ала алар, берәрсенең
Бушап китсә генә чалбары.
Көрәш кискен. Бүген чишелә ахры
Зур бәхәснең каты төене.
Һәр нәрсәнең буладыр, күрәсең,
Үз сәгате суккан үз көне.
Җиңүчегә монда тәкә дә юк,
Кызлар сузмый чиккән яулык та.
Ә шулай да ике малай бүген
Көч сынашып ята таллыкта...
Димәк,
Көрәшчеләр бетми халыкта.

## Кыңгыраулар тавышы

Сагынәм мин сабантуйларында
Чең-чең иткән кыңгырау тавышларын.
Алар хәзер чормаларда ята
Эчләренә йотып сагышларын.
Ана теле кебек якын иде,
Аңлаешлы иде алар тавышы.
Шул кыңгырау телләренә сыйган
Күпме йөрәкләрнең дәрте, сагышы.
Ул телләрне күгәртмисе иде,
Чыңласыннар, тынмасыннар иде.
Бабалары моңын оныклары
Кайта-кайта тыңласыннар иде.
Кыңгыраусыз яшьләр кавышмаган.
Кыңгыраусыз төшмәгән бер килен.
Кыңгыраулап ат җиккәннәр ирләр,
Киткән чакта саклар өчен илен.
Ана теле кебек яшьтән сеңгән
Кыңгыраулар моңы күңелебезгә.
Моңның дәвамлыгы турында да
Онытмаска иде менә безгә.
Кыңгыраулар — бәйрәм тургайлары,
Сайрасыннар иде дугаларда:
Бабайлардан калган моң аларда,
Әтиләрдән калган моң аларда.
...Кыңгыраулар ята чормаларда.

*

Туган авылым, якты тәрәзәм син,—
Иң беренче менә синең аша
Күзәттем мин серле җиһан серен,
Аяк очларыма баса-баса.
Иркен кырым — иң беренче тапкыр
Бил алышкан, көч сынаган мәйдан.
Синдә билне нығытмасам әгәр,
Бу гайрәтне алыр идем кайдан?
Авылымның горур, гүзәл кызы,
Яшьлек күгемдәге якты аем,
Мәхәббәткә булган тугрылыкны
Синнән алганмындыр мин, мөгаен.
Тел ачкычын — тирән сер ачкычын
Син биргәнсең миңа, туган халкым.
Телем якынга да — халкым якын,
Халкым якынга да — илем якын.

## Көлү аша

Яшәү авыр була кайчак —
Кайгы баса, борчу баса.
Ярый әле күп нәрсәгә
Карыйбыз без көлү аша.
Көләбез без үзебездән,
Ямьсез үткән көнебездән,
Оешмаган эшебездән,
Юкка түккән көчебездән.
Көләбез без, еламыйбыз,
Җирне яшькә буямыйбыз.
Яңгыр яуса, бар дөньяны
Су баса дип уйламыйбыз.
Үзебез еш кыйналсак та
Кеше җанын кыйнамыйбыз.
Көләбез без, ләкин һич тә
Тормыш белән уйнамыйбыз.
Җиңелүләргә, чигенүләргә
Карыйбыз без көлү аша.
Ничек җиңәр идек барсын
Пакьландыргыч, сафландыргыч
Бөек көч — көлү булмаса!

## Әйтәм, әйтәм...

Бу серемне артык яшерә алмыйм,
Аны яшерү үзе бер газап:
Утлы күмерне соң учка кысып
Саклап буламыни бик озак?!

Күңелем бакчасында алма пеште,
Өзелер дә төшәр беркөнне:
Тулып пешкән алсу алманы соң
Сабагында саклау мөмкинме?
Ул яшь бөркет, канат кагып тора,
Бәйли алмыйм аны ояга:
Әйтәм, әйтәм, каеннарга әйтәм,
Әйтәм, әйтәм, аккан елгага.
Әйтәм, әйтәм, бар да белсен әйдә,
Түзеп торыр чарам калмады.
Ул сер минем телләремне пешерә,
Битләремне ялкын ялмады.
Әйтәм, әйтәм, артык яшерә алмыйм,
Бар дөньяга үзем таратам:
Ишетәсезме мине, урман-кырлар,
Ишетәсезме мине, елга-сулар —
Мин яратам аны, яратам!

## Очрашырга тиеш без

Салават күперенең без
Икебез ике ягында;
Ашыгырга кирәк безгә,
Кавышырга кирәк безгә
Күперләр бар чагында.
Яшьлек — салават күпере,
Аның гомере кыска.
Ә хәзергә өстә кояш,
Күкләр нурдан тора тоташ,
Тамчылар бии учта.

Дөнья ефәк челтәр әле,
Күк белән җир кушылган.
Юл куймыйча болытларга,
Офыклардан офыкларга
Җепләр сузыйк шушыннан.
Үрлик, үрлик — кала күрмик
Мәңге юлда килеш без;
Күпернең нәкъ уртасында,
Күкнең биек ноктасында
Очрашырга тиешбез.

## Сиңа

Күргән саен дөнья гыйбрәтләрен,
Рәхмәтләрем сиңа арта бара.
Көн дә чагылып торган кешелегең
Күңелемне үзенә тарта бара.
Күпләр сине аңлап җиткермиләр,
Бу соң, диләр, нинди тиле йөрәк?
Сине аңлап җитү өчен дә бит
Синең биеклеккә менү кирәк.
Мине генә түгел, сөясең син
Мин табынган олы шигъриятне.
Мин табынган эшкә табынмасаң,
Аңлар идеңмени бу йөрәкне!
Мин көнләшмим ләкин, миннән ныграк
Шигъриятне сөйсәң син әгәр дә.
Гел унсигез яшьлек егет булып
Килермен мин сиңа шигырьләрдә.

## Рәшит Әхмәтҗанов

# КОШЛАР БӘЙРӘМЕНӘ ЧАКЫРУ

Яшел болыннарда — яшьлектә кал,
Дулкыннарда яшә... шауласыннар.
Ә мин китәм —
Ут күзенә кереп,
Кешеләргә бер җыр аласым бар.

Көт. Кайтырмын.
Дөрләп янсам да мин,
Күзләремдә калыр яфрак төсе.
Шул төс булыр сине сөюемнең
Мәңгелеге белән бүгенгесе.
Танымасаң, тагын бер кат кара —
Күзләремдә булыр яфрак төсе.

Күргәч... җәлләп берүк елый күрмә,—
Каршы чык та кайткан юлларыма,
Сулыш кебек кирәк, син тизрәк
Туган туфракны сал кулларыма.
Бер уч туфрак.. Күздә яфрак төсе!
Нәрсә кирәк тагын... Без бит кеше!
Туфрактан күккә күтәрелер
Могҗизалар инде — йөрәк эше.
Без бит кеше!

## Ышанма!

*Узган көннәр кебек төннәр озын...*

Нури Арсланов

Төннәр ай-һай озын... Йокламыйбыз.
Гомерлеккә, ахры, уяндык.
Шаулый урман: — Сезнең йөрәкне,— ди,—
Күккә кояш итеп куярлык.

Төннәр тоташ төтен. Ә без — учак.
Җанга төрле уйлар уела.
Дөм караңгы булмасын дип дөнья,
Йокламадык гомер буена.

Күзне йомсаң — яшь шагыйрә булып
Туган гөлне җирдә таптыйлар.
Иманнәрнең Туфан кебекләрен
Сайлап кына кисә, сантыйлар!

Һәм иң матур кошны үтерәләр,
Үз башлары кебек таш бәреп.
«Качыйк моннан, очыйк» диеп, кошны
Ак болытлар китә күтәреп...

Һәрбер гөлдә — күз нурыбыз иде,
Иман үрелгән як — кыйблабыз.
Кош йөрәген җыр итмәкче идек —
Без аларсыз, я, кем булабыз?!

Таудан ташлар булып тәгәрибез.
Иртән кояш булып менәргә.
Кошлар тагын таң балкышын күреп,
Су булмаса... коенып көлләрдә,

Очып узар әле Ил өстеннән...
Гомер шулай дәвам итәчәк.
Гомер шулай дәвам итәчәк тә,
Кыйблабызга барып җитәчәк.

Төннәр — сезнең гомер түгел, диеп
Әйтүчеләр булыр — ышанма!
Төннәребез озынайган саен,
Көн кыскара бара дошманга.

## Имән шаулаганда ишетелгән шигырь

Яшим ямь-яшел тавымда,
Беркем яшемне белми.—
Мин яшенне юкка гына
Җанга яшердеммени!

...Корычлар тузды... Ярый мин
Яралмаган корычтан:
Тетрәндем күреп кешенең
Җан биргәнен кылычтан.

Сыгылды... сынды күгәреп —
Сорамагыз тимердән:
Хәтерлим — тимер читлектә
Кемнәр, кайда тилмергән.

Яшен күргән бер яфрагым
Кадерлерәк алтыннан.

Беләм: кемнәр, кайсы чорда
Алтыннарга сатылган.

Яфраклары шауламагач,
Ник көнләшим танталдан[1]
Тамырсызлар гына аның
Ныклыгына таң калган.

Яшим дә яшим дөньяда —
Беркем яшемне белми.
Мин яшенне юкка гына
Җанга яшердеммени!

## Соклану

И дулкыннар,
Сезгә булган... булсын
Бу мәңгелек ирек!
Ялгышырмын, дигәндер лә дөнья
Аны миңа биреп.

И дулкыннар,
Сезгә булган... булсын
Бу мәңгелек сөю!
Сезнең мәхәббәтне кимсетүдер
«Мин дә сөям» дию.

И дулкыннар,
Боз-богаулар сынгач —
Сезгә бәйрәм генә!
Көзләр килә... Яфраклардан алда
Дөрләп янам мәнә.

И дулкыннар,
Бик тиз сүндерәсез
Уты тамса көзнең...
Уттан туып, уттан үлгәнегез
Юк шул әле сезнең.

## Аккошларны эзлим

Күлләрдән озак эзләдем —
Юк алар. Күккә менәм:
Кайтып килмиләр микән соң,
Ап-ак болытлар белән?

«Алып кайт инде» дигәндәй,
Иртәнге томан аша
Аккош күзенә охшаган
Чәчәкләр саубуллаша.

[1] Сирәк очрый торган бик каты металл.

Менәм... Ак кылганнар булып
Тирбәләмен тауларда.
Тагын менсәң,
ул тауларда
Эремиләр карлар да.

Ак болытны аккош дияр
Күңнәрем җитте менә —
Әвереләм бугай бүген
Мин шуларның берсенә.

Менәм... Күзәтеп торалар
«Нишләр?» дип көтүчеләр —
Аккошны, күкләргә чөеп,
Ак болыт итүчеләр.

...Тапмадым. Болытлар белән
Каралып кайтып барам,
Аккош күзенә охшаган
Чәчәкләремә табан.

Күктә буламы соң инде
Җир бирә торган кадер.
Шулай да... кара болыттан
Яңгыр явачак хәзер.

❁

Бөртек идек. Илдә үстек!
Җилдә шаулыйбыз менә...
Әгәр җилдә очкан булсак,
Читтә урып-сукмас иде
Безне, я, кемнәр генә?!

❁

Кошлардагы матурлыкны кайчак
Канатсызлар күреп яратмыйлар.
Ә бит кошлар кешеләрнең кылган
Батырлыгын күктә кабатлыйлар.

## Төнге элегия

Төн буе кемнәр сөйләшә? —
Әллә күк... җиргә эндәшә:
— Мин нишләрмен синнән башка?
— Сөю кебек озак яшә!

❀

Яратмавыңны да йотты язмыш!..
Инде бер сорауга җавап табыш:
Нишләтерләр ялгыз башкаемны
Үлгән каргыш белән тере сагыш?

## Фәнис Яруллинга

Су сибеп үстермәделәр —
Без гөлләр түгел идек.
Тугач та дөньяның үзен
Күлмәкләр итеп кидек...
Ул төсләр яндырачагын
Без әле белми идек.

Дөнья безне танып алды,
Ә без аңа табынып,
Дүрт ягында балкып яндык
Чакматаштан кабынып.
Җаннар атты таң булып та,
Җаннар тамды кан булып.

Яшәүгә гимн җырладык —
Йөрәкләр еласа да.
Ничә кат дөнья әйләндек
Шигъри куласада —
Кипкән иренгә тигерер
Сулары булмаса да.

Аудык, бөгелдек чит җирдә,
Күккә үрелдек илдә.
Чакматашлардан кабынган
Утлар сүнмәде миндә...
Язларны илдән җибәрми
Яна да яна синдә.

Су сибеп үстермәделәр —
Гөлләр булганбыз ласа.
Гөлләргә гомерләр булып,
Утларга баса-баса
Йөрербез әле дөньяда —
Йөрәкләр туктамаса.

## Уяныгыз әле...

Көнбагышлар, сары көнбагышлар,
Ник иелде әле сезнең башлар?

Әллә килеп сезгә салкын җилләр:
«Кояш инде кабат чыкмас» диләр?

Уяныгыз әле, уяныгыз!
Минем белән бергә уйланыгыз...

Кояшкаем сүнде — әнкәй үлде.—
Кайгы мине нәкъ урталай бүлде:

Узган гомер — шатлык, ә киләчәк...
Ятим калдым... мине... тилмертәчәк.

Ярамый ич яшәү башны иеп.
«Мин булмасам — Кояш кала» диеп,

Әйтте әнкәй. Иелмәсен башлар —
Без Кояшка таба, көнбагышлар,

Китик әле. Әйдә, уяныгыз,
Минем белән бергә уйланыгыз...

## Әниемнең шәле

Шатлыкларың сине сакламаган —
Салкын тигән. Я, күтәрел әле,
Бәйләтимче, кызым... Җылытсын бер
Әбиеңнең иске мамык шәле.

Сүнеп барган кара күзләреңә
Таң яктысы кабат иңсен әле.
Кояш булып иркәләсен әле
Әбиеңнең иске мамык шәле.

Кайнар маңгаеңа кар кирәкми,
Синең уйлар өшемәсен әле.
Төшләреңә кергән чәчәкләргә
Җәй булачак әбиеңнең шәле.

Әбиеңнән калган дөнья белән
Туган телдә сөйләш, серләш әле.
Төн узганчы терелтәчәк сине
Әбиеңнең, әниемнең шәле.

*

Аланнарда кызыл баланнарны
Җыеп йөргән нәни балаларны
Үстерегез тизрәк,—
Югарырак
Күтәрсеннәр кызыл байракларны!

Байракларда — фидаилар каны.
Шул кан белән тибә безнең йөрәк.
Һәр үлемне... үтерергә кирәк —
Балаларны үстерегез тизрәк!

# Кошлар бәйрәменә чакыру

Кайтып килә — читтә, каралганчы,
Кайгы күргән карлыгачларым,
Йөрәк ярылырлык сагышлардан
Исән калган сандугачларым...

Гөл бөртеге кадәр йөрәкләрдә
Үлемсезлек кайта илемә.
Мәхәббәтнең иле бер генә шул,
Мәхәббәтнең иле бер генә.

(«Ярый әле, китмәгәнмен» диеп,
Бер карт козгын әнә сөенә.

Томшыгында калган кан эзләрен
Канатына сөртеп ала да,
Асыл кошлар белән бәйрәм ясап,
Очып йөри зәңгәр һавада.)

Кошлар бәйрәменә чакырам мин:
Барыгыз да күккә менегез!
Әй, кешеләр,
Тик бер генә кабат
Кошка әверелә белегез!

Каралганчы кайгылар да күрдек —
Ишетмәсен кошлар... дәшмибез.
Йөрәк ярылырлык сагышлардан
Исән калдык әле — яшибез!

Туган җирне кабат кочакларбыз,
Оча-оча арып егылгач:
Барыбыз да күккә меник әле —
Барыбыз да бүген сандугач!

Әйдә, бүген безнең сөю-сагыш
Козгыннарның күзен бәйләсен.
Без дә очыйк кошлар бәйрәмендә —
Кеше бәйрәменә әйләнсен!

БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

## Марат Әмирханов

# ГАРМУН

хикәя



Заһит, дулкынланып, сак кына хәрәкәтләр белән конвертны ачты. Дүрткә бөкләнгән ак кәгазьгә түбәндәге сүзләр язылган иде:

«Хөрмәтле авылдашыбыз Заһит ага Мөбәракшин!

Сезне Бөек Җиңү көненә багышланган тантаналы сборга чакырабыз. Гармуныгызны алып киләргә дә онытмагыз.

Сбор 9 майда мәктәпнең музей залында 16 сәгатьтә була.

Зоя Космодемьянская исемендәге дружина пионерлары».

Чакыру кәгазен Заһит берничә мәртәбә укып чыкты, тик барыбер мәгънәсенә төшенә алмады. Ник дисәң, моңарчы аны мәктәпкә болай зурлап, исемләп чакырганнары булмады. Сугышта да булганы юк — малай-шалай гына иде ул чакта. «Гармуныгызны... онытмагыз»,— дигән сүзләре дә бик сәер. Гармуны нәрсәгә инде тагын? Кулына гармун тотмаганга да байтак ләбаса. Табышмак дисәң дә табышмак. Шулай да тикмәгә түгел бу, бер-бер хикмәте бардыр моның, булмый калмас. Әллә соң... Сугыш елындагы теге вакыйгаларны ишетеп белделәр микән?! Булмас ла, ул хәлләрне хәтерләүче юктыр инде хәзер, күпме гомер узган бит.

Әйе, күпме гомер узган, күпме сулар аккан... Хәтер дигәнең — үткәннең бер генә бөртеген дә — зурмы ул, кечкенәме — онытмый икән.

* * *

...Ул көнне Заһитның әнисе Торачы урманына утынга дип киткән жиреннән кире әйләнеп кайтмады. Дөресрәге, аны күршеләре Сәмига түти җитәкли-җитәкли китерде. Күз кабаклары шешенгән, җилкәләре салынып төшкән әнисен күргәч, Заһитның йөрәге «жу» итеп китте. Нигә елыйсың дип сорарга да курыкты ул, күңеле белән ниндидер хәвеф барлыгын шундук аңлады. Әтисенең үле хәбәре килгән икән. Каһәр суккан сугыш еракта, бик еракта булса да, әнә шулай һәр көн диярлек авылга зур хәсрәт, кара кайгы ташый. Әйтерсең, авызыннан ут бөркеп торган яман аждаһа авылның, авылның гына түгел — илнең иң асыл ирләрен ерак-еракка, кире әйләнеп кайтмаслык караңгылыкка урлап китә! Ни кирәк ул фашист мәлгуньгә, нигә ул кешеләрне

кыра? Әйбәт, бик әйбәт иде аның әтисе. Ничек матур уйный иде ул гармунда!

Малай әнисенең салкын куенына сыенды. Ана һәм бала кочаклашмаган килеш идән уртасында бик озак басып тордылар. Берсе — тол, икенчесе — үксез. Алда — иртәгесе көн, айлар, еллар көтеп тора...

Ә атна-ун көннән аларга атап кыр почтасыннан посылка килеп төште. Бу хәл һәммә кешене гаҗәпләндерде. Чөнки авыл халкы фронттан әйбер өмет итми, киресенчә, оек-бияләй бәйләп, ипи-бәрәңгедән сохарый киптереп сугышчыларга үзе озата. Ә монда — менә сиңа мә — фронттан посылка!

Аны күрше-күлән белән бергәләп ачтылар. Фанер әрҗәдән әтисенең гармуны, ике кисәк сабын, биш-алты шакмак шикәр килеп чыкты. Комиссар язган хат та шунда.

«Рядовой Хәлиулла Мөбарәкшин — чын совет солдаты,— диелгән иде анда.— Ул мылтыгы белән дә, гармуны белән дә немец-фашист илбасарларына каршы аяусыз көрәште.

Соңгы бәрелеш аеруча каты булды. Рота, берничә мәртәбә атакага күтәрелсә дә, уңышка ирешә алмады. Шул вакыт кинәт, һәммәбезне таң калдырып, окоплар өстендә гармун тавышы яңгырады. Бу — Сезнең ирегез, рядовой Мөбарәкшинның гармун тарта-тарта дошманга каршы күтәрелүе иде. Арып-талып җиргә яткан безнең сугышчылар өчен бу илаһи моң тормыш җыры, җиңү җыры, тылдагыларның әманәте булып яңгырады. Солдатларның күзләрендә очкыннар кабынды, йөрәкләрендә ышаныч артты. Алар сикереп тордылар да «Ура-ра!» кычкырып, Мөбарәкшин артыннан ташландылар.

Командование куйган бурычны үтәдек. Ләкин югалтуларга да дучар булдык. Батырларча һәлак булучылар арасында Сезнең ирегез Хәлиулла Мөбарәкшин да бар иде...»

Фронтка киткәндә биштәренә сохари урынына гармун салып чыгып киткән иде шул Хәлиулла. Хатынының: «Нәрсәгә җәфа итеп аласың аны, ризык тутырыр идең ичмасам»,— дигән сүзенә илтифат итмичә:

— Солдат кешегә ашау-эчү табылыр, ә гармунсыз булмый, карчык,— диде.

Әтисе һәлак булган елны Заһитка нибары тугыз яшь иде. Озын җәй буе колхоз атларын көтте. Аз сүзле, күбрәк ялгызы гына йөрергә яратучан, укуда һәм эштә сынатмый торган малайны укытучысы да, колхоз рәисе дә, әнисе дә ярата иделәр. Әнисе гармунны Заһитка биргәндә зур өметләр баглады, улының һәрьяктан әтисенә охшавын теләде.

— Әтиеңнең төсе итеп сакла, улым.

Кечкенә гармунның буяулары искереп беткән, купшакланган, хәтта урыны-урыны белән куба ук башлаган. Почмакларына, ян-якларына кадакланган бизәкле калайлары исә тылсымлы күзгедәй ялтырап торалар. Планка кнопкалары кыйшайган: күрәсең, дошман ядрәсе аларны да читләтеп үтмәгән.

Гармун солдат Хәлиулланың фронттагы батырлыгына кагылышлы бердәнбер ядкарь иде. Әле ядкарьнең дә ниндие: моңы белән сугышчыларга көч-ләрт өстәгәне, аларны Ватан азатлыгы хакына кургаш өермәсенә каршы күтәргәне!

Бу турыда уйланганда малайның иреннәре кысыла, калын кара кашлары сикереп куя, сәдәфтәй түгәрәк күзләрендә ниндидер илаһи ялкын, горурлык хисләре кабына. Зуррак булса, ул да әтисеннән калышмас иде! Икәүләп дөмбәсләрләр иде фашистларны.

Заһит әнә шулай уйлана, тик бу хакта дусларына түгел, хәтта әнисенә дә берни сөйләми. Саескан шикелле бөтен нәрсәне чат саен такылдап йөрмәс бит инде. Их, бөтен бер ротаны атакага күтәрерлек көч-куәте булган шушы гармунда уйнарга өйрәнәсе иде!

Беркенне, энисе эшкә киткәч, малай гармунны кулына алды. Тик бер-ике тарткалап карауга, үзеннән-үзе оялып күрекләрне кысты. Чөнки гармуннан рәшәткәгә кысылган кәҗә тавышлары чыга иде. Бәлки, бер-бер көйне эчтән көйләп караргадыр һәм шул көй җаена төймәләрне басканнарга...

Бу сиңа кишер кимерү түгел икән! Заһит бер ноктага текәлеп шактый ара гаҗизләнеп утырды. Аннары тагын гармун телләренә сарылды. Чү! Бүлмә эченә өзек-өзек тавышлар тарала башлады. Тора-бара бармаклар кирәкле телләрне таба башлады. Димәк...

Ниһаять, бер дә бер көнне ул әнисенә «Шахта» көен уйнап күрсәтте. Дөрес, яңа гына аякланган бала шикелле, ул әле гармун телләренә кыюсызрак, ялгышрак та баса, көйне «хәрефләп» кенә җыя иде.

— Улым, бәгърем,— дип әнисе аны кочып үпте, аркасыннан сөйде. Елап та алды бугай әле.

Заһитның гармунда уйнавы бераздан бөтен авылга билгеле булды. Ә бер көнне аларга таң белән колхоз председателе Рамазан абзый килеп керде.

— Яле, энекәш, суз өйрәнгәнеңне, тыңлап карыйк.

Заһит, кояш чыкмас борын нинди гармун уйнау, дип сүзсез генә кашын җыерып караган иде дә, олы кеше әйткәч, карышмады — гармунын тез башларында сикертә-сикертә «Сарман» көен уйнады. Кечкенә генә гармуннан олы моңнар сибелде. Председатель, кәефе килеп, Заһитның башыннан сыйпап куйды.

— Арурак күлмәк-ыштаныңны ки дә киттек, энекәш,— диде ул.— Болай булса рәт чыгасы синнән.

— Кетүгә барасы бар бит, Рамазан абый.

— Бүгенгә генә анысына кеше табарбыз. Гармуныңны да кыстыр.

Алар ындыр табагына килеп җиткәндә, ашлык төялгән арбалар, бәйрәмчә бизәлгән бричкалар юлга чыгарга әзер иде. «Кызыл олаулар» көне икән ләбаса. Председатель Заһитны дугасына чигүле сөлге уралган иң алдагы ат янына алып килде.

— Монда да фронт, энекәш, икмәк фронты. Син безнең полкның музыканты, сынатма, әтиең кебек бул,— диде.— Ә хәзер, әйдә, «Шахта»ны сыздыр!

Заһит җайлап кына тигез капчыклар өстенә утырды да, башын аз гына читкә бора төшеп, уйнап җибәрде.

Таулар артыннан кояшның кызыл маңгае күренде. Алсу нурлар иң элек агач яфракларын, өй түбәләрен иркәләп уздылар, аннары дымык су өстеннән күтәрелә алмыйчарак торган томан япмасын яктырттылар. Бер-берсе белән матурлыкта узышып, үлән һәм яфрак очларында чык бөртекләре җемелдәште. Шушы иртәнге гүзәллеккә гармун тавышы — тыл һәм фронтның бердәмлеген раслаучы көмеш аваз килеп кушылды.

Ындыр табагында эшләүчеләр, өнме бу, төшме дигәндәй, бер-берсенә карашып алдылар. Юк, төш түгел. Заһит күкрәкләре дугаланып килгәнче тартты гармунны. Кешеләр аны мөкиббән китеп тыңладылар. Кемдер елады, кемдер сызланды, кемдер елмайды: күңелләр бушап, өметләр яңарып китте.

Ындыр табагына байтак халык җыелган иде. Председатель, моннан ярты гына ел элек сугышта сыңар кулын өздереп кайткан фронтовик сержант, атылып урамга чыкты да:

— Яле, энекәш, «Чабата»ны сыздыр,— диде. Үзе, билендәге каештан шуып чыккан буш җиңен җилфердәтеп, биеп тә китте. Аңа башкалар кушылды. Халык, әйтерсең, әнә шулай бер селтәнү белән иң өстендәге сугыш авырлыкларын алып ташларга тели иде.

Кызыл олауны бөтен авыл белән озаттылар. Бу көн үзенә күрә бәйрәм булды. Ә кичен председатель клубны ачтырды. Заһит яшь-җилкенчәкне анда да хәлдән тайганчы биетте, җырлатты.

...Сталинград янындагы сугыш җиңү белән тәмамланды. Немецларның чолганышта калган гаскәрләре, фельдмаршал Паулюсы-ние белән бергә, әсир төште. Бу хәбәр кешеләргә канат куйды. Клубта данлы Совет Армиясенә багышланган спектакль, концертлар дисеңме — Заһит боларның уртасында кайнады. Рәхәт тә, кыен да иде аңа.

Фронтовик председательнең мактау сүзләре аеруча очындырып җибәрде аны. Ә белә иде Рамазан абзыйсы гармунчы белән ничек сөйләшергә: кирәк чакта салам кыстырғалап та җибәрә, хәтта киңәш тә сорап куйгалый синнән. Малайга шул җитә, ул инде үзен зурларча тотарга тырыша. Репетиция яки концерт көне җиттеме, гармунын култык астына кыстыра да клубка чыгып китә. Ашыкмый, кабаланмый. Дәрәҗәсен белеп кенә атлый. Очраган кешеләр белән җитди генә исәнләшеп уза.

— Халисә малаеның атлавын гына карагыз, чын егет диярсең, жепшек борын,— дип сөйләнеп кала күрше-күлән.

— Гармунчы!

Көннәрдән бер көнне ул репетициягә килмәде. Чакырып та төштеләр. «Концерт көнне барырмын әле, бармакларым Әндри казнасыныкы түгел»,— диде ул, ике сөйләшергә исәбе юклыгын сиздереп. Их, ничек ялгышкан ул чакта Заһит...

Иртәгесен, ни хикмәттер, чакырып килүче булмады. Түзмәде Заһит, үзе клубка китте. Башка чакта кызлар аны, очарга җыенган кыр казлары шикелле, тезелешеп ишек төбендә үк көтеп торалар иде. Ни хәл бу, бүген баскычта ник бер кеше күренсен? Клуб ябык дисәң, уты бар. Әллә гармун тавышы да ишетелә инде? Чыннан да! Кемдер уйный. Һәм оста уйный бит, каһәр. Моны гармунчы буларак, шунда ук абайлап алды ул, көнләшеп тә куйды хәтта. Клубка керергә кыенсынып, хәтсез вакыт баскычта таптанып торды... Их, ничек ялгышкан ул чакта Заһит! Һавалану егет эше түгел икән шул.

Әлеге гармунчы яраланып фронттан кайткан шушы авыл егете Искәндәр иде. Аннары Заһит Искәндәр абыйсы белән дуслашты, кичләрен ярыша-ярыша гармунда уйнар иделәр...

* * *

...Мәктәп янына җитәрәк Заһит, кызыл шәлъяулыкка төргән гармунын рәтләбрәк куйды да, тукталып калды. Көн искиткеч матур! Күк йөзе чалт аяз, ник бер болыт әсәре булсын. Баш очында — кояш һәм тургай... Барысы да элеккечә кебек: күк, кояш, яшел чирәм. Ә тормыш үзгәрде, нык үзгәрде. Күр син өч катлы таш мәктәпне, ак пароход кебек ерактан балкып тора. Колхоз биләмәләрен, йортларны, ихаталарны күр — һәркайда муллык, байлык!

Бу бәхетле тормышның чишмә башы әнә шул авыр елларга да барып тоташа. Безнең авылдан гына да күпме кеше җиңү сәгатен якынайткан, күпләр яуда башын салган. Әнә, исемнәре һәйкәл ташына алтын хәрефләр белән уеп язылган. Бер бөтен икмәк зурлыгындагы шушы гармунның да өлеше бар бит бу җиңүдә! Ә ул аны өендә, өстәл түрендә «бикләп» тота. Юк, алай ярамый: күрсеннәр, карасыннар, гыйбрәт алсыннар. Бүген менә мәктәп балаларына шул хакта сөйләр ул.

«Музейда калдырып кайтам мин сине, туган, үпкәләмә»,— диде Заһит гармунга, җанлы кешегә мөрәҗәгать иткәндәй, һәм эре-эре атлап мәктәп капкасыннан кереп китте.

## Салих Баттал

### Вакыт дисциплинасы

Кеше иҗат миссиясен
үтәр өчен туа.
Аның ничек үтәлүен
Вакыт карап тора.

Таш диварлар аша үтеп,
үтеп һәрбер чиктән,
үзенең балтасын тотып,
Вакыт килеп җиткән.

Кисеп ташлый белә хәтта
күзәнәкләп, ваклап;
көтеп шундый мөмкинлекне,
тора һаман саклап.

Иҗат эшен тәмамламый
ятсаң мендәреңә,
мендәр диеп, баш куясың
аның думгәгенә.

Гомереңнең бер сәгате
зая булып үткән,—
димәк, шул иҗатсыз гомерең
мәңгегә «кых» иткән...

Бары яшәп калырлык син —
күпме итсәң иҗат,
шул микъдарда син Вакытның
балтасыннан азат.

Кырыс ул, тик гадел, димәк:
Обломовны үтерә...
Хезмәт халкы, синең Вакыт!
Ә син, ялкау, тетрә!

### Сөю бәһасы

Хатын-кызлар белән ирләр —
берсенә-берсе — мунча,—
сафланырга омтылалар
бераз мөмкинлек булса.

Сөю — хисләрнең мунчасы,
тик бушлай кереп булмый,—
бала үстер!
Үстерәсең,—
керләнеп йөреп булмый.

### Язучы һәм табип

Сукыр сырхау, дәваланып,
ачылгач та күзләре,
табипка ул хатлар яза,—
ява рәхмәт сүзләре...
Син үзеңне язучы дип
атама да ичмасам,
каләм беләм укучының
күңел күзен ачмасаң.
Гәрчә аның күңел күзе
сукыр түгел, үткен ул,—
сине укып, тагын тирән
катламнарга үтсен ул!

## Мәхмүт Газизов

### КамАЗлар эргәсендә

Җырладык юлсыз юлларда
машина этә-этә,
кечәнәсең, кечең бетә,
«Эх, ухнем!..» куәт кертә.
Җырласаң җылынасың дип,
карлы-бозлы кезләрдә
бии-бии такмак әйттек
салкын, туң нигезләрдә.
Ни гаҗәп, җырсыз-җырусыз
сөю дә бармый иде,
эштәме син, аштамы син,—
моң бездән калмый иде;
һәркем үзен я Әлфия,
я Илһам саный иде,—
кешеләр гади иде шул,
күңелләр сабый иде!
Зөһрә бүтәнгә чыкса да,
Таһиры өйләнсә дә,
җырладык без, кайвакытта
җырлыйсы килмәсә дә...

Тулай торак төпләрендә
кызларны көтә-көтә,
өр-яңа җырлар чыгардык,—
мәхәббәт шагыйрь итә...
Ак кирпечләр тезә-тезә
йортлар күтәргән чакта,
без җырны да алып мендек
өскә, югары катка!
Ишетәм, безнең яшьлектән,
биектән дәшә алар,—
шаулы өмәләрдән дәшә
«Сәрвиназ», «Катюша»лар...
Әйе, мең дә тугыз йөз дә
җитмешләр тирәсендә
җитмеш телдә без җырладык
халыклар өмәсендә.
Җитмеш телдә җырласак та,
КамАЗлар эргәсендә,
бәбиләрне тирбәттек без
туган тел иләсендә!

*

Күк кырылыр, ахрысы,—
тынды кош-корт,— качты кояш,
сүрелде көн яктысы,—
давыл булыр, ахрысы.

Җан кыелыр, ахрысы,—
яшен суккан карт каенда
энә — козгын тавышы,—
авыр булыр, ахрысы...

Чыкты урман керпесе!
Керпе уйнаса,— йомылмаса,
давыл булмас анысы,—
бумас үлем ачысы.

Уйна, урман керпесе!

❋

Өйрәник әле серләрен,
болыт телен өйрәник,—
    ләйсән булып яварбыз.
Чакма чагып, очкын табып,
без ут телен өйрәник,—
    кара төндә янарбыз.
    Адашканга юл булыр,
    чакма теле шул булыр.

Күп беләбез дип сөйләнмик,
судан да тел өйрәник,—
    дәрьяларга агарбыз.
Дәрья ерак... Без иң башта
тамчы телен өйрәник,—
    яз җитте дип тамарбыз.
    Тама-тама күл булыр,
    тамчы теле шул булыр.

Абага телен өйрәник!
җиде төн урталарында
    чәчкә атып карарбыз...
Силә телен, сиртмә телен,
бишек телен өйрәник,—
    илгә бәби табарбыз.
    Кыз булмаса, ул булыр,
    абага теле шул булыр...

## Ут дугасы

*Дан орденнарының тулы кавалеры,*
*сварщик Зиятдин агай Арслановка*

Тимерләр ялгыйм. Орындым —
кызыл утлар күренде.
    ...Кызыл утлар кызу иде,
    кисте корыч, тимерне.
    Нәрсә — тимер?! Кисте алар
    безнең күпме гомерне...
    Фронтларда йөрелде,
    кызыл утлар күрелде...
Тимергә янә орындым —
яшел утлар күренде.
    Ату түгел, вату түгел, —
    тыныч утлар. Күңелле.
    Гүя Мәскәү күгендәге
    Фейерверк, күр инде!

Эшлим. Була! Орындым —
зәңгәр утлар күренде.
Ялганды җөй. Эзе нинди?
Анысы мәгълүм сер инде,—
утта булдым... Ут дугасы
кемгә дә бер — күмерле.
Ут дугасы... Дуга уты...
Утлар алар күп төрле...
Бүген тыныч үткәрермен
дигән идем көнемне,—
булмады, күзгә яңадан
кара утлар күренде,—
хәтергә сугыш орынды...

## Радик Фәизов

# ҖИР ХАКЫНА

*хикәя*



Үзенең бу сәфәренә күптән, бик күптән җыенды Билал. Еллар буе. Еллар буе күңелендә таш-гердәй авыр, сызланулы уйлар йөртте. Ничәмә тапкыр инде тәмам тәвәккәлләп бетереп тә ниятеннән кире кайтты. Аның өчен, гомерен басуда үткәргән тракторчы өчен, авыр сәфәр булып чыкты бу.

Быелгы яз көттереп килде. Март азакларына тикле, төннәрен көчле салкыннарны күрсәтеп, кыш аякны нык терәп торды. Тик апрель урталарында гына чын-чынлап, шәфкате белән җылытып җибәрде. Шунда гына күк йөзе болытлардан арынды, төпсез булып киңәйде, аның түрендәге алтын тәхеткә кояш менеп утырды. Менеп утырды да кояш, эшне кызу тотты: басуларда мул яткан карны ике атна дигәндә куып та бетерде. Басулар иркен сулыш алдылар, кайнар нурларга тиенеп, рәхәтләнеп, күпереп киттеләр.

Шуны гына көтеп торган игенче үзенең мәңгелек эшенә кереште. Көйле генә барды быел, инде тирә-күршеләр дә, «Таң» колхозы да дым капладың, тырма, культивация да бетеп килә, кайбер басуларда чәчүне дә башлап җибәргәннәр иде. Кичә төштән соң якындагы урман артыннан бәләкәй генә болыт чыкты. Чыкты да болыт, атап чакыргандай, «Таң» кырлары өстенә килеп, бик шәпле яңгырын койды. Бу инде бик вакытында иңгән ганимәт һәм икенче көнне төшкә кадәр эш калдырып торырга да туры киләчәк диган сүз иде. Шушы форсаттан файдаланып, «Таң» колхозы тракторчысы Билал Фазылҗанов район үзәге юлына, үзенең күптән җыенган сәфәренә чыкты.

Кичтән бу хакта сүз кузгалгач, өйдәгеләр дәррәү каршы килделәр. Алай гына да түгел, аны үгетләп карадылар.

— Дөреслекне табарсыңмы соң анда барып?— диде хатыны, фермада бозаулар багучы Фәимә.— Җанашкаем, анда сине тыңлап та тормаячаклар. Тыңласалар да артыңнан көлеп калырлар. Барысы шул булыр.

— Барысы шул гына булса, ярап торыр иде әле,— диде улы Айнур иплән кенә. Айнур да армиядән кайткач тракторга утырды, бергәләп эшлиләр.— Аның районга барып сүз салып йөргәнен мондагылар белеп алачак. Белеп алачак та, тотып ашаячак. Терeләй, баш-аягы белән.

— Булмас монысы!— диде Билал.— Мин — колхозның беренче механизаторы. Утыз бер ел эшләгән. Мин — Хезмәт Кызыл Байрагы белән бүләкләнгән кеше.

— И сиңа тагын нәрсә җитми?— дип, каптырып китте Айнур.— Әллә сиңа начар ремонтланган, иске трактор бирделәрме? Сиңа кешедән аз түлиләрме? Тракторың яңа, ике сезон йөрмәгән, сине безгә һәркөн үрнәк итеп куялар. Белмим сиңа тагын ни кирәктер?

— Миңа тагын күп нәрсәләр кирәк әле, улым!— диде Билал, ихластан китеп.— Басулар алар иген иккән изге җир. Шул изге җирләрдә изге тәртипләр дә булуы кирәк миңа. Ә анда нәрсә? Анда ваемсызлык, анда карак-бурлар. Менә шуларның булмавы кирәк миңа!

— Һе, теге булмавы, бу булмавы. Ә аның өчен, үзең беләсең, эткәй, начальство бар. Атап куелган кешеләре. Ул мәсьәләне әнә алар карасын.

— Ә без ни өчен монда?— дип сорады Билал.

— Безгә — трактор. Без — сукала, тырмала, чәч, ур. Ә башка гипотенуза һәм катетлары аның начальство кайгысы. Барып җиттеме сиңа?

Бу «Барып җиттеме сиңа?» Билалның ачуын китерде.

— Миңа акыл сатарга син яшьрәк әле, улым. Син бу дөньяга килгәнче мин җирне аз-маз сукалап өлгергән идем инде. Әгәр бу сиңа барып җитсә!— диде ул.

— Ну вот,— диде Айнур һәм почмак якка чыгып китте.

Менә аның үз улы, баштанаяк үзе ясап чыгарган механизатор. Эшнең рәтен белә, ялкау түгел. Җирнең булачак хуҗасы. Ә үзе әнә нинди фикердә?! Күп алар, бик күп андый фикердә торучылар. Кайдан килә аларга мондый уйлар, бу битарафлык кайдан килә?

Улыннан ишеткән сүзләр Билалның ниятен куәтләде генә. Юк, барырга кирәк, барырга кирәк район үзәгенә. Инде бу форсатны да кулдан ычкындыру, киенеп беткән аякны тагын чишенү хилаф эш булачак.

Һәм ул иртән торып юлга чыкты.

Бензин ташучы шофер Гөлназ белән ул кичтән үк сөйләшеп куйган иде. Гөлназның әле быел гына кайткан яңа машинасына Билал итекләренә ябышкан балчыкны кырып, хәтта өстендәге пальтосын каккаларга кереп утырды. Кабина эче ялт итеп тора, каршыга «Бездә тартмыйлар!» дип язып куелган иде. Гөлназ, әле кияүгә чыкмаган, бик сылу буйлы яшь кыз, руль артына утыруга, башындагы бүреген салып, модалы итеп үстергән чәчләрен күпертеп куйды. Руль түгәрәген үзенең озын бармаклы куллары белән нәзакәтле итеп тотты. Аның битләрендә нәфис алсулык, чаткылы күзләреннән үз эшен, җилләрдәй җитез машина йөртүне бик яратуы, шуның белән бәхетле икәне күренеп тора иде. Авылның гүзәле, җәүһәре, авылның киләчәге иде бу кыз. Бәхетле соң хәзерге яшьләр! Мәктәптән чыгалар, тракторын, комбайн, автомашинасын белеп чыгалар. Кулларына таныклыгын тотып. Аннан кайда теләсәләр, шунда эшлиләр рәхәтләнеп.

— Киттекме, Билал абый?— диде Гөлназ.

— Киттек, сеңелем, куала.

Авыл башыннан ук олы юлга чыктылар. Тик бу юлның хәле хәл иде. Куян тиреседәй юка асфальт язгы дымнан күп урыннарда түбән иңеп, кубып беткән, тирән казылмалар, кисентеләр хасил булган. Карап бармасаң, монда күчәреңне сындыруы да бик ихтимал! Олы юл түгел, җәфа иде бу. Районга чаклы илле километрдан да ким түгел, ә бу сәгать ярым вакыт дигән сүз.

Ә Билал ашыкмый иде. Барып җиткәнче аның әле үз уйларын тагын бер кат кыршау арасына кертәсе, күңеле аша тагын бер кат үткәреп тәртипкә саласы бар иде.

Аның үзенә килгәндә, үз хөкеме каршысында да, кешеләр алдында да намусы ак. Ул, утыз беренче елны туган кеше, ундүрт яшендә инде

басуга чыгып, атлы сука сабын кулына алды. Кайберәүләр белми дә торгандыр: атлы сука артыннан атлаган кеше көненә алтмыш чакрым чамасы юлны җәяүләп үтә. Алты ел шулай йөрде Билал. Аннары, курслар бетереп, егерме яшендә тракторга утырды. Быел аңа илле бер, димәк, утыз бер ел инде тракторда. Утыз бер ел! Шушы дәвердә тракторчы Билал һәр сменада тиешле күләмдә җирен эшкәртте, яхшы билгегә тапшырып килде, сәбәпсез бер генә көн дә эш калдырганы булмады.

Аның күз алдында басуларга нинди куәтле машиналар, нинди куәтле тракторлар килде. Җирне эшкәртү, ашлау, игеннәрне карап үстерү нинди югарылыкка куелып, кая таба китте. Кайчандыр өч тракторчы, ике комбайнчы булган «Таң» колхозында хәзер механизаторлар гына да йөздән артык. Ә нинди тракторчылар, комбайнчылар, нинди егетләр бар алар арасында! Нурислам, Сәлимҗан, Йосыфҗан, Хәмбәл, Хабил... Бу ир-егетләр Билалның үзеннән соң эшли башладылар, аны узып, әллә кайда калдырып киттеләр. Инде кайберләре орден да тактылар, бөтен районга билгеле булдылар.

Менә шундый техника заманасы, шундый кешеләр бар. Ә шулар кырында, янәшәдә генә күз буяучылар да бар, төрле хәрәмләшүләр, шомартып кына йөрүләр дә тулып ята. Бу хәлләр Билалның да, аның кебек ихлас күңелдән йөргән башкаларның да йөрәген бик талый. Үз тәҗрибәсеннән Билал шуны чыгарды: басулардан көткән икмәкне әле һаман да алып булмый икән, моңа табигать-ана гына түгел, ә күбрәге кешеләр үзләре гаепле.

Ник дигәндә, бөгештерү бар басуларда, турыга төбәп кыекка кереп китүләр күп. Былтыр йөз илле гектарлы Кара басуда нишләде? Арпа уңышы ызан аша гына булган басудагыга караганда дүрт центнерга ким чыкты. Һәр гектар җирдән. Йөз иллене дүрткә китереп салсаң, түгәрәк алты йөз центнер чыга. Менә бу инде тиеш булып та амбарга керми калган ашлык. Менә бу инде терсәкләнеп чыгу. Һәм моның нинди терсәк икәнен Билал яхшы сизенде. Ханнан белән Исмай хәрам керттеләр анда. Чәчү алдыннан үзегенә үткәреп тырмаламады, культиләмәде алар ул җирне. Иренеп, көн үтсенгә эшләделәр. Ә җир исә моның үчен тиз кайтарды, әле уҗым чагында ук арпаны сарут басты, булачак уңышны ашады. Моны бит белеп тордылар. Бригадир Хатип та, председатель Фәезхан абый үзе дә. Ә сүз кузгатмадылар, шул көе генә йомдылар. Ханнан белән Исмай быел тагын чәчүгә җир әзерли әле...

Вакытында дым каплый алмауның нәрсә икәнен, тырма теше тимәгән җирнең дымны һавага ничек очыруын һәр механизатор да, житәкчеләр дә белә. Монда инде алты-җиде сәгать кенә соңласаң да күпмегә оттырасың. Ә «Таң»да соңарулар алты-җиде сәгать белән генә исәпләнәме соң.

Бозыла сыйфат, сроклар китә кулдан. Һәммә төштә: сукада, тырмада, чәчү астына җир әзерләгәндә китә. Елның елында шулай. Юкса егетләр җиргә төшкән орлыкның өстенә йомшак ябынып ятарга тиешлеген дә бик белә. Кайберәүләре белә торып хәрамга керә шул менә. Ә колхоз җитәкчеләре, вәкаләтле кешеләр моңа күз йомгалап тора. Эшне үзара бик йөз ертмыйча гына, җиңел итеп алып барырга күнегеп китте кайберләре. Районнан, югарыдан килгән кешеләр күбесе моны күрми, дөресе, күрә белми. Ә белгәннәре тагын юри күрмичә дә үткәли. Килешеп торуның канаты киң хәзер.

«Туңга сөрүне — ничек тә булса иртәрәк!» Моннан ничәмә еллар элек күтәрелгән сүз инде бу? Әнә «Игенче», «Искра» да нишлиләр? Бу эшне августта, сентябрь урталарына тикле башкарып та куялар. Басуның үз вакытында туңга сөрә алсаң, андагы камыл, үсемлек калдыклары череп, менә дигән ашлама була. Августта сөрү — гектарга ун

тонна өстәмә тирес керттем дигән сүз. Ким куйганда. Ә октябрьда туңга сөрү — бу өстәмәдән колак кактым, сыйфат боздым дигән сүз. Октябрьда басуда җир ертып йөргән игенче ул инде пешмәгән игенче. Безнең «Таң»дагы шикелле.

«Чиста пар!» — дип, авыз суы корыталар. Чиста парның, ягъни бер җәй буе берни үстермичә, ашланып, кадерләнеп, ял итеп кенә яткан басуның ни икәнен, киләсе елны анда нинди уңыш үстереп алып буласын авылның һәр агае белә. Чиста парны ел саен калдыралар да, бу турыда районга мәгълүмат та китә. Китә һәм шул җиргә кулларын китереп тә тыгалар. Берьеллык үлән генә булса да чәчеп куялар анда. Яшертен генә. Монысы инде җитәкче абзыйлар бөккән тересәк була.

Бу терсәкләр дә кыеклап кына булса, бер хәл иде әле. Басуларда, икмәк үскән изге җирдә, турыдан-туры рәшәткә артына күрсәтә торган җинаятьләр дә эшләнә. Былтыр ике тракторчы, аларның чәчүче егетләре бер кичтә эштән барысы да исерешеп, машинада җырлашып кайттылар. Нинди ҩәйрәм, нинди туй бу кызу эш өстендә? Билалга монысы да килеп җитте. Чәчү бодае «аякланган», басуга су белән килгән зур сөт бидонына кереп тулган да аннан, күрше мари авылына китеп, ярты бидон көмешкә булып әйләнеп кайткан...

Күп уйлады Билал бу терсәк-кыекларны, хәрәмләшүләрне. Хәер, бер Билал гына түгел. Ремонтка йөргәндә, берәр җае чыкканда Нурисламм, Сәлимҗан, Хәмбәлләр белән сүз гел шушы тирәдә була. Күңеле әрни егетләрнең. Үз хезмәтләре, үз тырышлыкларының заяга китүенә йөрәкләре сыза.

Сыкранып кына торалар, дисәң дә дөрес булмый. Җыйнаулашып та, берәм-берәм дә йөреп карады алар. Дөрес, колхоз эчендә генә. Шактый зурдан кубып профсоюз җыелышы да җыйдылар. Анда сүз дә зур булды. Тик алар барысы да һаман шул гомуми сүзләр, кимчелекләрне кешеләрен күрсәтми генә сөйләүләр иде. Гаепле кешеләрнең исемнәрен атап, каршына бастырып, күзгә-күз сөйләшү булмады. Тегеләр мыек астыннан гына көлеп утырдылар. Кемнеңдер сүзне бик үткенгә җибәрәсе килмәве әллә кайдан сизелеп тора иде. Дөресрәге, председатель Фәезхан абыйның. Фәезхан абый инде олыгайган, калынайган кеше, пенсиясенә дә нибары өч ел калып бара, инде зурдан кубып сөйләшүләрдән, күзгә-күзне терәүләрдән, дөресен генә әйткәндә, курка иде. Ник, диләр, колхоз әле безнең урта бер җирдә. Алып мактамасалар да, салып таптамыйлар да бит әле. Менә шулай җай баруга ни җитә. Ә кимчелекләр... алар һәркайда бар инде.

Фәезхан абыйның төп буразнасын белгән механизаторлар аның янына кереп тә тормадылар.

Һәм менә бүген Билал, тәвәккәлләп, район үзәге юлына чыкты. Иптәгенең кушуы буенча, фикердәшләренең фатихасы белән. Юк, анда да чынын бер белсеннәр әле. Менә хәзер, нәкъ эш өстендә килеп карасыннар, күрсеннәр. Кайберәүләрне утлы табага бастырсыннар. Бик вакыт, бик вакыт!

* * *

Тракторчы шулай уйларын барлый, үз-үзен куәтли торгач, район үзәгенә килеп тә җиттеләр. Гөлназ аны район Советы башкарма комитетының ике катлы ак йорты янында төшереп калдырды.

— Син озаклый күрмә инде, Билал абый. Мин нефтебазадан әйләнеп менгәндә шушында бул. Көтә алмыйм, үзең беләсең,— диде ул.

Бу сәгатьтә иртәнге район үзәге урамнарында халык күп, яшь кенә таза-таза ирләр, бизәнгән чибәр-чибәр хатыннар, егетләр-кызлар төрле учреждение һәм оешмаларга эшкә чыгалар иде. Барысы да бик күәз-

ләр, шифырт та фифырт. «Ә бит барысы да авылдан чыккан кешеләр болар. Төрле авыллардан килеп монда урнашкан»,— дип, уйлап алды Билал.

Авыл хуҗалыгы идарәсе райбашкарманың түбәнге катында иде. «Иә, егет!» — диде Билал үз-үзенә һәм шул якка атлады. Тик парадный ишегенә якынлашкан гына иде, аның гомер буе җиргә нык басып йөргән аяклары кисәк хәлсезләнеп калды, йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Бу ни тагын? Тракторчы беразга тукталып, үз хәлен аңышты: ул бик тә уңайсызлана, артыгын дулкынлана, үзе өчен бик авыр эшкә алынган иде. Әлләә... кире борылып китәргә инде?

Ә кире борылу ярамас, ярамас бит инде. Иптәшләрдән хәер-фатиха алгач, монда тикле килеп җиткәч. Билал үзенең бик сирәк тарта торган «Золотое руно» сигаретын кабызып җибәрде, бер ара берни уйламаска тырышып карады. Аннан зур ишекне ачып коридорга керде, тиз-тиз атлап ары үтте дә, авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Сәфәргалиев кабинетының алгы бүлмәсе ишеген ачып керде.

— Сез аз гына көтәрсез инде, абый кеше. Анда — киңәшмә,— диде секретарь кыз, ике якка ачылмалы күн тышлы ишекләргә ымлап,— хәзер бетә ул.

Билал урындыкка утырып көтә башлады. Ул арада тышта көн дә матурланды, озынча тар бүлмәнең биек тәрәзәсенә ялт итеп кояш төшге. Болай булса, төшкә хәтле үк басуга чыгып булачак... Менә ишекләр ачылыр, андагы кешеләр таралыр,— дип көтә-көтә, йөрәге дөпелди-дөпелди байтак вакытлар үтте. Ә тәрәзәдә кояш һаман югары күтәрелә, һаман ныграк кыздыра иде. Тракторчы күңеле тасырдап, тирләп, җәфаланып бетте. Нәрсәсе беләндер телевидение дикторына бик охшаган секретарь кыз язу машинкасында һаман да нидер тукылдата, аңа борылып та карамый, ә күн ишекләр артында тып-тын, гүяки андагы кешеләр үлеп беткәндер кебек иде.

«Хәзер бетә» нәкъ бер сәгатькә сузылды. Менә ишекләр ачылып китте, култык асларына калын папкалар кыстырган идарә белгечләре тарала башладылар. Аларның күбесе Билалны таный иде, ым кагып үттеләр.

Сәфәргалиев — дәү башлы, күпереп торган бөдрә чәчләренә инде чал кунган, гөрелдәвек тавышлы адәм, Билалны бик күптән белә, дус тәнә күреп, «кордаш» дип йөри иде.

— Ә, кордаш килгән. Йомыш ни? Утыр әйдә. Утыр да сөйләп җибәр, кордаш!— дип гөрелдәде ул, аның кулын нык кысып.

Билалның үзе кебек үк, бөтен гомерен авыр, тынгысыз хезмәт белән үткәргән, механизатор халкының моң-зарын яхшы белгән кеше дип уйлый иде тракторчы аның турында. Шуңа Билал бердән тынычланып, иркенәеп китте. Нурми Ярулловичка күңел капчыгының төбен селкеп сөйләргә җыенды. Тик Билал сүз башларга өлгерми калды. Зур өстәлдәге ике телефон икесе берьюлы шалтырады. Сәфәргалиев алардан сөйләшеп кенә бетергән иде, бер папка кәгазьләрен күтәреп, экономист Нуретдинов килеп керде. Кәгазьләргә кул куеп бетергәч кенә Сәфәргалиев, башын күтәреп, Билалга карады.

— Ә син ник басуда түгел әле, кордаш, бу көндә?— диде ул, аны әле генә күргәндәй.

— Бездә кичә көчле яңгыр булды.

— Беләм, беләм. Хәбәр иттеләр. Ә синең мәсьәлә ни?

— Сез мине әйбәт беләсез, Нурми Ярулловнч. Үзем өчен йөри торган кеше түгелмен. Мине монда, сезнең янга бер төркем иптәшләрем җибәрде. Җәмәгать җибәрде!— дип башлады ул сүзен.— Безнең «Таң»да кайбер чуалчыклар бар. Сезнең ярдәм, аңлау кирәк, Нурми Ярулловнч. Эшләр менә болайрак тора әле бездә...

Буылган су бер ерып җибәргәнне генә көтә. Тракторчы үзенең дәү кулларын ике тезе арасына кушырып, күзләрен шул кулларына төбәп утырды да, үзе белән алып килгән авыр йөген район авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы каршысына чәчеп ташлады. Чөнки ул үзенең һәр сүзе кирәк сүз, игътибарга лаек сүз, дип саный иде. Чөнки сүз аларны еллар буе борчыган нәрсәләр турында бара иде.

— Менә бу кыеклар безнең ихластан йөргәнне ашап бара. Андый кешеләр хуҗалыкның чабуыннан тота. Менә шулар борчый безне, кордаш!— диде ул, сүзен очлауга тотып, һәм Сәфәргалиевка күтәрелеп карады. Күтәрелеп карады да... эчләре «жу» итеп китте. Сәфәргалиев аны тыңлый, ә үзе, теше сызлаган кешедәй, чыраен сыткан, аның коймактай түгәрәк йөзенә «йөрисең шунда... керән чәйнәп!» дигән сүзләр язып куелган кебек иде.

Тракторчы бердән шабыр тиргә батты. Ни әйтергә, ни уйларга белми телсез калды.

— Мин сезне төшендем, иптәш Фазылҗанов. Дөресен әйтим, без боларның күбесен белә идек инде. Нишлисең, барысына да кул җитми. Тире дә калын инде,— диде Сәфәргалиев, ышанасы килмәгән битарафлык белән. Аннары өстәп куйды.— Ә сезгә моны язып бирәсе калган.

— Ничек... язып бирәсе?

— Ак кәгазьгә кара белән. Сүзне документ итеп теркәп булмый бит аны, кордаш. Без монда аны райбашкарма утырышына куяр идек. Сезне дә чакырып...— диде Сәфәргалиев һәм хәйләкәр генә елмаеп куйды.

Билал аның киң йөзенә карады. Ихлас күңелдән елмаеп, ялтырап торган йөзенә. Һәм тракторчының күкрәгенә кайнарлык тулып, күз аллары караңгылана башлады. Ул җәтрәк урыныннан торып, ишеккә атлады. Озын коридорны үтеп урамга чыккач кына үз-үзен аңышыр хәлгә килде.

Бу нәрсә булды соң әле?! «Кул җитми... тире калын... язып бирегез...» Әллә Нурми Яруллович аны төшенеп җитмәдеме? Әллә кире кереп, кабат сөйләп бирергәме? Юк, монысы инде булмый. Чөнки аны бүтәнчә тагын ничек итеп сөйлисең... Сәфәргалиев тә бит инде аны икенче тиргә кереп тыңламаячак. Ә бит бик төшенде аны Сәфәргалиев. Төшенде һәм аның сүзләренә юл бирәсе килмәгәнен дә ап-ачык итеп төшендерде. Менә йөре инде син!..

Күңеле сыкранып, әрнеп, кыйналган кешедәй авыр атлап, Билал чатка чыкты. Әлбәттә, анда инде Гөлназ юк. Гөлназ күптән кайтып киткән иде.

* * *

Юл уңаена машина эзләп, ары талпынды, бире йөгерде Билал. Ул арада көн матураеп, тәмам җәй булды. Хәзер басуда рәхәтләнеп эшләр чак иде. Ә аның тракторы тик тора. Чәчү машиналары белән!

Син ут йотканда татын ут бирә ул. Мари пыяла заводына күмер ташучы машиналарны очратып, Билал авылга кичке якта гына кайтып җитте. Җәтрәк өс-башын алыштырды да, тамагына да кабып тормастан, басуга ашыкты. Әле ике-өч сәгать эшләп буласы иде.

— Ә син юкка болай җан атасың әле, Билал абый,— диде аңа басуга ашлык чыгаручы шофер Ильяс.— Синең тракторга хуҗа табылды.

— Ниткән хуҗа ул?!— диде Билал, йөрәге тагын «жу» итеп.— Син, егетем, шаяртып сөйләмә.

— Ник шаяртыйм. Синең районга барып йөргәнеңне Сәфәргалиев әллә кайчан шалтыратты инде монда. Тракторыңа Рафис утырды. Ул больницадан тазарып чыккан.

— Алайса, яхшы әле. Агрегат тик тормаган,— диде Билал, үз-үзен юатасы килеп.

Чәчү барган басу читендә аны бригада механигы Радин каршылады. Элегрәк Билал үзе эшкә өйрәткән, аннары укып механик булган Радин, гел елмаеп торган түгәрәк йөзле яшь кеше, аңа туры карарга кыймый-ча гына сүз башлады:

— Синең тракторда Рафис, Билал абый. Ә сиңа иртәгедән икенче эшкә.

— Нинди икенче эшкә?— диде Билал, үз колакларына үзе ышанасы килмичә.

— Ремонт звеносына.

— Кем кушты?

— Хатип абый. Ә аңа — председатель Фәезхан абый үзе.

— Ничек инде ул алай?

— Белмим,— диде Радин.— Алар сине профсоюз җыелышына куяр-га да сөйләштеләр әле. Эш өстендә тракторын ташлап йөргән, дип.

— Ә?!— диде тракторчы һәм, кисәк һәммәсен аңлап, төшенеп алды. Бу — үч алу, аның районга барып сүз күтәреп йөрүе өчен үч алу иде. Беркем дә юньләп тыңламаган, кабул итмәгән сүзләре өчен.

Ә бит алар, туры сүз сөймәүчеләр, әгәр ниятләрендә булса, аңа терсәкнең бик шәбен чыгарып куя алалар. Ул бүген көнозын басуга чыкмады. Сорап та китмәде. Моны эш ташлап китү, дип бик рәсми-ләштереп була. Монысы, эшне бер уңайдан алганда. Ә икенче уңайдан алсаң?.. Икенче уңайдан, өлкән тракторчының бөтен күңелен үпкәләү биләп алды. Үпкәләү, гайрәт чигү. Аның утыз еллык намуслы хезмә-тенә бирелгән бәя микәнни бу? Колхоз өчен кайгырып, хаклык эзләп йөрү шулай ук гаеп эш микәнни ул?

Ярый, әйбәт. Алай гаепкә алалар икән, ул да алар янына барып йөрмәячәк. Гафу сорап. Кая гына куйсалар да намуслы эшләячәк ул, куллары эшкә күнеккән аның.

* * *

Язгы эшләр беткәнче Билал Фазылҗанов ремонт звеносында йөрде. Аннан басуларга су сиптерүдә, көзен тагын ремонтка. Кая гына әйтсә-ләр дә карышмады ул. Үз хокукларын, тракторын да даулап йөрмәде.

Кыш урталарында районнан Сәфәргалиевне эшеннән алганнар икән, дигән хәбәр ишетелде. Билал моңа куанмады да, кайгырмады да — аны ниндидер тынычлык биләп алды. Соңрак күңелендә өмет уянды. «Яңа кеше килеп, бераз эш белән танышкач, тагын бер тәвәккәлләп карарга кирәк... Җир хакына!»..— дип уйлады ул.

## Кави Латыйп

# ТӨНЬЯКТА ДА КҮБӘЛӘКЛӘР ЯШИ

хикәя



Кече гыйльми хезмәткәр Рәмзи Закиров, ике атна югалып торгач, эш урынына килде.

— Кая югалдың?— диде лаборант кыз.— Саматов һәр көнне сине сорый, Закиров күренмәдеме, ди?

— Үзенә кирәк чакта җир тишегеннән дә эзләп таба иде. Кирәгем шул кадәр генә булгандыр.

— Күрәм, синең кәефең кырылган. Син миңа шуны әйт, табельга ни дип языйм?

— Минем өчен барыбер, китәргә булдым мин институттан. Сәбәбен үзең дә беләсең.

— Белмини, бөтен институт шаулый. Кандидатлык диссертациясен син дә яклый алмагач?

— Нигә алай дисең? Мин бит мөгезле түгел.

— Саматов каршы булган дип ишеттем, шул дөресме?

— Дөрес.

— Ә без, лаборатория сотрудниклары, сине котларга уйлаган идек. Акча җыеп букет сатып алдык. Әнә, сиңа адресланган тәбрикләү тексты эленеп тора.

— Күрәм, шрифты эре икән.

— Тырыштык инде.

— Ләкин юкка гына.

— Укып биримме?

— Кирәкмәс.

— Юк, син безнең хөрмәт сүзләрен ишетергә тиеш.

Лаборант кыз котлау текстын кычкырып укырга кереште: «Дорогой наш Рамзи, от души поздравляем тебя с защитой кандидатской, так держать. Все дороги ведут к докторской. Обратного пути нет. Твои коллеги».

— Ә мин әйләнеп кайту билеты юк дип әйтер идем.

— Ни өчен алай?

— Институттан гына түгел, туган каладан да китәм. Поездга билет та сатып алдым инде, менә ул.

— Ә диссертацияне кем яклар? Син аны җиде мәртәбә язып, җиде мәртәбә машинкада гына бастырдың.

— Вакланмыйк, Ирина. Обходнойга кул куй да, дүрт ягым кыйбла.

— Башта менә шушы «кара дәфтәр»дән синең гөнаһларыңны карыйк. Аннары күз күрер? Үзең беләсең, мин бит профгрупорг та.

Лаборант кыз кара тышлы калын дәфтәрне өстәлгә чыгарып салды һәм актара башлады.

— Син чыннан да, гөнаһлы икән, профсоюз взносын түләмәгәнсең.

— Ничә ай өчен?

— Сабыр ит, хәзер әйтәм... Өч ай түләмәгәнсең икән.

— Каһәр, диссертация дия-дия профсоюзны онытып җибәргәнмен.

— Дүрт сум егерме тиенең бармы?

— Рәхим ит. Профсоюзны хөрмәт итәм мин.

— Шулай булмыйни, синең хакта мин үзем дә уңай фикердә. Тик менә институтны ташлап китүең генә гаҗәпләндерә.

— Ә син, Ирина, гаҗәпләнмә, нормаль хәл дип кабул ит. Хәрәкәттә бәрәкәт. Йомышчы малай булып йөрү туйдырды. Дөрес, институт эшләрен ихлас күңелдән башкардым, ә хәзер башкарасым килми. Институт миңа вакуум булып тоела. Шуңа күрә белмәгән, күз күрмәгән ерак җирләргә китәм. Кандидатлык диссертациясен яклый алмадым, ә горур яңгырый торган кеше исемен якларга тиешмен. Тиеш кенә түгел, мәҗбүрмен!

— Ә син, чын ир-егет булсаң, әйдә, кеше исемен биредә якла.

— Якла дип әйтүе генә җиңел, ә чынлыкта? Саматов директор, фәннәр докторы, профессор...

— Докторлык һәм кандидатлык диссертациясен яклау буенча махсус совет председателе дә,— дип өстәде лаборант кыз.

— Әйе... Элек мин үземне институт өчен кирәкле дип исәпли идем. Алай түгел икән. Ә хәзер аяк астында буталып йөрисем килми.

— Менә обходной белән профсоюз билетың,— диде лаборант кыз.— Эштән азат ителүең турында приказ китерергә онытма. Бүген үк, яме?

— Обходнойны бирдең бит инде, приказ ни хаҗәтемә?

— Приказ делода кала, тәртибе шулай.

Рәмзи үз теләге белән эштән азат ителүе турында приказ китереп бирде.

— Әйткәнне үтәргә яратам мин,— диде ул.

— Синең ышанычлы кеше икәнлегеңне институт халкы яхшы белә. Ләкин фәннәр кандидаты булыр өчен ул гына җитми, күрәсең. Хәер, синең диссертациягә карата рецензияләр уңай иде.

— Уңай иде, ә уңайсыз хәлдә калдым...

Поездда барганда Рәмзи үзенең соңгы тапкыр лаборант кыз белән гаплəшүен исенә төшерде. Әйе, профессор Саматов Рәмзи Закировның кандидатлык диссертациясен юкка чыгарды. Ә бит Рәмзи профессорга нык ышанган иде. Диссертация яклана, Рәмзи язмышы хәл ителә дигәндә генә профессор, соңгы сүз алып, Рәмзи Закировның гыйльми хезмәтен сызды да ташлады: темасы бәхәсле, методикасы камил түгел, эксперимент нәтиҗәләре шикле, теоретик өлеше йомшак, соискатель, ягъни гыйльми дәрәҗә дәгъвалаучы, җитештерүчәнлекне күтәрүдә ЭВМны күккә чөеп мактый, ә хезмәт коллективы ролен икенче планда калдыра, социаль процесслар белән идарә итүдә, математик модельләргә өстенлек биреп, кешене машина белән алыштырмакчы, алай гына да түгел, әйе, алай гына да түгел, роботның фикерләү механизмына караганда, кешенең фикерләү механизмы чамалырак дип, дәлилләмәкче була, бу — аның яшьлек хатасы, диде.

Вагон түшәмендәге ноктага төбәлеп, элекке гыйльми хезмәткәр уйга батты: «Яшьлек хатасы?.. Ләкин сәбәп ЭВМны күккә чөюдә, математик модельләргә өстенлек бирүдә түгел, ә биш елга якын профессор Саматовка ярдәм итеп йөрүдә. Әйе, әйе. Кешене машинадан аера белә

Рэмзи. Җиһанда көн — көн, төн — төн булып калганда, нинди генә техник үсеш заманы килмәсен, машина үз ролен башкарачак. Ә менә ул — Рэмзи — профессорны танып бетермәгән икән, Саматовка яхшылык эшлим дип, яшьлеге белән мавыгып киткән, үзен робот хәлендә калдырган. Рэмзи профессор файдасына нинди генә эшләр башкармады! Нәрсәдән башланды соң әле Рэмзинең бу хәлгә калуы? Әлеге дә баягы шул техникадан, төгәл әйткәндә, автомобильдән. Саматов белән бергә, Горький шәһәрендәге заводтан «Волга» маркалы автомашина алып кайттылар. Үткен телле Рэмзи, запас частьлар да юнәтеп, ак төстәге-сен эләктерде. Аннары машинага обкатка ясады, шәһәр тирәсендәге авылларда йөреп, профессор кулына каклаган каз тоттырды.

— Мактанма, каз, һөнәрең аз,— диде Саматов, серле генә елмаеп. Профессор әйткән сүз әллә каз турында, әллә Рэмзинең үзе турында иде, ихлас күңелле егет аңлап бетермәде.

Кече гыйльми хезмәткәр Рэмзи ак «Волга»ны үз акчасына сатып алган бензин белән йөртте.

— Син, коллега, мәңгелек ягулык уйлап таптың, ахры,— диде профессор белмәмешкә салынып.— Нинди ягулык икәнлеген сорасам да, әйтмәссең инде, сер итеп тотасың. Син бухгалтердан талоннар сора, ак «Волга»— служебный машина. Хәер, миндә дә талоннар бар, ләкин «НЗ» итеп тотам. Мәскәүдән академик килмәгәе дим.

Кызыл белән «Бензин» дип язылган талоннарны профессорның шәхси машинасы өчен файдаланганын яхшы белсә дә, «Вакланма!» дип, үз-үзен юатты Рэмзи. Ял көннәрендә, служебный машинага утыртып, профессорны Идел буендагы дачасына алып барды гыйльми хезмәткәр Закиров. Саматов, коенудан күңеле булгач, күбәләкләр аулап йөрде, киптерелгән үләннәр белән бергә, күбәләкләрдән дә коллекция җыя иде ул. Рэмзи исә, өмәгә килгән ир-егетләр белән мунча бурасы бурады, дөресрәге, профессор әйтүе буенча, өмәгә килүчеләрне барлады, сыйлау эшләре белән шөгыльләнде. Ә сый җитәрлек иде. «Безнең профессор юмарт икән, йомычка очкан саен стакан капладык, ысланган колбаса ашадык, хәер, түләп эшләтсә, бурасы кыйммәткәрәк төшәр иде»,— диючеләр дә булды өмәгә катнашучылар арасында.

Мунча салынгач, профессор дачасында төрле вак эшләр белән шөгыльләнде Рэмзи: җиләк-җимеш, яшелчәләрне ашлар өчен тирес китертте, дүрт аякланып чүп утады, ял көннәрендә мунча якты. Ә инде, профессор ашказаны белән каты авырып алгач, аны җиңел ризыклар белән тукландыру мәсьәләсен кайгыртты. Курорт-санаторийларга да Саматов белән бергә йөрде Рэмзи, шулай итеп, профессорга биш ел буе йөкченең дә кирәге булмады. Профессорның чит илдә эшләүче кызы белән киявен дә Рэмзи каршы алды, Рэмзи озатты. Саматовның кабинетын җиһазландыруда да Рэмзи күп тырышлык күрсәтте, теләсә кем көнләшерлек мебельләр табышты. Ә инде гыйльми эштә Саматов, докторлык диссертациясе яклаганда, кече гыйльми хезмәткәр Рэмзи Закиров үткәргән эксперимент нәтиҗәләреннән дә файдаланды.

...Поезд төньякка бара, Рэмзи уйлануларын дәвам итә. «Кандидатлык диссертациясен язар өчен бирелгән вакыты узса да, нигә эштә күренми?»— дип сораган бер көнне директор Рэмзи турында. «Үзенә гыйльми җитәкчеләр эзли бугай»,— дип җавап биргән аңа лаборатория мөдире. «Нинди гыйльми җитәкчеләр? Читтәнме? Безнең институтта эшли торып. Үзебездә генә ничәләп фәннәр докторы бар. Рэмзи Закировның темасы институт өчен «чирәм җир» түгел. Аннары кандидатларны әзерләүдә докторларның нормасы бар. Сабак укытырга кирәк ул җилбәзәккә. Акылга утырырга вакыт аңа... Кемнәр икән аның гыйльми җитәкчеләре?.. Байбурин белән Сабитовлардыр инде... Соңгы вакытта Закиров алар тирәсендә чуалды. Әйе, кабатлап әйтәм, акылга утырырга кирәк ул малайны».

һәм Саматов Рәмзине «акылга» утыртты...

Рәмзи яткан урыныннан торып, тәрәзә янына килде. Төньякның салкын җиле исеп куйды. Җәйнең соңгы ае — август җиле. Бу вакытта Саматов Кара диңгез буенда ял итәргә ярата, андадыр инде, җилкәнле яхтасында йөзәдер. Саматов Кара диңгездә җилкәнле яхтада йөзә, ә Рәмзи, гомуми вагонга утырып, төньякка юл тота... Робот Саматов кеше кебек кыланган булып, спекуляциягә нигезләнгән исәп-хисап белән, Закировның иҗат җимешен юкка чыгарды. Әйе, Саматов, коллекция өчен җыйган күбәләкләредәй, Закировны корбан итмәкче булган. Ләкин мәкерлелекнең аягы кыска, яхшылыкның иге-чиге юк. Әнә, сскропия дигән күбәләк мәңгелек тундра да яши, үлемнән аны тәнендәге глицерин — антифриз саклый. Рәмзине туңдырмаучы антифриз — ул яхшылыкка, ихласлыкка инану. Төньяктагы бер станциядә техник-оператор булып эшли башлагач, Рәмзи кат-кат әнә шушы хакта уйлады. Үзенең дөньяда барлыгын белдерер өченме, Рәмзи үзе эшләгән институт лаборанты Ирина исеменә, конвертка салып, төньяк күбәләге җибәрде һәм кайчандыр үзен тәбрикләр өчен язылган текста охшашлы зур хәрефләр белән: «Төньякта да күбәләкләр яши», дип бер генә җөмләдән торган хат юллады.

## Ямаш Игәнәй

### Шагыйрь

Күпме яшен яшьнәде,
Күпме болыт агылды,
Күпме бөре ачылды —
Һәммәсе дә күңелдә.

Күпме гомер киселде,
Күпме туплар атылды.
Күпме еллар ватылды —
Һәммәсе дә күңелдә.

Күпме язлар килмәде,
Күпме гашыйк иреннәр
Үрелмәде иренгә —
Һәммәсе дә күңелдә.

Җанда мәңгелек яра,
Һәммәсе бизәк-нәкыш.
Һәммәсе дә бер ачыш —
Бөтенесе күңелдә...

*

Әле монда җәйрәп ята иде басу.
Чыгып бассам — күккә тия иде башым.

Хәзер өйләр, түбәләр күккә тигән.
Һәм мин үзем чаклы калкып торам җирдән...

*

— Бәхет, син кайда?
— Бәхет, син кайда?
— Игеннәр шаулап
Үскән кырларда,
Икмәк җылысы
Сеңгән кулларда.
Сабый йөзенә
Кунган нурларда,
Туган телеңдә
Откан җырларда.
Туган илеңә
Илткән юлларда.
Кем дәшә миңа?—
Кил, үзең кайда!?.

*

— Әйтче, мондый гүзәл көйне
Кайдан оттың, кошчыгым?
— Эчтем кояшны үзенә
Сыйдыралган таң чыгын.

Анда җемелдәгән нурлар
Җанымнан балкып тулып,
Кучтеләр бар да — җырымның
Көенә аваз булып...

Йөзеңдә нур уйнаганда —
Кояш балкый минем җанда.
Йөзеңдә нур сүнгән чакта —
Җанымдагы кояш бата...

## Яшьлек монологы

Мин табигать тарафыннан
Яратылган бер чәчәкмен.
Бәхет булып һәр язмышның
Үзәгенә күчәчәкмен!

Вакытта тик мизгел белән
Чикләнсә дә минем гомер —
Мәңгелекнең үзе кадәр
Озайтачак аны кемдер...

## КамАЗ төзүче итеге монологы

Көязләнеп йөри белмәдек без
Парад итеге кебек.
Затлы күннән теккән түгел ич без —
Гади кирза идек.
Юк, бәйрәмгә түгел, КамАЗ нигезен
Салырга, дип, килдек.
Шакыраеп ката идек, көн-төн
Туң балчыкны ерып.
Әмма эретәләр иде безне
Җылы сулыш өреп...
Бу зарлану түгел, мактану да —
Нидер дәгъва итеп.
Дәрәҗәбез безгә бик тә җиткән,
Без — тик кирза итек.
Инандык без: эзләребез, диеп
Җирдә мәңге калыр.
Шәһәр үсте менә ялан кырда...
Күзнең явын алыр!
Асфальт хәзер шәһәр урамнары,
Шөкер шунысына.
Әнә җете туфли йөзләрендә
Кояш нуры сына!
Бөтен гомеребез буена ич
Өметләндек шуңа.
Һәм ирештек!— Уеп эзебезне
Заман тупсасына...

## Рөстәм Фәйзуллин

# НЕОН УТЫ

✻

Беләм, ул килми;
бүген килми,
килми иртәгә...
Тик нигә соң
телефон,
ишек кыңгыравы,
тәрәзәләр
һәрчак уяу булып
көтеп тора аны,
нигә соң, нигә?..

✻

Мин бәхетле бүген...
Бер сүз дәшмә,
мин бит беләмен:
иртәгесен,
шушы бәхет өчен
күз яшьләрем белән түләрмен...

✻

Офыкларга карап бер кычкырдым:
— Кая китә мәхәббәтле язлар?
Кая китә алсу бу таңнар?!

...Өзелгән яфраклары артыннан
ботакларын сузып
юл читендә тора бер чаган.

✻

Күңел сизә: нидер булыр миңа
нидер булыр, әйе, бу язда.
Этләр өнә бүре булып улый,
йорт казында аккош уяна...
Нидер булыр миңа...
Салкын боз суга әйләнеп,
дулкын булып ярга чыкканда...

*

Үз-үзеңне булмый алдалап,
үз-үзеңә булмый ялганлап.
Көзгегә бер кара —
чәлпәрәмә китер,
кисәкләрен җыйма яңадан...

*

Язган идек исемнәрне
ап-ак каенга.
Һәр хәрефтән тамды тамчылар...
Син күз яше дидең аларны,
мин каен суы дидем...

Аның нәрсә булганлыгын
мин хәзер генә белдем...

*

Кайгы килсә — хәсрәт басса,
тормышларың китсә авышып,
Син үзеңнең вак мәшәкатьләреңне
дөнья гаме белән чагыштыр.

## Юри, үтешли генә...

Сипкелле күрше кызының
тәрәзәсе ачык иде.
Ыргыттым чәчәк бәйләмен,
аннары... качтым инде.

Бу шаяру иде минем
үтешли, юри генә.
«Миңа гашыйк булганнар»,— дип,
чын-чынлап йөри менә.

*

Күләгәсез шәүләм йөри
таңнарда урамнардан...
Күңелне шул сорау били:
бәхетләме һәр көлүче,
бәхетсезме — елаган?..

*

Бозга әйләнгән
сулар йоклый
ярлары кочагында.
Бәкегә төшеп,
Ай су эчә
болытлар юк чагында.

*

Ах, бу торгынлык,
кая куйыйм — бу җанымны,
Кем иңенә — башымны?..
Сәерсенеп тыңлап торам
торгынлыктан туган тынлык,
тынлыктан туган шомны...

*

Яну... Янып була —
Караңгыда — балкып,
анда яна черек агач та!..

Ә син минә балкып кара
Кояш яктысында,
неон уты янып торганда!..

*

Бер сүз әйтмәде ул,
бер сүз дәшмәде.
Поезд киткән иде,
башкасын көтмәдә.
Кул изәргә теләгән иде,
кул гына селтәде...

*

*И...ка*

Соңгы тәмәкегә — соңгы шырпы...
Ә без аны барыбер кабызган.
Болай булгач, югалмабыз әле,
син кайгырма,
бәхетле без хәтта бик аздан!..

*Тарас Шевченконың тууына 170 ел*

# ШЕВЧЕНКОНЫ УКЫП УЙЛАНАМ...

«Ул крестьян малае иде, ләкин кеше рухы патшалыгының олы әһеле булып үсте. Ул крепостной иде, ләкин кешелек культурасында бөек көч була алды. Ул рус армиясе коллыгында ун ел газап чикте, ләкин Россиянең азатлыгы өчен аның эшләгәннәре унлап армия башкарган эштән дә күбрәк булды».

Тарас Шевченко турында аның милләттәше һәм шәкертләреннән берсе Иван Франко әйткән бу сүзләр шагыйрьнең газаплы һәм героик тормыш юлын, аның талантының чиксез колачын, иҗатының революцион йогынтысы зурлыгын төгәл һәм тулы бәялиләр.

Аның якты фигурасы патша Россиясендәге хезмәтчел халыкларның караңгы тереклеге фонында ялтырап күтәрелә. Кобзарь җырында изелгәннәр һәм юксыллар сыкравы, азатлык өчен аяусыз көрәшкә өндәгән набат яңгыравы, киләчәк көннәр бәхетен котлаган куанычлы авазларның ягымлы чыңлавы берләшә. Шагыйрь халыклар ирege өчен көрәшеп яши, шуның өчен самодержавие аның гомерен өзә. Ләкин халыклар Шевченко үлеме турында һичкайчан сөйләмәде, ә аның үлемсезлеге турында һәрвакыт сөйлиләр һәм сөйләрләр.

Шевченко бик ышанып көткән бәхет инде күптән яулап алынды. Милли һәм социаль җәбердән Россия халыклары гына түгел, бүтән күп илләр дә котылды. Еллар аша текәлеп, Кобзарьның күңел күзе күзәткән матур киләчәктә яшибез без хәзер.

*Яшәрерләр кипкән чүлләр,*
*Туар анда елга-күлләр,*
*Карурманнар шаулар далада,*
*Җырчы кошлар сайрар аларда...*

Шагыйрь безнең бүгенге көннәрне уйлап шулай илһамланган.

Вакыт уза. Еллар җебе гасыр йомгагына урала бара. Һәм безнең Шевченконы аңлавыбыз да һаман тирәнәя. Аның үлемсез образы торган саен үсә һәм күтәрелә. Хәзер аны планетабызның бик күп халкы ярата һәм укый. Кобзарьны укып һәркем матур итеп тормышны ярата белергә, дошманга нәфрәтле булырга өйрәнә, канатлана һәм көрәшкә рухлана — кыскасы, зур тормыш һәм иҗат мәктәбе үтә. Бу үрнәк һәркемне ватандар булырга, җан-тән белән бирелеп туган илгә хезмәт итәргә өйрәтә.

*Тик йөрәге гарип булган кеше*
*Якын итми туган илкәен...*

Үзенең патриотик хисләрендә Шевченко әнә шул фикерне раслап җырлый. Аның иртәгәге көнгә ышанычын һич нәрсә какшата алмаган.

Шевченко тормышын өйрәнүчеләрнең язганы искә төшә: Гурьев шәһәре урамында ул кемдер сындырып ташлаган, ләкин әле яшел булган, кипмәгән бер тал чыбыгын күрә. Күрә дә, шуны коймага салып, үзе сөргенгә бара торган яңа урынга алып китә. Каспий диңгезенең кырыс Мангышлак ярына, ташландык ярымутрауның ташлы туфрагына тере яшел чыбык килеп төшә! Яңа җиргә казып утыртылган шул чыбык

үренте җибәрә. Шагыйрь аңа көн саен су сибә һәм әлеге тал еллар үткәч өянке булып үсеп җитә. Эссе көннәрдә Шевченко шуның күләгәсендә утыра...

Шагыйрь үлгәч, Украинада ул барлык паркларда һәм бакчаларда искиткеч матур шундый тере һәйкәлләр күпләп калкып чыга — халык яшь имәннәр, юкәләр һәм өрәңгеләр утыртып үстерә һәм аларның барсын да Шевченко куаклары дип атый. Яшел һәйкәлләр әле хәзер дә өзлексез күтәрелә. Сөекле шагыйренең бәхетсезлектә үткән тормышын халык, әйтерсең, чәчәкләр белән, яшәешнең күркәм шатлыгы белән шулай бизәргә тырыша. Чөнки халык тынгысыз Кобзарь йөрәгенең тормыш ямен чиксез яратканын белә — шундый йөрәкле булганга да ул һичкайчан рух төшенкелегенә бирелмәгән, үзенең кешелек дәрәҗәсен җуймаган, аның кайнар темпераменты нинди генә кыенлыклар алдында да сүрелеп калмаган. Шагыйрьнең күпчелек еллары чамасыз авыр шартларда үтә, ләкин ул һәрвакыт һәм һәркайда үзенең рухи дөньясын кешеләргә файдалы булган эшләр белән баета белгән.

Үзеннең бөтен сәләтеңне, рухи көчеңне, талантыңны һәм илһамыңны биреп халыкка ничек хезмәт итәргә кирәген Шевченкодан өйрәнергә мөмкин һәм өйрәнергә кирәк.

Бездә күбрәк шагыйрь Шевченко турында сөйләнелә. Ә бит Шевченко хәрби коллыкта үткәрелгән җәфалы елларда тормыш хакыйкатен тулы чагылдыра торган, югары художестволы повестьлар циклы («Ялчы хатын», «Каторжан», «Князь бичәсе», «Музыкант», «Бәхетсез кеше», «Капитан хатыны», «Игезәкләр», «Рәссам», «Морале булган һәм рәхәт бер прогулка») иҗат иткән прозаик та әле. Шул ук вакытта ул драматург та — «Назар Стодоля» пьесасы һәм «Никита Гайдай» исемле драматик әсәр авторы. Шагыйрьнең «Көндәлек»ләре томын аның тулы автопортреты дип бер дә икеләнмичә әйтергә мөмкин. Анда Кобзарьның иҗат психологиясе, чиксез киң белем даирәсе, дөньяга карашы, фәлсәфи һәм политик фикерләве бик ачык күренә.

Шевченко үз гомерендә эшләмичә, язмыйча бер генә сәгать тә, бер генә көн дә тормаган. «Виртуоз уйнаучыга инструмент, рәссамга пумала кирәк булганы кебек үк, дип яза ул, әдәбиятчыга да язу эше белән бертуктаусыз шөгыльләнү кирәк».

Бу — аның иҗат эшендә батырлыкка өндәве!

Кобзарь үзен фикер иясе — материалист, тарихчы, археолог, революционер-демократ һәм фольклорчы буларак яхшы таныта. Ә Шевченко-рәссам турында сөйләгәндә, белгечләр аның оста портретчы, бик яхшы иллюстратор булуын әйтәләр. Ул агачка, металлга яки сөяккә чокып рәсем ясау һөнәре — офорт һәм гравюра өлкәсендә дә зур уңышларга ирешә. Искиткеч башкарылган шундый эшләре өчен аңа гравюра академигы дигән мактаулы исем дә бирәләр.

Билгеле булганча, сөрелгән Шевченко Арал диңгезен һәм ярларын өйрәнү буенча экспедициядә катнаша. Фәнни максат белән шул вакытта ул ясаган рәсемнәр хәзер дә чиксез кыйммәтле сәнгать документы булып саналалар. Шул ук сөргендә шагыйрь скульптура белән дә шөгыльләнә — балчыктан әвәләп фигуралар ясый, аларны алебастрдан үзе үк коя.

Замандашлары Шевченконы бик оста җырчы һәм актер, театр белгече һәм декламатор, бик сирәк очрый торган зәвыклы музыкант итеп белгәннәр. Ул хәтта опера да язып караган...

Үзенең әнә шул сәләтен, бетмәс-төкәнмәс шул талантын Шевченко кеше бәхете өчен көрәштә корал итә, хезмәт ияләре арасында революцион идеяләр һәм культура пропагандалау өчен куллана.

Үләр алдыннан ул Киевта ярлы-ятимнәрне, «кара» эшчеләрне түләүсез укыту өчен «Якшәмбе көн мәктәпләре» оештыручыларның берсе була, шул мәктәпләр өчен махсус «Украин әлифбасы» төзи. Үз әлифбасына ул, аңарчы булганча, догалар һәм дини язмалар тутырмый, ә героик әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр кертә. Ә боларын инде аның иҗтимагый эшчәнлегенең героик үрнәге итеп санарга кирәк.

Шевченконың кеше йөрәгенә үтеп керә торган кайнар сүзләренә һәркем колак салган — аларны күңелдән ятлаганнар, җыр иткәннәр. Моның сере — шагыйрьнең югары осталыгында, әлбәттә. Кобзарьне төрлечә тәрҗемә итүчеләр, шул җөмләдән мин дә, әнә шул осталык мәктәбен үтү белән аеруча бәхетле. Ул осталык исә шундый гади, шундый көчле һәм шундый камил, беренче карауда, аңа хәтта бик җиңел

ирешелгәндер төсле тоела. Ләкин асылда чиксез зур хезмәт, бик зур тырышлык таләп итә ул.

Шевченко — халыкчан. Аның шигырьләренең һәр юлы халык уйлары, халык хисе, аның сагышлары яки куанычлары белән сугарылган. Шуңа күрә алар үзләренең образлар системасы, эпитетлары, метафоралары белән дә чын халыкчаннар. Шигырьләренең музыкаль яңгырашы исә бу сыйфатны тагын да көчәйтә.

**Шевченко — новатор.** Ул үзенең иҗат практикасында әдәбияттан түгел, ә турыдан-туры халык поэзиясеннән алынган гаять үзенчәлекле һәм катлаулы форманы үзләштерә. Аның шигъри илһамчысы да, әдәби осталык мәктәбе дә халык поэзиясе иде.

Рәсем сәнгатендә Шевченко үзенең укытучысы Брюллов кагыйдәсе буенча эш итә: «Әйбернең копиясен эшләмә, ә аны җентекләп өйрән — күзәт!» Әдәби иҗатта да ул шул закон белән эш итә. Менә аның иҗат программасы: «Кешеләрне белү өчен, алар белән бергә булырга кирәк. Ә алар турында язу өчен, син үзең кәгазь пычратучы гына түгел, ә кеше булырга тиешсең. Шулай икәнсең — яз, һәм синең эшең намуслы эш булыр».

...Кобзарьны укып без бүген үткәнебезне яхшырак аңларга, крепостной стройлы Россиянең халыклар төрмәсе караңгылыгын ачыграк күрергә өйрәнәбез. Илнең иреге аяк астына салып тапталган ул империядә:

*Молдаван да дәшми, фәннәр дә,*
*Сыкрый халык барлык телләрдә.*

*...Таллар булып иелә кеше*
*Ачы җилләр иссә.*
*Ятимнәргә кояш карый,*
*Тик җылытмый һич тә.*

*...Бирәүләр киң кырлар били,*
*Исең китәр — күр генә.*
*Ә бирәүгә — өч аршын җир:*
*Салкын кара гүр генә.*

Крестьян авылларының хәерчелеге белән алпавыт һәм паннар йортындагы зиннәтләр арасындагы чагыштыргысыз аерманы шулай бармак төртеп күрсәтеп, кыргый һәм башбаштак хуҗаларны симергән чучкалар белән чагыштырып, Николай патшаның үзен «Россиянең тормозы» санап һәм аны «ләгънәт төшкән бәндә син, каргалган да, иблис җан да син һәм кара елан да син» дип каһәрләп, Кобзарь социаль гаделсезлекне фаш итә, крепостной ятимнәрне яклый, җәберләнгән кешеләргә теләктәшлек белдерә, алар күңелендә азатлык дошманнарына каршы сүнмәс нәфрәт утларын дөрләтә.

Әгәр юксылларны кызганып, алар алдында ихтирам белән баш иеп кенә калса — шагыйрь бер яклы булыр иде. Киләчәкнең азат кешнәренә гашыйк Шевченко алга, еракка карый һәм коллыкка чик кую, азатлыкны яулау өчен берләшеп баш күтәрергә, «балта кайрап» көрәшергә чакыра: «Көрәшегез! Сез җиңәрсез! Изге ирек, хаклык һәм изге дан сезнең якта, дуслар!»

Ә көрәшү — батырлар эше. Шуңа күрә дә, менә карагыз, ди шагыйрь, безнең ата-бабаларыбыз җәберчеләргә, дошманнарга һәм баскыннарга каршы ничек кыю чыкканнар һәм куркусыз көрәшкәннәр!

Без аның шулай тәкъдим ителгән тарихи әсәрләре «Иван Подкова»ны, «Тарас төне»н, «Гамалия»не, «Гайдамаклар»ны укыйбыз. Көрәш героикасын оста тасвирлаган, паннарга каршы восстание күренешләрен күз алдына китергән бу циклның «үч алучы батырларга» чиксез мәхәббәт һәм хөрмәт белдергән «Дивана» поэмасы белән тәмамлануы шулай ук очраклы түгел. Чөнки шагыйрьнең «мин үлгәч, мине күмегез Украина җирендә сез» дигән шигырендә бөтен халыкларга адреслап әйтелгән мәңгелек васыяте бар:

*Күмегез дә кузгалыгыз,*
*Богауларны өзегез сез.*

*Дошман канында юыгыз*
*Азатлыкны үзегез сез!*

Әйтергә генә җиңел: аның 47 ел гомереннең 24 елы крепостнойлыкта, 10 елы сөргендә үткән...

Киевта яшерен оешма эшендә катнашып, законга һәм патшага каршы шигырьләр укыганы өчен шагыйрьгә хөкем карарының «иң салкынын һәм иң кешелексезен» чыгаралар. Шул карарга Николай патша үзе болай дип тә өстәгән: «Бик каты күзәтеп торырга, язарга һәм рәсем ясарга рөхсәт бирмәскә». Ватаныннан, ирегеннән, дусларыннан һәм иҗат хокукларыннан да мәхрүм итеп, Оренбург һәм казах далаларына газаплы сөргенгә озаталар.

Ләкин тормыш сөючән, үзенең бөтен гомерен һәм эшчәнлеген кешеләрнең якты көне өчен көрәшкә багышлаган шагыйрь һич тә рух төшенкелегенә бирелми, үзенең кешелек дәрәҗәсен какшатмый һәм җуймый. «Тоткынлык музасы» бер генә минутка да тынып тормый, кыю иҗат туктаусыз дәвам итә. Яшереп саклаган бәләкәй дәфтәр битләренә сагышлы һәм үчле, ягымлы һәм көчле юллар өстәлеп кенә тора... Тиңсез батырлыкның шундый үрнәге алдында баш имәскә мөмкин түгел!

Сөргеннән соң шагыйрьгә, үзе әйткәнчә, бәйдәге ирек кенә бирелә, аны күзәтеп торалар, аңа Мәскәүдә һәм Петербургта яшәү тыела. Ул Идел буйлап Нижний Новгородка кайтырга мәҗбүр. Интегеп бик күп ялваруларыдан соң гына, бары тик 1858 елда, үзе укыган художество Академиясенә эшкә әләгергә мөмкинлек туа... Украинага кайтып семья корырга, Днепр ярындагы берәр йортта яшәргә омтылыш та нәтиҗәсез кала — туган якларга кайтып төшүенә Кобзарьны тагын кулга алалар һәм, чак кына төрмәгә утыртмыйча, Петербургка куалар. Академиядә ул салкын бер бүлмәдә ялгызы яши, водянка белән авырый башлый һәм йөрәк параличыннан үлә... Дөресрәге, караңгы заманның рәхимсез режимы үтерә Кобзарьны...

Шевченко тормышы — барлык халыкларның фидакарь дуслыгын яклап һәм зурлап яшәүнең бөек үрнәге ул. Шагыйрьнең Брюллов һәм Айвазовский кебек художниклар, Герцен, Чернышевский, Белинский, Добролюбов шикелле революцион-демократлар, Некрасов, Кольцов, Плещеев, Аксаков һәм Тургенев кебек язучылар белән шәхси дус булып, якыннан аралашып яшәве, поляк революционерлары Залесский һәм Сераковский, негр актеры Айра Олдридж һәм башка бик күп милләтләрнең бөек уллары белән очрашулары һәм яхшы танышлыгы барысы да шул дуслык турында сөйли. Чех халкының бөек җитәкчесе Ян Гус турындагы «Еретик» дигән поэмасында ул барлык славяннарның бергә берләшеп азатлык өчен көрәшүләре турында хыяллана. Сөргендә чакта аның казахлар тормышын өйрәнүе һәм аларның авыз иҗаты әсәрләрен тәрҗемә иткәне билгеле. Ә Идел буйлап узганда Шевченконың Казан һәм Чебоксар турында уйлануылары нинди җан тетрәткеч итеп язылганнар...

Шуңа күрә дә хәзер Днепр ярындагы Шевченко каберенә куелган һәйкәл янына илебезнең милли республикаларыннан бик күп шагыйрьләр килә. Шевченко «Васыяте» бик күп телләрдә яңгырый. Шунысы характерлы 1939 елны — әлеге һәйкәлне ачу тантанасында — үзе тәрҗемә иткән «Васыять»не татар телендә безнең Муса Җәлил укый. Бу фактта, миңа калса, символик мәгънә бар, чөнки Җәлил үзенең Кобзарьлар токымыннан булуын артыгы белән исбат итте.

Кыскасы, Тарас Шевченконың тормышы һәм иҗаты — зур батырлык үрнәге. Ул миллионнар йөрәгендә бик күп гасырлар буена яшәр. Шагыйрь гомере — аның җырларында. Ә кайнар йөрәктә туган канатлы җырлар һичкайчан да үлмиләр!

**Зәки НУРИ.**

# Тарас Шевченко

❀

Ага су зәңгәр диңгезгә —
Кире кайтмас инде.
Казак эзли үз бәхетен —
Әмма тапмас инде.

Сәфәргә кузгалды казак —
Диңгез ярга суга.
Күңел ышана бәхеткә,
Бары акыл гына...

...Сөйгән яры елап калды,
Калды әткә-әнкә.
Кемгә ташлап китеп барды
Күз күрмәгән якка?

Чит җирләрдә очратыр ул
Кырыс кешеләрне.
Сөйләшер дә, елашыр да
Сердәш тапмас әле.

...Ул йөргән ерак җирләрдә
Диңгез ярга какты.
Уйлады бәхет табарга,
Бары хәсрәт тапты.

Торналар оча... Чал диңгез
Карап ята астан.
Елый казак — кайтыр юлын
Куе үлән баскан...

*1838. Петербург*

❀

Уйларым минем, уйларым —
Килдегез Сез хәсрәт булып,
Бастыгыз кәгазь битенә
Кырыс йөзле бер рәт булып.
Уяндыгыз сабый кебек,
Көтмичә дә таң атканын —
Нигә җилләр тузан итеп
Киңлекләргә таратмады?..

Уйларым минем, уйларым —
Чәчәкләрем, балаларым.
Үстердем Сезне, сакладым —
Җылы куыш табалмадым.

Кайтыгыз, и, балаларым,
Украинам туфрагына —
Ятимнәрне юатыгыз,
Мин үләрмен монда гына.
Табарсыз дуслар йөрәген —
Сыенганда күкрәгенә.
Бәлки дөреслек табарсыз,
Бәлки килер шөһрәте дә.
Сыендыр, и Украинам,
Кабул ит, и Ватан-анам!
Акылсызлар булсалар да,
Минем балам — синең балаң.

*1839. Петербург*

## Гогольгә

Уй артыннан уйлар оча, очып китә.
Берсе алдый, берсе канат вәгъдә итә.
Өченчесе әрнеп елый — күрми хода!
Йөрәгемә ятып елый тып-тын гына.
...Кемгә күрсәтим аларны,
Кайдан табыйм рухи туган,—
Үз янына сыендырып
Бөек сүзне аңлый торган?
Күрә белгән, ишетә белгән
Богауда үткәрә көнен.
Син көләсең, ә мин елыйм,
И бөек туганым минем.
Күз яшеннән ни тишелер?
Нибарысы яшел үлән...

Туган җирем капланырмы
Азат үскән үлән белән?
Украинам азатлыгы,
Даны һәм вөҗданы өчен,
Кырыс ата үз улының
Төшерерме башын кисеп?
Юк, төшермәс... Туйдырыр да,
Сугымга тапшырыр аны.
Әйтер патшага: «Бу сезгә
Безнең өлеш — ил корбаны».
Бирер патшага. Ул аны
Немец этләренә сузар.
Ә без менә... Ә без бары —
Беребез көләр, беребез елар.

*30 декабрь, 1844*


**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ** тәрҗемәләре.

Тукайның 100 еллыгына

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

**И Казан шәһре, торасың тауда зур**
**шәмдәл кеби,**
**Мәсҗедең, чиркәүләрең, һәр часларың**
**шәмнәр кеби.**

Г. Тукай. «Казан вә Казан арты», 1912



Иске шәһәр күренеше

Т. Зуева рәсеме

# ТУКАЙ ҺӘМ АНЫҢ ТИРӘЛЕГЕ

Хәзер Г. Тукай һәм аның күп кенә замандашларының тормышлары тарих булып калды. Бу тарихны саф, дөрес, чын итеп саклау һәм күрсәтү — тарихчылар вазифасы. Ләкин шулай булса да үткән хәл-әхвәлләрне үзләре күреп белгән кешеләрнең фикерләре белән танышу да зарарлы булмас. Шуңа күрә мин дә үзем белгәннәрне язып калдыруны тиеш дип табам.

Рәфикъ Нәфиковның «Казан утлары» журналының 1983 елгы дүртенче санында басылган «Иң бөек максат» дип аталган мәкаләсен зур игътибар белән укып чыктым. Сәбәп, бәлки, шундадыр — мин дә Уральск шәһәреннән чыгып, хәзер Казанда яшәүче кешеләрнең берсе. (Әти-әни Казан артыннан.) Уральск шәһәрендә 20 ел яшәдем (1927 елга кадәр). Шуңа күрә миңа ул дәвердә Уральскида булган күп кенә вакыйгалар билгеле. Уральскида миңа Габдулла Тукайны белгән күп кенә кешеләр белән очрашырга туры килде. Алар — шагыйрьнең якын туганнары, шәкертләре, дуслары, иптәшләре, аның мөгаллимнәре, Бәдри абзый, Алты-биш Сапый һәм башкалар. Тукайның кайбер мөгаллимнәрендә миңа да укырга туры килде (Фәтхетдин хәлфә һәм учитель Әхмәтша). Минемчә, мәкаләнең авторы 1916 елда Уральск шәһәрендә төзелгән яшьләр түгәрәге «Дуслык» турында бик вакытлы һәм урынлы язып чыккан. Мәкаләдә әйтелгән: «Шагыйрьнең (Тукайның — Х. З.) Уральскидагы дуслары, алдынгы яшьләр 1916 елда шәһәрдә «Дуслык» дип исемләнгән музыка түгәрәге оештыралар. Бу түгәрәктә алар музыка коралларында уйнарга өйрәнеп кенә калмыйлар, белемнәрен дә күтәрәләр. Бу максат белән алар үз китапханәләрен булдыралар... Шушы түгәрәктә үскән кешеләр, совет властен яклап, гражданнар сугышында актив катнашалар».

Бу сүзләрнең барысы да хаклы. «Дуслык» түгәрәгендә булган эшләрнең күбесе минем күз алдымнан уздылар. Вакытында «Дуслык» түгәрәге Уральск шәһәрендәге татарлар тормышында тирән, мәгънәле һәм күңелле эзләр калдырды. Түгәрәк спектакльләр дә куя башлады, җәмәгать файдасына лотореялар да уйнатты. Хәтердә лоторея белән бәйләнгән бер кечкенә генә эпизод сакланган. Лотореяга куйган әйберләр арасында бер зур гына төре кәҗә дә бар иде. Ул кәҗәне Төкә оч байлары, Белоусовлар түгәрәк алдында куштанлык күрсәтеп биргән булганнар. Шунысы кызыклы — ул кәҗәне безнең ярлы гына күршенең кызы отты. Ул кызның кәҗәне өстерәп кайтканы әле дә күз алдымда тора (Уральск шәһәрен татарлар һәм казахлар арасында «Төкә» дип тә атыйлар иде. Урал елгасына якынрак, шәһәр кырыенда торучы татарларны «төкә нугайлары» дип атаганнар). «Дуслык» түгәрәге Уральскида хатын-кызлар җәмгыятен төзүдә дә катнашты. Алдынгы яшьләрнең, хатын-кызлар җәмгыяте әгъзаларының 1917 ел 1 нче Май көнендә кызыл әләмнәр тотып, «алга, алга...» дип татар телендә «Марсельеза» җырлап, мәйданга килеп митинг уздырулары да хәтердә калган.

Кызыл әләмнәр тотып алда баручылар арасында минем әни, Газизә Зәбирева да бар иде. Аннан соң, 1920 нче елда, ашау-эчү ягыннан кыенлыклар башлангач, урамда барганда бер хатын әнине шундый сүзләр белән битәрләде: «Менә, Газизә, син кичтердәң бу тормышны, син кызыл әләмнәр күтәреп җырлап йөрдең, менә хәзер инде әләмеңне кочаклап утыр». Әни аңар кул селкеп — «юкны сөйләмә» — дип кенә җавап бирде.

«Дуслык» түгәрәгенең беренче китапханәсе безнең өйдә ачылды (Воронеж урамы, 38 нче йорт). Аннан соң китаплар һәм укучылар күбәйгәч, бер татар меценаты

биргән зур бүлмәгә күчерелде. Китапханә безнең өйдә булган вакытта, аның китапханәчесе Вәли Зәбиров булды. «Дуслык» түгәрәген оештыручылар һәм аның җитәкчеләре Вәли Зәбиров һәм Гобәй Калаков булдылар. Кыскача гына булса да аларның тормышлары турында язып узмакчы булам. Вәли Габдрахман улы Зәбиров 1898 елда Уральск шәһәрендә туган. 1919 елның башыннан ук партия члены. Уральск шәһәре оборонасында катнашып, акларга каршы сугышып йөрде. Аннан соңрак партия һәм совет идарәләрендә эшләде — Джамбейтада районның партия секретаре, Уральскида партиянең губкомында бүлек башлыгы, 1923 елда — губернаның башкарма комитетының председатель урынбасары һәм шул ук вакытта профсоюзның губерна идарәсе җитәкчесе, 1924 елда Кустанайда губерна халык мәгарифе бүлеге башлыгы, соңрак партиянең губком секретаре. Шул ук елларны Кустанайда казах телендәге «Аул» исемле газетаны оештырды һәм беренче редакторы булды. Ул газета хәзерге көннәргә хәтле чыгып килә, тик исеме генә үзгәртелгән. 1930—36 елларда Ленинград шәһәрендә, СССР фәннәр академиясе системасында фәнни эштә булды. Соңгы хезмәт урыны СССР фәннәр академиясе тарихи ассоциациясенең гыйльми секретаре. Вакытсыз вафат булуы сәбәпле, башлаган фәнни эшләрен дәвам итә алмады. Гобәй Калаков шулай ук карт большевик, Төркиядә Совет илчелегендә эшләде.

Миндә «Дуслык» түгәрәге члennарының гомуми рәсеме саклаԥып килә. Шулай ук Уральскидагы партия активының гомуми рәсеме дә. Алар арасында казах язучысы Мохтар Ауэзов белән Вәли Зәбиров тә бар.

Шунысын әйтергә кирәк, Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты күптәннән өйрәнелә башлауга карамастан, бу өлкәдә «ак таплар» яки гомумән ялгыш фикерләр һаман да кала килә. Кызганычка каршы, әдәбият галиме И. Нуруллинның соңгы елларда чыккан һәм массовый тираж белән укучыларга таралган китаплары да мондый җитешсезлекләрдән азат түгел. Мәсәлән, хәзерге көнгә кадәр Тукайның Кырлайдан Уральскига килү датасы төгәл билгеләнмәгән килеш кала. Төрле авторлар төрле даталарны күрсәтәләр (1894—1897 еллар). Ләкин архив документларына карагандa, Тукайның апасы (безнең әниебез) Бибигазизә кияүгә 1895 елның 18 декабрендә чыккан. («Казан утлары», 1981, 12 сан, 176—177 битләр). Истәлекләрдән билгеле булганча, Тукай Уральскига килгәндә Бибигазизә кияүдә була инде. Димәк, шагыйрьнең Уральскига килүе дә югарыда күрсәтелгән вакыттан соң гына булуы мөмкин. Шагыйрьнең хатын-кызларга мөнәсәбәте мәсьәләсе дә ачыклык кертүне сорый. Тукайның замандашлары, туганнары, укытучылары, дуслары белән булган әңгәмәләр искә төшкән саен мин шагыйрьнең хатын-кызлар белән аралашырга теләмәвенең бердәнбер сәбәбе итеп аның туберкулез белән авыруы дигән фикергә киләм. «Күк сыер» (1908) исемле шигырен генә искә төшерик. Анда шагыйрь язган чакта йөткерүенә зарланып түбәндәге сүзләрне әйткән:

*Я, минем кайда хикәям? Ник аны читкә борам?*
*Юк, зарарсыз; мин шулай язган чагында йөткерәм.*

Билгеле булганча, бу вакытта аңа нибарысы 22 яшь кенә иде.

Кыскасы, халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүче галимнәребез шагыйрь шәхесенә кагылышлы һәрбер фактка бик игътибарлы булсыннар иде.

**Хөсәен ЗӘБИРЕВ.**

**Әлфия Галләмова**

# КАЛАЛАРГА КАРАП...

Хәзер һәркем күреп-белеп тора: авыл хуҗалыгындагы эшләр камилләшә, механикалаша бара. Бу шартлар авылларның шәһәрләргә якынаюына, ике арадагы аерымлыкларның кимүенә китерә. Республикабызның даны булырдай КамАЗ янындагы хуҗалыкларны гына алып карыйк.

Бу якта киң масштаблы производство комплексларының барлыкка килүе һәм аларның тиз үсеш алуы экономиканың нык үзгәрүен билгеләде. Регионда азык-төлеккә ихтыяҗ арта бару исә, анда нык нигезле авыл хуҗалыгы зонасын булдыруны таләп итте. Шуның белән бергә Татарстан республикасында шундый зона төзү тәҗрибәсен өйрәнү практик һәм фәнни әһәмият тә ала.

Ләкин бу тема һаман да фәнни яктан эшләнмәгән әле. Матбугатта дөнья күргән мәкаләләр санаулы гына. Шулар арасыннан КПССның Тукай район партия комитеты беренче секретаре Йолдыз Курмашевның ТАССРның 60 еллыгы уңае белән басылып чыккан, «Чәчәк ат, Татарстаным» җыентыгына кертелгән «КамАЗның аграр цехы» исемле мәкаләсен аерып күрсәтергә мөмкин.

Нидән башланды соң бу яңалык? КПССның XXIV съезды Директиваларында, Татарстанда йөк автомобильләре җитештерә торган заводлар комплексы төзү белән бергә шул тирә районнарда ярдәмче предприятиеләр булдырырга кирәк, диелә.

Съезд карарлары нигезендә Кама аръягында зур территориаль производство комплексын төзү эшләре кузгалды. Ләкин, Ленин өйрәткәнчә, нык нигезле авыл хуҗалыгыннан башка бернинди хуҗалык төзелеше дә мөмкин булмаган кебек, әллә нинди бөек планнар да тормышка аша алмый.

Совет дәүләте безгә, яңа индустриаль комплекс төзелә башлагач, шәһәр яны зонасын булдыруга да зур игътибар бирде. Кама автогигантының нигезен салган вакытта ук КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы күрсәтмәсе һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты тәкъдиме белән РСФСР Министрлар Советы Кама автомобиль заводы һәм Түбән Кама нефть-химия комбинаты төзелешләре районында специальләшкән совхозлар оештыру турында кайгыртучанлык күрсәтә башлады. Бу зонада яшелчә, бәрәңге, сөт буенча специальләшкән дүрт совхозны эреләндерү, утызлап яңа эре совхоз төзү күздә тотыла иде. Шәһәр яны зонасы Тукай, Түбән Кама, Алабуга, Зәй, Минзәлә, Әгерҗе, Сарман, Мамадыш районнарының җитмеш ике колхозын берләштерде.

Мондый планнар зур чыгымнар таләп итә. Тугызынчы һәм унынчы бишьеллыкларда Кама комплексының аграр зонасын үстерү өчен республикабызда авыл хуҗалыгына бүленгән барлык капиталь чыгымнарның 23 проценты тотыла, аның мәйданы республика җирләренең уналты процентын били. Һәр кешегә туры килә торган электр энергиясе күләме дә елдан-ел арта. Кама промышленность гигантының авыл хуҗалыгы зонасын төзегәндә хуҗалыкны төптән үзгәртеп кору күздә тотыла. Бу — күп тармаклы хуҗалыкларны специальләшкән хуҗалыкка әйләндерү юнәлеше. Алар, нигездә, сөт, ит, яшелчә җитештерү тармакларына бүленеп йөртелә.

Җитмешенче еллар башында бу зонада вак фермалар шактый күп иде. Барлык

---

Бу санда «Азык-төлек программасы — бөтенхалык эше» рубрикасы 1983 елгы «Авыл офыклары» конкурсына укучыларыбыздан килгән материаллардан тупланды.

хуҗалыклар, аз-азлап, сыер да, дуңгыз да, кош та асрыйлар. Аларның күбесе кул хезмәтенә генә нигезләнгән, иске биналарга урнашкан, шунлыктан монда хезмәт җитештерүчәнлеге түбән иде.

Сөт җитештерү проблемасын хәл итү заманча салынган терлекчелек комплекслары төзүдән башланып китте. Яңа авыл хуҗалыгы предприятиеләре төзелешенә фәнни-тикшеренү проекты институтлары, «Камгэсэнергострой», «Татнефтестрой», «Татэнергострой» кебек идарәләр тартылды. Ике еллык эш тәҗрибәсе специальләшкән бүлекчәләр булдыруның зарури икәнлеген күрсәтте. Шунлыктан, «Камгэсэнергострой» һәм «Татэнергострой»га авыл төзелеше өчен махсус идарәләр төзү бурычы йөкләнә. Тугызынчы бишьеллык елларында ук зонада «Гигант», «Ильбухтинский», «Камский», «Новотроицкий» совхозларында һәм Җәлил, Калинин исемендәге колхозларда 800—2000 баш савым сыерына исәпләнгән комплекслар кулланууга тапшырылды. Унбиш абзарга реконструкция ясалды.

Материаль база булдыру сөт җитештерүне эре, специальләшкән хуҗалыкларда тупларга, аны промышленность технологиясенә күчерергә ярдәм итте. Сөт җитештерүдәге яңа производство куәтләре аларны промышленность технологиясе шартларына яраклаштырылган яхшы нәселле терлекләр белән тәэмин итү мәсьәләсен алга куйды.

Моны хәл итү өчен 1974 елда «Ворошиловский» совхозы базасында нәселле, югары продуктлы мөгезле эре терлекләр үстерү комплексы төзелде, ә бу хуҗалыкта булган терлекләр башка хуҗалыкларга тапшырылды.

Ит җитештерү проблемасы исә мөгезле эре терлек симертүче хуҗалыкара предприятиеләр һәм берләшмәләр оештыру белән хәл ителә. Шәһәр яны шартларында ит җитештерү өчен зур масштабларда мөгезле эре терлек үрчетү сөт җитештерү юнәлешендәге хуҗалыкларга тискәре йогынты ясый. Шунлыктан сөтчелек комплексларын— шәһәргә якын торган Тукай районында, ә ит җитештерү хуҗалыкларын читтәге — Зәй, Алабуга, Минзәлә районнарында булдыру планлаштырылды.

Үсеш юлында туган кыенлыкларны җиңү максаты белән 1973 елны Зәйдә ит җитештерү буенча хуҗалыкара берләшмә төзелде. Эшли башлавының беренче елында ук ул үзенең зур мөмкинлекләрен ачты. 1974 елда биредә 500 мең сумлык табыш алынса, 1975 елда ул 897 мең сум тәшкил итте. Хуҗалыкара берләшмә оешу ит җитештерүне рентабельле тармакка әверелдерде. 1980 елда район күләмендә җитештерелгән барлык итнең 90 проценты Зәй хуҗалыкара берләшмәсенә туры килә.

Ит продуктлары җитештерүче Брежнев дәүләт-колхоз берләшмәсе төзелгәч кенә хуҗалыкара кооперация җитди үсеш алды. Элек хуҗалыкара мөнәсәбәтләр колхоз белән колхоз, совхоз белән совхоз арасында гына булса, хәзер аның колхоз белән совхоз арасында да урнаштырылуы Брежнев дәүләт-колхоз берләшмәсе мисалында ачык күренә. Хуҗалыкара берләшмә төзелү зонада ит җитештерүне өч тапкыр арттырырга мөмкинлек бирде. 1975—76 еллардагы Бөтенсоюз социалистик ярыш нәтиҗәләре буенча оешмага СССР Министрлар Советы, ВЦСПС, ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы тапшырылды.

Яшелчә җитештерүне арттыру Кама буе шәһәр яны зонасының хәл ителәсе мәсьәләләреннән берсе иде. Бу тармак зонада яңабаштан төзелде.

1971 елда барлык хуҗалыклар да диярлек өлешчә яшелчәчелек белән шөгыльләнделәр. Әмма ул — бик аз мәйдан биләгән, кул хезмәтенә нигезләнгән, алдынгы технологик ысуллар бөтенләй кулланылмаган өченчел тармак иде.

1975 елда Кама шәһәр яны зонасында яшелчәчелекне үстерү мәсьәләләре ТАССР Министрлар Советы белән берлектә КПСС өлкә комитеты бюросында яңадан каралды, әһәмиятле чаралар билгеләнде.

Карар күрсәтмәләреннән күренгәнчә, «Ворошиловский», «Ильбухтинский», «Гигант», «Камский» совхозларында яшелчә үстерүгә аерым игътибар бирелә башлады.

Унынчы бишьеллыкта бу зонадагы яшелчәчелек рентабельле тармакка әверелде. Бишьеллык ахырында исә, яшелчәчеләр шәһәр сәүдә оешмалары белән тыгыз элемтәгә керделәр. Брежнев шәһәре сәүдә идарәсе һәм «Ворошиловский» совхозы арасында төзелгән килешү нигезендә махсус график кабул ителә. Иртә өлгерә торган яшелчәләр кырдан туп-туры кибетләргә китерелә башлады.

Яшелчә белән тәэмин итүдә өзеклек булдырмау максатыннан чыгып совхоз кы-

рында лаборатория, вакытлыча саклау һәм сортларга аеру өчен асфальт-бетон мәйданчыгы булган яшелчә кабул итү һәм тапшыру пункты төзелде.

«Ворошиловский» совхозында өч мең тонна сыйдырышлы саклау склады салынды. Унынчы бишьеллык ахырында яшелчә һәм бәрәңгене контейнерлап хәзерләү методы кулланыла башлады. 1980 елда андый контейнерлар саны уналты меңгә җитте. Бу хәл зонада аграр-промышленность берләшмәсе булдыру мәсьәләсен республика эшләренең көн тәртибенә куйды. Бу мәсьәлә бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмый.

Без югарыда шәһәр яны зонасындагы авыл хуҗалыгы производствосына караган өч төп юнәлешкә генә күзәтү ясадык. Бу юнәлешләргә кагылышлы мөнәсәбәтләр башка тармакларда — химияләштерү, сугару, электрлаштыру өлкәсендә дә үсеш алдылар.

Зонада 1977—78 елларда «Сугару», «Сельхозхимия», «Сельхозэнерго» кебек оешмалар барлыкка килде. Алар, алдынгы метод һәм фән казанышларына таянып, сугару, химияләштерү, электрлаштыру мәсьәләләре белән махсус шөгыльләнәләр. Тукай районы «Сугару» берләшмәсе эшчәнлегенә кыскача тукталып үтик. Ул 1981 елның 1 гыйнвареннан эшли башлады. Аның карамагына районның барлык хуҗалыкларының сугарулы җирләре һәм техника тапшырылды. «Сугару» берләшмәсе сафка басу белән яшел масса хәзерләү күләме сизелерлек артты. Шулай ук «Сугару», «Сельхозхимия», «Сельхозэнерго» берләшмәләре эшендә җитешсезлекләр әле шактый иде.

Барлык сугару механизмнарының «Ворошиловский» совхозында тупланувы үзен акламады. «Сугару» берләшмәсе продукция җитештерү белән тиешле дәрәҗәдә кызыксынмый.

Зонада терлекләр өчен азык хәзерләү проблемасы җитди мәсьәлә булып кала бирә. Культураларның түбән уңдырышлылыгы — бу өлкәдә җитди кимчелекләрнең берсе. Аны ашламаларның аз кертелүе, басуларны даими сугармау белән аңлатырга туры килә.

Унынчы бишьеллыкта яшелчә җитештерү планнары, тулаем алганда, арттырып үтәлсә дә, башлы суган, иртә өлгерә торган кәбестә җитештерүдә шәһәр кешеләренең ихтыяҗы тулысынча канәгатьләндерелмәде.

Җитешсезлекләр булса да, авыл хуҗалыгы продукцияләре җитештерүне сизелерлек арттыруда зонада аграр-промышленность интеграциясенең әһәмияте зур. 1970 ел белән чагыштырганда, унынчы бишьеллыкта уртача еллык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү: яшелчә — 10,8; сөт — 2; ит 2,3 тапкырга артты.

Мондый күркәм үзгәрешләр тәэсирендә авылларның йөзе дә башка төс алды. Унынчы бишьеллыкта «Гигант» совхозы бу яктан районның барлык хуҗалыклары өчен дә үрнәк була ала. Бирәдә ике мең баш терлеккә исәпләнгән комплекс белән бер үк вакытта урта мәктәбе, Культура йорты, кибетләре, больницасы, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты булган Яңа поселок үсеп чыкты. Һәр йортның телевизоры, суыткычы, кер юу машинасы, күп кенә гаиләләрнең үз машиналары яки мотоцикллар бар. Юллар, мәйданнар, үзәк урамнар асфальтланды.

Кама промышленность комплексы авыл зонасында киң мәйданда алып барылган социаль-культура чаралары крестьян психологиясенә дә уңай йогынты ясый. Бу озак дәвамлы процесс һәм без аны ныклап өйрәнергә тиешбез.

«Ворошиловский» совхозы базасында югары продуктлы терлекләр үстерүче хуҗалыкара берләшмә оештырганда, мәсәлән, төп кыенлык хуҗалыкны үзгәртеп коруда түгел, ә күп кенә җитәкчеләрнең психологик каршылыкларын җиңүдә булды.

«Ничек инде, үзеңнең күз карашы кебек тәрбияләгән сыерларыңны башкага биреп җибәр дә, кемнәндер өлен-төпен үстергән бозавыйн ал имеш,— ди бер колхоз председателе.— Болай хуҗалыкның төп башына утыруы да бар бит...»

Бу — бер аның фикере генә түгел. Яңа эш күп вакыт һәм көч сорады. Мәгълүм ки, крестьяннар бары тик үзләре күреп торсалар гына яңалыкның файдасына ышаначаклар. Бу фикер В. И. Ленин хезмәтләрендә дә бар.

Тукай районында, Ленинның шушы күрсәтмәсенә нигезләнеп, хезмәткә яңа форманың өстенлекләрен аңлату эшләре дә алып барылды. Нәтиҗәдә элек-электән икмәк игү белән генә шөгыльләнгән авыллар, чагыштырмача кыска арада үзенең йөзен үзгәртеп, икмәк белән бергә ит, сөт, йомырка, бәрәңге һәм яшелчә җитештерүдә шатландыргыч нәтиҗәләргә ирештеләр.

# Фирдәвес Гыйльметдинов

# ТУАР КӨННӘР ЯКТЫЛЫГЫ

Кояш чыгышыннан искән салкынча җил агачларның яфракларын лепердәтә. Инде ярыйсы ук озынайган сентябрь төне куе караңгылыгын таратырга ашыкмый: офык читеннән кыяр-кыймас яктырып килгән таңга баш бирергә теләмичә, суынган җиргә ныграк сарыша. Тик аның минутлары санаулы, инде мең миллион кен һәм төннәрне каршылаган чал җиһан яңа көн туугa йөз тота.

Раушания, биек урыс капканы тавышсыз гына япканнан соң, китәргә бик ашыкмады, әле йокыдан да ачылып җитмәгән зиһенен сафландырырга теләгән кебек, йөзен тыгыз җил иркенә куйды. Җылы, йомшак урында рәхәтләнеп йоклыйсы иде әле дә, эшкә өлгерергә кирәк. Механизаторларга иртәнге аш әзерлисе бар. Хезмәт көне кайнар аштан башланып китәргә тиеш: көнозын басуда бит алар, тамаклары тук була күрсен. Раушания адымнарын кызулатты, ашханәгә юл тотты.

Чыгарылыш имтиханнарыннан соң, җәй колхоз ашханәсенә бәйле мәшәкатьләр белән үтте. Иртәнге сәгать бишенче яртыдан кичке җидегә кадәр алар — аш-су тирәсендә. Әүвәл пешерәсең, авыл эшчәннәре ашап-эчкәннән соң, җыештырасың. Бу эшкә дүртәү алындылар алар. Алабуга районының Иске Юраш урта мәктәбен тәмамлап, шушы эштә калуына Раушания үзе сәбәпче.

Әйләнә-тирәдә яз тантана итә иде. Шомырт агачлары, сирень куаклары шау чәчәккә күмелгән. Хыяллар, өметләр. Унынчы класста күңел бигрәк ашкынучан була икән. Мәктәп ишеген дәррәү ачып чыгалар да, әллә кайдагы институтларның колонналары арасыннан кереп киткәндәй тоялар үзләрен. Ерак та түгел, завод-фабрика морҗалары күренә. Кайберәүләрнең шунда китәсе килә.

— Егетләр, кызлар, сезгә булган ышанычны акларсыз, дип уйлыйм. Колхоз производствосында да белем илендә тырышкан кебек кайнарсыз, йөзгә кызыллык китермәссез!

Мәктәп директоры Әнәс Мирзаяновичның тигез, тыенкы тавышы Раушанияне уйлар дулкыныннан чынбарлык ярына чыгарып бастырды. Ул сиздерми генә янәшәсендә басып торган иптәш кызларына күз салды. Линейкага тезелгәннәр бар да директорның сүзләрен йотлыгып тыңлыйлар. Үз уйларына оялып куйды хәтта: нигә кирәксез хыялларга бирелде соң әле ул. Алар бит, Иске Юраш авылы кызларыннан үзгә буларак, җиде кыз һәм өч егет үз авылларында калырга теләк белдерделәр. Апрельдә Илмәт һәм Юраш авылларының колхоз җитәкчеләре белән очрашып сөйләшү булды. «Тиешле хезмәт һәм ял шартлары тудырылса, без үз җиребездә калып эшләргә каршы түгел»,— диделәр илмәтләр. Очрашудан Калинин исемендәге хуҗалык җитәкчесе ачык йөз белән кайтып китте. Аныкылар калачак!

Сүзләрендә тордылар кызлар: калдылар. Май аенда яшьләр партиянең Алабуга шәһәр комитеты беренче секретаре Й. В. Курмашев белән очрашуда булдылар. Анда аларга шулай ук кулларыннан килгән ярдәмне күрсәтергә вәгъдә иттеләр. Туган туфракларында калырга уйлаган кызлар өчен махсус ферма салынырга тиеш иде. Кызлар колхоз һәм район җитәкчеләренә шартны кабыргасы белән куйдылар: без, әниләребез шикелле, әче таң белән торып төнгә кадәр эшләргә теләмибез, безнең өчен җиде сәгатьлек, ике сменалы эш булсын, диделәр алар. «Теләгегезгә ирешерсез!» Җавап шундый булды.

...Беркөнне Раушания эштән кәефсезләнеп кайтты. Әтисе Гайфетдин төпчек кызының йөзенә карау белән нинди дер күңелсезлек булуын чамалады.

— Нәрсә булды, кызым, төсең киткән? Утыр әле каршыма, сөйләп җибәр,— диде.

— Әти, нишләп колхозда калдым икән мин,— диде Раушания.— Кыен бит ашханәдә эшләве. Кайберәүләр сангa да сугып бетермиләр.— Раушания ашханәдә өлкән пешекче һәм мөдир вазифасын үти иде.— Тагын шунысы: вәгъдә иткән фермалары быел әллә җитешә, әллә юк. Кышын нишләрбез?

Гайфетдин ага беравык дәшми-тынмый уйланып утырды. Кулын кызының җилкәсенә куйды.

— Рәушания, син инде хәзер олы кеше, кайбер мәсьәләләрне акрынлап үзең дә хәл итәргә тиешсең. Тик шулай да, әтиең буларак, шуны әйтәсем килә: тормышта бар да син дигәнчә генә булмый, аның матур яклары күп, һич көтмәгәндә, кырыслыгы да калкып чыга. Үзебезне генә ал син. Әниең белән утыз елдан артык гомер кичерәбез. Шахтада эшләгәндә миңа бәла килде, авырлыкның зурысы әниең җилкәсенә төшеп калды. Ул бик акыллы булып чыкты. «Әйдә, авылга кайтыйк, без җир кешеләре, ничек тә җиргә берегеп гомер итәрбез»,— диде. Аның киңәшен тоттык. Мәнә күреп торасың, сезнең җидегезне дә карап-тәрбияләп үстердек, кеше иттек. Безнең янда бер син генә калдың. Авыл безнеке, без авылныкы, кызым. Монда җиргә аякның итеп басып йөреп була. Беренче кыенлык чыгуга, чигенергә ашыкмыйк әле.

Һәр дүшәмбедә партиянең шәһәр комитетында уздырыла торган киңәшмә азагына якынлашты. Төрле оешма-предприятие, колхоз-совхоз җитәкчеләре беренче секретарьның бүлмәсеннән чыга башладылар. Йолдыз Вагыйзович Курмашев райбашкарма комитеты председателе Н. Б. Баһрамовка беразга тоткарланырга кушты.

— Нурулла Баһрамович, безнең Калинин исемендәге колхозда хезмәт биографияләрен башлап җибәрергә калган укучылар белән эшләр ничегрәк тора соң?

— Әле үткән атнада гына райбашкарманың киңәйтелгән утырышында яшьләр хакында зур сүз булды. Район күләм мәрәҗәгать белән чыккан бу уңганнар өчен ферма тезелешен барлык чаралар белән тизләтергә күрсәтмә бирелде.

Илмәт кызларының киләчәккә булган якты өметләре районның иң зур оешмаларында да шундый күзәтү астында тора икән, димәк, туар көннәр, мөгаен, аларның ышанычын аклар!

## Гаилә Закирова

# КҮТӘРЕЛҮ

Бәркәтә авылының иң мөхтәрәм кешеләре Шушма колхозы председателе Кәрам Әхмәтҗанов өенә туй мәҗлесенә җыелдылар. Өй иркен, якты, табын зур, мул, кунакларның иң кадерлеләре килгән: уңган колхозчылар, авылның өлкәннәре, механизаторлар, укытучылар, бригадирлар...

Мәнә табын хуҗасы тирә-юньне яңгыратып торган музыканы туктатты. Шау-гөр килеп утыручы кунаклар тынып калдылар. Улы белән яшь киленгә үз теләген әйтү өчен, беренче сүз ата кешегә — Кәрамга бирелде.

Шушы минутка кадәр әллә нилэр әйтер кебек җилкенеп утырган иде, вакыты җиткәч, шактый каушады. Дулкынлануын башкаларга сиздермәскә тырышып, гадәти сүзләр генә сайлап алды да, улы Ибраһим белән Җәүһәриягә матур киләчәк теләп, тиз-тиз кабат утыру ягына карады. Кешеләр сизгәндерме-юктырмы, бу тантана аның шактый тирәндә яткан хатирәләрен яңартып, күңелен тәмам алгысытып җибәргән иде.

Туй бара, Кәрамның олы улы Ибраһим туе. Заманында Нәфисә белән икесенең еллар буе көтеп алган шатлыклары булып, беренче балалары тугач, Кәрамның әнисе Хатимә карчык кыяр-кыймас кына:

— Балалар, бер фикерем бар иде,— диде.— Әллә улыгызга сугышта ятып калган абыегыз Ибраһим исемен кушасызмы? Әтиегез-мәрхүмнең дә теләге шул иде: исән улларымның балалары туса, сугышта шәһит киткән өч улымның исемен куштырырбыз, гел үзебезнең янда кебек тоеп яшәрбез, ди торган иде...

Җәлилнең улына һәлак булган туганнары Гаяз исемен куштылар. Кәрамның олы улы Ибраһим булды, кечесе — Әкрам. Өлкәннәрнең киңәше нәселгә сугыш батырларын кире кайтаргандай итте.

Гомерләр уза торды. Инде әнә икенче буын вәкиле, яшь Ибраһимның да туе килеп житте. Өй тулы — кунаклар.

— Яле, Мингалим абзый, әйт әле күңелең түрендә яшьләргә саклап йөрткән кадерле сүзләреңне! — Мәжлесне алып баручы үз вазифасын бик төгәл үти иде.— Жәмәгать, Мингалим абзый Гатинны тыңлап карыйк әле!

Кәрам да, уйларыннан арынырга тырышып, Мингалим агайга карап тора башлады. Авылның аксакалыннан саналучы агай:

— Бу йортның мактанырлык тарихы бар,— дип еректан алдырып сөйләп китте.— Монда биш малай, бер кыз үсте. Егетләрнең өчесен сугыш алды...

Хәтерли Кәрам, барын да яхшы хәтерли. Алар юа, кузгалак, какы жыярга, түбәсендәге манарасына менеп, тирә-юньдәге авылларны күзәтеп төшәргә Биек Тауга барганнар иде. Кайткан жиргә — елаш та сыкташ. Сугыш башланган. Абыйлары гына да түгел, хәтта колхозның алар жигеп йөртә торган атларын да фронтка алдылар. Кәрам кебек 9—10 яшьлек малайлар абыйларын да, атларны да берәм-берәм озатып калганнар иде. Тимеркүк исемле аттан аерылуы бигрәк кыен булды. Кәрам аны, муеныннан кочаклап, яңакларыннан сыйпап бик озак иркәләп торды. Ат караучы Миңниса апа:

— Туйганчы ашап калсын инде, малайлар, житте, барыгыз!— дигәч кенә, абзардан чыкты.

Анда да әле такмаклый-такмаклый саубуллашты:

— Тимеркүк, жиңеп кайт! Абыемны күреп кайт!— диде.

Бу такмакны башка малайлар да кабатлады: «Тимеркүк, жиңеп кайт! Абыйларны алып кайт!».

Моннан кырык өч ел элек әйтелгән такмак яңадан колак төбендә яңгырагандай булды. Кәрам сискәнеп китте. Ул еллар малайларны шактый тиз олыгайтты. Кәрам дус-ишләре белән жыелып, шаярышып-уйнап йөрүләрен башка хәтерләми дә инде. Ул чорның бала-чагасы, карт-корысы авылларның төп терәгенә әйләнгән иде. Эш, эш, эш. Укуны да әллә ни күпкә сузып булмады, жидееллыкны тәмамлаучылар ул елларда өлгереп житкән колхозчы санала иде инде. Кәрам дә яшьтәшләреннән аерылмады. Колхозның иң зур эшләрен тартучылар рәтенә басты...

Гажәп! Күңелләр бердәм талпынган икән — сүз алган Мингалим агай да нәкъ Кәрам уйлап утырган хәлләр турында сөйли:

— Энем Ибраһим, Жәүһәрия килен, сезгә киңәшем шул: сез әтиегез Кәрам белән әниегез Нәфисәнең гомер юлын үзегезгә өлге итеп алсагыз, ялгышмассыз!— ди. Сүзен раслар өчен ул шактый элекке вакыйгаларга кагылып узды.— Кәрам Әхмәтжановның армиядән кайтып төшкән чагын яхшы беләм мин. Ул чакта колхозда председатель идем. Килде Кәрам идарәгә. Авылда калам, эш кирәк, ди. Полевод иттек үзен. Шул чагыннан башлап ул безнең авылдагы эшләрне рәткә салырга тотынды. Басуларның агротехник картасын булдырды. Кырдан вак таш жыйдыру, ужымга ашлама кертү башланды. Уңыш күтәрелде. Председательлекне Кәрамгә тапшырганда, пенсиягә киткәндә, минем жаным тыныч иде. Син, Ибраһим энем, колхоз эшенә институт бетереп, югары белемле агроном булып тотындың. Әтиеңә кыенга килде, ул белемне эшли-эшли алды, башта урта мәктәпне, аннары читтән торып институт тәмамлады. Бары да безнең күз алдында булды. Сез дә шушылай тырышыгыз! Кәрам белән Нәфисәнең эшчәнлеге балаларына гына түгел, бөтен авылга үрнәк!

Кунаклар: «Дөрес! Дөрес!»— диделәр, кул чаптылар. Мәжлес гөр килде.

Йорт хужасы тынычлана төшкән иде инде. Табынга кирәкле нәрсәләрне дә караштыргалады. Тик, бөтен жанны биләп алган кадерле хатирәләр тәэсиреннән тиз генә котылырмын, димә икән. Мингалим агайның сүзләреннән истәлекләрнең икенче дулкыны күтәрелде. Нәфисәгә, колхозга бәйләнеләре.

...Нәфисә белән алар печән өстендә, күмәк эш вакытында дуслаштылар. Аннан соң шактый еллар үтте әле. Кәрам армиягә китте. Дүрт ел хезмәт итеп кайтты. Беренче хисләре чын, нык булган, күрәсең, вакытка да, аерылышуларга да бирешмәде. Алар өйләнештеләр. Ике ул үстерүенә дә, иренең председательлегенә дә аркаланмады Нәфисә. Киресенчә, Кәрамның йөзенә кызыллык китермәс өчен, чөгендерчеләр арасында алдынгылыкка чыгарга тырышып эшләде. Кәрам өлешенә шактый авыр йөк

төшкәнен, колхоз җитәкчесе вазифасының мең төрле мәшәкатен күреп-тоеп яши ләбаса! Беренче тапкыр сайлаганда ук халык Кәрамга кырт кисеп үзенең теләген әчып салды:

— Эш тап! Һәммәбезне әйбәт түләнә торган хезмәт белән тәэмин ит! Җанга ятышлы эш булса, бездән калмас! — диделәр.

Чирмешән районының Бәркәтә кешеләре борын-борыннан тырыш булганнар, тик авылның табигый шартлары гына бөтен көчне бирел эшләрлек түгел: басулары тау-таш арасына кысылган, көтүлекләр юк дәрәҗәсендә, җире уңдырышсыз — таш та балчык. Җитмәсә, авылның культура йорты, мәктәбе дә иске. Кыскасы, яңа председатель кай якка гына кагылса да, муеннан мәшәкатькә чумарлык иде.

Зур-зур шушындый мәшәкатьләрен белеп торса да, Кәрам халык теләгенә каршы килмәде, ризалашты, әмма 1966 елның эш башлап җибәргән көннәре искә төшсә, әле дә тәннәре чымырдап куя. Әгәр шул чакта таянып кешеләр табылмаса, әгәр колхозчылар, вәгъдәләрен бозып, эшкә салкын караган булсалар, бер Кәрам нишләр иде икән?!

Бәхеткә, ике як та сүзләрен үтәделәр: колхоз идарәсе халыкка иң кирәкле мәсьәләләрне алга куеп тотынды, халык исә көчен кызганмады. Кәрам председательлегенең өченче елында ук, дәүләт алдындагы бурычларны арттырып үтәгәне өчен, Шушма колхозына, КПСС ҮКның, СССР Министрлар Советының, ВЦСПСның һәм ВЛКСМ ҮКның Күчмә Кызыл байрагы, акчалата беренче премия бирделәр. Авылга бәйрәм килде. Соңра мондый тантаналар ел саен диярлек кабатлана барды.

Кәрам Әхмәтҗанов, кирәксә, колхозы ирешкән уңышларның әзлекле үсеш баскычын сызып та күрсәтә алыр иде кебек. Нидән башланды бу күтәрелү? Өзеп кенә әйтсәң, идарә белән колхозчылар омтылышының бердәмлеге нәтиҗәсе бу.

Кешеләр беренче җыелышта ук даими эш табуны үтенделәр. Бу — кыен мәсьәлә иде. Әмма, кеше теләгән үзәккә алып уйлаганда, хәл итү юллары да табылды. Мелиораторлар ярдәмендә ташландык җирләрне, тау битләрен эшкәртә-эшкәртә, колхозның чәчү мәйданын тагын 500 гектарга арттырдылар. Ир-егетләргә төзелеш мәшәкатьләре йөкләтелде. Төзелешкә кирәкле төп материалны үз авылларына терәлеп торучы таулардан чыгара башладылар, ташны хәтта башка хуҗалыкларга да саттылар. Өйләргә су үткәрелде, телефон челтәре булдырылды. Техниканы дөрес тоту һәм файдалы итү өчен җитмешләп кешегә механизаторлык һөнәре өйрәтелде, авылда күршедәге училищеның филиалы булдырылды. Төзүчеләргә дә уку мөмкинлеге тудырылды. Белемле төзүчеләрнең хезмәт төсе булып авылның әр-яңа күренеше барлыкка килде: ике катлы мәктәп, идарәнең яңа бинасы, балалар бакчасы, кунакханә, ашханә, тегермән, гаражлар, берсеннән-берсе күркәм йортлар.

1980 елны халык Шушма колхозы председателе Кәрам Әхмәтҗановны РСФСР Верховный Советына депутат итеп сайлады.

Хуҗалыкның һәм аның җитәкчесенең күтәрелүе әнә шул юлдан бара...

Туйга җыелган кунаклар Кәрамның күрше колхозда агроном булып эшләүче улы Ибраһимга да әнә шушындый ук тормыш юлыннан барырга кирәклеген белдерделәр. Ата кеше өрлектәй баласына карап торды: «Мин аңа кулымнан килгәнне бирдем, күрсәттем, өйрәттем инде,— дип уйлый иде ул.— Мәстәкыйль юлда сыгылып төшә күрмәсә генә ярар иде! Бу юл җиңелләрдән түгел, үр менү, югарыга күтәрелү гомер-гомергә иң авыр юллардан саналган»...

Баласының киләчәге өчен борчылса да, күңел түрендә шик-шөбһәләрне басарлык ышаныч бар иде — аның балалары, үзе кебек ук, кечкенәдән җиргә турылыклы булдылар. Ата белә: Җир мондыйларны кимсетми, түбәнсетми, киресенчә, алар куйган көчне бише белән кайтара Җир. Шуңа күрә Ибраһимның киләчәге дә, мөгаен, матур булыр. Авылның алдагы көннәре кебек...

Председатель үзалдына елмая иде. Бәркәтәнең киләчәккә корган планнары шулай елмайталар аны: авыл даими газ белән тәэмин ителсә, елга аша нык күпер салынса, юллар асфальтланса... Һай, күп әле, күп башкарасы эшләр. Ибраһимның улына да җитәрлек, артып та калырлык!

Атаның шатлыклы фикерләренә көч-куәт биргәндәй дәртле музыка яңгырады. Кунаклар җыр башладылар.

Зиннур Мансуров

# ХАЛЫККА БӨЕК ЭШЛӘРЕНДӘ БУЛЫШУЧЫ...

## ПОЭЗИЯДӘ ПРОБЛЕМАЛЫЛЫК ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Без чәчәклрдән сүзләр, ә сүзләрдән чәчәкләр ясыйбыз.

Сез бәлки моңа гаҗәпләнә торгансыз, гаҗәпләнерсез дә шул, чөнки шагыйрьләрнең эшләре гаҗәбрәк.

Без гади җөмләләрне бер-беренә кушабыз, тоташтырабыз да, алардан чылбыр, бизәкле чәчәкләр чылбыры ясыйбыз. Ул чылбырлар белән сизгер йөрәкләрне үзебезгә тартабыз, бәйлибез...

«Шагыйрьләрнең эшләре»н үзенчә аңлаткан Ф. Әсгать белән, бер караганда, бәхәсләшеп тә булмыйдыр шикелле: әлеге парчаның фикер-мәгънәсе инде үзенә күрә хакыйкатькә әверелгән. Шагыйрьләр дә, әйе, «матурлык законнары буенча» эш итәләр, һәм, гомумән, матурлык — поэзиянең чишмә-чыганагы. Гүзәллек, димәк, шигърияттелек; шигъриятлелек, димәк, гүзәллек. Кушма сүзләр, игезәк төшенчәләр. Монысы — бәхәссез.

Шулай да матурлыкның хакыйкатьтән аерылгысыз булуын онытмыйк, һәм аны шулай ук дөньяны танып-белү һәм практик үзгәртеп кору максатын аңлатучы идея төшенчәсеннән аермыйк. Әдәбият белемендә идея үзе проблемага «тугандаш» санала, тема төшенчәсе дә, икенче төрле аңлатканда тормышчан нигездә яктыртылган философик, социаль, этик һ. б. идеологик п р о б л е м а л а р  рәвешендә кузаллана. Кулларына каләм алучыларга да иң элек шундый кисәтү яңгырый: «Кешелекнең зур социаль проблемалары борчыса гына, син язарга хаклысың».

Проблемалылык... Матурлыктан шартлы рәвештә шундый төшенчәгә «килеп чыгуыбыз» табигыйдер, чөнки һәрбер әсәрнең эстетик кыйммәте, гадәттә, проблематика җирлегенә таянып билгеләнә. Әйдәгез, «матурлык таҗы»— поэзиягә дә, шартлы рәвештә генә булса да, проблемалылык ягыннан караш ташлыйк.

Әдәбиятта проблема төшенчәсен «өйрәнеләсе һәм чишеләсе мәсьәлә» итеп кенә аңларга ярамый. Һәм проблемалы әсәрне тормышта хәл ителергә тиешле мәсьәләләргә игътибарны юнәлтергә, уйланырга, фикер йөртергә этәрүче әсәр дип кенә күзаллау да бик үк тулы ачыклык бирмидер. Һәрхәлдә, поэзиядәге проблемалылык төшенчәсенә тирәнрәк һәм киңрәк мәгънә салынган. Шушы мәгънәнең бер төсмере— поэзиянең ф а й д а л ы л ы г ы н а игътибарны юнәлтик.

Поэзияне өйрәнүдә дә зур көч куйган, кайбер мәсьәләләргә карата полемистларча караш белдергән Г. Ибраһимов «Пролетариат әдәбияты турында» исемле хезмәтендә (1924) А. Пушкинның «Шагыйрь һәм гавам» (1828) шигыреннән, фикри тәрҗемә итеп, бер өзек китерә: «Без, шагыйрьләр, көрәш өчен, гади файдага хезмәт

өчен, тормыш дулкыннары өчен түгел, бәлки илһам өчен, дога-гыйбадәт өчен, күңелле авазлар өчен туган кешеләр...»[1]

Ачыклык кертү максатыннан шуны әйтик: әлеге юллар шагыйрьнең каләмен поэтик идеаллардан ерак торучы практик максатлар һәм мәнфәгатьләргә хезмәт иттерергә тырышучылардан, аны «сарай шагыйре» итәргә теләүчеләрдән котылу өчен җавап рәвешендә язылган. һәм Г. Ибраһимов бу өзекне поэзиянең җәмгыятьтәге вазифасын аңлатуда бик урынлы файдалана һәм шуны ассызыклап белдерә: «...Шигырь... күктә йолдыз булып янмый, җирдә, халык эчендә җәмгыятьнең кирәгенә хезмәтче ролен үти». Аннары кемнеңдер сүзләрен дә әйтеп куя: «...Сәнгать тә коры бер кызык өчен, рәхәтлек бирер өчен түгел, тормышта кирәк булган бер файдалы эшкә хезмәт кыйлсын».

Җәмгыятьнең кирәгенә хезмәт итү, димәк, халык алдында торган проблемаларны хәл итүгә өлеш кертү. Менә ни өчен поэзиягә проблемалылык кирәк, менә ни өчен поэзия файдалы хакыйкать булырга тиеш.

Кайвакыт поэзиянең нәкъ менә шушы реаль ягын игътибардан читтәрәк калдырабыз. «Шагыйрьләрнең эшләре»н «ритмлы һәм рифмалы сүз сөйләү», «матур сүз уйнату», буриме уены итеп кенә күз алдына китерүчеләр дә байтак. (Ярый ла уйнатa торган сүз канатлы булса — «Кирәк түгел мәгънәсе юк келке, уен»). Тагын да аянычрагы, эчтәлексез матурлыкка авышу шагыйрьләрнең үзләрендә дә очраштыргалый. Берьяклы матурлык башлангычына табыну исә, Марксча әйткәндә, «хисләр белән кыланчыкланып уйнау, бизәкләр чуарлыгы, гадәттән тыш образлылык, ясалмалылык, купшылык»ка китерә. Тыштан ялтырый, ә эчтән... («Ялтыравык» ясаучыны элек пиит дип атаганнар). һәм мондый «эстетлар», гадәттә, үз күңелләрендә күбрәк казыналар. (Күңел «файдалы казылма»дан гына тормый). Менә шул рәвешле реальлектән күпмедер читләшә баралар. Аларның язганнары үтә лирик импрессионизмны хәтерләтә; анда социаль императивны таба алмыйсың.

Дөнья әдәбияты тарихы буколик поэзиянең, әйтик, пастораль, идиллия, эклога кебек төрләрен хәтерли. Әмма алар яшәүчәнлеккә ирешә алмаган. Ни өчен? Җиңел һәм күңелле, мәшәкатьсез һәм борчусыз тормыш кичерү турында язуны, димәк, поэзия үз максатына ярашлы итеп санамаган. Ни өчен имажинизм, импрессионизм кебек агымнар иҗтимагый тормыш дулкыннарына кушылып китә алмаганнар? Сәбәбе бер генә: «файдалы эш коэффициенты» булмауда. «Ә безгә сүз, Маяковскича әйткәндә, тормыш өчен кирәк. Без файдасыз сәнгатьне танымыйбыз». һәм аның түбәндәге шигъри юллары да бик табигый яңгырый:

*...Исәпләп чыгарыгыз да*
*шигырьләрнең*
*эшләү көчен,*
*хезмәт хакымны*
*өч йөз елга бүлеп*
*салыгыз...*

Кайчандыр укылган бер истәлек хәтердә яңара. Югары художество остаханәләре тулай торагында яшьләр В. Маяковскийның бер шигыре буенча мондый лозунг язып куялар: «Тимер-бетон тондырабыз без күкләргә»... Әлеге язуга В. И. Ленин да игътибар итә һәм, үзалдына көлә-көлә, аңа үз мөнәсәбәтен белдерә: «Ни өчен күккә атарга? Тимер-бетон безгә җирдә кирәк...»

Билгеле, «Тимер-бетон тондырабыз без күкләргә» һәм «Без файдасыз сәнгатьне танымыйбыз», дигән сүзләр бер авыздан чыксалар да, алар күпмедер вакыт аралыгы — үсеш-күтәрелеш еллары аша әйтелгәннәр. Тагын бер мәртәбә кабатлыйк: поэзиянең максаты — файдалы хакыйкать. Канатлы ат рәвешендә күзалласак та, поэзия безгә җирдә кирәк, «халыкка бөек эшләрендә булышучы» (С. Хәким) буларак кирәк.

---

[1] Не для житейского волненья,
Не для корысти, не для битв,
Мы рождены для вдохновенья,
Для звуков сладких и молитв.

*Сезгә хат язарга утыру белән,*
*Кинәт хат язуны*
*Артык зур эш диеп санадым;*
*Сезгә язар өчен зур фикерләр,*
*Проблемалар эзләп карадым...*

Хәтерегездәдер, Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасындагы икенче хат әнә шулай башлана. Һәм әлеге бүлектә мондый сүзләр дә бар: «һәрбер проблеманы үзебезнең файдабызга карата чишәбез». Шушы кечкенә-кечкенә өземтәләр генә дә әсәрнең җәмгыять өчен файдалы эшкә хезмәт итү максатыннан язылуын, кулындагы каләмен «кешелекне үзгәртүнең куәтле коралы» дип санаган шагыйрьнең үз заманы алдында торган иҗтимагый-социаль проблемалар белән янып яшәвен раслый. Хәер, бу хакта ул үзе дә алдан ук ачыктан-ачык әйтеп куя: «Мин һәрбер хатны аерым проблемага багышларга уйлыйм». Гомумән, ул поэзиягә аяк басканда ук: «Мине ...бөек проблемалар кызыксындыра», дип белдергән. Шулай ук аның поэзиядәге эшлексезлеккә каршы көрәшүе дә үз каләменең куәтенә тирәнтен ышануын күрсәтә. «Бездә кайбер иптәшләр бар,— дип яза ул,— аларның шигырьләренең исемнәре дә «кызыл» була, шигырьләренең эчләрендә дә бик күп ясалма пафослы сүзләр була. Ләкин ул «пафослы» сүзләр билгеле бер фикерне, идеяне җанландыруга хезмәт итмәүләре сәбәпле, буш, җансыз, нәфрәтләндерерлек дәрәҗәдә эшсез-«безработный» (ассызык безнеке.— З. М.) сүзләр генә булып калалар».

Галимнәребез өйрәткәнчә, иҗат методы төшенчәсендә идеялелек белән сәнгатьлелек бербөтен итеп карала. Ә идея үзе — проблемалылыкны да үз эченә алган идея әсәрнең барлык эчтәлек һәм форма компонентлары берлеге буларак күз алдына китерелә. Әмма шушы берлек, идеялелек белән сәнгатьлелек төрле иҗатта төрлечә кристаллаша. Берәүләрдә идеялелек көчлерәк, икенчеләрдә сәнгатьлелек баса төшә. Баксаң, менә шундый «тирбәлеш» поэзиянең аерым-аерым этапларында да күзәтелә икән. Әйтик, рус әдәбияты белгечләре билгеләп үтүенчә, XX гасыр башы шагыйрьләренең шактые поэзияне «осталык», «сүз уйната белү» итеп кенә аңлаганнар, ягъни сәнгатьлелек ягына авыша төшкәннәр. Ә шушы чор татар поэзиясендә, «ашны — ташка, канны — җанга оештыра белгән һәркем»нең шагыйрьлек таҗы киярга омтылуы күзәтелсә дә, мондый күренеш профессиональ әдәбиятта тенденция буларак алай ук күзгә ташланмый. Сүзебез һавада асылынып калмасын өчен, Тукай, Гафури, Дәрдмәнд, Рәмиев, Бабич исемнәрен генә санап үтү дә җитәдер. Алар иҗатында идеялелек белән сәнгатьлелекнең тупас диспропорциясе сизеләме? (Дөрес, Дәрмәнд шигырьләренең сәнгатьлелек ягы бераз калкыбрак тора шикелле. Шуңа күрә дә без аның иҗатын «осталык мәктәбе» дип атыйбыз. Әмма аларда сәнгатьлелек эчтәлек компонентларын басып китми). Кечкенә генә әсәрләрдә дә замана проблемалары аермачык булып күренә. Гомумән, бу чор поэзиясендә идеялелекне сәнгатьчә гәүдәләндерүнең матур үрнәге төсмерләнә.

Ә менә утызынчы еллар татар поэзиясендә сәнгатьлелек башлангычына игътибар ничектер киметелде. «Ник без мастерлыкка ярлы, ә бай елтыр сүзгә, төче үгеткә?!»— дип борчылган Ә. Фәйзи дә.— «...Әйдә, һәр җыр кирпеч булып ятсын «нигез»гә». Үлчәүнең бер ягы аскарак төшсә, гадәттә, икенче ягы өскәрәк күтәрелә. Утызынчы еллар башында исә проблемалылыкның берьяклы, ягъни сәнгатьлелекне бераз югалта төшү бәрабәренә үсүе күзәтелә. Социалистик җәмгыять төзелеше яңадан-яңа иҗтимагый-социаль проблемалар тудырды. Заманның идея-эстетик концепциясе белән коралланган поэзия, халык тормышына тагын да якынаеп, үзенең «хезмәт житештерүчәнлеген» арттырырга омтылды. Әлеге чорда проблемалылыкның арта төшүен публицистик-агитацион поэзиянең көчәюе белән дә аңлатырга буладыр. «Канатлы ат» заман арбасына мичәүгә җигелде. Әмма бер якка ташлану сиздертте: «поэзиядән поэзия китте», дип көенүләр ишетелгәли башлады. (Шундый ук күренеш рус поэзиясендә дә күзәтелде). Бу очракта мисаллар китереп торуның да кирәге юктыр. Шулай да М. Крыймовка гына тукталып үтик, чөнки аның иҗатында проблематиканың сәнгатьчә гәүдәләнеш табып җиткермәве бигрәк тә ачык күренә. Әйтик, «Чүкеч җырлары» җыентыгында (1925) автор нинди генә мәсьәләләргә кагылып үтмәгән?! Ә менә аларның сәнгатьчә бирелеше...

Утызынчы еллар башы татар поэзиясенең төп җитешсезлеген Т. Галиуллин бик

дөрес билгеләде: «Лирик шигырьдә шәхеснең йөрәк серләре, аның олы дөнья, иҗтимагый проблемалар белән катлаулы мөнәсәбәте, иҗат процессы аша үтеп, сүз, образ ярдәмендә шигъри калыпка кереп, гомумирәк форма алгач та, үзәк идея, мотив үзенең сафлыгын, садәлеген, беренчел яңачалыгын сакларга тиеш. Блок бу моментны «беренче сафлык кыйммәте» дип атаган. Менә шунда эффектлы, нәфис формалы, әмма чор проблемаларын читләтеп үткән салкын, битараф шигырь янсә тормыш күренешенең, хисенең бер халәтен натурадан күчереп, рәсемгә төшереп алган лирика белән чор хакыйкатен, кешенең шатлыгын-кайгысын, сөенечен-көенечен, киеренке эзләнүләрен үзәккә алган чын сәнгать әсәре арасындагы чикне билгеләве, кыскасы, яхшыны яманнан, матурны ялтыравыктан аерып алуы читенләшә».

Тәнкыйтьче әлеге сүзләрне, искәрткәнебезчә, утызынчы еллар поэзиясе җирлегенә таянып белдергән. Уйлап карасак, аларны бүгенге һәм, гомумән, теләсә кайсы чор поэзиясенә карата да әйтергә мөмкиндер. Укучыга «ялтыравык» (матур белән бергә) теләсә кайсы заманда тәкъдим ителә. Үтемле товарга кеше алмый торганын өстәп биргәндәй. Ни хәл итмәк кирәк: сүз кибәксез булмас. Барысы да «поставщик»ларга бәйле. Кем нинди җан азыгы бирә. Шул ук проблемалылык белән сәнгатьлелекне дә, әйткәнебезчә, һәркем үзенчә синтезлаштыра. (Кайда да индивидуальлек!) Атом реакторы тезгенгә бирелсә дә, «канатлы ат» тулысынча буйсынырга теләми. Шулай да без матур белән ялтыравык арасындагы чикне бетерергә, гомумән алганда, иҗатның эчке агышы белән күпмедер дәрәҗәдә җитәкчелек итәргә омтылабыз. Утызынчы еллар уртасында да бит «поэзиянең поэзиялелеге» акрынлап ярларына кайта башлады. Шундый уйлар да килә: поэзиядә яңадан-яңа проблемалар туганда, сәнгатьлелекнең беркадәр югалып торуы әллә котылгысызмы?! Бәлки, иң элек яңа проблема «бәреп» керәдер, ә аннары аның эстетик гәүдәләнеше камилләшә... Кешелек тә үз киемен тора-бара камилләштергән. Күнегелмәгән яңа проблемага шундук камил гәүдәләнеш бирүе кыенрактыр. Шулай түгелме? Бу эчтәлек компонентларының беренчел булуыннан килмиме? Һәрхәлдә, монда ниндидер эчке закончалык бар шикелле. Проблемалылык белән сәнгатьлелек берлегенең төрле вакытта төрлечә булуы да әнә шундый уйларга этәрә.

«...Җанга тынгылык бирмәгән катлаулы проблемаларга безнең заман аеруча бай бит». Чыннан да, С. Сөләйманова искәртеп үткәнчә, бүгенге көндә Кеше һәм Дөнья проблемасы тагын да катлауланды. Мәсьәләләр йомгагы зурайды, җеп очларын табу кыенлашты. Болай да учарлы тамырлар яңа тармаклар җибәрде. Фән-техника революциясенең яңа ташкыны үзе генә дә әллә нинди проблемалар китереп чыгарды. Кеше һәм җәмгыять, кеше һәм табигать, вакыт: тарих-заман һ. б. шундый олы төшенчәләрнең яңадан-яңа мәгънәви катламнары ачылды, алар арасындагы бәйләнеш һәм мөнәсәбәтләрнең күпьяклылык асылы тирәнәйде. Әхлак проблемасын гына алыйк. Көн тәртибенә ул яңача күтәрелде, үзәк мәсьәләләрнең берсенә әверелде. Акыл ияләре хаклыдыр: кешелекнең киләчәктәге үсеше техника казанышлары дәрәҗәсенә түгел, ә аның әхлакый җирлегенә бәйләнгән....

Проблемалар артында проблемалар. Ә шагыйрь, Белинскийча әйткәндә, замана чынбарлыгы мәсьәләләре белән борчылып-янып яшәргә бурычлы. Бу яктан карaганда, югарыда санап үтелгән проблемаларның барысы да поэзиябезнең иҗат орбитасына алынган. Хәзер шагыйрьләрне җирдәге мәшәкатьләр генә түгел, һәм, аерым алганда, биосфера мәсьәләләре дә кызыксындыра. Шулай да җирдәгеләре күбрәк борчыйдыр.

Исебезгә төшерик, Р. Рождественскийның «Ике йөз ун адым» исемле поэмасындагы бер бүлек... юл төзелеше мәсьәләләренә багышланган. Гаҗәпләнмәгез. Шагыйрь «газетчы» өлешенә алай ук артык кермәгән. Мәсьәлә идея-эстетик планда күтәрелә. Туры мәгънәдә генә аңламыйк: юл сүзенә йөз төрле эчтәлек салынган. Йөрәкләрне йөрәкләр белән тоташтыручы юлны гына алыгыз. Шушы юлны кыскарту һәм чәчәкле иттерү өчен бездән күпме көч сорала! Туры мәгънәсендәге юл мәсьәләләре дә шактый. Поэма авторы «юл төзелеше проблемасы»н менә нинди ясcылыкларда чишәргә омтыла. Шушы урында К. Симонов сүзләрен китерү урынлы булыр: «Мин Роберт Рождественскийда авыр мәсьәләләрне күтәрү һәм китап укучылар күзе алдында уйлану кебек көнләштергеч сәләтне аеруча бәһалим... Әлбәттә, поэзия бердәнбер проб-

лемалылык белән генә яшәми, мин моны яхшы аңлыйм, әмма поэзия дә проблемаларсыз — үле, моңа шулай үк иманым камил».

Поэзиянең «күтәрү көче» уңаеннан Р. Фәйзуллин да үз фикере белән уртаклаша: «Канатлы сүзнең, җырның (шигырьнең) халык язмышындагы хәлиткеч вакыйгаларда үткен һәм дәһшәтле корал була алганын истә тоткан хәлдә, көндәлек тормышта без еш кына поэзия атлы затлы жанрның нәфис иңнәренә күтәрә алмаслык йөкләр өймибезме икән, дөресрәге, өяргә тырышмыйбызмы икән? Шигъриятнең символы да гыйбрәтле: борынгы мифлар буенча Пегас-Тулпар ат (димәк, көчле дә булырга тиеш ул, күпмедер йөк тә тарта алырга тиеш), ләкин канатлы ат шул ул! Канат янына тәртә куеп булмый».

Шагыйрь, әлбәттә, хаклы. Шулай да поэзиянең җегәре «ат көче» белән генә үлчәнми. Аксакалларыбызның берсе үз шигырен болай төгәлләгән: «Революция ясап буламы шигырь белән?» Сорауга җавап бирелмәүдә тирән мәгънә ятадыр. Хыялыйларның башларын кисмиләр, ә үз өсләренә бик күпне алган шагыйрьләрнекен... «Язучысыз языладымы бу Коръән?» дип, Тукай да тикмәгә генә әйтмәгәндер. «Күпмедер йөк тә тарта алырга тиеш», дигән сүзләр, һәрхәлдә, поэзиянең мөмкинлекләрен бераз чикли шикелле. «Кабуснама»дә әйтелгәнчә, шигырь — әдәбиятның патшасы. Әмма авыр күтәреп эшли торган патша!

Соңгы еллар поэзиясендәге проблемалылык мәсьәләләре турында сөйләшкәндә, С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы» исемле поэмасын читләтеп узу гөнаһ булыр сыман. «Халыкка бөек эшләрендә булышучы» шагыйрьнең әлеге әсәрендә без проблематизм поэтикасының үрнәк булып торырлык камил гәүдәләнешен күрәбез.

*Июнь ае, июнь ахырлары,*
*Һич колачлый алмый акыл әле,*
*Хисләремнең ашыкканын беләм,*
*КамАЗ үзенең масштабы белән*
*Басты үйны, ник, дим бөек КамАЗ?*
*Килә җавап үйны җыеп алгач:*
*«Кама монда, тарих үзе монда,*
*Утырды ул кереп шушы фонга...»*

Фән-техника революциясе төзелеш мәйданнарында да, экскаватор чүмечедәй, йөз төрле проблемалар актарып чыгарды. «Төзелеш мәйданнары, яңа буын кешеләре, туган илнең табигате, бәхәсләр, шатлык һәм әрнүләр...» Тормыш метаморфозалар кичерә. Үзара бәйләнгән мәсьәләләр үзләре үк әллә нинди көтелмәгән мәсьәләләр китереп чыгаралар. Чылбырлы реакция барамыни. «Атып читкә бөтен чүп-чарын, аерып КамАЗ Болгар туфрагын, бодай үскән кара туфрагын, кара туфрак — дала туфрагын өйдә бергә...» Нигезләр актарыла. Иске белән яңа үзара каршылыкка керә. «Югалды дип юкка уынма, ул туфракны шул ук урынга сипте КамАЗ, шул ук урынга — киләчәккә, яңа буынга...» «Дәверләр капкасы» әсәрендә менә шундый социаль янгырашлы проблемалар күтәрелә, алар кешеләр аңындагы каршылыклар гаммасында киң гомумиләштерүләр белән ачып бирелә. Поэманы укып чыкканнан соң Е. Евтушенконың «Братск ГЭС»ын хәтерләп куясың. Үзләренең проблематикалары ягыннан алар бер-берсенә аваздаш шикелле. Шундый ук мәсьәләләр уртаклыгы Р. Мингалимнең «Күз карасы» әсәрендә — КамАЗ турындагы беренче поэмада, Р. Харисның «Кеше һәм машина» оратория либреттосында, «Яр-Чаллыда яңару» циклында да сизелә.

Бүгенге поэзиядәге проблемаларның тулы комплексын ачып бирергә дәгъва итмәстән, тагын кайбер күзәтүләр белән уртаклашып үтик. Иң элек әхлак турында. Югарыда искәртеп үтелгәнчә, кешенең җәмгыятьтә үз-үзен тотышын билгеләүче нормалар игътибарны торган саен күбрәк тарта башлады. «Әдәбият» сүзенең ясалышы «әдәп»тән башлана, димәк, сүз сәнгате әхлак проблемаларыннан читтә яши алмый. «Минем гражданлык намусым кулдан килгәнчә, семья, мәхәббәт, мораль мәсьәләләренә кагылган уйларымны шигырьгә салып әйтергә чакырды,— дип яза С. Хәким «Суд залыннан» циклы турында.— «Дулкынланулар һәм борчылулар» исемле китабымдагы күп кенә әсәрләр шул хакта сөйли».

Әхлаксыз әсәрләр булмый! Турыдан-туры әхлак проблемасына багышланмаган юлларда да «шагыйранә мораль кодекс» чагыла. Витаминга дару кушылгандай, шигырьгә дә әхлак салына. Шулай булырга тиеш! Әдәбият яшәү сәнгатенә өйрәтергә, замана рухын сафландырырга бурычлы.

Шулай да әхлак проблемаларын юл уңаеннан гына хәл итәргә мөмкин түгелдер. Бездән сиксәненче еллар кешесенең эч йөзендәге үзгәрешләрне махсус рәвештә өйрәнү таләп ителә. «Әхлак 'соусы» салынган әсәрләр шактый, ә менә мәсьәләгә махсус багышланганнары күпме? Андыйлары соңгы вакытта сирәгрәк күренә. «Суд залыннан» циклына тиңләшерлек шигъри бәйләмнәрне хәзер бөтенләй таба алмыйбыз. Поэма осталарын хәзерге гаилә тормышы да кызыксындырмый башлады. «Яратышу кодексы», мәңгелек сөю мәсьәләләрен интимлык кысаларыннан чыгарып, социаль гомумиләштерүләр югарылыгына күтәргән «Мәхәббәт тәүбәсе» (Һ. Такташ), «Дон-Жуанның өйләнүе» (В. Федоров) кебек поэмалар Кеше һәм Дөнья проблемасының «зуррак һәм җитдирәк» мәсьәләләре хакында язылган әсәрләр арасында икенчеләр күмелебрәк калды шикелле. Ярый әле И. Юзеев «Мәхәббәт китабы» язып бирде. Татар поэзиясен баетучы әлеге үзенчәлекле әсәрдә, «Кешелекнең сөю тарихы» җирлегендә, нинди генә әхлак мәсьәләләре күтәрелми! «Мәхәббәт ачкычы» әллә нинди рухи катламнарны ачып күрсәтә, мәхәббәт темасына тугрылыклы булып калучы шагыйрь игътибарны заман әхлагы йөзендәге яңа чалымнарга юнәлтә. Ләйлә һәм Мәҗнүннәрдән үк килә торган «борынгы» мәсьәләләрне ул заман концепциясе яктысында күрсәтергә омтыла. Әсәрнең файдалылыгын нәкъ менә шундый сыйфатлар билгелидер.

Үзебез үк актуаль санаган әхлак проблемасы тагын кемнәрне борчый? Махсус язылган әсәрләр бармы? Турыдан-туры бүгенге гаилә мәсьәләләренә багышланган «Тормыш әлифбасы» поэмасы (Ә. Рәшитов), «Әгъзалар күп ул башта...» циклы (Н. Арсланов), «Мещан» триптихы (Р. Харис)... Тагын? Бармак бөгеп саный китсәң, әллә ни мактанырлык түгел икән.

Суның кадерен чишмә корыгач беләсе дигәндәй, хәзер кешелек табигатькә хуҗаларча, юк, сакчылрак карый башлады. Үзебез табигать балалары булсак та, табигатькә «хуҗа» икәнлегебезне күрсәтергә омтылып карадык. Нәтиҗәдә ике якның да зыян күрүе ачыкланды. Аңладык. Бөтендөнья табигатьне саклау стратегиясе кебек проектлар төзелде. Шулай да Җир-ана әлегәчә рәнҗетелә — «Кызыл китап»ның т у л ы л а н д ы р ы л г а н басмалары чыгарыла. Табигатьне саклау проблемасы үзенең җитдилеген киметми, алай гына да түгел, ул глобаль проблемага әверелде.

Кем әйтмешли, татар шагыйрьләренең туксан тугыз проценты авылда туган. «...Үзем авыл баласы», дип җырлагандагыча. Авыл баласы, димәк, табигать баласы. Табигатьне саклау проблемасы, үзеннән-үзе аңлашылганча, шагыйрьләрне аеруча дулкынландыра. Барыбыз да язабыз. Хозурланып та, борчылып та. Әйтик, Рәшит Әхмәтҗанович, үз-үзебезне гаепләп тә.

*Яндырганнар... Бөдрә таллар*
*Ята җирдә... күлләрдә.*
*Еланнарны качырырлык*
*Агулар бар кемнәрдә?*

Шунысы гыйбрәтле: узган гасырлар поэзиясендә мондый мәсьәлә уңаеннан кеенеп язылган әсәрләрне таба алмассың, ә менә бүгенге шагыйрьләр иҗатында борчулы күңел чаңы торган саен көчлерәк яңгырый. Сәнгатьчә сурәтләү чаралары чыганагы, иң-иң камил матурлык, шулай ук гармония үрнәге булып хезмәт итүче табигать бүген безне хафалы уйларга да сала башлады. «Казан шәһәренең 39 нчы кварталы янындагы сазлыкның төнге бәхилләшүе»... Үзенең бер шигырен Зөлфәт әнә шулай исемләгән. Ара-тирә язылган аерым шигырьләр белән генә канәгатьләнмичә, табигатьне саклау проблемасын бөтен кискенлеге белән күтәргән тулы бер цикллар да иҗат итәбез. Мәсәлән, Н. Дәүлинең «Табигать исеменнән» дигән бәйләме Җир-ананы саклау буенча үзенә күрә бер «шигъри проект» буларак кабул ителә. Шулай да соңгы еллар татар поэзиясендә әлеге проблеманы үзләштерү буенча Марс Шабаев белән Роберт Әхмәтҗанов бөтенебездән дә нәтиҗәлерәк һәм максатчанрак эшлиләр шикелле. Әдәби исәп-хисапларда еш телгә алына торган «Җикән камыш» циклын гына искә төшерик. Өч бәйләмнән торган әлеге тупланма М. Шабаевның шагыйрьлек абруен да күтәреп җибәрде, күпләрнең раславынча, «Җикән камыш»та ул, иҗатчы буларак, тулырак ачылды.

*...Кичер мине, кеше томымын, кичер... соңгы зубр!*
*Экспонат булып калдың бөек корбаннарга...*
*И, бозавың үксеп елый сыман ерак урманнарда!..*

Кем ничек уйлыйдыр, Роберт Әхмәтҗановның «җиде катлы күк»кә — Йолдызстанга үренүенә караганда, аяк астындагы бәбкә үләне язмышы турында кайгыртып язуы күңелгә якынрак кебек тоела. «Табигатькә дүрт җыр», «Иделгә ялвару», «Очрашу»... Әлеге әсәрләрдә кеше табигатьнең аерылгысыз бер күзәнәге итеп күрсәтелә, һәм шагыйрь безне җир ярасын үз тәнебездәге яра итеп тоярга чакыра. Гомумән, югарыда санап үтелгән шигырьләр гаепләү акты булудан битәр, әйтик, тынычлыкны саклау хакына имза җыю кебек, ниндидер файда китерүгә юнәлдерелгән. Һәм әлеге мәсьәләләрнең барысы да Кеше һәм Дөнья проблемасы эчендә карала, шул рәвешчә аларның гаять җитди һәм күпьяклы булулары тулырак ачып бирелә.

Балалар поэзиясеннән проблемалылык эзләргә без нигәдер бөтенләй күнекмәгәнбез. Балачак илен артык дәрәҗәдә идиллик итеп күрергә телибезме? Үзебезнекен искә төшерик. Онытгыкмыни? Сабыйда да гамь була! Дәрестерме-юктырмы, дүрт яшьтәге бала көнгә уртача дүрт йөздән артык сорау бирә икән. Дөньяга балалар күзе белән карау Эйнштейнга нисбәтлек теориясен ачарга булышкан. Үзләрен мәктәптә проблемалы укытабыз, ә поэзиядә... Зарланырга ашыкмыйк. Мондый йөкне балалар поэзиясе дә көченнән килгәнчә күтәрә. Проблемалылык Ш. Галиев иҗатында аеруча ачык күренә. «Тургайлар министрына хат»ны гына укып китегез.

*Абый:*
*Быел бездә тургайлар юк.*
*Мин аларны һаман көтәм.*
*Килмәсләрме инде бүтән?*

*Абый!*
*Вәли әйтә, дару сипкәч*
*Самолеттан, качканнар, ди,*
*Бүтән якка очканнар, ди.*

*Абый!*
*Безнең кырга тургай җибәр,*
*Көн дә чыгып мин көтәрмен,*
*Килгәч тә хәбәр итәрмен.*
*Яме!*

Поэзиянең проблемалылыгы турында сөйләшкәндә, без ни өчендер кечкенә әсәрләрне читләбрәк узабыз. «Микрохирургия операцияләре», әлбәттә, авыррак бирелә. Аннары кыска шигырьдә ниндидер мәсьәлә күтәреп булуына да шикләнебрәк карыйбыз. Теләсә нинди әсәрдән проблема эзләү, дөрес, бик үк урынлы да түгелдер. «Канатлы ат»ны сукага җигеп өзлектерергә ярамый. Шулай да иҗатчының зурлыгын дөнья төзелешенә, иҗтимагый проблемаларга мөнәсәбәте билгели. Әлеге сөйләшүдә дә без поэзиянең «файдалылык» дәрәҗәсен билгеләүче әсәрләргә йөз тотабыз.

Һәрбер кечкенә әсәрдә бәлки мәсьәлә күтәреп булмыйдыр, әмма анда шагыйрьнең дөньяга карашы, дөнья гаме барыбер чагылырга тиеш! Аннары бездән теге яки бу проблеманы чишәр өчен ниндидер адекват теория таләп ителми. Кайчак мәсьәләгә игътибар юнәлтү дә җитә. Шушы урында Р. Фәйзуллинның тәмамланган мөстәкыйль әсәр булу-булмавы, «кирәклеге» һәм «аңлаешлылыгы» ягыннан шактый бәхәсләр уяткан кыска шигырьләреннән «Кызыл китап» исемлесенә тукталып узыйк.

*Яңа бите ачып куелган... Кем чираты?..*

Нибары алты сүздә, күргәнебезчә, җитди мәсьәлә кузгатыла, иң кимендә, җитди мәсьәләгә карата борчылу белдерелә. Бер авыр сүз. Уйландыра. Бездән җавап сорый. Поэзия өстенә төшкән йөкне, бәлки, менә шундый берьюллыклар да күтәрешә аладыр.

Поэзиянең дөнья проблемаларын читләтеп үтә алмавы хакында фикер йөрткәндә, С. Сараиның (1321 еллар — 1396) түбәндәге юлларын искә төшерү урынлы һәм кызыклы булыр шикелле.

*Кыз әйләнде бу батыр — яшь тирәли,*
*Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли...*

Бүгенге көндә үтә гадәти булып тоелган шушы чагыштыру бик күп еллар элек үзенә күрә бер «проблема»ны чагылдырган. Җирнең Кояш тирәли әйләнүе әлеге юлларда Коперник туганчы ук әйтелгән! (Шуңа ышанасы килә). Сүз дә юк, мондый фикер шактый элегрәк, Пифагор, Платон кебек акыл ияләрендә үк туган, әмма җитәрлек нигезләнмәгән фикер булып кала биргән. Шагыйрь менә нинди бөек проблемага кагылып үткән, дөньяны шагыйранә танып-белү омтылышының менә нинди уникаль үрнәген бирүгә ирешкән!

Татар поэзиясе тарихының әлеге кызыклы сәхифәсе чынбарлыкның үзенә иш формасы белән түгел, ә э ч т ә л е г е белән матур булуын тагын бер мәртәбә искәртә, безне үз сәнгатебез белән иҗтимагый файдалы эшкә хезмәт итәргә чакыра.

«Җәмгыятькә файдалы эш»... Әлеге төшенчә бездән һәрвакыт сорау ала, гражданлык җаваплылыгын әледән-әле искә төшерә. Заман маңгайга бәреп сорый; Г. Рәхим сүзләре белән әйткәндә:

*Юк, шигырьдә йокы симертергә*
*Рөхсәт итми безгә бу замана.*

Югарыда сөйләгәннәр буенча гына да икеләнмичә шуны әйтергә мөмкиндер: заман проблемаларын сәнгатьчә чишәргә омтылу юнәлешендә поэзиябез тагын да югарырак баскычка күтәрелде. Бурычларга комплекслы якын килү хәзер поэзиядә дә шактый ук ачык күзәтелә. Поэзия җәмгыятькә файдалы эш башкаруын уңышлы дәвам иттерә. Халыкча әйткәндә, сүз эштән аерылмый. Партиянең иң югары форумында билгеләп үтелгәнчә, соңгы елларда әдәбиятта да Госпланны «тирләтеп чыгарырлык» җитди проблемалар күтәрелде. Шулай да тынычланырга ярамый. Бүгенге поэзия ташкынында, әйтик, эшсез-«безработный» сүзләр юкмыни? Җитәрлек. «Сүз белән колак иркәләргә» омтылучылар, «буш сүз конструкцияләре»н ювелирларча тезә белүчеләр арабызда шактый. Берьяклы «осталык», соңгы исәптә, тел белән һава кыйнауга, борчак атуга кайтып кала, кайвакыт идеясезлеккә дә китерә. Кайберәүләр иҗатындагы мондый күренеш, гомумән алганда, поэзиябез уңышларына күләгә төшерә алмый, шулай да форма компонентларына өстенлек бирү тенденциясенең чагылгалап китүен яшермәскә кирәктер. Шундый берьяклылык бигрәк тә яшьләрдә күзәтелә. Араларында шигырьне шулкадәр матур итеп үрүче «вундеркинд»лар бар ки, акрын гына койләп барган борынгы аучылар шикелле, хәтта филне дә адаштырып калдыра алалар. Метафоралар белән генә сиптерәләр. Ф. Хөсни әйтмешли, бик «мудрый» шигырьләр. Матурны ялтыразыктан аерып алуы читенләшә. Матурлык, гадәттә, алдаучан. Тасмателлелек ышандырмый. (Шигырьне «ат уйнаткан кебек» уйната белүче А. Вознесенскийның да иҗат йөзен виртуозларча нәфис итеп эшләнгән изопллары түгел, ә дөнья гамен сеңдергән реаль җирлектәге җитди әсәрләре билгели.) Гәрәбәдәй чикләвекләрнең бушлары да очраштыра. Шигырь язарга «борча дагалау» осталыгы гына җитми. Ялтыр әсәрләрдән берни дә тотып ала алмагач, яхшы әсәрләрне саплы калачка охшатып куясың. Җирлеге булмаган образ, халыкча әйткәндә, матурлык өчен генә ярый. Элегрәк авылдагы кайбер кешеләр яңа-матур киемне да аяк астына салып тапташтырганнан соң гына кигәннәр.

Әюб бине Гасан әйтте: «Минем каршымда шул күлмәктән вә шул киемнән күркәм вә гүзәл нәрсә юктыр ки, әтрафына кара тамган әсәре булса. Вә шул бармак ни гүзәл бармактыр ки, каләмнән йоккан карасы булса...»

Яшьләр иҗаты турындагы бер мәкаләсендә Р. Мостафин шундый күзәтү белән уртаклаша: «... поэтик күге ар ык дәрәҗәдә аяз, болытсыз». Мондый «идиллизм» иҗтимагый тормыш мәсьәләләреннән читтә торудан, поэзияне җиңел жанр, ягъни җитди мәсьәләләр күтәрмәүче жанр итеп аңлаудан килмиме? Шигырьдә, бройлердай, симермибезме? Дөньядан аерылган сарай шагыйрьләре түгел лә без, ә «халыкка бөек эшләрендә булышучы» шагыйрьләр!

«...Шигырь — күңел чәчәге...» Поэзиянең асылын аңлатуда матурлык башлангычын ничектер калкытыбрак күрсәтү шигъри бәхәсләр дә китереп чыгаргалый. Мәсәлән, «Шигырь турында шигырь»дә (Р. Харис) шундый полемика чагыла.

*...Шигырь — күңел чәчәге генә булса,*
*Рудакиның якты күзләрен*
*Караңгылык чокып атмас иде;*

*Пушкинны*
*Алтын бөркетле гайбәт*
*Дуэльгә тартмас иде;*

*Тука[illegible] ишеген, Газраилдан узып,*
*Жандармнар какмас иде...*

*Чәчәк өчен Жирдә беркемне дә*
*Беркайчан да үтергәнне тарих белми...* [1]

Мондый бәхәснең тууы бик табигый, чөнки шигырьне төрлечә аңлау һәм аңлату (ничек кенә сәер яңгырамасын) әлегәчә яши. Эчтәлек һәм форма компонентларын, кат-кат әйткәнебезчә, һәркем үзенчә синтезлаштыра: берәүләрдә дөнья гаменең барлыгы сизелми (тегермән ташы, гүя, бушка әйләнә), берәүләрдә формаль осталыкның өстенлек алуы күренә, берәүләрдә тегесе дә җитәрлек булмый, монысы да... Гармоник бөтенлеккә ирешү теләсә кемгә бирелми. Матур да булсын шигырь, батыр да. Эчтәлексез матурлык табигатьтә дә очрамый. Шигырьне чәчәккә тиңлибез. Үзара көрәшүче чәчәкләр дә булгалый. Ә көрәшнең үз сәнгате бар. Шагыйрьләрнең көрәшче булырга тиешлеген онытмыйк.

Дөньяны эстетик танып-белү, марксизм-ленинизм өйрәткәнчә, билгеле бер проблематиканы сайлап алуга китерә. Проблематика — сәнгатьчә гәүдәләнеш... Әдәби әсәрләрнең идея-эстетик кыйммәтен ачу, Кеше һәм Дөнья проблемасын чишүгә керткән өлешен билгеләү әнә шундый ачкыч ярдәмендә башкарыла. Кулына каләм алган иҗатчы, бәлки, мондый «сүтеп карау»ларны күз алдында да тотмыйдыр. Шулай да бу хакта уйлану зыян итмәс. Уйланыйк.

...Шигырь — күңел чәчәге генә булса...

---

[1] Шигырь кыскартып алынды. З. М.

библиография

# КИТАП ТУРЫНДА КИТАП

Кешелек культурасын үстерүдә китапның роле бәхәссез. Татар халкының рухи үсеше дә татар милли китабы таралуга бәйле. Күп гасырлар дәвамында ул кульъязма китап булды, чагыштырмача аз санлы бу кульъязмалар кулдан кулга, буыннан буынга күчеп, дистәләрчә еллар буена кешеләргә хезмәт итеп килде, белем бирде, борынгы заманнарда ук булган вакыйгалар өчен янып-көяргә, тормышны алга җибәрүнең яңа юлларын эзләргә мәҗбүр итте, матур киләчәк өчен көрәшкә чакырды.

Татар милли культурасының үсеш тарихын китап басу эше мисалында өйрәнү кешене кеше эксплуатацияләүне генә түгел, бәлки милли изүне дә бетергән, элек изелгән халыкларның культурасын, әдәбиятын, сәнгатен чәчәк аттыру өчен бөтен шартларны тудырган Бөек Октябрь социалистик революциясенең әһәмиятен тирәнтен аңларга ярдәм итә.

Хәреф җыеп китап басу эшә барлыкка килү белән китап киң массаларга тагын да якынайды, аларга аң-белем китерде, хезмәт ияләрен һәр төрле эксплуататорларга каршы үз хокукларын яклап көрәшкә тартты.

Басма китап тарихын өйрәнү идея көрәшендәге яңа фактларны ача, татар җәмгыятендәге капма-каршы көчләрнең урнашу тәртибен, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең, демократик фикернең үсешен тәгәлрәк күзалларга ярдәм итә.

Һәр тарихта милли китапның үз тарихы, ягъни барлыкка килү, таралу, үсеш тарихы бар. Ул һәрвакыт халык тарихы, аның рухи һәм политик үсеше, милли үзенчәлеген саклау өчен көрәше белән тыгыз бәйле була.

Татар китабының тарихы нинди соң? Аның үзенчәлекләре нәрсәдә? Бу һәм шуның кебек башка күп сорауларга иң күләмендә танылган китап белгече, филология фәннәре докторы Әбрар Гыйбадуллович Кәримуллин менә инде 30 ел җавап эзли. Аның «Татар китабы...» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1971), «XX йөз башы татар китабы» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1974) дигән хезмәтләре китап сөючеләргә яхшы таныш. Аларның беренчесендә барлыкка килгәннән алып XIX гасыр урталарына кадәр басма китап тарихы күздән кичерелә, икенчесенең эчтәлеге 1901—1917 елларны колачлый. Ниһаять, Әбрар Кәримуллинның өченче китабы пәйда булды. Ул «Реформадан соңгы Россиядә татар китабы» (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1983) дип атала, анда XIX гасырның икенче яртысы тарихы сурәтләнә.

Ә. Кәримуллинның бу китабы биш бүлектән тора: 1) Казанда һәм аннан читтә татарча китап басу эше; 2) Татар китабына цензура; 3) Басмалар саны һәм аларның тиражы, китап басучы кадрлар, китап сәүдәсе; 4) Татар вакытлы матбугатын булдыру өчен көрәш; 5) Казанда Көнчыгыш халыклары телләрендә миссионерлык максатында һәм рәсми китаплар басу. Китап бөтенләе белән беренчел архив чыганакларына, күләме ягыннан алганда да бик зур фактик материалга таянып язылган. Шушы гаять зур чорны, иксез-чиксез чыганакларны өйрәнү, аңлау-төшенү өчен автордан 20 ел буена баш күтәрми эшләү, бай эрудиция, байтак көнчыгыш телләрен һәм төрле әлифбаларны белү таләп ителгән.

Автор татар китабы тарихын түбәндәге юллар белән тикшерә.

— Бөтен Россия масштабында татар китапларын басу белән шөгыльләнүче типографияләр тарихын өйрәнә;

— китап продукциясенең басмалар санын, тиражын, күләмен ачыклый;

— китап продукциясен эчтәлеге һәм кемнәр өчен чыгарылуы ягын анализлый, китап сәүдәсе челтәрен һәм китапларның кай төбәкләрдә таралуын билгели;

— бөтен Россиядәге китап басу тарихын өйрәнә, рус һәм татар типографияләренең күмәк эшчәнлеге нәтиҗәләрен ачыклый.

Һич шөбһәсез, автор милли китап теориясен иҗат итте, һәм бу теорияне хәзер китап тарихын өйрәнүчеләр, совет китап белеме үзенә кулланма итеп алды. Аның фән буларак китап белеменең төшенчәләр системасының төп элементларын җитәрлек дәрәҗәдә тирән анализлавы, «милли китап» төшенчәсенә үз билгеләмәсен бирүе игътибарга лаек.

Ә. Кәримуллин татар китабы тарихына караган кызыклы мәгълүматлар тапты. Революциягә кадәрге татар китабы, дип яза автор, басмалар саны һәм тиражы ягыннан, я литва, я әрмән китабын кайчак узып, кайчак аларның берәрсеннән артта калып, СССРдагы рус булмаган халыклар арасында икенче-өченче урында тора. Төрки халыклар арасында татарларның беренче булып хәреф җыеп китап басуга күчүләре мәгълүм булды. Ә. Кәримуллин ачыклавынча революциягә кадәр татар нәширләре 70 миллион данә гомуми тираж белән 10 мең исемдә китап басып тараткannар.

Ә. Кәримуллинның рецензияләнә торган китабы татар китабының Октябрь революциясенә кадәрге тарихын тугәрәкли. Бу шул мәгънәдә әйтелде: автор татар басма китабының барлыкка килүеннән, ягъни 1722 елдан алып 1917 елга кадәрге өч томлык тарихын язды. Авторның китап белеме фәнендәге роле, татар милли культурасын үстерүгә керткән шәхси өлеше шушы факттан ук күренеп тора.

Әлеге китап, татар китабы тарихы яктылыгында алып караганда гына түгел, татар мәгърифәтчелек фикере, татар әдәбияты һәм мәктәбе үсеше ягыннан килеп караганда да, саллы фәнни сүз булып тора. Китап турындагы китапны болай гына сөйләп чыгу җиңел түгел. Бу — фәнни марксистик-ленинчыл эзләнү методологиясенә, тарихи күренешләрне анализлауга тарихилык һәм сыйнфый якын килү принцибына нигезләнгән тирән фәнни тикшеренү.

Патша Россиясендә барлык изелгән халыкларны алдынгы рус культурасына якынайту милли, культура изүенең фаҗигале фонында, иҗтимагый, рухи фикернең табигый үсешен тоткарлаучы газап һәм мәхрүмлекләр дәрьясы аша барды. Татар китабын үстерүгә аның «инородец» китабы гына түгел, бәлки әле «татар», «басурман» китабы булуы да үтә тискәре йогынты ясады. «Татарлар» дигән этнонимны шушы төбәктә элгәре заманнардан ук яшәп килгән Идел буе болгарларына самодержавиенең милли-колониаль политикасы ябыштыра» (6 б.). Бөек рус демократы Н. Г. Чернышевский «хәзерге татарлар — шушы тирәләрдә Бату явы килгәнче яшәгән һәм Бату тарафыннан руслар кебек үк буйсындырылган элекке кабиләләрнең оныклары» дигән иде. Ә царизм идеологлары татарларны монгол илбасарлары нәселеннән дип күрсәтергә омтылдылар һәм, шуннан чыгып, аларның культурасына карата тагын да кырысрак эзәрлекләү политикасы алып бардылар.

Табигый ки, татар халкы тормышындагы шушы үзенчәлекләрне исәпкә алмый гына китап басу эше тарихын, халыкның рухи тормышында китап сүзенең ролен өйрәнү һәм аны бәяләү үтә гомуми характерда булыр иде. Реформадан соңгы Россиядә татар китабы политик китап та булган дия алабыз, чөнки царизмның татарларны рухи коллыкка төшерү политикасын фактларга таянып ачып, ул үзендә пропагандистик очкын йөртә, хәзерге заман белән чагыштырып карау һәм коммунистлар, Совет дәүләте элек аяусыз изелгән халыкка үзенең милли культурасын, рухи дөньясын үстерү өчен ирек һәм мөмкинлекләр бирү буенча башкарган бинниһая зур эшен күрсәтү өчен дә материал булып тора. Татар китабы турында шушындый гомумиләштерүче хезмәт язылу — үзе генә дә формасы белән милли һәм эчтәлеге белән социалистик татар культурасының үсеш дәрәҗәсенең бер күрсәткече ул.

Ә. Кәримуллин хезмәтендә китап тарихы дәреслекләр басу тарихы, күп гасырлар дәвамында ислам дине схоластикасыннан арына алмаган татар мәктәбе тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Китап басу эше үсеш алу, рус программаларын һәм дәреслекләрен татар теленә тәрҗемә итү XIX гасыр ахырына мәктәп эшен сизелерлек яхшыртуга китерде. Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү 70 нче еллардан башлана. Тәрҗемәләр саны елдан-ел ишәя. Моннан тыш, арифметика, геометрия, ботаника, география дәреслекләрен авторлар рус дәреслекләренә таянып язганлыктан, алар, башлыча, рус авторлары әсәрләрен татар телендә бәян итү рәвешендә була. Шул елларда авыл хуҗалыгының төрле тармакларына караган басмалар саны күбәя, кошчылык, бакчачылык, үсемлекчелек, туф-

ракны ашлау, йорт терлекләрен асрау буенча ярдәмлекләр басыла башлый.

Татар укучысы табигать, төгәл фәннәр, техника казанышлары белән танышу өчен киңрәк мөмкинлекләр ача.

1917 елга кадәр татар китапларының күпчелек өлеше дини эчтәлектә булган дигән фикер хәзергәчә яшәп килә. Тикшеренүче моның киресен исбатлый. Дөньяви китаплар үзәк урын алып тору үзе генә дә китап репертуарының төп эчтәлеген характерлый. Дини китаплар бастыруны цензура да хуплый, ә алдынгы карашлы китаплар чыгаруга төрле тоткарлыклар куела. Моның сәбәбен әллә кайдан эзлисе юк — китап сүзе өстен сыйныфлар мәнфәгатьләренә хезмәт иттерелә. Басмалар санына һәм аларның тиражына карап кына да татарларның күпчелеге укый-яза белгәнлеген чамаларга мөмкин. Патша цензорлары һәм башка эшлекләләр икърар итүенчә, халыкның 80 проценты «үзләренчә укый-яза белә» (120 бит).

XIX гасыр ахырында Көнбатыш Европа язучылары әсәрләре дә татар телендә басыла башлый. Яңа, мәгърифәтче, реалистик татар әдәбияты барлыкка килү һәм көч туплауда китапның роле зур. XIX гасырның икенче яртысында басылган татар китапларының авторлары — Каюм Насыйри, Заһир Бигиев, Муса Акъегетзадә, Габдрахман Ильяси, Фатих Халиди, Риза Фәхретдинев һ. б. Шушы чордагы басмаларда татар тарих фәне (Ш. Мәрҗани, Г. Ильяси, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Ш. Таһиров һ. б. хезмәтләре) формалашып килү чагылыш таба.

«Реформадан соңгы Россиядә татар китабында миссионерларның җирле халык телендә православие дине китапларын бастырып тарату буенча эшчәнлегe дә җитәрлек тулы яктыртылган, бу эшчәнлекнең чын максатлары дәлилләп күрсәтелгән. Ә. Кәримуллинның миссионерларның эшчәнлеге татар китабына, гомумән, татар культурасына карата бөтенләе белән реакцион, ә үз китаплары булмаган башка халыклар телендә китап бастыруга карата күпмедер дәрәҗәдә прогрессив булган диган объектив фикере белән килешми мөмкин түгел.

Автор татарча китап басу эшен рус полиграфиясенең казанышы дип саный. Татарча китаплар басуда, татарлардан типография эшчеләре хәзерләүдә Казан университетының прогрессив роле тирәнтен ачыла. Татар китаплары басуда, ана телендә китап басу хокукы өчен көрәштә рус нәширләренең ярдәме аерым күрсәтеп үтелә. Шул ук вакытта Идел буенда рус матбугатын үстерүдә татар эш осталарының да өлеше булган икән.

Татар нәширләре Урта Азия, Казахстан халыкларының авыз иҗаты истәлекләре, фәнни хезмәтләрен, Көнчыгыш классиклары әсәрләрен басып чыгаруга да зур игътибар бирәләр. Җыентыкларга Рудаки, Ясәви, Лотфи, Бабур, Фирдәүси, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Руми, Хафиз, Җами, Навои һ. б. бик күпләрнең әсәрләре кертелә. Бу әсәрләр татарча да, оригинал телендә дә нәшир ителә.

Ә. Кәримуллин хезмәтеннән күренгәнчә, татар нәширләре XIX гасырда рус әдипләрен, фәнни-популяр китапларны, рус авторлары язган истәлекләрне татар теленә активрак тәрҗемә итә башлыйлар. Бу татар китабы, мәгърифәтчелек хәрәкәте рус культурасына, әдәбиятына йөз белән борылган чор, бу исә китапларның эчтәлегендә дә чагылыш таба. Автор рус классик әдәбиятының татар әдәбиятына йогынтысы көчәя баруын оста тасвирлый, гәрчә патша цензорлары Л. Толстой хикәяләрен, А. Пушкин әкиятләрен еш кына басарга рөхсәт итмәсәләр дә, рус әдәбияты үрнәкләре аз-азлап татар укучысына килеп ирешә. Автор демократик идеяләрнең татарлар арасына, әлгәре интеллигенциягә, анналары Казан, Урал, Донбасс һәм Бакуда яшәүче татар эшчеләренә үтеп керү юлларын еш күздән кичерә. Инде XX гасыр башында ук татарлар арасында социал-демократлар тарафдарлары байтак булу очраклы түгел. 1903 елда ук инде татар революционерлары татарча язылган большевистик әдәбият тараталар.

Ә. Кәримуллин татар милли китабы өчен иң авыр чорны тасвирласа да, хезмәтнең гомуми рухы оптимистик: патша хөкүмәте берничә хәйлә-мәкер белән дә татар китабын бугазлый алмый. «Иң авыр эзәрлекләү елларында да татар нәширләре үзләренең эшчәнлекләрен туктатмыйлар, 1851 елдан алып 1893 елга кадәр ел саен 25—90 китап чыгып килә, аларның гомуми тиражы кайвакыт миллионга җитә, ә 1895 елдан башлап басмалар саны тыелгысыз арта башлый, ел саен 150-200 китап чыгарыла, гомуми тираж ике миллион данәгә җитә. Берничә дә карамастан, XIX гасырның икенче яртысында татар китабы исән кала һәм культураны, мәгарифне, әдәбиятны үстерүгә шактый өлеш кертә, ха-

лыкка алдынгы рус һәм Европа культурасына, фәнгә, алдынгы иҗтимагый-политик һәм демократик фикергә ишек ача. Шушы аспектта алганда, аның әһәмияте милли кысалардан читкә чыга. Ул Россиядә яшәүче бик күп төрки халыкларның культурасын, мәгарифен үстерүгә сизелерлек өлеш кертте. Нәкъ менә басма китап милли-азатлык һәм демократик хәрәкәт күтәрелеше өчен иҗтимагый-экономик шартлар өлгереп җиткән чорда халыкларның милли һәм сыйнфый үзаңын үстерергә ярдәм итте. Китап халыкның сыйнфый аңын формалаштыруда катнашты, аны XX гасыр башында булачак, татар эшчеләр сыйныфы, бөтен халык актив катнашачак вакыйгаларга әзерләде.

Шушы бөтен тарихны китап үсү юлын анализлау аша күрсәтү — фундаменталь монография авторының иң зур казанышы.

Мирза МӘХМҮТОВ,
СССР Педагогия фәннәре академиясе академигы.

# ИСЕМ АРТЫНДА НӘРСӘ?

## ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ХӘТЕРДӘГЕ ТӨЕННӘР» КИТАБЫН УКЫГАЧ ТУГАН УЙЛАР.

Минем алда — китап. Әле кайчан гына ул миңа үзем дә белмәгән ниндидер бер ачыш вәгъдә итүче укылмаган китап иде. Хәзер инде ул — укылган китап.

Нәрсә үзгәрде, күңелдә ни калды соң? Китапның тышлыгыннан ук сирпелеп торган аклык, пакьлек тойгысы калды. Ниндидер бер зур канәгатьлек, эстетик ләззәт калды. Әдип күтәргән проблемалар өчен борчылу калды. Ә тагын, җыентыкка кертелгән әсәрләрнең күбесе шактый элек язылган булуга да карамастан, яңалык тойгысы калды.

Китапны кулга алгач, мине иң нык сөендергәне аның исеме астындагы «Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр» дигән өстәмә булды. Олы язучыларыбыз еш язамы соң мондый әйберләрне? Язган очракта да андый әсәрләр барысы бергә кайда гына очраша ала соң? «Сайланма әсәрләр»нең соңгы томында. Әйе, бары шунда гына.

Ә «Хәтердәге төеннәр»дә әле тагын тегеге яки бу уңай белән әйтелгән фикерләр, язучы биргән интервьюлар да бар. Җыентык әдипнең тормышка мөнәсәбәтен шактый тулы чагылдыра, аны шәхес буларак күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Һәм китап авторы әдәбиятыбыз, культурабызның киләчәген кайгыртучы, шуның хакына кадерле исемнәрне — халкыбызның «рухи медальләрен» чистартып-ялтыратып торучы кеше буларак та ачыла.

Әмирхан ага махсус рәвештә мәкалә яки истәлек язуны максат итми дә кебек. Алар, повесть һәм хикәяләре кебек үк, кеше, гражданин буларак, шатлыгын, кайгысын-гамен тапшыру чарасы, ягъни яшәвенең табигый бер чагылышы. («Бу ике көн турында язмыйча калу мөмкин түгел, чөнки шунсыз җан тынычланмаячак», — ди ул бер истәлегендә.)

Юк, Әмирхан ага канәгатьсезлек күрсәтү белән генә чикләнми, әлбәттә. Дәлилләр китерә, анализлый. Мәсәлән, ул С. Сүнчәләйнең «Сайланма әсәрләр»е чыгу уңаеннан язылган бер мәкаләсендә шагыйрьнең революция алды һәм революциядән соңгы еллар әдәбиятындагы ролен күрсәтә, үзенчәлекле ритмикасы, интонациясе белән Такташ, Бабичларга юл яручыларның берсе булуын, көчле тавышлы революция һәм мәхәббәт җырчысы булуын исбатлый. Ә ул ясаган нәтиҗә, минемчә, хәзер дә, егерме елдан артык вакыт үткәч тә актуаль яңгырый: «Сайланма әсәрләр»гә, әлбәттә, сайлап кертергә кирәк. Ләкин шулай сайларга кирәк ки, китаптан шагыйрьнең күләгәсе түгел, ул үзе ачык күренеп торсын. Мәгълүм тарихи шартларда яшәгән шагыйрьнең шул шартлар билгеләгән кытлаулы рухи дөньясын бөтен каршылыгы һәм чуарлыгы белән бергә аңлап-тоеп булсын».

Җырчылар, композиторлар турында да, театр, архитектура турында да яза Еники. Кемнедер яклый, нәрсәдер даулый — «тынычлар мәкаләләре» бөтенләй юк диярлек. Күп нәрсә борчый аны. Ә туктаусыз бор-

чып торганы — культура мирасыбызга, үткәнебезгә, халкыбызның горурлыгы булган кешеләр истәлегенә ихтирам җитмәү.

Менә ул Лев Толстойның музей-усадьбасын карап йөри. Бөек язучы исеме белән бәйле, аның кулы тигән һәрнәрсәнең кадерләп саклануына сөенә ул. һәм... «Шул ук вакытта, йортның беренче бүлмәсенә кереп карый башлагач та, минем йөрәктә бер әрнү, ачыну хисе кузгалды. Бу хис бүлмәдән-бүлмәгә күчә барган саен көчәя дә барды. Нидән туды соң бу әрнү һәм ачыну хисе?..»

Моның сәбәбе шунда: әдип тарихи мирасыбызга, «бөек кешеләребездән калган кадерле реликвияләргә» бездә әлегә җитәрлек игътибар бирелмәү турында борчыла, үткәннәрне өйрәнүдә реаль җирлек һәм киләчәк буыннар өчен гаять зур тәрбияви әһәмиятле фактор буларак, аларны бөртекләп сакларга чакыра.

Шул ук «Косогор заводы — Ясная Поляна» дигән юлъязмада менә нинди фикергә игътибар иттем: «Без күп йөреп, күргәннәрне язып өйрәнгән язучылар түгел. Шуңадыр ахрысы, безнең хәзерге әдәбият һәртөрле юлъязмаларга ярлы да. «Бу сүзләр әйтелгәннән соң узган утыз елда язучыларыбыз да, журналистларыбыз да бик йөремсәккә әйләнделәр: ил генә түгел, дөнья гизәләр. Әмма жанр һаман әле «якорьда» килеш тора шикелле. (Дөрес, берничә казанышыбыз бар: Рафаэль Мостафин һәм Миргазиян Юныс юлъязмалары). Моның бер сәбәбе, минемчә, жанрның шундый үзенчәлегендәдер: юлъязмаларда авторның үз шәхесе калку күренеп торырга тиеш, шунсыз аларның тәэсир итү көче дә, гомуми егәре дә аз була. Менә шул «миннән курку һаман бетеп җитмәгән әле.

Әнә шундый формаль күзлектән карагында, Әмирхан Еникинең Хәсән Туфан турындагы истәлеген («Очрашу һәм аерылышу»), «авторның үзе турында бит ул!» дип, «бетереп» ташлап булыр иде. Башкортстанга китәр алдыннан Әмирхан ага шагыйрьнең хәлен белергә больницага бара. Әнә шул очрашу тасвирланган ике ярым китап бите дәвамында Туфан нибары биш сүз әйтә. Ләкин аның шул биш сүзе («Сәйфинең хәлен... хәл-әхвәлен белеп кайт!»), кайчагында җөпләү төсендә баш кагып, тын гына карап ятуы, менә шул ике ярым битлек кыса эчендә булу сәбәпле, гаять зур мәгънә ала, нурланып-балкып куя.

Истәлекнең калган өлешендә (9 бит) әдип Уфада йөри, Фатих Кәримнең туган авылына бара, күпләгән кешеләр белән очраша. Әмма укучы Туфанны, аның нинди хәлдә калуын истән чыгара алмый. «Онытмыйк, унынчы июнь!», «Башларны иеп, без Хәсән абзыйның әнә шул моңнарын тыңлап утырабыз... Әмма ләкин без берни дә, берни дә белми идек әле». «Унынчы июнь үтте инде, унберенче июньнең таңы туып килә...» Язучы әнә шулай безне кайгы хәбәренә әзерли. Тавышындагы драматик киеренкелек алдан ук югалтуның зур, кайгының олы булачагын сиздерә... һәм менә әлеге хәбәр язучыга барып ирешә...

Әйе, автор Хәсән ага турында берни дә сөйләмәде диярлек. Әмма күңелдә җентекле сурәтләү-тасвирлаулар да сыза алмаслык тирән эз калды. Аристотель Җирнең түгәрәклеген аның Айга төшкән күләгәсеннән белгән кебек, без Хәсән Туфанның кимлеген кайгы күләгәсенең язучы күңелендәге чагылышыннан күрдек.

«Әйе, күпме генә яшәмә, ахры бер кеше китә... Шагыйрьдән нәрсә калганын без беләбез — анысы кулыбызда. Ә менә үзе белән алып киткәнен белү — юк, мөмкин түгел. Хәлбуки, киткәне дә аз булмаска тиеш...»

Әмирхан ага мондый мәгънә салмагандыр да, әмма мин барыбер аның бу сүзләрен шелтә кебек кабул итәм. Сиксәннең теге ягына чыккан шагыйрьнең дә язылмаган шигырьләре аз калмагандыр, Әмирхан ага әйткәнчә, «уйланудан, борчылудан, өметләнүдән туктамаган шагыйрь иде». Монысы, ни дисәң дә, табигый югалту. Икенче нәрсә борчый. Такташ, Кутуйлар кордашы — ул бит безнең арага дәреслектән төшкән кебек килеп керде, гомеренең соңгы 25 елын безнең буын күз алдында үткәрде. Ә үзе биргәннән тыш нәрсә генә алып калдык соң без аңардан?

Әдәбият янындагы актив зона — әдәбиятыбызның «ишегалды» юк — шуннан да бу. Ә журналистлар нәрсә карый? Кызыксынучанлык, яңалык табу теләге безнең канга сеңгән булырга тиеш ләбаса! АКШның Ливандагы башбаштаклыгы турында, әйтик, Бакый Урманче ни уйлый, Ренат Ибраһимовның яңа концерт программасын Сибгат Хәким ничек бәяли, Зөлфәтнең яңа поэмасы турында Илһам Шакиров нинди фикердә? Моңа охшаш сорауларга укучы көнендә-сәгатендә үк җавап алырга тиеш түгелме соң? Журналистикабыз - әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрендә әнә шулай актив, тере-үткен булганда, культура пуль-

сыбыз да дәртләрәк булыр иде кебек.

Әдәбиятыбыз зур югалтулар кичерә килде. Баксаң, шөкер, сөенечле яңа күренеш турында да сөйли алабыз икән бит: бер төркем өлкән язучыларыбызның иҗат стажы 60-65 ел тәшкил итә! Нәкый Исәнбәт, Афзал Шамов, Гариф Галиев, Мөхәммәт Гайнуллин, Әхмәт Исхак, Сәлих Баттал, Газиз Иделле... Иске тормышны күреп белгән, татар совет әдәбиятының нигез ташларын салышкан аксакалларыбыздан нәрсә алабыз, язмышның бу бүләгеннән ничек файдаланабыз соң?..

Алда әйткәнемчә, Әмирхан ага (Илдар Юзеев белән бергә) Фатих Кәримнең туган авылы Аетта була, анда Башкортстан Язучылар союзы һәр елны җәй башларында үткәрә торган «Фатих Кәрим укулары»нда катнаша. Мондый теләк белдерә ул ахырдан: «... Минә безнең шагыйрьләр бу җирне, бу халыкны онытмасыннар иде, якын итсеннәр иде, ел да «Кәрим укулары»на ерак араны якын итеп килсеннәр иде... Кәрим сүзләренә язылган бик матур көйләребез бар, бер-ике җырчы да килеп, «укуларны» бизәсәләр, халыктан бары рәхмәт кенә ишетеп китәрләр иде. Шулай ук художникларыбыз шагыйрьнең бюстын эшләп, музей алдына китереп куйсалар, Ает авылына бу бик зур бер бүләк булыр иде».

Өлкән язучыбызның ташка басылган сүзенә, иплән кенә әйтелгән бик тә урынлы сүзенә колак салганнармы соң? Теләкнең беренче өлеше үтәлә: былтыр җәй Аетка Ренат Харис белән Рәдиф Гатауллин барганнар. Әмма эш шуннан узмаган кебек әле.

Әдипнең истәлекләре Һади Такташ, Гадел Кутуй, Әхмәт Фәйзи кебек олы язучыларыбызның без, яшьләр, төрле чыганаклардан җыеп күз алдына китергән портретына яңа төсмерләр өсти.

Әмирхан аганың бу җыентыгын яшьләр бигрәк тә яратып укырлар. Чөнки китапка кергән очерклар, истәлекләр, мәкаләләрдә алар куралмый торган төрле шомарту-түгәрәкләүләр, матурлау, гади дөреслектән качу, авторның үз сүзе белән әйткәндә, фальшь юк. Укучыларның бер өлеше, бәлкем, бу сүзләрнең дөреслеген таныган хәлдә, аларга артык әһәмият тә бирмәс: шулай булырга тиеш тә инде, янәсе. Тиешен тиеш тә, әмма, гомумән алганда, шуңа омтылган язучыларның да һәркайсы шуңа бара аламы соң?

«Сабан туен без дә күрдек» дигән мәкаләдә сабан туена авылга кайткан бер төркем кунакның (арада автор үзе дә) ничек сыйлануын, башкаларның үз-үзләрен ничек тотуларын, үзенең ни уйлау-кичерүен әдип документаль төгәллек белән теркәп куйган. Бу бәләкәй «җәмгыятьне», димәк үзен дә, психологик күзәтү объектына әйләндергән ул. Ә «эксперимент» менә мондый нәтиҗә ясау өчен кирәк булган: «Йоласы шул, гаеп итәр урын юк. Әмма бөтен ашаган-эчкән халык бергә җыйналгач, исереклек гомуми төс ала икән». Бу «ачыш»ка әр-яңа күзәтүләр дә өстәлгәч, «картина» туа: «Җитмәсә, монда да куак төбе саен табын, табын саен шул ук яшьләр аунап эчәләр... Ә аракыга кытлык юк, сәүдә «точкалары» ак башларны да, кызыл башларны да китереп тутырганнар».

Ә нигә әле Еники яза бу турыда? Соң сабан туен без дә күрдек бит! Мондыйларын да аз күрмәдек. Юк шул, исерекләргә абына-сөртенә карап кайта идек тә, матуршома отчет-репортажлар, «Аһ, сабантуй!» тибында шигырьләр язып бастыра идек. Милли бәйрәмебез бит, ничек хурлыйсың ди аны! Ә. Еники исә «әдәп сакларга» кирәк санамаган. Язучы намусы, гражданин намусы дигән нәрсәләр һәм, гомумән, намуслылык әнә шундый ситуацияләрдә күренә дә инде ул.

Менә шушы сыйфат — намуслылык — әдипнең язу манерасында ук чагыла. Нәрсә турында гына язмасын, төбенә төшәргә, һәр фикер, кешегә бирелгән һәр бәясенең абсолют төгәллегенә ирешергә омтыла ул. Без аның уйлау процессын ук күреп торабыз кебек. Менә ул учына фактлар ала да, берәмтекләп, саф хаклык орлыклары гына торып калганчы, чистарта, аралый... Мондый нечкәлек, мондый җентеклелек кайберәүләрнең саруын да кайнатырга мөмкиндер. Әмма игътибарлы, җитди укучы өчен Әмирхан аганың фикер сөрешен күзәтү — үзе бер ләззәт...

«Хәтердәге төеннәр» мине күп нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итте. Шул исәптән, күренекле язучыларыбызның биографияләре турында да. Менә дигән итеп язылган биографияләр, әмма кәгазьгә күчмәгән, киң даирәгә мәгълүм булмаган биографияләр турында. Сугышка кадәрге Җәлил, Алишлар биографияләре кебек, беренче карашка үтә гади күренгән биографияләр турында.

Аларның чын кыйммәте бирелгән дан вексельләрен бише белән түләргә җитәрлек. Моны бары күрсәтә белергә, хәтердәге төеннәрне ешрак чишәргә кирәк.

**Рафикъ ЮНЫСОВ.**

Җәмил Зәйнуллин

# «КӘЛИЛӘ ВӘ ДИМНӘ» — ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА

Татар әдәбиятының башка әдәбиятлар белән тарихи бәйләнышы әлегә аз өйрәнелгән, әмма ул гаҗәп кызыклы һәм әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шундый бәйләнышларның бер җебе борынгы Һиндстан әдәбиятына барып тоташа.

Билгеле булганча, Һиндстанда III—IV гасырларда «Панчатантра» (Биш китап) исемле әсәр иҗат ителеп, аның даны чит илләргә дә тарала. 531—579 елларда аны борынгы фарсылар шул замандагы әдәби телләре булган пәһләвичәгә тәрҗемә итәләр. 721—757 елларда Ибне әл-Мөкаффәгъ исемле күренекле әдип әлеге әсәрне гарәп теленә тәрҗемә итә һәм исемен дә үзенчә — «Кәлилә вә Димнә» дип куя. Әмма аның бу эше үз тормышы өчен фаҗига булып әверелә: аңа электән дә ачу саклап килгән түрәләр һәм руханилар, динсезлектә гаепләп, әдипне ерткычларча газаплап үтерәләр, гәүдәсен утта яндыралар.

Ибне әл-Мөкаффәгъ эшләп калдырган тәрҗемәдән «Кәлилә вә Димнә» дөньяның күп телләренә күчерелә. XI гасырда аны инде грек телендә, XII гасырда славян телендә, XIII гасыр урталарында латин телләрендә укыйлар. 1889 елда рус ориенталистлары әсәрне рус телендә бастырып чыгаралар.

Соңыннан әсәр дөньяның күп телләренә тәрҗемә ителә, төрле илләрдә әледән-әле басылып тора. Рус телендә совет чорында аның яңадан-яңа тәрҗемәләре басыла[1].

Шулай итеп, «Кәлилә вә Димнә» дөнья әдәбиятының алтын фондына кергән. Аның татар әдәбиятына мөнәсәбәте ничек соң?

XIV—XV йөзләрдә Идел буенда Низаминың «Хөсрәү вә Ширин», Сәгъдинең «Гөлстан» кебек даһи әсәрләре тәрҗемә ителгән. Бәлки «Кәлилә вә Димнә» дә тәрҗемә ителгәндер, тик безгә генә килеп җитә алмагандыр. Шулай уйларга нигез бар. Соңгы елларда аның борынгы әдәби телебездә тәрҗемә ителгән күчермәләре табылды. Тик аларның беренче һәм соңгы битләре сакланмаганлыктан, кайда, кайчан һәм кем тәрҗемә иткәне мәгълүм түгел. Шундый кульязмаларның берсе хөрмәтле белгечебез Касыйм ага Хәмзин архивында сакланган. Аның кызы — филология фәннәре кандидаты Гөлшат ханым бу ядкярне, тикшерү өчен, галимнәргә тапшырды.

Игътибарга лаек тагын бер табыш бар. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре кульязмалар фондыннан әсәрнең бүтән күчермәсен тапты. Ике кульязманың да төп тексты охшаш, хәтта бер үк диярлек булуы исә әлеге тәрҗемәнең татарлар арасында күчермә юл белән таралганлыгын раслый. Әйтергә кирәк, әсәрнең гарәп телендәге тексты да борынгы заманда күп тапкырлар күчерү нәтиҗәсендә нык кына үзгәртелгән. Соңгы гасырларда галимнәр махсус тикшеренүләр нәтиҗәсендә әсәрнең төзек текстын булдырырга ирешкәннәр. Шушы хәлендә ул 1816 елда Парижда, 1899 елда — Бәйрутта гарәп телендә аерым китап итеп басылган. Хәзерге фән дөньясында «Кәлилә вә Димнә»нең шушы басмалары иң ышанычлы дип санала.

---

[1] Крачковский И. Ю., Кузьмин И. П. Калила и Димна. М.-Л.,1934.

Касыйм ага Хәмзин нөсхәсен өлеге басмалар белән сүзгә-сүз чагыштырып чыкканда гарәпчә һәм төркичә текстларның бер-берләренә яхшы ук тәңгәл килүләре ачылды. Бу, әлбәттә, бездәге кульязма шул басмалардан тәрҗемә ителгән дигән сүз түгел. Ул үзенең тел-стиль хасиятләренә карaганда, һичшиксез, болардан элегрәк ядкяр. Кыскасы, бу китапларның өчесе өчен дә бер чыганак — ниндидер дүрtенче, борынгырак гарәпчә нөсхә булгандыр.

«Кәлилә вә Димнә»нең Казан татарларында урта гасырларда ук мәгълүм булуын бүтән дәлилләр дә раслый. Казан шагыйре Мөхәммәдъяр 1539 елда үзенең атаклы «Төхфәи мәрдан» һәм 1542 елда «Нуры содур» әсәрләрен яза һәм күп кенә очракларда Көнчыгыш әдәбиятлардан алынган хикәятләрне шигырьгә сала. «Кәлилә вә Димнә»дән дә ике хикәят алынган: берсе аның «Гадел Нәүширван», икенчесе «Заһид хикәясе» дип атала.

Борынгы заманның бу бөек әсәре һәр яңа дәвер өчен яңа хәзинә булып ачылган. Мөхәммәдъярдан соң өч гасыр үткәч, XIX йөздә татар мәгърифәтчеләре «Кәлилә вә Димнә»не яңадан күтәреп чыгалар. Бу үзе кызыклы хәл. Идел буенда берничә гасыр элек укылып та, соңрак онытылып торган кайбер күренекле әсәрләр — «Мең дә бер кичә»ләр, «Тутый намә»ләр яңадан калкып чыга. Бу чорда Казан үзе дә Россиянең Көнчыгыштагы атаклы фән үзәгенә әверелә. Университет эшли. Ул татар халкын русның фән һәм культура казанышлары белән таныштыра, университет фәнендә Көнчыгышны өйрәнү зур бер юнәлешкә әверелә. Алдынгы татар укымышлылары үзләренең мәгърифәт эшчәнлеген киң җәелдереп, рус галимнәре белән бердәмлектә эшлиләр, табышларын уртаклашалар. Шушы чорда «Кәлилә вә Димнә» мәйданга яңадан чыга. Мисал буларак Хөсәен Фәезхановның рус тюркологы Н. И. Ильминскийга язган хатыннан шундый сүзләрне китерү урынлы булыр: «Миндә сезнең төркичә «Кәлилә вә Димнә»ңез бар. Бер форсат булганда йибәрермен...»[1] — ди ул. Х. Фәезханов татар теле дәреслеген яза[2] һәм аңа «Кәлилә вә Димнә»дән «Кеше үз кабилиятеннән тыш булганны эзләсә максудына ирешә алмаячагы һәм барын да югалтачагы белдерелер» дигән бүлекне кертә.

Зыялы Фәезхановлар гаиләсеннән тагын бер мәгърифәтче үсеп чыга. Габделгалләм Фәезханов агасы Хөсәен башлаган эшләрне дәвам иттерә. Ул яңадан гарәп теленә кайтып, «Кәлилә вә Димнә»не яңабаштан татарчага тәрҗемә итә[3]. Шунысы әһәмиятле, бу юлы яңа тәрҗемә Көнчыгышны өйрәнүче рус галимнәрен дә кызыксындыра.

Габделгалләм Фәезханов моны эшләүдән нинди максатларны күздә тоткан соң? Монда төп ике нәрсәне искәртеп үтәргә кирәк: «Кәлилә вә Димнә»не Г. Фәезханов «гаҗәп әсәр» дип атый. Ул — әсәрнең гуманистик хасиятен һәм сәнгать гүзәллеген, балалар күңеленә тирән тәэсирен шулай бәяли, кызыклы хикәятләр аркылы татар халкына кешелекле идеяләр һәм күңел ләззәте бирергә тели. Монда чынбарлыкка тәнкыйть күзе белән карау да роль уйнаган. Бу чорда Россиядә татарлар арасында да куәт алган буржуаз мөнәсәбәтләргә, буржуалашкан катлауларда таралган ямьсез күренешләргә нәфрәт уяту ягыннан «Кәлилә вә Димнә» мәгърифәтчеләр өчен әһәмиятле әсәр булган. «һәркем бу китапның форсатына карап үзенә кирәк бүлекне укысын һәм хәленә лаек нәсыйхәтләр, вәгазьләр алсын! — дип яза Г. Фәезханов. Сүз уңаенда шуны әйтеп үтәргә кирәк, прогрессив эчтәлекле әсәрләрне татарчага тәрҗемә итү Г. Фәезхановның мәгърифәтче буларак киң эшчәнлек программасын тәшкил иткән.

1905—1907 елгы Беренче рус революциясе чорында «Кәлилә вә Димнә» белән кызыксыну янә җанланып китә һәм үзенчәлекле мәгънә ала. Ул татар революцион-демократик әдәбияты, татар прогрессив культура хәрәкәтенең уртасына килеп керә. Гарәп теле өйрәнелә торган дөньяви мәктәпләргә уку әсбабы буларак Казанда «Сабах» нәшрияты китапны гарәп телендә бастырып чыгара (1907 ел). Татар телендә чыккан дәреслекләргә «Кәлилә вә Димнә»дән тәрҗемә итеп кызыклы хикәятләр урнаштырыла. Хуҗамөхәммәт-Закир Ишмөхәммәтов, мәсәлән, үзенең дәреслегенә «Кәлилә вә Димнә»дән кыскартып «Эт илә күләгәсе» дигән хикәятне алган. «Бер

---

[1] Госманов М. Хөсәен Фәезхан углының бер хыялы. «Казан утлары». 1971, 3 нче сан.
[2] Фәйз-ханов Х. Краткая учебная грамматика татарского языка. СПб., 1862.
[3] Фәезханов Г. Кәлилә вә Димнә. Казан, 1889.

эт авызына сөяк кабып, күпер аркылы чыгып барганда, суга төшкән үз күләгәсен күреп фикерләде: суда дәхи авызына сөяк күтәргән эт бар икән дип. Шуннан соң үзенең авызындагы сөяген ташлап, суда булган этнең сөяген алырга суга ташланды. Әмма судагы этнең сөяген ала алмады, үзенең сөяге суга батып китте»,— дип тәмамлана әлеге хикәят. Габдулла Тукай «Ике күгәрчен», «Картайган арыслан» исемле хикәятләрне иҗади тәрҗемә итеп, балалар өчен җыентыгына кертә («Энҗе бөртекләре». Казан, 1909). Бөек шагыйребез «Кәлилә вә Димнә»дән башка хикәятләрне дә тәрҗемә иткән булса кирәк, һәм бу фикерне раслаучы кайбер мәгълүматлар бар инде.

Бу чорда татар поэзиясендә мәсәл жанры җанланып китә. Моның мөһим сәбәпләреннән берсе шунда: реакция елларында патша цензурасы котырына, матбугат битләрендә аз гына күренеп киткән ирекле фикерне дә рәхимсез эзәрлекли. Хөр карашларны киная, шартлы сурәт аша белдерә торган әсәрләр языла, киная иҗтимагый-политик идеяләрне яктыртуга хезмәт итә, ә бит «Кәлилә вә Димнә» асылда чәчмә белән язылган мәсәлләрдән гыйбарәт. Шагыйрьләр «Кәлилә вә Димнә»нең гомуми әдәп-әхлак идеяләрен гәүдәләндергән сюжетларын алалар да шулар аша реакция чорындагы иҗтимагый-политик золымны гаепләгән идеяләрне үткәрәләр. Дөрес, монда кайбер персонажлар нәкъ «Кәлилә вә Димнә»дәге кебек үк алынмаган, әмма сюжет принцибы аңардагыча кала.

«Кәлилә вә Димнә» әсәренең илебез халыклары мәдәни тарихында күп гасырлык гомере бар. Бөек дустыбыз һинд халкы белән безнең халыклар күңелен ул күп заманнар дәвамында бергә баглап килгән, газаплы, дәһшәтле дәверләрне кичкәндә, рухи юлдаш булган. Бөек Октябрьдән соңгы елларда ул рус теленә яңадан тәрҗемә ителде, әзербайҗанчасы, үзбәкчәсе, таҗикчасы да яңадан-яңа тәрҗемәләрдә дөнья күрде.

Сезнең игътибарыгызга югарыда искә алынган кулъязмадан ике хикәят тәкъдим ителә. Билгеле булганча, ул чорның язма теле хәзерге әдәби телебездән шактый гына аерылып тора. Борынгы төрки, гарәп, фарсы сүзләренең күп булуы, җөмлә төзелешендәге үзгәлекләр хикәятләрне укып аңлауны кыенлаштыралар. Шуны күздә тотып, үрнәк өчен бер хикәяттән өзек үзгәртмичә, оригиналдагыча, ә икенче хикәят хәзерге әдәби телгә якынайтыбрак бирелә.

## Кәлилә вә Тәминә сүзләре

...Кәлилә әйде: бер бичен бар, дорудкәрнең ике шийна ясап бер йыгачны йарар ирмеш. Күрмеш: бу арада ул кийте йыгачны ярым пучук ярыб, үзине гайре эшкә бирмеш.

Тәкый бер бичен килеб, ул йыгачның ярылмаган башы уза ултурмыш, тәкый койрыкы, ул йыгачның арасында калмыш, үзе тәкый сөңге шийнаны ормайын борунгы шийнаны оруб чыкармышда. Шул заман биченнең койрыкын ул йыгачның арасында катыйг кысмыш. Тәкый дорудкәр килеб, бу эшне күрүб әймеш: кем әй бәдбәхет, ни файдасыз эшкә мәшгуль булдың тиб, тукмак алыб биченне һәлак кылды.

Ул сәбәбдин бу мәсьәләне аныңчүн йад кылдым: әйтүрләр — кем биченгә үз эшен кылгу кирәк, дорудкәрлек эше биченгә нә кирәк?

Сүзлек: бичен — маймыл; дорудкәр — балта остасы; шийна — чөй; йыгач — агач; ярым пучук — яртылаш мәгънәсендә; тәкый — тагын, шулай ук; уза — башка; йад кылдым — искә алдым, сөйләдем.

## Маймыл белән Ташбака хикәяте

Бер дәрья буенда бик күп маймыллар яши иде. Аларның гадел, белдекле патшалары бар иде. Гомеренең язы үтеп картаеп, көчсезләнеп калгач, аны падишаһлыктан алып, башка бер маймылны шаһ итеп куйдылар.

Бичара карт маймыл кайгы-хәсрәт дәрьясына чумды. Йөри-йөри бер зур дәрья буенда үскән агачлыкка килеп чыкты. Ул җирдә җимеш агачлары бихисап күп иде. Мескенебез үзе кебек бер карт инҗир куагына менеп үзенә урын җайлады. Беркөнне шулай инҗир куагында утырып, аның җимешләрен берәм-берәм өзеп ашап утырганда бер җимеше кулыннан суга төшеп китте. Бу инҗир җимешенең чапылдап суга төшүе маймыл күңеленә хуш килде һәм ул тагын да бер-бер артлы җимешләрне суга ташлый башлады. Шул суда бер ташбака яши иде. Суга төшкән инҗирләрне йөзә-йөзә ашый һәм күңеленнән дәхи маймыл мине танымый, минем белән дуслыгы да юк, шулай булса да миңа нинди шәфкатьле эш кылыр; әгәр мин аның белән дуслансам, ул миңа тагын да яхшырак мөнәсәбәттә булыр, дип уйлый иде. Шул чак ташбака әйтте: әй маймыл! Мин синең белән дуслашасым килә, диде. Маймыл исә: теләгәнне теләмәк кирәк, дип җавап кайтарды һәм үзе утырган инҗир куагыннан төшеп ташбака белән исәнләште. Шул рәвешчә бака белән маймыл дуслыкны беркеттеләр. Алар һәркөн сөйләшеп, киңәшләшеп, дөнья хәлләре турында хәбәрләшеп утыра торган булдылар һәм бер-беренә әйтеп бетергесез дуслык хисләрен саклый иделәр. Әйтерсең лә алар — ике тәндә бер газиз җан, бер күкрәктә ике йөрәк...

Маймыл дустына үзенең дәүләтеннән, малыннан мәхрүм булганлыгын сөйләп бирде. Дусты исә аның сүзләрен тыңлый-тыңлый, үз өенә кайтырга кирәклеген дә онытып җибәрде. Ташбаканың хатыны иренең озак вакытлар кайтмавына борчылып, нишләргә белми аптырап, күршесе янына керде.

Күршесе әйтте: һич кайгырма, дускай, иреңнең кайда икәнлеген мин сиңа әйтә алам, диде.

Ташбаканың хатыны: тизрәк әйтә күр, кайда ул, диде.

Күршесе әйтте: синең ирең бер маймыл белән дуслашып, аңа тәмам гашыйк булган һәм үзенең йөрәк җылысын ул маймылга сарыф итеп йөри икән. Инде мин сиңа әйтим, юкка әрнеп, нәрсә белән бетәр икән боларның дуслыгы дип, көтеп ятасы юк. Иреңне өйгә кайтару өчен берәр чара күрү кирәк, диде.

Болар икәүләп киңәшә башладылар. Ниһаять, маймылны үтерүдән башка чара юк, дигән фикергә килделәр. Күршесенең киңәше белән, ташбака хатыны авыруга салышты. Ташбаканы чакыртып кайтардылар. Өенә килеп керсә, ташбака ни күзе белән күрсен, хатыны урын өстендә ята. Хатыны янына килеп аның хәлен сорады, ләкин хатыны аңа җавап кайтармады.

Ташбака хатынының нинди авыруга дучар булуы һәм ни сәбәптән сөйләшмәгәнлеге турында күршесеннән сорады.

Күршесе әйтте: әгәр авыруның хәле авыр булып, үз жаныннан нәүмиз булса, ничек итеп ул сөйләшә алсын, диде.

Ул надан бака бу сүзне чынга санады һәм елый-елый күршесеннән сорады: нинди дару кирәк, әйтче миңа, әгәр бу тирәдә табылмаса, башка җирләрдән, дус-ишләремнән, дошманнарымнан булса да ялварып сорармын, диде.

Күршесе әйтте: хатыныңа кирәкле дәва — ул маймыл йөрәгедер. Без хатыннарга хас булган бу авыруны маймыл йөрәгеннән башка һичнинди дару белән дәвалап булмый, диде. Ташбаканың башына кайгы төште. Әгәр маймылны үтерсәм, дуслыкка хыянәт иткән булам, үтермәсәм — өем таянычы, тормышым-көнем бизәге, балаларымның анасы булган газизем, сөекле хатынымнан аерылып ялгызым гына калам, дип уйлый иде.

Шактый гына вакыт шундый уйларга чумып аптырап йөрдө һәм, ниһаять, хатынына булган мәхәббәте өстенлек алды, маймылны үтерергә карар итте. Ташбака маймыл янына барды да, хатынының каты авырып ятуын елый-елый сөйләп бирде.

Ташбака әйтте: әй дустым! Синең белән аерылып тору мине утларга салды, гаиләмне күрү дә күңелемне тынычландыра алмады. Менә инде синең янына килдем, ялгызлыгым исемә төшкәндә дөнья караңгыланган кебек була. Әй дустым! Рәхим итеп минем өемә барсаң икән, минем балаларымны, хатынымны шатландырсаң, карендәшләрем, дусларым арасында башым күккә тияр иде. Алар әзерләгән ризыклары белән сине сыйлау бәхетенә ирешерләр иде. Шуның белән үземне синең миңа күрсәткән яхшылыкларыңа бераз гына булса да җавап кайтарган дип исәпләр идем.

Маймыл әйтте: бу турыда күп уйлама. Синең миңа яхшылыкларың күп булды. Арабызда дуслыкның пәйда булуына син сәбәпче булдың; синең белән дуслашканчы мин ихтыярсыз үз мөлкәтемнән, илем-көнемнән аерылып, бу дәрья буенда хәсрәт эчендә, япа-ялгыз гомеремне уздыра идем. Синең белән дуслашкан көннән башлап минем хәсрәтләрем таралды, караңгы көннәрем якты булды. Инде синең бу изгелекләреңә кайчан гына игелек эшли алырмын икән. Әй дустым! Ерак сәфәр чыгу җиңел эш түгел, ләкин чын дусларның теләге белән ризалашмау ул дошманлык эшләү белән бәрабәр торыр. Син мине гаиләңне күрсәтү өчен чакырасың; ярый, дустым, мин риза, ләкин ничек итеп мин дәрья аркылы чыгармын соң?

Ташбака әйтте: борчылма, дустым, сине үз аркама атландырып өемә алып барырмын. Синең мөбарәк дийдарыңнан хатыныма күп шифалар тияр. Күп төрле ләззәтле нигъмәтләрдән авыз итәрсең, андагы сыйлар биредә юк, дип сөйләнә-сөйләнә, ташбака суга керә башлады. Маймыл исә барырга ризалык бирде һәм үз язмышын бакаының кулына тапшырды. Суның уртасына җиткәндә ташбака уйланып калды һәм үз-үзенә әйтте: галимнәр әйтүенчә, тугрылыксыз һәм хыянәт, бигрәк тә игътибарсыз хатыннар өчен эшләнгән хыянәт иң зур гөнаһ булып исәпләнә. Бөек кешеләрнең тагын шундый сүзе бар: алтынның сафлыгын утта, хайванның көчен авыр йөк тартканда, кешенең тугрылыгын аманәткә хыянәт итмәгәндә генә белеп була. Укымышлылар — хатыннарның мәкер-хәйләләренә алданмаска кирәклекне мәслихәт итәләр. Шундый уйлар уйлап бара-бара ташбака суның уртасында кинәт туктап калды... Маймыл исә ташбаканың ниндидер житди бер нәрсә турында уйлаганын сизенде һәм шөбһәләнеп ташбакадан сорады: нәрсә булды сиңа, нинди сәбәпләр аркасында уй-фикерләр дәрьясына чумдың, бәлки мине күтәреп бару сиңа авырдыр?

Ташбака аңа әйтте: нәрсәгә нигезләп син мондый сорауны миңа бирдең? Әллә мин үземнең берәр хәрәкәтем белән сиңа моны сиздердемме, диде.

Маймыл әйтте: минем күрүемчә, синең вөҗданыңны нәрсәдер азаплый, диде.

Ташбака әйтте: дөрес әйтәсең, дустым! Менә син беренче мәртәбә минем өемә барасың. Синең кебек якын дустымны хатыным авыру чакта өемә кунакка чакырдым. Үзем кунак сыйлауның рәтен белмимен, оятка калмасам гына ярар иде дип, уйланып барам әле, диде.

Маймыл аңа җавап итеп: дустым! Синең пакъ намуслы, тугры булуың һәм чын дустанә хисләр белән, яхшы ният белән мине өеңә алып барганлыгың күренеп тора. Синең дәстәрханең никадәр ярлы булса да, сөхбәтебез шул кадәр самими һәм матур булыр. Синең саф йөрәкле икәнлегеңне беләм, дустым; шуны белеп әйтәмен ки, юкка борчыла-

сың, болай борчылырга сәбәп юк, диде. Бераз йөзеп барганнан соң ташбака тагын туктады.

Маймылның шөбһәләре арта башлады һәм күңеленнән әйтте: үз дустыннан шөбһәләнгән кешенең шул ук минуты-сәгатендә чарасын күреп саклык белән эш итүе кирәк.

Йөрәк тиз генә үзгәреп торганы өчен аны калеб [1] дип атаганнар да инде. Һәр минут саен ул нинди хыялга чума, нияте яхшымы, начармы— һич белеп булмый, дип уйланды һәм ташбакадан: тагын нәрсә булды сиңа, нинди хыял диңгезенә чумып киттең? — дип сорады маймыл.

Ташбака әйтте: нишлим соң дустым, хатынымның хәстәлеге күңелемнән һич кенә дә чыкмый.

Маймыл әйтте: хатының нинди авыруга дучар булган, нинди дәвага мохтаҗ — әйтә алмассыңмы, диде исә, ташбака аңа болай диде: табиблар маймыл йөрәген ашарга куштылар, шуннан соң терелер дип әйттеләр, диде.

Моны ишетү белән маймылның күз аллары караңгыланып китте һәм үз-үзенә: инде мине бер әр төрле хәйләдән башка һичнәрсә коткара алмас, әгәр үзем суга сикерсәм, батып һәлак булачагым көн кебек ачык, диде.

Төрле уйларны хыялыннан кичереп, маймыл ташбакага әйтте: әй ташбака дустым! Безнең хатыннарыбызга да мондый зәхмәтләр йогып тора. Шуңа күрә без йөрәгебезне еш кына хатыннарыбызга биреп, аларны мондый зәхмәтләрдән коткарып калабыз, ә үзебез исә йөрәксез генә яши бирә идек. Әгәр, дустым, син бу сүзләрне минем өем янында әйткән булсаң, йөрәгемне үзем белән алган булыр идем. Картайгач миңа йөрәкнең кирәге юк инде, аны күтәреп йөрүе дә бик авыр. Шуның өчен михнәтләргә төшкән йөрәгемне аерым саклыйм, күңелемә кайгылы-хәсрәтле уйлар да азрак килә, диде маймыл.

Ташбака әйтте: нигә бүген йөрәгеңне өйдә калдырдың?

Маймыл әйтте: безнең маймыл халкында бер гадәт бар, якын дусишләребезгә кунакка барганда, мәҗлесләре яхшы булып матур хатирәләр калдырсын өчен, йөрәксез генә барабыз. Чөнки йөрәк бит ул бик сизгер нәрсә. Синең хатыныңның авыру икәнлеген ишеткәч тә, йөрәгем әрнемәсен дип, өйдә калдырдым. Инде, дустым, әгәр синең хәләл җефетеңә минем йөрәгем бик зарури икән, әйдә, борыл, мине өемә илт, йөрәгемне алыйк һәм соңыннан синең өеңә барырбыз, диде маймыл.

Ташбака бу сүзләргә бик сөенде һәм маймылны өенә илтеп куйды. Маймыл шул заман инжир куагына сикереп менеп тә утырды. Исән-сау котылганы өчен тәңре-тәгаләгә мең шөкерләр кылды.

Ташбака бераз көткәннән соң маймылга әйтте: я дустым! Йөрәгеңне алып төш инде, вакытыбыз заяга үтмәсен, диде.

— Әй ташбака! Син бигрәк тә надансың, тәңре-тәгалә мине синең кебек, изгелекнең кадерен белмәгән явыз ниятле бәдбәхеттән, имансыздан коткарды, саклап калды. Әгәр инде мин тагын үземне сиңа ышанып тапшырсам, безнең эшебез ишәк белән төлкенеке шикелле булачак, диде исә, ташбака сорады: ничек булган ул, сөйләең, диде. Маймыл хикәят кылды:

«Бер арысланның бөтен тәнен чуан баскан булган. Шуңар аның көче-куәте китеп, ауга йөрер хәле калмаган, имеш. Арысланның төлке хезмәтчесе бар иде. Ул арысланнан калган кисәкләрне ашап көнен үткәрә иде. Арыслан ауга йөри алмагач, төлкенең ризыгы киселгән, әл-

[1] Әйләнү; үзгәреп тору; йөрәк (гарәп сүзе).

бәттә. Шулай бер көнне төлке арысланга: әй арыслан! Бу авыруыңнан берәр төрле дәва булса кирәк, нигә шуны эзләмисең, дигән. Арыслан әйткән: әй төлке, әгәр дәрманым булса, бу газапларга чыдап, ач ятмас идем. Минем бу авыруымнан ишәкнең колагы белән йөрәген ашарга куштылар, дигән.

Төлке аңа: әгәр рөхсәт бирсәгез, мин сезгә ишәкне табып китерермен, дигән. Биредән ерак түгел болак буенда бер адәм заты һәр көн кәзурлык[1] белән шөгыльләнә. Аның бер ишәге бар. Ул кәзур мәшгуль чакта ишәге болак буенда утлап йөри. Мин ул ишәкне хәйлә белән алып килим. Ләкин минем сезгә бер үтенечем бар торыр: ишәкнең колагы белән йөрәген сез ашарсыз, ә калган итен миңа бирерсез, дигән.

Арыслан төлкенең сүзләренә риза булган. Төлке исә ишәк утлап йөргән җиргә киткән. Ул ерактан ук ишәкне күреп алган, аның янына килеп исәнләшкән, миһербанлык күрсәтеп, аның хәл-әхвәлен сорашканнан соң ишәктән сораган: әй ишәк дус! Син бик арыганга ошыйсың, нигә бик ябыктың?

Ишәк әйткән: хуҗам миңа һич ял бирми, көн-төн мине эшләтеп интектерә, торган саен ашарыма да азрак бирә, дигән.

Төлке аңа: бу кадәр мәхлүк булмасаң, качып китеп, бу җәзадан котылган булыр идең, дигән.

Ишәк әйткән, бер мин генә мондый авыр тормышта яшәмим, бу шәһәрдәге барлык ишәкләрнең язмышы шундый ук, дигән.

Төлке әйткән: әгәр теләгең булса, мин сиңа ярдәм итим, сине бик матур һәм мул ризыгы булган утлауга алып барыйм. Андагы кеби тәмле суны, ләззәтле ризыкларны беркайдан табалмассың, дигән. Әле менә күптән түгел генә шулай бер ата ишәккә анда барырга киңәш иткән идем, хәзер дә булса ул анда тәмле ризыклар ашап, татлы сулар эчеп, бернинди уй-хәсрәтләрсез рәхәттә яши дип ишеттем.

Бу сүзләрдән ишәкнең авызына сулар җыелган һәм ул бик шатланып төлкегә әйткән: әй төлке! Синең бу сүзләреңә, киңәшеңә ышанмый мөмкин түгел, чөнки син моны миңа ихлас күңелеңнән, шәфкатьлелегең йөзеннән әйтәсең, дигән.

Төлке ишәкне туп-туры арыслан янына алып барган.

Арыслан исә аны-моны абайламастан, ач күзләрен акайтып ишәккә ташланган, ләкин ишәкне ега алмаган, ишәк исә качып киткән.

Төлке арысланга: арыслан кадәрле арыслан башыгыз белән шул арык ишәкне генә дә ега алмадыгызмы, дигән.

Төлкенең бу сүзләре арысланга бик авыр тоелган һәм ул күңеленнән уйлап куйган: әгәр инде мин бу төлкегә ишәкне егарлык көчем калмады дисәм, үземнең хәлсезлегемне тану була, дигән. Арыслан төлкегә әйткән: шаһларның эшләгән эшләренең сәбәбен белү сиңа кирәк түгел. Синең мондый сорауны миңа бирүең ул артыграк узынуыңны күрсәтә. Артыгын сөйләп торганчы, син тагын берәр хәйлә табып, ишәкне монда алып кил. Әгәр бу эшне башкарсаң, үзеңнең миңа нисбәтән никадәр дәрәҗәдә фидакарь булуыңны күрсәтерсең, дигән арыслан.

Төлке, урыныннан торып, тагын ишәк янына барган. Ишәк исә аны күрү белән ачуланырга тотынган. Төлке бераз тыңлап торган да ишәккә әйткән: юкка гына рәнҗисең, дустым. Ул — мин сиңа теге вакытта сөйләгән ата ишәк иде бит, сине күрү белән, үзенең хисләрен тыя алмыйча, тизрәк сиңа ташланды, дигән. Әгәр син тынычланып янә аның янына барсаң, ул сиңа үзенең кайнар хисләрен бүләк итәр иде, дигән. Мондый сүзләрдән ишәкнең йөрәге чымырдап куйган. Мескен ишәк, моңарчы арысланны бер тапкыр да күргәне булмаганлыктан, төлкегә ышанып ияреп киткән.

---

[1] Кер юу.

Төлке алданрак барып арысланны кисәтеп куйган, аңа ишәк тәмам якын килмичә, бернәрсә дә эшләмәскә кушкан.

Арыслан исә төлке әйткәнчә эшләгән дә. Ул ишәкне бик яхшылап каршы алган. Ишәк һичнәрсә абайламыйча арысланның алдына ук килеп баскан, арыслан шуны гына көткән дә инде, каты итеп тибеп тә җибәргән. Ишәк бичараның җаны да чыккан. Соңыннан төлкегә арыслан: мин барып елгада су коенып килим, ә син мин килгәнче ишәкне саклап тор. Соңыннан аның колагын һәм йөрәген ашармын, дигән дә китеп барган. Төлке исә арыслан су коенып кайтканчы ишәкнең колагы белән йөрәген ашап та куйган.

Арыслан килеп, ишәкнең йөрәген һәм колагын тапмагач, төлкедән сораган: моның йөрәге һәм колаклары кайда?

Төлке әйткән: әй шаһым! Әгәр бу ишәкнең колагы белән йөрәге булса, ике мәртәбә минем ялганыма ышанып, монда килмәгән булыр иде, дигән.»

— Әй ташбака! Бу хикәяне шуның өчен сөйләдем ки, әгәр кем дә булса ишәк кебек колаксыз һәм йөрәксез булса, әҗәлен тиз табар. Мин дә синең ялганыңа ышанып үземне һәлакәткә дучар итәсем юк, дигән маймыл.

Ташбака әйткән: дөрес сөйлисең, мин дә үз наданлыгым аркасында, явызларның сүзенә ышанып, синең кебек якын дустымны рәнҗеттем, хыянәтче булдым. Инде мин үземнең йөземә мәңгелек кара яктым, аны бернәрсә белән дә юып булмас, дигән дә өенә кайтып киткән.

Кулга кергән дәүләтне саклап кына сарыф итәргә, дусларның кадеренә җитәргә кирәк. Кулдан киткән нәрсәне кире кайтару мөмкин түгел икәнлеген акыл һәм сабырлык ияләре белсеннәр, хикәят иткәннән гыйбрәт алсыннар.

**Фуад Вәлиев,**
сәнгать фәннәре докторы

# БОРЫНГЫ СӘНГАТЕБЕЗ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Сәнгатебезнең борынгы сәхифәләре Идел буе Болгар дәүләтенең элгәрләре булган борынгы бабаларыбызга барып тоташа. Ләкин кемнәр соң алар безнең борынгы бабаларыбыз? Алар — болгар, сувар, берсула, эсегел һ. б. исемнәр белән йөртелгән кабиләләр. Безнең эраның IV йөзендә алар Төньяк Кытай һәм Көньяк Монголия далаларыннан көньяк-көнчыгыш Европа далаларына күчеп, Кавказ, Азов, Кара диңгез буена килеп урнашалар. Тарихта бу чор халыкларның Бөек күченү чоры дип атала.

«Болгар» сүзе, «гун» сүзе кебек үк, бер союзга тупланган күп кабиләләрнең уртак исеме булып тора. Алардан тыш әлеге союз составына кергән һәр кабиләнең үз исеме дә булган. Көнбатышка күченгән чакта гуннар һәм болгарлар Көньяк һәм Көнбатыш Себердә яшәгән фин-угор кабиләләрен дә, Каспий далаларындагы иран телле аланнарны да өлешчә үзләренә ияртәләр.

Гун һәм болгарлар күчмә культурасының нигезе Памир-Алтай, Тянь-Шань тирәләрендәге шактый катлаулы шартларда салына. Ул чорда алар кытай һәм иран те-

ләндә сөйләшүче кабиләләрнең күршесендә яшиләр. Үзәк Азия, Көньяк Себер кабиләләре белән дә элемтәләре була. Шушы чорда ук гун-болгарларның инде үз культуралары, сәнгате формалаша. Ул сәнгатьтә күрше халыкларның йогынтысы сизелә.

Язма һәм археологик чыганаклар безнең эрага кадәр III йөздән алып, безнең эраның I йөзенә кадәрге чор гун-болгар культурасының төп сыйфатларын билгеләр. Ул чорда алар агач кайрысы һәм киез белән капланган күчермә кибиткаларда яшиләр. Ярымтүгәрәк түбәле кибитка ике көпчәкле арбага утыртылган була. Кибитка эчендәге сәкегә дә, идәнгә дә киезләр яисә келәмнәр җәелә. Сәке янындагы стенада еш кына еракка ата торган зур җәя, агачтан ясалган яки тиредән тегелгән ук савыты, камчы, кынылы пычак һәм аркан эленеп торган. Ук савытлары, пычак кынылары бакыр яки көмеш пластинкалар белән бизәлгән. Савыт-саба исә ул чорда тигез төпле шар сыман чүлмәкләрдән һәм кырыйлары тимер пластинкалар белән ныгытылган чүмеч кебек агач савытлардан гыйбарәт. Таш өеп ясалган учак гадәттә кибитканың урта өлешендә, төннек турысында була, учак янына ашау-эчү өчен кыска аяклы өстәл куела. Хуҗа өстендә кытай ефәгеннән яки өйдә сугылган тукымадан тегелгән утыртма якалы күлмәк, күлмәкнең якасы, җиңнәре үсемлек бизәге төшкән орнамент белән чигелгән. Туры тегелгән күлмәк итәге чалбарга кыстырылмый, тышта калдырыла. Чалбар үзе билдән каеш яки йоннан үрелгән бау белән буыла. Каеш очында бизәк төшкән металл каптырма, чалбар балаклары үкчәсез тегелгән йомшак (сафьян) читек балтырына кыстырыла. Гадәти көннәрдә баш киеме кыек бүрек булса, бәйрәмнәрдә яки берәр тантана вакытында башны кызыл тасма белән урый торган булганнар. Сул колакта алтын яки көмеш алка, хәллерәк болгарлар муеннарында көмеш кыршау да йөрткәннәр.

Хатын-кызлар ефәктән тегелгән яисә өйдә тукылган озын буйлы киң итәкле күлмәк кигәннәр, күлмәк изүен шнур белән бәйләп куйганнар. Баш киеме ирләрнеке кебек бүрек яисә маңгай чәчләрен тотып торган кызыл тасма булган. Чәчләрендә көмеш шпилька (инә), муеннарын перламутр, пыяла, алтын йөгертелгән яисә таш мәрҗәннәр белән бизәгәннәр. Кулларында алтын-көмеш йөзекләр, колакларында шулай ук алтын, көмеш, бакыр алкалар булган. Йон штан балаклары читек кунычына яшерелгән. Шунысы кызык: күчмә халыкларны өйрәнүче галимнәр А. Марцеллин, А. Бернштам язып калдырган тормыш-көнкүреш гадәтләре, кием-салым, бизәнү әйберләре Идел буе болгарларында гына түгел, хәтта казан татарларында да саклана килгән.

Гун-болгарларның IV йөз ахырында көньяк-көнчыгыш Европага килеп чыгулары борынгыдан ук шушы төбәктә яшәгән иран телле кабиләләрнең ассимиляцияләнүенә китерә, аларның кайберләре Төньяк Кавказга күчenә, Алания дәүләтен төзи. Шул ук вакытта ишле болгар кабиләләре гуннарны да үз араларында эретә.

VII йөз ахырында бу төбәктә ике кабиләләр берләшмәсе хасил була. Берсе — Каспий буе төркиләрен туплаган Хазар каганаты, икенчесе — Азов буендагы Бөек Болгария, Бөек Болгариянең башкаласы Тамань ярымутравында урнашкан Фанагория шәһәре була. Ул чорда бу дәүләт Днепрдан алып Дон буена, Кубань елгасына кадәрге җирләрне били. Болгарлар Азов, Кара диңгез буе шәһәрләре, Византия, Иран, Кавказ белән политик һәм экономик элемтәдә торалар. Фанагория, Пантикапей, Тану һ. б. шәһәрләр аша алар Византиягә мал-туар, тире, йон, мех һәм авыл хуҗалыгы продукциясе озаталар, шуның бәрабәренә үзләренә шәһәр һөнәрчеләре җитештергән товарлар, корал, савыт-саба, бизәнү әйберләре һәм югары зәвык белән эшләнгән сәнгать әсәрләре китертәләр.

Шулай итеп, болгарлар (суварлар, берсулалар) Урта Иделгә күчеп килгәнче Азов, Кара диңгез, Төньяк Кавказ тирәләрендә яшиләр. IV йөз азагыннан алып 350 ел аралашып яшәү дәверендә аларның культурасына алан кабиләләренең дә, Азов, Кара диңгез буендагы шәһәрләрнең эллинлашкан грек-сарматларның культурасы да, шулай ук Кавказ һәм Иран сәнгате дә байтак йогынты ясый. Алан кабиләләре хәтта болгарларның этносына да күпмедер өлеш кертәләр. Бу йогынтылар металл эшкәртү, ювелирлык, чүлмәк ясауда, бизәнү әйберләрендә һәм орнаментта чагылыш таба.

Азов һәм Төньяк Кавказда яшәү дәверендә болгарлар күчмә тормыштан акрынлап утраклыкка күчәләр, җир эшкәртеп көн күрүче халыклар белән даими аралашу нәтиҗәсендә үзләре дә югары культурага ирешәләр. Бу процесс бигрәк тә Төньяк

Кавказ шәһәрләрендә яшәүче сувар һәм берсула кабиләләрендә көчле бара, чөнки аларның экономик элементләре киң була. Тора-бара һөнәрчелек тә үсеп китә.

Бөек Болгар дәүләте озак яши алмый. VII йөзнең икенче яртысында хазарлардан җиңелгәннән соң, болгарларның бер өлеше буйсына, икенче өлеше Көнбатышка күчеп китә, Дунай буендагы җирләргә барып утыра (675 ел). Хазар дәүләте составына кергән сувар, берсула кабиләләре нәкъ менә шул хазарлар буйсындырган Төньяк Кавказда яшәүче болгарлар була. Алар Каспийның көнбатыш ярыннан алып Төньяк Кавказдагы Дербент шәһәренә хәтле җирләрне биләп торалар. Илнең башкаласы язма чыганакларда Беленджер, Ванандер дип йөртелгән Варачан шәһәре. Чыганакларда шулай ук Чунгарс, Тарки, Хамзин, Семендер шәһәрләре дә искә алына. Сувар һәм берсулаларның бер өлеше һаман әле күчмә тормышта яши. VI йөз уртасына кадәр сувар, берсула, хазарлар хәрби-политик союзда торалар. Соңрак сувар һәм берсула кабиләләре, Азов буе болгарлары кебек үк, 657 елда оешкан Хазар каганаты тарафыннан буйсындырылалар. VIII йөздә бу дәүләт Көнчыгыш Европадагы иң көчле политик берләшмәгә әверелә. Халкының асылын болгар-алан кабиләләре тәшкил итә.

Язма чыганакларда сувар һәм берсула кабиләләрендәге социаль-экономик стройның нинди характерда булуы турыдан-туры әйтелмәсә дә, шул ук чыганаклардан аларның тарханнарын, ханнарын, ак һәм кара халыкка бүленүләрен белеп була. Бу хәл үз чиратында аларның бик иртә утрак тормышка күчүе, җир эшкәртеп, һөнәрчелек, сәүдә белән шөгыльләнүләре, шәһәрләрнең ныгуы, югары катлам феодалларның үз ныгытмаларында яшәве хакында сөйли. Күрше халыкларның монда бер йогынтысы булса, көньяк-көнчыгыш Европаны Кавказ, Иран, Урта Азия белән тоташтыручы мөһим кәрван юлларының сувар-берсула җирләреннән үтүе дә үзенекен итә.

Шул ук язма чыганаклардан күренгәнчә, сувар-берсула кабиләләре җир эшкәртүдән тыш бакчачылык белән дә шөгыльләнәләр. Мәсәлән, Төньяк Дагыстандагы Семендер шәһәре җиләк-җимеш бакчаларында күмелеп утырган, ә шәһәр тирәсендәге кырларда йөзем үстерелгән. Шәһәрдә җәйге эсседә тору өчен корылган киез тирмәләр янында читән үреп ясалган балчык өйләр дә, саман кирпечтән яки бура бурап салынган йортлар да булган дип фараз ителә. Шул ук вакытта сувар, берсула кабиләләренең бер өлеше мал-туар да асраган, күчмә тормыштан да аерылып бетмәгән.

Бу чорда әле әйтеп үтелгән кабиләләрдә мәҗүсилекнең тамыры нык була, шулай да аларга инде ислам, христиан, яһүд дине үтеп керә башлый. Шунысы кызык: сувар-берсулаларның князе бер үк вакытта өч динне тоткан: җомга көнне мөселман мәчетенә барган, шимбәдә яһүдләр белән гыйбадәт кылган, ә ял көнне христиан чиркәвенә йөргән.

721—722 елларда бу төбәккә гарәпләр үтеп керә. Ут һәм кылыч ярдәмендә алар халыкны буйсындырырга керешәләр, шәһәрләр, авыллар җимерелә. Беленджер, Тарку һ. б. шәһәрләр яндырыла, халыкның байтагы әсирлеккә төшерелә һәм ерак илләргә озатыла. Гарәп яулары җирле халыкның күбесен бу тирәләрдән китәргә мәҗбүр итә, кабиләләр тынычрак урыннарга — Урта Иделгә агылалар, яңа тормыш коралар. Соңрак шушы урында Идел Болгариясе үсеп чыга. Сувар, берсулалар Урта Иделгә гарәпләрнең 732 елгы икенче яуларыннан соң да күчеп утыралар, ләкин аларның исеме әл-бәрәнҗәр була. Ягъни Бәрәнҗәр шәһәреннән чыккан халык. Урта Иделгә күчкәндә алар инде ислам динендә булалар. Яңа урынга күчкәч, алар элекке кебек утрак тормыш көйләп җибәрәләр, мәчетләр төзиләр, диварлары нык булган Сувар шәһәрен дә алар сала. Монда да электән килгән һөнәрчелек, нәфис әйберләр эшләү традициясе үсеп китә. Бу һөнәрне алар үзләренең Төньяк Кавказдагы шәһәрләреннән алып киләләр.

Шул ук 732 елда гарәпләр Төньяк Кавказның Терек һәм Кубань елгалары бассейннарындагы утрак тормышлы аланнарга да һөҗүм итәләр. Бу һөҗүмнән соң аланнарның яслар (аслар) дигән төркеме Төньяк һәм Көньяк Донец елгаларының югары агымына күчеп утыралар, яңа урында үзләренең культурасын, сәнгатен, архитектурасын үстерәләр. Яңа авыллар, шәһәрләр, таш ныгытмалар төзиләр. Безгә

аларның Сугров, Шарукань, Балин исемле шәһәрләре булуы билгеле. Ул шәһәрләрне соңрак кыпчаклар яулап ала.

Шул ук елларда яки күпмедер элегрәк Терек белән Кубань елгаларының дала өлешендәге «кара» болгарлар да гарәпләрдән качып киткән булырга тиешләр. Чөнки гарәпләр «кара» болгарларга юлыкмыйча һич тә аланнарга барып җитә алмаслар иде. «Кара» болгарлар — хәзерге балкар халкының ерак бабалары. Бер уңайдан гарәпләр аларны да таркатып узганнар. Аланнардан (аслардан) аермалы буларак, «кара» болгарлар соңрак Урта Иделгә хәтле килеп җитәләр, шунда урнашып калалар. Хәзерге Тәтеш районындагы Олы Тархан каберлеге шуны раслый. Утрак тормышта яшәүче сувар, берсула, бәләнҗәр (шул ук берсула) һәм ярымкүчмә «кара» болгарларның (бәлки эсегелләр дә алар белән килгәндер) VIII йөз урталарында Урта Иделгә килеп чыгуларын шушы тарихи шартлар белән генә аңлатып була.

Әлеге күчү чорында монда инде төрле этноска караган кабиләләр берләшмәсе яши. Шул исәптән кайсы этноска караганлыгы әлегә ачыкланып җитмәгән Имән кискә культурасы кабиләләре дә шушында яшиләр. Бу кабиләләр болгарлар белән элемтәгә керми һәм, күрәсең, башка тарафка күчеп китә. Аларның культура йогынтысы болгарларда чагылыш тапмый.

IX йөзнең икенче яртысы һәм X йөзнең башында бу төбәккә Танкеевка культурасы кабиләләре килеп урнаша. Бу ярымкүчмә тормышта яшәүче төркиләшкән фин-угор һәм угыз-кыпчак теленең берәр диалектында сөйләшкән төрки кабиләләр булырга тиешләр. Чулман-Урал тирәсеннән килгән шушы кабиләләр болгарлар белән этник мөнәсәбәткә керәләр һәм, археологларның әйтүенә караганда, болгар культурасы аларга көчле йогынты ясаган. Шул ук вакытта Танкеевка кабиләләре нишле булу сәбәпле, аларның угыз-кыпчак теле төрки телдә сөйләшүче башка кабиләләр арасында өстенлек алуы да мөмкин.

Болгарларның төньягында һәм көнбатышында җирле фин-угор кабиләләре — марилар (чирмеш), мордвалар яши. Шул ук археологик тикшеренүләр күрсәтүенчә, аларның культурасы болгарларга сизелерлек йогынты ясамаган, киресенчә болгарлар культурасы аларга нык тәэсир итә. Болгарларга аларның бары тик кайбер бизәнү әйберләре генә үтеп керә алган.

Археологик тикшеренүләр X йөз башында Урта Иделдә алан компонентының көчәеп китүен күрсәтәләр. Бу безнең фикерне раслый торган факт, ягъни Идел буе болгарларына соңрак тагын бер төркем качкыннар килеп кушылуы турында сөйли. Әйткәнебезчә, алар X йөз башында хазарлар тар-мар иткән Төньяк Донец һәм Донның югары агымында яшәгән аланнар була. X йөзнең икенче яртысында хазарлар тарафыннан җиңелгән славяннар да шундый ук язмышка дучар ителәләр. X йөз башында Идел Болгариясенә аланнар белән бергә, хазарлар кысрыклавыннан качып, русларның Роменск-Борщевск культурасы кабиләләре дә килеп урнаша. Идел Болгариясенең археологик материаллары арасында бу культураның чүлмәк савытлары булуы нәкъ менә шушының белән аңлатыла. Әлеге славян кабиләләре төрки болгарлар арасында тиз ассимиляцияләнә, йотылып бетә.

Шулай итеп, Идел Болгариясенең этник нигезен сувар, берсула, болгар, эсегел, Төньяк Кавказда яшәп төркиләшкән алан кабиләләре тәшкил итә һәм бу хәл монгол яуларына кадәрге сәнгатьнең, архитектураның, гомумән культураның гаять югары формалары барлыкка килүгә китерә.

Хазар дәүләтенең нигезен тәшкил иткән болгар-алан кабиләләрендә VIII—IX йөзләрдә сыйнфый каршылыклар көчәя — алар утрак тормышка күчеп, феодализм чорына аяк басалар, сәүдә, һөнәрчелек көчәеп китә, төзелеш, архитектура, декоратив-гамәли сәнгать чәчәк ала. Икенче төрле итеп әйтсәк, шушы кабиләләр яшәгән төбәкләрдә Салтау[1] культурасы үсеп чыга һәм үзенең югары ноктасына җитә. Шушы культураны өйрәнүче галим С. А. Плетнева язуынча, «алан компонентын да үзенә күпмедер сыйдырган болгарлар нәкъ менә Салтау культурасына нигез салганнар, ә аның нигезен үз чиратында сармат-алан культурасы тәшкил итә»[2].

Болгар-алан кабиләләре ул вакыт Дон, Төньяк Донец, Кубань, Азов, Төньяк Кав-

---

[1] Харьков шәһәре тирәсендә Верхнее Салтово каберлеген тикшергәндә ачылган культура. Урта гасырларда шушы типтагы культура Көнчыгыш Европа төркиләрендә киң таралган була.
[2] Плетнева С. А. От кочевий к городам. М., 1967, 33 б.

каздагы дала һәм урман катнаш далаларда яшиләр. Хазар дәүләтеннән тыш әлеге культура Дунай буенда (Дунай Болгариясе) һәм Көнчыгыш Тавриядә (Кырым) тарала. Идел Болгариясе бу культураның көнчыгыш чигендә утырган һәм VIII—IX йөзләрдә бу зур территориянең халкы культурасы белән генә түгел, этник составы белән дә бер төрле булган. Дәүләтнең этник нигезен төрки болгарлар һәм төркиләшкән аланнар тәшкил иткән.

Салтау культурасына, шул исәптән Идел Болгариясенә хас үзенчәлекләрне, сармат-алан культурасына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Монда эллинлашкан Азов, Кара диңгез буе шәһәрләренең төзелеш, архитектура, сәнгать өлкәсендәге югары казанышларын, аларның ролен дә исәпкә алырга, шуңа Кавказ һәм Иран йогынтысын да өстәргә кирәк.

Салтау культурасы вәкилләре әкренләп әлеге казанышларны үзләштерә баралар һәм нәтиҗәдә һәр төбәкнең үзенә хас үзенчәлекләре барлыкка килә, бөтен көньяк-көнчыгыш Европага таралган Салтау культурасының җирле вариантлары туа. Бу культура, тикшеренүчеләр М. П. Артамонов һәм С. А. Плетнева әйтүенә караганда, Донның югары агымында яшәгән болгар-аланнар аша полян, северян, вятичи, родимичи кебек Роменск-Борщевск культурасына караган славян кабиләләренә дә сизелерлек йогынты ясый. Бу кабиләләр, билгеле булганча, ул чорда Хазар дәүләтенә буйсындырылганнар. Салтау культурасының йогынтысы славяннарның йорт төзелешендә, бизәнү әйберләрендә чагыла.

Болгар-аланнар таралган гаять зур территориядә Салтау культурасы бер генә төрле булмый. Төрле факторларга карап, этник компонентларның индиелеген, шул исәптән географик үзенчәлекләрне дә исәпкә алсаң, бу культура җиде вариантка бүленә. Болар — Урта Идел, Дагыстан, Азов, Түбән Дон, Югары Дон, Кырым, Дунай буе вариантлары.

Салтау культурасының Урта Идел вариантын тудырган Идел Болгариясендә иң әүвәлге археологик материаллар VIII йөзгә карый. Алар Олы Тархан тибындагы каберлекләрдә чагыла. Бу чорда әле Урта Иделдә Салтау культурасы оешып кына килә. Төньяк Кавказдан шушы төбәккә агылган сувар, берсула, бәрәнҗәрләрнең (шул ук берсулалар), ә X йөз башыннан Салтау культурасының шактый югары формаларына ирешкән утрак болгар-алан кабиләләренең монда килеп утыруы бу культураның Урта Идел вариантына байтак үзенчәлекләр кертә. X йөздә барлыкка килгән Идел Болгариясе шартларында бу культура тагын да үсеп китә һәм тиз арада төбәкнең үз культурасына әверелә. Болгарларның экономикасы, сәүдәсе, җитештерүче көчләренең һәм шәһәрләренең үсеп китүе дә, һөнәрчелекнең, монументаль һәм хәрби архитектураның, декоратив-гамәли сәнгатьнең югары формалары барлыкка килү дә әлеге культура казанышлары дип каралырга хаклы.

Идел буе болгарлары культурасын дәвам иттерүче казан татарлары сәнгате һәм архитектурасының нигезен дә шул ук Салтау культурасы тәшкил итә. Киңрәк планда алганда, Салтау культурасы печенег, половец-кыпчак, башкорт, Алтын Урда татарларына, монголларга, татар-мишәрләргә, касыйм татарларына билгеле түгел, шул ук вакытта бу культураны күпмедер дәрәҗәдә төрки угызларда һәм аларның дәвамы булган халыкларда табарга мөмкин. Салтау культурасы шулай ук чувашларга да билгеле түгел. Алар, безнең фикеребезчә, бу якларга гуннар белән килеп чыгып, Урта Иделгә, Азов һәм Төньяк Кавказ казанында кайнамыйча, андагы культураны үзләштермичә, турыдан-туры, болгарларга хәтле үк килеп утырган булырга тиешләр. Аларда Салтау культурасының булмавын һәм аның урынына спираль мотивлардан торган архаик орнамент комплексының эзләрен, безнең тикшеренүләр күрсәтүенчә, Көнчыгыш Азия сәнгатенең I—V йөзләрендә очратырга була.

Болгарларның Салтау культурасы, бигрәк тә сәнгате борынгы Алания, Төньяк Кавказ халыклары культурасы белән бик нык аваздаш. Бу нәрсә болгарларның керамика сәнгатендә, металл эшкәртүдә, ювелирлык эшендә генә чагылып калмыйча, казан татарлары сәнгатендә дә сизелә һәм бу культураның урта гасырларда Төньяк Кавказда яшәгән халыклар культурасы белән уртак булуы турында сөйли. Әлеге уртаклык шулай ук орнаментта, бизәнү әйберләрендә, кием-салым һ. б. чагылыш таба.

Болгарлар һәм казан татарлары культурасының нигезен тәшкил иткән Салтау культурасы проблемасы бу төбәкнең сәнгать үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм итү белән бергәттән, аларның килеп чыгышын, этногенезын ачыклаганда үзенә күрә бер ачкыч булып тора.

Исмәгыйл Илялов

# ИКЕ ХАТИРӘ

Беренче татар операсы «Сания» уңышлы узганнан соң без: Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши һәм мин — өчәүләп гастрольгә чыгып киттек. Астрахань, Ташкент, Сәмарканд, Актүбә һәм Уфа шәһәрләрендә булдык. Май аенда яңадан Казанга кайттык.

Шул елның (1926) июнь аенда безнең өчебезне Гыйльми Үзәк Рәисе Галимҗан Ибраһимов үзенә чакырды. Башта исәнлек-саулык белән кызыксынды, гастрольләрнең ничек үтүен сорашты. Аннары: «Алдагы планнарыгыз ничек, егетләр?» — диде. Без үзебез уйлаган бер әсәрне атадык. Ә Галимҗан Ибраһимов: «Эшче-крестьяннар турында булса яхшы»,— диде. Без: «Либретто юк бит...» дип акландык.

Әнә шунда безгә Галимҗан Ибраһимов: «Сез Мәҗит Гафуриның «Эшче» поэмасын укып карагыз әле. Бер опера әсәре чыгар дип уйлыйм»,— диде. Без аңа киңәше өчен рәхмәт әйтеп, чыгып киттек. Кайтышлый китап кибетенә кереп, берничә данә «Эшче» поэмасын сатып алдык. Газиз фатирына кайтып, аны кат-кат укыдык. Соңыннан, әгәр дә Мәҗит агай либреттосын язарга алынса, Газиз белән Габәши музыка язачакларын белдерделәр. Бу хакта Галимҗан Ибраһимовка да әйттек.

1926 елның җәендә Казанда телчеләр конференциясе үткәрелде. Аңа Уфадан Мәҗит Гафури да килгән иде. Шул вакытта аннан ризалыгы алып калынды.

Җәй ахырында үпкә авыруы көчәю сәбәпле, Галимҗан Ибраһимов үзе Кырымга китте. Без аның вагонына кереп, соңгы мәртәбә исәнләшеп, күрешеп калдык.

Аның кушуы буенча 1927 елның җәендә безне: Мәҗит Гафури, Газиз Әлмөхәммәтов, Солтан Габәши, Әхәт Хисамов һәм мине Иж тамагы санаториена — икенче татар операсы «Эшче»не язарга җибәрделәр.

Санаторийда безгә аерым йорт бирделәр. Кама буеннан ук. Шунда урнашып, авторлар бик зур дәрт белән эшкә керештеләр. Санаторий җитәкчеләре безгә бөтен шартларны тудырдылар.

Эштән туктаган сәгатьләрдә бик матурлап ял итеп ала идек. Якын-тирә авыллардан яшьләр дә килә иде. Бервакыт Мәҗит ага Гафури барын белгәч, бер көнне мәктәп балалары белән бергә укытучылар да килде. Бакчада бик озак сөйләшеп утырдык. Мәҗит агайның бик күңеле булып калды.

Кыңгыраулы пар атка утыртып якындагы авылга Сабан туена да алып киттеләр безне. Анда бик матур кунак иттеләр, уеннарда катнаштык.

Шулай итеп унбиш көнләп яшәгәннән соң Мәҗит агай либреттоның беренче пәрдәсен тәмамлады да, Уфага кайтып килергә булды. Мин Мәҗит агайны пристаньга озата бардым. Киткәнче ул Газизләргә хат та язды. Миндә ул хатның копиясе саклана. Менә ул хат:

Газиз, Солтан, Әхәт!

Һәркайсыгызга сәлам. Бу сәлам хатын үзегезгә мәгълүм йортта пароход көтеп утырганда язам. Яшь кыз белән Исмәгыйль рәхәтләнеп йоклап яталар (әлбәттә, ике урында), карт кешенең гадәттә йокысы аз булганга күрә, минем күзгә йокы керми әле.

Кичә сезнең озатып калуның матур һәм моңлы тәэсире әле дә күңелдән чыкмый, бәлки ул тәэсир үзем үлгәнче дә күңелдән чыкмас.

Ах, минем шул вакыттагы моңым белән бергә аерылышу хәсрәтен белсәгез иде!..

Күзләрем үземнән рөхсәт сорап тормый берничә тамчы кайнар яшьләрен агызганлыкларын сизми дә калдылар. Үземне аңлап алганнан соң папирос кабыздым.

Рәхмәт шул тәмәкене башлап чыгарган, ягъни ләззәтен белгән кешегә!..

Кичә кич, әлбәттә, күзгә йокы кермәде, баш астындагы мендәрне иң азында егерме-утыз әйләндереп салганмындыр, янган йөрәк салкын бер нәрсә тели, ләкин

аны мендәр әйләндерү генә бирә алмый. Өч-дүрт сәгать йоклый алмый үткән вакыт эчендә. Иж мәгдән сулары санаториясындагы аз гына вакыт эчендә читтән генә карап үткәргән тәэсирләрнең барын да уйлап чыктым, баш бер кино аппаратына әйләнгән кебек булды, һәрберегезнең сүзе һәм үзе тәкрар-тәкрар күз алдында үтте, кайсы ки мин аларны яшерен генә күзләренә карап утыра идем, алар минем күз алдында җанландылар, шуларның матур сурәтләре күз алдына килгәч, күңелсез, чебенле, черкиле, караңгы «кәтү йорты» матур гына булып күренә башлады. Кеше бит ул күңелсез урыннарда күңелле истәлекләрен уйлап янган йөрәген юатучы була.

Исмәгыйль миңа якын иптәш булды, ул салмак кеше, минем кебек йөрәгендә кайнаган уйларын тиз генә чыгарып ташламый, һәрхәлдә ул һәркемгә юлдаш була торган кеше. Минем өчен берничә рәт татлы йокыларын бүлүен күреп үзем дә борчылып беттем.

Кичә сез безне озаткач, әлбәттә, тагын да матур тормыш кору ягын карагансыздыр һәм эшләрегез теләгәннән артык матур булып чыккандыр... Мин шуларның һәммәсен дә уйлап үткәрдем. «Ике җаның булса иде дә», берсе монда булса, икенчесе сезнең белән бергә булсачы!.. дигән уйда булдым.

Кичә минем зур бәхетемә каршы теге авыл укытучылары килде бит, авылда торып, авылда укытып аларның шулай күңелле, йомшак аңлаучан булуларын күреп бик вә бик шатландым. Гомер булса, мин аларга, сезнең аркылы, аерым хат язармын әле.

Санаторий миңа бик күп төрле яктан төрлечә тәэсир калдырды, минем кебек җиңел күңелле кешегә бу тәэсирләрнең һәрберсе матур да... кызык/та...

Газиз, син кайчакта бик уйчан һәм эшчән булып китәсең, шуны Солтанга нык тәэсир иттереп (уйнап) эшләгез инде.

Пароход килә. Хәзергә хушыгыз. Дәвамы киләчәк хатта.

Хөрмәт белән Мәҗит.

14 июль 27 ел.

Калган вакыт эчендә Газиз белән Габәши музыканы язып бетерделәр. Шул елның ноябренда операның беренче пәрдәсе халыкка да күрсәтелде.

Тулысынча опера 1929 елны язылып бетте. Берничә мәртәбә Казанда куелды һәм Мәскәүдә бөтенсоюз күләмендә үткәрелгән милли театрлар олимпиадасында зур яңгыраш алды.

* * *

1932 елның язында мин Мәскәүгә килдем. Газиз Әлмөхәммәтов, Рабига Борнашева, Җәмилә Әдһәмова, Фәйзулла Туишевлар белән концертлар уздырдык. Көзен Мәскәү консерваториясе каршында башкорт бүлеге оештыргач, шунда эшләргә калдым.

Менә шул вакытларда минем Муса белән дуслыгым башланды.

Мин Мусаның Столешников тыкрыгындагы фатирында ул ялгыз чагында да, Әминәгә өйләнгәч тә еш була идем. Без бергәләп мандолинада уйныйбыз, ул минем тормыш белән кызыксына, кайвакыт минем уйнаганны тыңлап тора.

Ә 1940 елның гыйнвареннан мин Татарстан радиокомитетында Җәүдәт Фәйзи белән бергә эшли башладым. Ул елларда Муса Җәлил белән яңадан очраштым. Шагыйрь безнең янга еш кереп йөрде.

Шул елның җәендә без: Галия Кайбицкая, Муса Җәлил һәм мин Кече Дербышки авылына, Җәүдәт Фәйзи янына кунакка бардык. Анда Җәүдәт Фәйзинең туганы Гөлсем Фәйзуллина да бар иде. Шаулашып-гөрләшеп, төрле әңгәмәләр белән чәй эчкәннән соң, бергәләп рәсемгә дә төштек.

1941 елның июнь аенда Муса радиокомитетка «Алтынчәч» операсының либреттосын тотып керде. Исәнлек-саулык сорашканнан соң, минем турыда бик матур сүзләп әйтеп, үзенең китабын бүләк итте. «Исмәгыйль Һилал дуска истәлек» дип язды. Мин ул китапны хәзер Татарстан Дәүләт музеена тапшырдым.

Шәриф Рахманкулов

# ЦИРК КАБЫЗГАН ЙОЛДЫЗЛАР

Цирк сәнгате — бик борынгы һәм үтә халыкчан сәнгать. Моннан нәкъ йөз ел элек, 1883 елның җәендә, вакытлыча төзелгән бинада М. Труцци труппасы Казанда беренче мәртәбә цирк программасы күрсәтә.

Рус цирк сәнгатенә ныклы нигез асылда цирк артистлары һәм цирк тотучы данлыклы бертуган Никитиннар тарафыннан салына. 1870—1880 елларда Мәскәү, Саратов, Пенза, Иваново, Киев, Астрахань, Баку кебек шәһәрләрдә цирк бинalары төзеткән шушы Никитиннар 1890 елда, махсус бина салдырып, Казанда да цирк сәнгатенә киң юл ачып җибәрәләр.

Революциядән соң Никитиннар циркы дәүләт карамагына күчә. Шактый какшый, искерә башлаган бу бина урынына 1928 елда, җәйге сезонга яраклаштырып, яңа бина салына һәм аңа ТАССРның сигез еллыгы исеме бирелә. Янәдән 1932 елда бина реконструкцияләнә, кышкы шартларда да эшләрлек хәлгә китерелеп, яңадан төзелә.

Цирк сәнгатенең татар тамашачылары булса да, татарлар арасыннан күтәрелгән цирк артистлары булмый диярлек. Дөрес, рус цирк сәнгате тарихында милләтләре белән татар булган ике исем бар. Аның берсе, үзенең иҗат юлын цирк манежында башлап, соңыннан премьер-концертант буларак даны Россия күләменә таралган мәшһүр Ф. К. Туишев[1] булса, икенчесе — Чарли Чаплин маскасында палас клоуны жанрында танылган, юморы, манежда үзен яраттыра алуы белән дан казанган, союз аренасына күтәрелгән һәм цирк артистларыннан беренче булып Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән атаклы Х. Г. Мусин.

Утызынчы елларда Казан циркы манежында татар телендә сөйләшүче парлы татар шамакайлары булдырылып, алар уңышлы гына эшләп килсәләр дә, кызганычка каршы, алар чит төбәкләрдә чыгышлар ясый алмыйлар, мәйдан тарлыгы аркасында дуэт таркала, Фәйзи Йосыпов эстрадага күчә, Кәрим Мортазин административ эшкә китә.

Менә шушы ике-өч бөртек татар артистларының фәкать берсе генә, Хәсән Мусин гына цирк сәнгатенә турылыклы булып кала, манеждан аерылмый, ялга чыкканда да үзенә алмаш әзерләп, үз юлына цирк һәм эстрада сәнгатенең дәүләт училищесын тәмамлаган улын бастыра.

Казан циркының хәзерге яңа бинасы төзелү белән, алга аның махсус үз труппасын булдыру мәсьәләсе килеп баса, һәм аңа әзерлек тә башлана. Тиздән цирк студиясе оештырыла һәм аңа кабул итү буенча конкурс игълан ителә. Мәскәүдән И. Вавилова, К. Кох, А. Маншилина, Б. Аберт, И. Девяткин, И. Кантемиров, А. Нелипович, Г. Нестеров, В. Фаертах һ. б. танылган цирк сәнгате белгечләре, педагог-режиссерлар чакырыла. Татар цирк коллективына сәләтле, талантлы көчләр сайлау нияте белән оештырылган бу конкурс 1969 елның җәендә була. Анда биш йөзгә якын яшьләр катнаша. Ул сан өченче турдан соң утыз ике кешегә кала.

[1] Файзулла Кабир улы Туишев (1884—1958) төрле (шырпы тартмасы зурлыгыннан алып баянга хәтле) гармуннары белән манежга күтәрелә. Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә танылa.

Шушы утыз икенең барысы да диярлек — цирк сәнгатеннән ерак торган, таныш булмаган, таныш булганнарының да танышлыклары цирк тамашасын караудан узмаган төрле сәнгать түгәрәкләреннән, спорт секцияләреннән килгән һәвәскәрләр. Бу егетләр белән кызларны артист итеп хәзерләү, билгеле, җиңел булмый. Режиссер-педагогларга зур көч куярга, шактый тир түгәргә туры килә, һәм аларның вакыт-вакыт күңелләре кайткан, хафаланган чаклары да була. һәм өйрәнүне цирк сәнгатенең әлифбасы булган гап-гади акробатик, пластик күнегүләрдән башларга мәҗбүр булалар. Бу үзе күп көннәрне, шактый вакытны ала. Шулай да, көнне-төнне белми күнегүләр ясау, бөтен көчне һәм сәләтне биреп өйрәнү нәтиҗәсендә цирк сәнгатенең аерым жанрлары үзләштерелә. Әгәр дә, составка чакырылган өч профессионал артистны, цирк һәм эстрада сәнгатенең дәүләт училищесын тәмамлап манежга баскан эквилибрист Роза Хәсәенова, гимнаст Зинаида Васильева һәм палас шамакае Алик Низаметдиновларны искә алмасак, татар цирк коллективы асылда әнә шул һәвәскәрләрдән туа.

Татар цирк коллективы — автономияле республикалар арасында беренче булып манежга баскан һәм иҗат юлын 1970 елның 23 июнендә, Татарстан республикасының 50 еллыгы көнендә башлап җибәргән беренче милли коллектив. Казанлыларга коллектив үзенең программасын 1967 елда ачылган, хәзерге заман таләпләренә җавап бирерлек техника белән җиһазландырылган яңа бинада күрсәтә башлый. Шулай итеп мәһабәт цирк бинасы салыну белән бергә цирк сәнгатенең яңа иҗат коллективы, милли труппасы барлыкка килә. Казандагы дебютыннан соң коллектив цирк артистлары тормышы белән яшәүгә күчә, шәһәрдән шәһәргә күчеп хезмәт итә башлый.

Шушы кыска вакыт эчендә коллектив утызга якын шәһәрдә булырга өлгерде. Татар цирк коллективының тамашаларын Ташкент, Алма-Ата, Тбилиси, Ереван, Севастополь, Волгоград, Ульяновск, Курган, Пенза, Тула, Горький кебек шәһәрләрдә яратып алкышладылар. Составы фәкать комсомол яшендәге кызлар белән егетләрдән һәм асылда татарлардан гына торган бу коллектив меңләгән совет тамашачылары алдында иҗат имтиханы тотып, үзенең башкару осталыгы белән дә, югары художестволылыкка ирешә алуы белән дә өлгергәнлеген таныта алды. Моны коллективның уңышлы чыгышлары һәм ул чыгышларга язылган күп санлы рецензияләрдәге хаклы әйтелгән мактау сүзләре белән раслап була. Җыеп кына әйткәндә, коллектив профессиональ яктан ныгыды, номерларының идея-художество дәрәҗәсе сизелерлек күтәрелде. Союзгосцирк җитәкчелеге тарафыннан бирелгән характеристикадагы сүзләр белән әйтсәк, «кайсы гына төбәккә җибәрсәң дә, һәрьяклап үзен акларлык коллективка әверелде. Татар цирк коллективы составында һәм аннан тыш эшләүче татар артистлары арасында хәзер инде үз илебездә генә түгел, ә чит илләр тамашачылары алдында да йөзгә кызыллык китерми торган, танылган цирк сәнгате осталары җитеште».

Бу турыда сүзне Берлинда үткәрелгән конкурста югары эстрада-цирк бүләген алуга ирешкән, цирк артистларының бөтенсоюз смотры лауреатлары, Татарстан республикасының атказанган артистлары Рамазан Абдикеев белән Замир Мостафиннардан башлыйк.

Замир тимер юл техникумын тәмамлап алган профессиясе белән генә канәгатьләнми, ул цирк сәнгатенә омтыла. Цирк һәм эстрада сәнгатенең дәүләт училищесына укырга керә. Училищены тәмамлаганнан соң ул Франциягә гастрольгә җибәрелә.

Ә бу вакытта Рамазан Астрахань циркында униформист[1] булып эшли, укырга берничә еллар эшләгәч кенә керә. Училищены тәмамлап чыккач, башта клоун Анатолий Шерманның партнеры, аннан берничә ел турник гимнастлары группасында катнаша. Менә шушы, берсе авыл, икенчесе шәһәр егете 1974 елда очрашалар һәм иҗади дуэт, клоун дуэты барлыкка килә.

Р. Абдикеев һәм З. Мостафиннар клоунлык жанрында искерә башлаган әзер юлдан китмиләр. Киресенчә, алар үз юлларын табарга, реприз һәм интермедияләрдә үз темаларын булдырырга омтылалар. Хәтта алар бу жанрга хас, кайчандыр мәҗбүр саналган физик контрастлыкны файдаланудан да, тышкы антиподны үзмаксат итеп алудан да баш тарталар.

Хисләренең ихласлыгы, көлкеле хәрәкәтләр табудагы тапкырлыклары, зирәклек-

[1] Униформист — тамаша һәм репетиция вакытларында цирк артистына хезмәт күрсәтүче.

ләре һәм сәләтләре белән аерылып торган бу дуэт күптән инде, цирк тамашачыларының җылы мәхәббәтен яулап алды һәм үз жанрларында искиткеч осталыклары белән алгы планга, беренчеләр рәтенә басты. Бу палас клоуннарының иҗат алымнары турында цирк сәнгатенең белгечләре югары бәя биреп, әледән-әле үзәк матбугат битләрендә үзләренең күләмле мәкаләләре белән чыгыш ясап торалар.

Рамазан белән Замир татар цирк коллективы составында түгел. Дөрес, алар Татарстанның 60 еллыгына багышланган программада катнашу өчен Казанга чакырылдылар һәм программаның сыйфатын күтәрүдә, эчтәлеген баетуда үзләреннән зур өлеш керттеләр. Әмма алар бөтенләйгә коллективта кала алмадылар, моңа аларның бик еш Мәскәү цирклары программаларында катнашулары, әледән-әле чит илләргә гастрольләргә барулары сәбәп булды, ахрысы. Шулай итеп, Замир белән Рамазанның исеме совет цирк тамашачылары өчен бик якын һәм дә хөрмәт ителгән исемнәргә әверелде. ГДР, Польша, Дания, Франция кебек илләрдәге тамашачылар да бу ике артистның чыгышларын ихластан алкышладылар. Клоунада цирк сәнгатендә иң авыр жанрлардан санала. Үзәк матбугатта басылган, цирк сәнгате белгече Н. Кривенко мәкаләсендә Замир белән Рамазан адресына төбәп: «Үзләренең профессионал осталыкка ирешкәнлекләрен раслый алалармы?» — дигән сымак сорау куя да, шунда ук «Әйе, алалар!» — дип җавап та бирә[1]. Әйе, З. Мостафин белән Р. Абдикеев номерларының үткен һәм реаль эчтәлеккә корылулары белән танылган клоуннар рәтенә күтәрелделәр.

Татарстан республикасының атказанган артисты дигән мактаулы исем татар цирк коллективы артистларыннан беренче булып Роза Хөсәенова белән Зинаида Васильевага бирелә. Тимер чыбык өстендә биюче Роза да, акробат Зинаида да — югары башкару осталыгына ирешкән манеж осталары. Алар үзләрен тиз таныталар һәм, кайда гына чыгыш ясамасыннар, һәр чак тамашачыларның җылы һәм югары бәясен алалар. Ихтыяр көченә ия булган Зинаида Васильева чыгышлары табигый җитезлек һәм нәфислеге белән аерылып тора. Роза Хөсәенова исә чын мәгънәсендә үз профессиясенең остасы дәрәҗәсенә күтәрелгән артистка. Сәләтлелеге һәм үзенә булган искиткеч таләпчәнлеге аркасында ул — талантын бөек сәнгать бурычларына буйсындыра алган артисткаларның берсе.

Тимер чыбык өстендәге эквилибрлыкта үзен танытып өлгергән Розаның биографиясе гади һәм бик кыска. Ул унике яшеннән цирк сәнгате белән кызыксына башлый. Квартиралары иске цирк бинасы янында булганлыктан, ул һәр яңа килгән труппа чыгышларын карап бара һәм цирк артистлары белән танышып ала. Аңа укырга, цирк сәнгате училищесына керергә киңәш итәләр. Кыз киңәшне шатланып кабул итә һәм озакка сузмый гариза белән документларын Мәскәүгә җибәрә. Ләкин аны кабул итмиләр. Вакытны әрәм үткәрми ул, татар опера һәм балет театрының хореография студиясенә укырга керә, аны тәмамлап, сәхнәгә күтәрелә.

Шул елларда Казан циркына танылган цирк артисткасы, тимер чыбык өстендә биюче Вера Сарбинаның килүе һәм аның чыгышы Розаны сихерли. Ул тагы бәхетен сынап карарга була, документларын Мәскәүгә җибәрә. Бу юлы шатлыклы хәбәр килә.

Шулай итеп, Роза цирк һәм эстрада сәнгатенең дәүләт училищесын 1966 елда уңышлы тәмамлап, эквилибристка буларак тимер чыбык өстенә баса. Күптән таныш трюклар һәм хәрәкәтләрдән торган беренче номеры Розаны канәгатьләндереп бетерми. Ул уйлана, эзләнә, һәм, биш ел дигәндә, Роза Хөсәенова тамашачы алдына яңа номер, милли стильдә иҗат ителгән «Шүрәле» балеты музыкаларына корылган номер белән чыга. Ул үзенең Казанда алган хореографик белемен яңа профессиясенә органик бәйләп оста берләштерә алуга ирешә.

Менә пәрдә ике якка ачыла, манежга зифа буйлы кыз килеп керә. Артистка «Шүрәле» балетындагы әкият-кош Сөембикә образында. Билгеле, алты минутка исәпләнгән номерда балетның сюжетын тулысы белән гәүдәләндерү мөмкин нәрсә түгел, һәм артистка үз алдына андый максат та куймый. Роза өч бию музыкасын ала. Шул өч бию белән Роза Хөсәенова тимер чыбык өстендә балетның төп идея юнәлешен, ягъни мәкерле, явыз көчләрдән кеше ихтыяры һәм акылының өстенлеген чагылдыра алуга ирешә. Биюендәге милли колоритка корылган хәрәкәтләре музыкага авваздаш килеп, органик бәйләнештә биреләләр.

---

[1] «Совет циркы һәм эстрадасы», 1977 ел, № 1, «Замир белән Рамазан дуэтлары».

Роза Хөсәенованың бу номеры үзәк прессада югары бәяләнде. РСФСРның атказанган артисткасы, мәшһүр Клара Кох «Совет циркы һәм эстрадасы» журналында (1971 ел, № 6) болай дип язды: «Хөсәенова, музыканы һәм ритмны тоюдагы нечкәлеге, биюендәге гүзәллегенең искиткечлеге белән тамашачыларны да һәм үз коллегаларын да гашыйк итә. Ул башкарган барлык биюләр музыкадагы ритмнар белән акцентларга төгәл үрелеп баралар. Шулай ук тимер чыбыкта музыка тактына баш өстендә әйләнеш ясап, веерсыз һәм балanссыз тиз генә узып китү дә — бик авыр трюк... Күңелне үзенә тартып торган һәм артистлык сыйфатларының дәрәслеге Роза Хөсәенованың уңышын тагы да куәтли, арттыра төшәләр».

Шул ук журналның 1976 елгы 7 санында басылган мәкаләсендә Л. Булгак Розаның бу номерына тәфсилле анализ ясый һәм аны цирк сәнгатендә иҗади ачыш дип атый: «Роза Хөсәенованың тимер чыбык өстендәге хезмәте экспериментлар ясау, яңа эчтәлек һәм образлылык таба алу мөмкинлекләрен күрсәтте. Ул тимер чыбык өстендә кечерәк пьесалар, кечерәк драмалар уйнау, тимер чыбык өстендә бер актер театры булдыру мөмкинлекләрен ачты».

Әйе, Роза Хөсәенова үз һөнәре техникасын барлык нечкәлекләре белән үзләштергән совет циркы сәнгатенең танылган мастерына әйләнде.

Роза Хөсәенованың чыгышын Һиндстанның атаклы киноартисты һәм режиссеры Радж Капур күрә һәм цирк сәнгате осталары турында төшерәчәк картинасында катнашырга тәкъдим ясый. Шулай итеп, татар кызы Роза Хөсәенова бөтен дөньяга танылган мәшһүр цирк сәнгатенең осталары рәтендә экранга алына. Аның буш вакыты юк. Көндез репетиция, кич манеж. Үзе театр сәнгатенең дәүләт институты студенткасы. Шул институтның режиссура факультетын тәмамлап, тагын бер сәнгать һөнәренә ия булды.

Роза Испаниядә коррида уеннарын карый. Аңа тореадор, пикадор һәм матадор гәүдәләренең скульптурлыгы, алардагы кыюлык ошый. Һәм, уйлана, эзләнә торгач, аның хыялы менә шушы уенга килеп кушыла: «Әгәр дә коррида уенын тимер чыбык өстенә алып менсәм?» Шунда ук үз хыялына үзе каршы төшеп: «Булмас. Бернично башкаручы сорый торган уен. Дөрес, ул кеше түгел, ике: тореадор һәм үгез... Шулай да...»

Чынында ике тереклек иясенең хәтәр бәрелешен цирк сәнгате чаралары белән, җитмәсә, тимер чыбык өстендә бирү җиңел эш түгел. Аннан соң тимер чыбык өстендә тигезлек саклауның авырлыгын да онытырга ярамый. Менә шундый кыен шартта капма-каршы ике образ тудыру, икегә әверелү, ике формага керү... Билгеле, тореадорны гәүдәләндерү кыен булмас, характеры — ирлек, батырлык, профессиясенең шарты — куркуны белмәү, кыю йөрәкле һәм «башсыз» булу. Ә үгез? Тышкы якларын бирү генә түгел, һәр икесенең үз эчтәлеген, мәгънәләрен, максатларын да табарга һәм шуларны тимер чыбык өстендә күрсәтергә кирәк...

Һәм менә репетицияләр башлана. Яңа номер кош-кыз Сөембикәдән соң нәкъ җиде ел узгач тамашачыга күрсәтелә.

Кош-кыз Сөембикә номерын караганнан соң, Розаның бу экспериментына хәйран калып, тимер чыбык өстендә «бер артист театры» тудыруга юл күрсәтте дип чыккан цирк сәнгате белгече Л. Булгак коррида номерына карата язылган соңгы мәкаләсендә үзенең күрәзәлелегенең тормышка ашуын әйтә.

Роза Хөсәенова кайчандыр: «...Минем тимер чыбыгым — тормыш юлым. Аның өстеннән чайкалмый гына тигез йөреп китә алырмын микән?..» дигән сыман сүз дә әйткән иде. Йөреп китү генә түгел, ул бу «Сират күпере» өстендә бер артист театры булдыруга да иреште.

Менә манежга, жанры художник-моменталист дип исемләнгән, артист Илгизәр Зарипов килеп чыга. Өстендә күе кызгылт, кура җиләге төсендәге блуза, «дудочка» дип аталган тар балаклы чалбар. Манежга ул ниндидер ягымлы кызулык белән килеп керә һәм шунда ук эшкә дә керешә. «Корбаннарын» сайларга вакыт юк, күзенә чалынган тамашачылары алдына килеп баса. Беренчесенә, аннан икенчесенә, өченчесенә, алтынчысына... Шулай йөреп моңа кадәр бер кайчан да күрмәгән кешеләрнең күз төшереп алырга гына өлгергән кыяфәтләрен зур тизлек белән ясый да куя. Артистның күз ачып йомганчы охшатып ясый алу осталыгына тамашачы хәйран кала,

канәгатьләнү белән елмая һәм шатлыгыннан кул чабарга тотына. Артист осталыгына зал гөр килә.

Илгизәрдә кеше йөзендәге сыйфатларны тиз тотып ала белү сәләте зур, һәм артистның күз хәтере көчле, кулы җитез. Ул цирк сәнгатенә фанатикларча бирелгән зат. Илгизәр бала чакта ук, беренче тапкыр әнисе белән цирк тамашасына барган көнне ук цирк уеннарына гашыйк булып кайта. Һәм шул көннән алып Казан циркының даими тамашачысына әйләнә. Күргән уеннарын булдыра алганча өйдә үзе дә ясап карый. Нәтиҗәдә бу шашыну аны цирк һәм эстрада сәнгатенең дәүләт училищесына, клоунада бүлегенә алып килә.

Керү имтиханнарын уңышлы биреп, укый башлавына ике ай дигәндә тренировка вакытында кулын һәм умрау сөяген сындыра. Өмете киселгән Илгизәр кире Казанга, өенә кайта. Шушы хәлдә булуына карамастан, цирктан аерылырга уйламый, башка юл калмагач, циркка дворник булып урнаша. Берничә айдан өлкән униформист Володя Анисимов ярдәме белән Илгизәр униформистлыкка күчерелә.

Володя Илгизәрдәге өметне сүрелдерми, киресенчә, аның киләчәккә булган ышанычын тагы да куәтләп һәр даим булыша, тора-бара буш вакытларында алар икәүләп цирк сәнгатенең кайбер жанрларындагы уеннарны өйрәнергә тотыналар. Казан циркының ике униформисты, ике дус бер көнне артист буларак манежга басалар. Илгизәр — художник-моменталист, ә Владимир Анисимов өйрәтелгән песиләр белән.

Цирк сәнгатендә йорт песие белән манежга чыгу алтмышынчы елларда күренә башлый. Песи белән манежга беренче булып Хәсән Мусинның улы, РСФСРның атказанган артисты Валерий Мусин чыга. Аның песи белән манежга чыгуы фәкать шаяру дип кенә карала. Ә менә артист Юрий Куклачев йорт песиләренең сәләтләрен ачып, аларның артистлык хезмәтенә яраклы җәнлекләр икәнен исбатлап күрсәтә һәм аларның «авторитетын» күтәрә.

Шулай итеп, Владимир Анисимов йорт песиләрен өйрәтергә тотына. Аның бу эшендә, РСФСРның атказанган артисты Александр Поповның ассистенты булып эшләгәндә алган практик тәҗрибәләре дә, Монголия дрессировщигы Церендорш белән очрашу һәм аның алымнары белән танышуы да Анисимовның хезмәтен билгеле бер дәрәҗәдә җиңеләйтә төшәләр. Зур түземлелек белән, озак вакытлардан соң Владимир Анисимов уңышлы нәтиҗәгә ирешә һәм татар цирк коллективы составында артист сыйфатында тамашачылар алдына чыга.

Бер карагандa манежда гади йорт песиләрен күрү сөер дә кебек. Цирк тамашачыларын арыслан, юлбарыс, пантера, каплан, аю кебек ерткычларны күрү бер дә гаҗәпләндерми, аларга өйрәнелгән, күнегелгән. Ә песиләр уены — моңарчы булмаган, күнегелмәгән тамаша. Хәер, песиләр дә бит шул ерткыч җанварлар токымыннан. Әгәр дә песи сүзенең мәгънәсен япон теленнән тәрҗемә итеп аңлатсак, ул «үч төбеннән ашаучы юлбарыс» булып чыга.

Булмаганны булдыру В. Анисимовка бик авырлык белән бирелә. Песиләрнең дә бит һәркайсысының үз гадәте, үз акылы... Мәсәлән, Анисимов песиләреннән Катя исемлесе флегматик, ягъни авыр табигатьле, бик сүлпән, Мишкасы — кыю, батыр йөрәкле, күзенә чалынганны эләктереп алырга гына тора, Барсик — бик тә иркә, Сильва — артык интеллигентка, Меркуция — фантазер, фараз итәргә яратучан...

Песиләр еш авыручан булалар. Дрессировщикка фельдшерлык белемен дә үзләштерергә, аларны белеп дәваларга, укол ясарга да туры килә. Билгеле, кыргый җанварларны өйрәтү кебек үк, песиләрне дә «артист» итү җиңел түгел. Озак елларга сузыла һәм гадәттән тыш түземлелек таләп итә торган авыр хезмәт ул.

Артист Владимир Анисимов тарафыннан бу эшкә зур көч салынса да, аның песиләренең «артистлыгы» тамашачыларны хәйран калдырса да, әле яңа күнегүләр, яңа ачышлар алда. Ирешелгән кадәресе дә моңа өметле ышаныч тудыра. Тик тәвәккәллек белән зур түземлелек һәм вакыт кына кирәк.

Татарстанның атказанган артисты Габделхак Гыйбадуллин да «аңгыра» дип исәпләнгән йорт хайваннарын манежга алып чыга. Габделхак бала чагыннан ук хайваннарны ярата. Колхозның ат абзарларында әнисенә атлар карарга булыша, әтисе белән колхоз көтүен көтә. Гел табигать эчендә, мал-туар тирәсендә була. Йорт хайваннарына булган мәхәббәте балалык елларында ук башлана, ә инде үсмерлек яшендә бу мәхәббәт аның профессиясенә әверелә.

Бөтен күңелен, осталыгын биреп, ул йорт хайваннарын өйрәтергә тотына. СССР халык артистлары Ирина Бугримова белән Валентин Филатов һәм башка атаклы хайван өйрәтүчеләрнең чыгышларын күзәтә, сәгатьләр, көннәр буе аларның репетицияләрендә утыра, сораша, кызыксына, алымнарын өйрәнә. Төннәр буе хайваннар турындагы махсус әдәбиятны укый.

Әлбәттә, хайваннарның «телен» аңлау, холык-фигыльләренә төшенү болар белән генә чикләнми, Габделхак «артистлары» белән уртак тел табуга, аларны буйсындыра алу серләренә ирешүгә озак еллар сарыф итә. Эше белән канәгать булмаган көннәре, төшенкелеккә бирелгән минутлары да була. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар»,— ди халык. Габделхак Гыйбадуллин да зур түземлелек белән теләгенә ирешә, үзенең «артистларын» «акылга» утырта. Иң әүвәл ул манежга дуңгыз балалары, шаян мәче һәм кире беткән ишәге белән чыга. Аның труппа составына кәҗә белән әтәч өстәлә, аннары каз, эт, сыер һәм, тамашачыны таңга калдырып, күседән дә артист ясый...

Г. Гыйбадуллин «артистларының» чыгышлары коры өйрәтүдән генә тормый, ул хайваннарның һөнәрләрен органик төстә катлаулы комик хәлләргә бәйләп алып бара. Аның тапкырлыгының бу ягына цирк училищесында укыганда атаклы М. Румянцев (Карандаш) һәм Ю. Никулиннар белән бергә эшләп алуның йогынтысы тигән булса кирәк. Нәтиҗәдә ул хайваннарыннан кызыклы трюклар ясата алуга ирешә.

Бу яшь клоунның (училищеда ул клоунада бүлеген тәмамлый) осталыгы тагын тамашачы белән тиз аралашып китеп, аларның ышанычын яулап ала белүендә. Аның һәр хәрәкәте карап утыручыларның дикъкатен җәлеп итәрлек дәрәҗәдә төгәл һәм акыл белән эшләнгән.

Габделхак Гыйбадуллинның «артистлары» цирк манежы белән генә чикләнми, экранга да алыналар, кино артисты буларак та танылалар. «Шаян» кушаматлы песи «Хезмәт урынындагы гашыйк» исемендәге фильмда, ә «Белок» кушаматлы кәҗәсе «Петр Беренче ничек үзенең гарәбен өйләндерә?» картинасында катнашалар. Цирк сәнгатендә хәзергә бердәнбер саналган бу аттракционның чыгышы һәр шәһәрдә зур уңыш казана, тамашачының җылы мәхәббәтен яулап ала. Мичкәләр өстендә кызыклы акробатик номерлар ясаучы, ТАССРның атказанган артистлары, ирле-хатынлы Әлфия белән Илдар Рәхмәтуллиннар да — өлгереп җиткән манеж осталары. Гаҗәеп җитезлек һәм гүзәллек белән мичкәдән-мичкәгә сикерә-сикерә югарыга менүләре бик тә җылы тәэсир калдыра. Кайчандыр бу жанрда И. Вавилова белән В. Фаертах тамашачыларны таңга калдырган булсалар, хәзер инде ул трюкларны аларның укучылары булган Рәхмәтуллиннар искиткеч осталык белән башкаралар. Бу механик төстә күчерелгән номер гына түгел, ә яшьләр номерга үз хыялларын салганнар, аны кечкенә генә үзенчәлекле акробатик-драматик күренешләр өстәп баеткannar. Нәтиҗәдә — номер тамашачыларны сокландыра һәм ул өзлексез алкышлар астында бара.

Акробат-эксцентриклардан Р. Асанов белән В. Котникова чыгышлары да, аеруча сәгатьләр белән булган мәзәкчән уеннары, һава гимнасты Ринат Әхмәтҗанов чыгышы, ТАССРның халык артисты Дамир Гыйбадуллинның жонглерлык итүе һәм төрле предметларны чөеп уйнаучы Валентин Деев җитәкчелегендәге акробатик ансамбль чыгышы да катлаулы һәм тамашачыларны кызыксындырырлык элементлардан тора. Татарстанның атказанган артистларыннан Николай Козыльскийның гимнастик күнегүләре, Марат Шаһиевның тәлинкә аулау номерлары да кызыксынып караланар. Палас шамакайларыннан Алик Низаметдинов белән Илдар Хаҗиевлар да күңелле тәэсир калдыра.

Татарстанның атказанган артистлары Раиса белән Грант Ибраһимовларның — аюлар, Р. Хисаметдинованың этләр белән чыгуы цирк тамашачылары өчен күптәннән таныш һәм күпмедер гадәтләнгән, ияләнелгән номерлар булса да, мәзәк күренешләре белән кызыклылар.

Ш. Хәйретдинов белән И. Бәдретдиновларның атлетик номерлары да матур тәэсир калдыра. Әгәр дә бераз милли колорит та өстәлсә, номерның уңышы тагын да арта төшәр иде.

Менә шулай татар сәнгате дөньясында тагы бер художество коллективы барлыкка килә. Ләкин, үзен танытып өлгергән, тамашачы алдында уңыш казанган, тулы хокук белән Союз аренасына баскан милли цирк коллективының вакыты-вакыты белән

кыенлыклар алдында калгалавы һәм аңа алдан хәзерлек күрелмәве бик тә аяныч. Кайбер номерларның вакытлыча яки бөтенләйгә икенче коллективка күчерелүе коллективның ансамбльлегенә, программаның бөтенлегенә кире тәэсир ясый. Цирк сәнгатендә дублерлык булмаганлыктан, сыналган, тамашачы күңеленә хуш килгән кайбер номерлар программадан төшеп калырга мәҗбүр булалар. Алар урынына алмашка кертелгән номерлар, билгеле, җиңел һәм тиз генә өлгерә алмый.

Югарыда әйтелгәннәргә табигать үзе таләп иткән кыенлыклар — цирк сәнгате өчен табигый яшьлек мәҗбүри таләп булуы да өстәлә. Цирк сәнгатендә артистлар тиз «картаялар». Бу — хакыйкать. Димәк, коллектив даими төстә яшьләр хисабына өстәлеп, яңартылып торырга тиеш. А. В. Луначарский сүзләре белән әйткәндә, цирк сәнгате — «үткен акыллылык һәм физик гүзәллек академиясе» ул. Шулай булгач, коллектив яшьлек кысасыннан чыкмаска, гел яшәреп торырга тиеш. Алмаш кадрлар хәзерләү, труппаны әледән-әле яшьләр хисабына тулыландырып тору — төп бурычларның берсе һәм иң әһәмиятлесе.

Татар артистларын без төрле коллектив составларында очратабыз. Мәсәлән, 1983 елга кергәндә күрсәтелгән беренче Мәскәү циркының бәйрәм программасында да татар артистлары катнаштылар. Бу программада З. Мостафин белән Р. Абдикеевлардан гайре тагы ике яңа исемгә тап булдык. Аның берсе — чын мәгънәсендә физик гүзәллек тантанасы булган Рәшит Камалетдинов җитәкчелегендәге акробатик ансамбль чыгышы, икенчесе — искиткеч тәэсир калдырган Фәрит Якуповның ат, эт һәм маймыллардан торган аттракционы. Шулай ук «Боз өстендәге цирк» труппаларында ике татар егете бар. Хәзер инде аларның икесе дә РСФСРның атказанган артистлары. Берсе — гайрәтле солдат Швейк маскасындагы боз өсте клоуны З. Шакиров, икенчесе — Ф. Сәфәргалиев — ике төр спорт (фигуралы шуу һәм акробатика) мастеры һәм цирк гөмбәзе астында зур тизлек белән әйләнеп йөрүче аппарат өстендә партнеры Е. Рамазанова белән бик тә катлаулы һәм гаҗәп авыр трюклар ясаучы һава гимнасты. Икенче бер коллективта баш өстендәге бөҗра эчендә төрле гимнастик трюклар ясаучы Лилия Шварцның партнеры, эквилибрист Каюм Хәйретдинов бар. Исемлекне озынга сузмый, тагы бер генә исемне, тормышын цирк сәнгатенә багышлаган һәм цирк манежындагы татарлардан беренче булып СССР халык артисты исеменә лаек булган Хәким Зарипов исемен күрсәтү белән чикләнү дә җитә.

Безнеңчә, цирк һәм эстрада сәнгате училищесына даими рәвештә укучылар җибәреп торылса, милли цирк коллективын башка бригадаларда эшләүче милли кадрлар тулыландырып торганда, эш нәтиҗәләрәк тә, уңышлырак та булыр иде.

# СҮЗ ЯНЧЫКТА ЯТМЫЙ

*Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укыган елларда миңа Арча якларында педагогик практикада булырга туры килде. Төгәлрәге, Түбән Көек сигезьеллык мәктәбендә балалар укыттым. Менә шунда әдәби түгәрәк оештырып, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю белән дә шөгыльләнгән идек. Шактый гына мәзәкләр, бәетләр, мәкаль һәм әйтемнәр, әкият һәм җырлар тупланды. Бу мавыктыргыч эшне мин ял вакытларында туган ягым Әлкигә кайткач та дәвам иттердем.*

*Игелекле эш югалып калмаска, халыктан җыеп алынган күңел җәүһәрләре халыкның үзенә кайтарылырга тиеш, дигән ният белән, мин аларның кайберләрен «Казан утлары» журналын укучыларга тәкъдим итәргә булдым.*

*Шамил МАННАПОВ.*

## Тапкыр егет

Булган ди, торган ди бер бай. Бу бик бай булган, хәтта тирә-юньдәге байлардан да бай булган ди.

Көннәрдән бер көнне бу байның хезмәтчесе үлә. Моңа яңа хезмәтче кирәк була бит инде. Бу бай саранлыгы белән дан тотканга, бер дә яңа хезмәтче килми икән. Шулай да бер көнне бер егет каккан моның ишеген.

— Сезгә хезмәтче кирәк дип ишеткән идем,— дигән ул,— мин ялланырга телим, ләкин шундый шарт белән: миңа фәлән кадәр акча түлисең.

Акча сүзен ишеткәч, бай шартларга житешкән.

— Юк,— дип кычкырган ул,— мин сине киендерермен, ашатырмын, эчертермен, шул да бик җиткән!

Егет елмаеп куйган да:

— Ярый алайса, анысына да риза,— дигән.

Кич булган, егет йокларга яткан.

Иртәгесен бай йокыдан торган һәм, ишегалдына чыгып, яңа хезмәтчене күзли башлаган. Ләкин егет һаман күренмәгән. Бай абзаң көткән-көткән дә түзмәгән, егетнең бүлмәсенә киткән. Килеп керсә, ни күрсен: хезмәтче юрганга төренеп утырып тора икән. Бай җикеренеп:

— Нишләп һаман тик утырасың, оятсыз!— дигән.

Егет күзен дә йоммыйча:

— Әле бит, бай абзый, килешенгәнчә, мине киендермәдең дә. Мин ялангач килеш өстәл янына да утыра алмыйм ләбаса,— дигән.

**Арча районы, Әйшияз авылында яшәгән**
**Әхәт абзый Габделхаковтан язып алынды.**

## «Үгез исәбе барыбер...»

Берәү, үгез җигеп, урамнан узып бара икән. Хуҗа тиз генә өеннән йөгереп чыга да таяк белән үгезне кыйнарга тотына.

— Нишләвең бу, Хуҗа?!— ди үгез иясе аптырап.

— Әле белмәмешкә салышкан була тагын. Бер көнне мине үгез сөзгәнне үзең күреп тордың бит.

— Соң бит ул минем үгез түгел иде ләбаса.

— Миңа үгез исәбе барыбер,— дип җавап бирә Хуҗа тыныч кына

## Көрәк сакал белән чөй сакал

Хуҗага сорау бирәләр:

— Ни өчен байларның сакалы көрәк кебек, ә ярлыныкы чөй сыман була?

Хуҗа болай җавап бирә:

— Аның сере бик гади. Бай абзаң «Фәлән кешедән фәлән кадәр аласым бар, тегән кешедән тегән кадәр аласым бар», дип сакалын якякка тарткалап уйлана. Шуңа күрә аның сакалы көрәк кебек була. Ярлының исә берәүдән дә аласы юк, алган бурычларын гына түлисе бар. Ул сакалын учлый да: «Һәммәсенә бурычлы!» дип кенә куя. Менә шуңа күрә аның сакалы да чөй кебек...

## Кая барсаң да...

Элекке заманда, бер агайның ике улы, тормыш авырга күрә, бәхет эзләп читкә китәргә булганнар. Әтиләре каршы төшкән:

— Кая барсаң да, кара сакалың арттан калмас, таралмагыз, оланнар,— дигән ул.

Малайлар тыңламаганнар, чыгып киткәннәр.

Көньяк шәһәрләренең берсенә барып җитеп, эш эзли башлыйлар болар. Эш тә, аш та таба алмыйча, урамда каңгырып йөргәндә, ни күрсеннәр: боларга каршы ишәккә атланган кара сакал килә! Егетләр, авызларын ачып, бер мәл карап торалар да:

— Кара сакалны эти арттан калмый дигән иде, баксаң, ул бездән дә алдан килеп куйган икән,— дип, кире үз авылларына кайту юлына борылганнар, имеш.

## Тимерче һәм шайтан

Борын заманда була бер тимерче. Эше бик авыргадыр, үзенә ярдәмче таба алмый интегә бу.

Көннәрдән бер көнне тимерчелеккә бер шайтан килеп керә.

— Мине ярдәмчең итеп алмассыңмы икән?— ди.

Тимерче, ярдәмгә бик мохтаҗ булганга, шайтанга да риза.

— Тик мин бик тиз эшлим, ай-һай өлгерә алырсыңмы икән?— ди ул шайтанга.

Шайтан көлә:

— Һи, әйттең сүз. Миннән дә өлгеррәкләр тумаган әле дөньяга...

— Ну, ярар, хәзер сынап карарбыз,— ди тимерче.

Бер тимерне утка салып кыздыра да кыскыч белән алып сандалга куя һәм шайтанга кинәт болай дип кычкырып җибәрә:

— Сук, өрдер, су бир, идәнне себер!!!

Шайтан кайсына тотынырга белми аптырап кала. Аннары:

— Мин шайтан түгел икән, син икән ул шайтан!— ди дә чыгып кача.

Әлки районының Татар Мулла авылында яшәгән Мәгыйзь Маннаповтан язып алынды.

## Акча чәчүче

Бер кеше юлдан бара ди. Үзе бераз барган саен тиенле акча төшереп калдыра икән. Моннан сораганнар:

— Ни өчен акча чәчеп барасың?

Теге кеше:

— Бу акчалар тишелеп чыккач, чәчәк аткач, җимеш биргәч тагын да ишәерләр. Шунда мин аларны җыеп алырмын,— дигән.

Арча районы, Әйшияз авылында яшәүче әнисеннән Рая Газизова язып алды.

## Гомәр бәете

Мең тугыз да җитмеш беренче
Елның җиденче июлендә
Гомәрнең гомере киселде
Чирмешән күпере төбендә.

Аклы ситсы күлмәгемне
Бер генә дә кимәдем.
Иртән чыгып киткән чакта
«Сау булыгыз», димәдем.

Башымдагы фуражкамны
Армияләрдә кидем.
Һәлак буласымны белсәм,
Кайтмаган булыр идем.

Армиядә йөреп кайттым
Ике елым тутырып;
Чирмешәнгә төшеп киттем
Тракторга утырып.

Иртән эшкә чыгып киттем
Өстем-башым киенеп.
Әнкәй мине озатып калды
Балам, диеп, сөенеп.

Тракторның рулләре
Әйләнәдер кулларда.
Әнием карап елар инде
Мин йөрегән юлларга.

Әнкәй, ашың пешеп җиткәч,
Балаларың җыелыр.
Алар булып, мин булмагач,
Күз яшьләрең коелыр.

Зиратларда сайрый торган
Мин яраткан кош булыр.
Чәй эчәргә утырырсыз,—
Минем урын буш булыр.

Машиналар кызу бара,—
Төягәннәр ташкүмер.
Егерме бер яшькә җиткәч,
Әрәм булды яшь гомер.

Бакчадагы чәчәкләрнең
Төпләрен корытмагыз.
Әткәй, әнкәй, туганнарым,
Мине дә онытмагыз.

Сабан туе көннәрендә
Яшьләр җыела чатларда.
Дуслар, мине искә алыгыз
Урам йөргән чакларда.

Уралып-уралып ага
Шул Чирмешән сулары.
Мәңгелеккә кала миннән
Мулла авылы басулары.

Туганнарым, китәм инде,
Мәңгегә сау булыгыз.
Күперләрне үткән чакта
Зинһар, дим, сак булыгыз.

Әлки районы Татар Мулла авылының Румия Фәсәховадан язып алынды.

## Сәмигулла бәете

Урманнарга барган чакта
Зур басуны үтәбез.
Сәмигулла карт бәете,—
Тыңласагыз, әйтәбез.

Әкрен йөрсәм, бай тиргәде,
Шәп йөрсәм, ат тирләде.
Арыш икмәген зур капсам,
Бай хатыны тиргәде.

Семьям ачка үлмәсен, дип,
Чирле килешкә йөрдем.
Байга сабан сөргән чакта
Басуларда җан бирдем.

Дәва тапмадым чиремә,
Кырда интегеп үләм.
Әрнүенә түзми күмәм
Тәннәремне кәс белән.

Арча районы, Иске Шимбер авылында яшәүче Гайшә Нигъмәтҗановадан язып алынды.

## БЕР СОРАУГА — ? — БЕР ЖАВАП

**Сорау:** Соңгы елларда Г. Тукайның иҗаты һәм биографиясе нинди яңа мәгълүматлар белән тулыланды?

**Марсель Әхмәтҗанов**, филология фәннәре кандидаты.

— Күптән түгел татар халык шагыйре Габдулла Тукайның бабасы Зиннәтулла Әмировтан калган китапханә табылды. Аны безгә Арча районының Өчиле авылында яшәүче Кадыйр ага Курамшин (1906 елда туган) тапшырды. Бу китапханә барлыгы 14 кулъязма һәм 22 басма китаптан тора. Кулъязмаларның берсендә шундый автограф сакланып калган: «...Казан өязе, Яңа Кишет волосте, Малый Бирәзә авылында (Өчиленең борынгы исеме — М. Ә.) указнуй имам Зиннәтулла Зәйнелбәшәр угылы 1884 нче елда гыйнварның 9 көнендә митрәсский дәфтәрдән купия язып кулым куйдым». Шулай ук басма китапларның да Әмировлар милке булуы бәхәссез. Кәшфел-Кәбир тарафыннан (Зиннәтулланың улы), 1911 елның 21 октябрендә, аларның икесен Галимелфәрит исемле танышына биреп торуы хакындагы хаты да моны раслый.

Бу кулъязмаларда татар әдәбияты һәм культурасы өчен әһәмиятле мәгълүматлар туплануы ачыкланды. Шуларның берсендә борынгы Болгар галиме Хәсән Болгариның (XIII гасыр) соравына Димәшкъ һәм Иерусалим мөфтие Мөхәммәд-Таһирның җавап тексты сакланган. Бу текст Болгар иле хакындагы санаулы язма чыганаклар рәтенә керергә хаклы. Шиһабетдин Мәрҗани әсәрләренең күчермәсе дә галимнең халык арасында популярлыгы хакында сөйли.

Басма китапларның да байтагы фәнни кыйммәткә ия. Аларның кайберләре Габдулла Тукайныкы булу ихтималы да зур.

Әмировлардан калган бу китапханә — безгә Тукай биографиясен һәм иҗатын өйрәнүдә яңа бер чыганак.

# ФИДАКАРЬЛЕК

*Хәмит Ярминең тууына 80 ел*

Халык авыз иҗатын җыю, бастырып чыгару һәм фәнни өйрәнү эшенә зур өлеш керткән Хәмит Ярмигә быел 80 яшь булыр иде. Арабыздан ул күптән түгел, олы юбилеена берничә ел калгач кына китте. Шуңа күрә үзенә бер ачык, мөлаем йөзле, ап-ак чәчле, Себер татарларына хас кысынкырак күзле, кулыннан килгәндә һәркемгә ярдәм итәргә әзер торган бу оптимист кешене әле күпләр хәтерли.

Хәмит Ярми — татар халкының беренче профессиональ фольклорчысы. Дөрес, халык авыз иҗатын туплау кебек изге эшкә үткән гасырда да, безнең дәвердә дә күп кешеләр көч куя. Борынгы чорда башланган бу мактаулы хезмәтне соңрак Петр Рычков, Иван Лепехин, Николай Рычков, М. Д. Чулков, Казан университеты профессорлары К. Фукс, Ф. И. Эрдман һ. б. дәвам иттерәләр. Г. Ваһапов, С. Кукләшев, Г. Фәезхановларның әдәбият һәм тел дәреслекләрендә, китапларында фольклор үрнәкләре зур урын ала. Фин галиме П. Паасонен, В. В. Радлов, Н. Ф. Катановлар белән берлектә халык иҗатын туплауга һәм өйрәнүгә К. Насыйри, Г. Тукай зур өлеш кертәләр. «Бездә фольклорны турыдан-туры җырчының, әкиятченең үз авызыннан, тиешле игътибар белән язып алу эше Каюм Насыйридан башланып китте»,— дип Х. Ярми бик хаклы яза. Совет чорында фольклор байлыклары җыйнап, кире халыкка кайтару чарасын күргән Ф. Туйкин, Г. Толымбай, Х. Бәдигыйлар исеме безнең өчен шулай ук кадерле.

Әйтергә кирәк, аларның хезмәтенә иң беренчеләрдән булып объектив бәяне Хәмит Ярми бирә: «Х. Бәдигыйне татар халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәнү һәм аларны фәнни тикшерү өлкәсендә Каюм Насыйри һәм Г. Тукай традицияләрен дәвам иттерүче, алар тарафыннан башланган бу мөһим эшне совет шартларында тагын да үстереп, билгеле бер фәнни нигезгә салучы галим дип атарга мөмкин». Һәм галим үзе дә шул традицияләргә таянып, фольклорны өйрәнү юлына чыга.

Хәмит Ярми фольклорны өйрәнүгә бөтен гомерен бирә, физик һәм рухи көчен шуңа багышлый. Аның сөенече дә, көенече дә, шатлыгы да, кайгысы да шул өлкә белән бәйле.

Ул утызлап экспедициядә катнаша, биш йөзләп авылны йөреп чыга. Сугышка чаклы ук Төмән, Тобол, Новосибирск якларында булып, халык дастаннарының эзенә төшә. 1940 елда оештырылган Себер экспедициясе турында Х. Ярми түбәндәгечә яза: «Безнең группа Новосибирск һәм Омск өлкәләрендә ике ай йөреп, барлыгы 5 шәһәрдә, 7 районда, 34 авылда булып, 6363 километр юл үтте. Шуннан 5855 километры тимер юл һәм су юлы белән, ә калган 508 километры машина, ат белән һәм җәяү үтелгән... Экспедиция вакытында төрле районнарда Күчем хан һәм Ермак турында ике вариант риваять, 136 әкият, 18 дән артык бәет, 1500 ләп җыр һәм 100 дән артык табышмак, мәкаль-әйтемнәр язылып алынды».

Илленче-алтмышынчы елларда халык иҗатын җыйнауның географиясе тагын да киңәя: аңа Саратов һәм Ульяновск, Куйбышев һәм Киров, Оренбург һәм Пенза өлкәләре, Мордовия, Мари, Удмурт республикалары да керә. Хәмит Ярми һәм аның юлдашлары иңләгән төбәкләрне санап чыгу гына да күп нәрсә турында сөйли. Гомәр Бәширов әйткәнчә, бу «тынгысыз җан»га тирән ихтирам уяна.

Ә бит һәр экспедиция вакытында күпме очрашулар, мәшәкатьләр, юл газаплары, халык иҗаты әсәрләрен үзендә саклаган кешеләрнең «телен ача» алу хикмәтләре. «Телне чишү» мәсьәләсендә Хәмит ага тумыштан килгән, зур сәләткә ия иде. Ул хәл-әхвәлләр, дөнья вакыйгалары, табигать яме турында иң гомум темаларга сөйләшә-сөйләшә, сиздермичә генә теләсә нинди картны, карчыкны, җилкенчәкне җыр, әкият, бәет турында фикерләшүгә алып чыга белә иде. Һич булмаса, алдан үзе бирәр гыйбрәтле истәлек, мәзәк сөйли, шуңа бергәләп бәя бирергә, аның бу якта яшәгән варианты турында гәпләшеп алырга, чагыштырып карарга чакыра. Алай да булмаса, халык иҗатын җыйнап, киләчәк буынга калдыруның дәүләт эше, намус эше икәнен иренмичә аңлата. Кыскасы, бу яктан ул вата алмаган чикләвек юк иде.

Хәмит Ярми эшчәнлегенең бу тармагы җәмәгатьчелекнең югары бәясен алды. «Син татар халык иҗатын җыеп алуда, аны бер үзәккә туплауда, фәнни системага салуда һәм матбугатка чыгаруда моңа кадәр беркем дә эшләмәгән дәрәҗәдә гаять зур һәм әһәмиятле эш башкардың һәм башкарасың»,— дип яза Афзал Шамов аны 60 еллык юбилее белән котлап язган хатында. Габдрахман Әпсәләмов та шул ук фикерне куәтли: «Сез халык күңеле җәүһәрләрен җыюга гомерегезне багышладыгыз. Бу — батырлык».

1964 елда «Казан утлары» журналында (5 сан) басылган мәкаләсендә Гомәр Бәширов Х. Ярминең партия һәм халык эшенә җаны-тәне белән бирелгән кеше булуын искәртеп, аның сәләтле оештыручы, фольклорны армый-талмый пропагандалаучы булуына басым ясый.

Тормышының иң зур өлешен халык арасында йөреп, фольклор әсәрләрен телдән язып алуга багышламаса, бәлки, аның фәнни мирасы тагын да саллырак булыр иде. Ә икенче яктан, Г. Әпсәләмов әйткәнчә, аның батырлыгы да, халык авыз иҗаты тарихында калачак хәзинәсе дә менә шул эшчәнлеккә бәйле. Х. Ярми бит турыдан-туры халык теленнән 50 табак күләмендә материал язып алган! Ә рухи байлыкның аның һәр бөртеге, һәр мыскалы кыйммәтле.

Шунысы бәхәссез: халык хисендә, халык зиһенендә туган һәм телендә, күңелендә яшәгән, авторы билгесез әсәрләрне язып алу өчен аның белән ярыша алырлык фольклорчы кирәк. Халык иҗатының аерым жанрларын өйрәнүне күздә тотып, М. Мәһдиев болай дип язган иде. «Татар халык иҗатының үзенчәлекле жанры — бәетне телгә алуга Х. Ярми күз алдына килә. Чөнки бездә халык бәетләрен җыю, теркәү, эшкәртү, өйрәнү ягыннан соңгы егерме-утыз елда аның кадәр эшләгән бер генә кеше дә юк». («Казан утлары», 1968 ел, 11 сан).

Хәзер яңа әсәр, вариант, версия табуы гаять читен. Өлкән буын белән бергә халык иҗаты җәүһәрләренең күбесе югалып бара. Язма әдәбият, радио, телевидение дә фольклорны кысрыклый. Халык телендә күбрәк шагыйрьләребез, композиторларыбыз әсәрләре яши. Шуңа күрә Хәмит Ярминең үзенә бер үҗәтлек һәм фидакарьлек белән халыктан мөмкин чаклы күбрәк әсәрләр язып калырга ашыгуы, шуңа гомеренең төп өлешен багышлавы сокландыра.

Х. Ярми катнашы белән бер-бер артлы 18 җыентык дөнья күрә. Татар халык әкиятләре Х. Ярминең кереш сүзе белән 1952 елда Мәскәүдә рус телендә басылып чыга. Бу җыентык соңрак кытай, әрмән, украин, казах телләрендә дә дөнья күрә.

Филология фәннәре докторы Хәмит Ярми мәктәп һәм югары уку йортлары өчен язылган дәреслекләр, фольклорга багышланган китаплар, күп санлы проблемалы практик мәкаләләр авторы да. Бу яктан ул универсальлеккә омтыла. Әдәбият фәненең бер ягын да онытмаска, «рәнҗетмәскә» тырыша. Аның гыйльми эшчәнлеген шартлы рәвештә өчкә бүлеп карап булыр иде. Беренчесе — революциягә чаклы һәм 1917 елдан соңгы халык иҗатын барлау, бу юлда аерым намуслылык, гыйльми зирәклек үрнәкләре күрсәткән галимнәр эшчәнлеген бәяләү, вульгар социологизм тегерменәнә су коючыларга каршы көрәш, фольклорның идея-эстетик эчтәлеген бозып аңлатучыларны фаш итү. Икенчесе — халык әдәбиятының килеп чыгышын, туу тарихын, юнәлешен, көчен, жанрларын, сурәтле фикерләү алымнарын, ритмикасын, рифмасын өйрәнү. Өченчесе — халык күңелендә туып, шәхес зиһене, шәхес тойгылары белән бизәлгән, гасырлар буена шомартыла, нәфисләнә килгән мирасның татар әдәбиятының аерым вәкилләренә шифалы йогынтысын ачыклауга омтылыш.

Фольклор белгече әкият, бәет, җыр, мәкаль кебек жанрларның яшәеш үзенчәлеген, тарихилыгын, тормыш белән бәйләнешен тикшерә. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Бәширов кебек язучыларның дөньяны кабул итү, аңлау үзенчәлекләренә, сурәтле фикерләү рәвешләренә фольклор традицияләре аша үтеп керү юлларын эзли.

Үзенең иң уңышлы тикшеренүләрендә Хәмит Ярми чорның фәнни-методологик казанышларына таянып эш итә. Аның әкият, бәет кебек жанрлар үсеше, яшәеше турында уйлануларын, «Кузы Көрпә», «Алпамша» кебек эпик әсәрләрнең татар халкы арасында таралган вариантлары турында фикерләрен шундыйларга кертеп булыр иде. Ул күбрәк тарихи-хронологик принципны алга сөреп, санап, аңлатып, күрсәтеп бару юлын яратса да, фәнни классификация алымнарын да кире какмый.

Әйе, Х. Ярми әдәбият белгече түгел. Бу халык иҗаты җәүһәрләренең аерым язучыларга ясаган тәэсирен өйрәнгән әсәрләрдә сизелә. Ләкин анда да автор үз заманы өчен кызыклы гына фикерләр әйтә, проблеманы калкытып куя.

Ә инде аның әкият, бәет, җыр кебек жанрларның туу, үсү, яшәеш тарихына, тормышны, халык хыялын чагылдыру ысулларына, сурәтләлек хасиятләренә багышланган хезмәтләре, дәреслекләре хәзер дә кыйммәтен, заманча рухын саклый. Фольклорның рухына, эстетик нечкәлекләренә үтеп керергә омтылышлары хәзерге галимнәр һәм тәнкыйтьчеләр өчен үзенә бер мәктәп ролен үти.

Хәмит аганың «эшләгән кешене халык күрә, бәяли, берәүне дә онытмый» дигән яраткан гыйбарәсе бар иде. Хак сүзләр әйткән икән. Аның үз хезмәте дә тиешле бәясен алды. Хәмит Ярми орден-медальләргә, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе дигән исемгә лаек булды.

Ерак Себердә гади бер гаиләдә туып, белемгә сусаган хисләре белән Казанга килеп, тормыш авырлыгын үз җилкәсендә татып, совет чоры шәхесе буларак формалашкан, халык иҗатын туплауга, бастырып чыгаруга, өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән Хәмит Ярминең культурабыз тарихында үз урыны бар.

Фольклор әсәрләрен бастырып чыгару эше хәзер бездә шактый җайга салынды. 1976 елдан башлап татар халык иҗатының төп жанрлары — кыска җырлар, табышмаклар, әкиятләр, мәзәкләр, йола һәм уен җырлары, бәетләр дөнья күрде. Алда дастаннар, риваять һәм легендалар, мәкальләр чират көтеп тора. Тәзүчеләр заман дәрәҗәсендә эш итеп, методологик һәм фәнни тәгаллеккә ирешәләр. Х. Ярминең шәкертләре башкарган бик кирәкле һәм файдалы эш бу. Халык акылы, халык зиһене, халык хисе тудырган шул китапларны кулга тоткач, Хәмит Ярми исемен янәдән рәхмәт хисе белән телгә аласың...

**Тәлгать ГАЛИУЛЛИН.**

# ХӘМИТ ЯРМИГӘ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ФРОНТТАН ЯЗГАН ХАТЛАРЫ

Ярми, Агиш, Хәй абый, Әмир,
Җәләй ага һәм Шабанов!
Сезгә фронттан яңа ел сәламе!

Мин миллионнар арасына кереп сезнең күздән югалдым ахры, сездән ни сәлам, ни хәбәр юк. Ә мин, чынлап әйткәндә, югалмадым гына түгел, киресенчә, зур өметләр һәм күңелем тулы якты хисләр белән яңа — 1942 нче елга атлыйм.

Үлем немец оккупантларына! — менә безнең лозунг. Нәкъ 700 ел элек — 1242 елда немецлар Чуд күлендә тар-мар ителгән булсалар, 1942 нче елда аларны тагын да рәхимсезрәк һәлакәт һәм тар-мар ителү көтә. Без җир йөзендәге барлык гүзәллекнең иҗат итүчесе — Кеше өчен сугыш алып барабыз, аның бөек иҗат җимешләрен — культураны һәлакәттән саклап калу өчен көрәшәбез. Бу көрәш авыр, ләкин безнең халыкның кодрәтле рухы бу авырлыкны җиңеп чыгар һәм бөтен халыкларга азатлык

һәм тыныч тормыш алып бирер. Без моңа ышанабыз һәм 1942 ел безнең ышанычларны чынбарлыкка әверелдерәчәк.

Сәлам, дуслар!

Безнең җиңү елыбыз башлану белән һәммәгезне дә чын күңелдән тәбрик итәм!

Сугышчы Хатип Госман

Төньяк-көнбатыш фронт.

31. 12. 41.

Хәмит дускай!

Җибәргән рекомендацияңне һәм шуның белән бергә матур хатыңны алдым. Бик зур рәхмәт сиңа, Хәмит, мине бик нык шатландырдың. Мин һаман шатланам, һәм киләчәктә дә, нинди генә минутларым, сәгать-көннәрем булмасын — мин гелән сине, сезне — дусларны исемә төшереп, күзләрем алдына китереп торачакмын. Мин синең кебек дустым, ачык, көр күңелле, сизгер дусларым булуына үземне бәхетле саныйм. Рәхмәт, дускай, кат-кат рәхмәт сиңа!

Дуслардан сәлам хаты алу — иң кадерле, онытылмас көн булып санала безнең өчен. Синең бу хатың минем өчен бигрәк тә кадерле, әлбәттә. Мин хәзер, нинди генә кыенлыклар булмасын, барысын да җиңәргә әзер торам һәм синең белән бәхетле очрашу көнен каршылаганда күзләреңә туры карап, горурлык белән: «Без җиңдек!» — дип әйтергә әзер торам. Ул көн якыная... Таң сызыла инде...

Әгәр дә тәкъдир дигән нәрсә яңадан очрашырга язмаса, моңланмагыз, сыкранмагыз, бәлки: «Идрис тә үзен егетләрчә кызганмый яшәде... Күтәрик бокалларны аның өчен дә!» — диярсез. Минем белән нәрсә генә булмасын, Хәмит дускай, мин шуны гына телим: балалар тагы да ныграк кычкырып көлсеннәр, чәчәкләр тагы да матуррак булсыннар, музыка тагы да көчлерәк яңгырасын, хатын-кызлар тагы да матуррак булсын, бокаллар эчемлектән һаман тулы, тулыдан тулы булсын иде...

Армиец тормышына акрынлап мин дә күнегәм һәм, билгеле, кырыс, батыр армиец булырга тырышам. Күптән түгел, саф алдында миңа (яхшы хезмәт өчен) рәхмәт белдерделәр. Командирларым минем — сизгер һәм акыллы сугышчылар. Алар миңа чын күңелдән ярдәм итәләр.

Хәмит дус, бу хатны алуың белән син үзеңнең исемеңне һәм атаңның исемен аерым кәгазьгә язып, расլап җибәрче. Рекомендациядә син Х. Х. дип кенә куйгансың. Алай гына ярап бетми, — ди. Икенчедән, Газиз Иделле, Агиш һәм Рамазанов иптәшләрдән рекомендацияләр һаман юк әле. Бу нишләп алай микән? Алар әллә Казанда түгелләрме, районнарга чыгып киткәннәрме? Үзем, вакыт табылган саен, язгалыйм да сызгалыйм. Ике нәсер һәм ике кечкенә хикәяләр өстендә уйланып йөрим. «Уйланып йөрим» — дим, чөнки язарга кәгазь-кара юк диярлек. Хәер, бу бер яктан уңайлырак та: күбрәк уйларга һәм азрак язарга-сызарга күнегәсең, ягъни теләсә нинди җөмләне язып ташларга ашыкмыйсың. Шулай да мин Союздан посылка (ягъни мәсәлән кәгазь, карандаш, ручка, кара, башкаларын үзең кара дип) сораган идем. Посылканы Москва Союзына җибәреп, ә аннан безгә җибәреп була да дигән идем, җавап-фәлән юк әле...

Агиш, Халит, Яфаров, Рамазанов иптәшләр ни хәлдә яшиләр? Аларга бик күп сәлам әйт. Минем «Нәни хикәяләр»емне Татиздат кайчан чыгара икән? «Совет әдәбияты» элеккечә һаман чыкмыймы?

Маннур һәм Абдул иптәшләргә дә хәбәр-хат язасым килә, ләкин адресларын белмим, язып җибәрче (аларга — минем адресны, миңа — алар адресын).

Хәзергә хуш, хуш иттек. Кулларыңны кысып, синнән хат көтеп: Туктаров (Идрис Туктар).

21. 8. 43.

Ярми дус!

Күптән мин сиңа язганым һәм синнән берни алганым юк. Гомер дигәнең яшен тизлеге белән үтә-китә тора. Иптәшләр, дуслар, Казан сагындыра, күрәсе, сөйләшәсе, серләшәсе, көләшәсе килә: бу «килү» аның саен көчәя бара. Минем Кызыл Армиядә

булуыма 10 ай вакыт үтеп тә китте инде! Нинди айлар! Бу айларда байтак күрелде, байтак сизелде, байтак уйланылды... Партия сафына кабул ителүне генә алганда да тиз генә сөйләп бетерерлек түгел. Ләкин, Ярми дус, шуны әйтми чыдамыйм мин сиңа: шатлыгым зур, таудан биек, диңгездән киң. Бу шатлыкны барлауга син дә гаепле. Әгәр дә синең кебек сөекле дусларым булмаса, мин мондый шатлыкларга, әлбәттә, очрый алмаган булыр идем. Аннан соң шуны да әйтергә кирәк: минем сугышчы тормышында төрле-төрле, гаять чуар вакытлар булып торалар. Ләкин армиядәге вакытларым нинди генә булмасыннар — бары да алар бер ноктага — дошманны тизрәк тар-мар итүгә юнәлдерелгән булалар...

Бик «фәлсәфә»гә бирелдем бугай... Үзең ни хәлдә? Семьяң? Дус-ишләрең? Барына да миннән ялкынлы, сугышчан сәлам! Абдул белән Маннурлар нихәлдә яшиләр икән? Абдулга хат язган идем, җавап юк әле...

Үзем форсат чыккан саен язгалыйм да сызгалыйм, бәлки «С. Ә.» журналын күрә торгансыңдыр. Карашларың ничек? Әлбәттә, тагы да яхшырак язу кирәк, чөнки кеше дигәнең иң элек иң яхшыга мохтаҗ. Хәзерге көндә мин бер шагыйрь әйтмешли: «Песня зреет» — дим. Кечкенә генә булса да хат язсаңчы! Сәлам белән, кочаклап: И. Туктар.

5. 3. 44.

Ярми дус!

Мин күп азаплана торгач 23 нче декабрьда килеп җиттем. Фикерләрнең таркаурак чагы, шуңар күрә җөмләләр арт яклары белән чыгалар.

Иптәшләр көтеп алдылар. Монда кайткач китапларны карадык һәм барыбыз да сиңа зур рәхмәтләр укыдык. Чынлап та, дустым, мин үземнән бигрәк тә зур рәхмәтләр укыйм сиңа. Син миңа аеруча зур һәм әйтеп бетергесез дуслык һәм иптәшлек күрсәттең. Исән йөреп сау кайтсам, мин боларның берсен дә онытмам, дустым.

Чын дуслык шундый вакытларда сынала бит ул!

Монда килгәч тә эшкә тотындым, нәүбәттәге санга бер кечкенә шигырь дә язып ташладым. Газеталарны сезгә җибәреп бара башладык. Озакламый китаплар өчен ачык рәхмәт хаты да язып җибәрергә җыенабыз. Тик Агишка гына бераз хәтер калды, бөтен кирәкле китапларны тыкса да, үзенең «Тукай патриот»ын куймаган. Ни өчен, белмим. Ә безгә ул бик кирәк. Бу хатны алу белән конвертка тыгып булса да 2 данә җибәрмәсә бик үпкәләячәкбез.

Мин Хәким белән Абдулга хат язып куйдым, иртәгә җибәрәм. «Абдул»ны чакыртып булмый, Гыймадиның мондагы кешеләрне җибәрәсе килми.

Минем сезгә тагын бер үтенечем бар: «С. Ә.» журналының 3, 5, 6, 7, 8, 9 саннарын җыеп җибәрә алмассызмы. А. Гомәр алдады мине бу мәсьәләдә, койрыксыз булып чыкты.

Без монда Шамовны көтәбез, ул нинди хәбәрләр алып килер тагын. Без бу урыннан озакламый күчәбез. Алга, брат, алга! На запад!

Я, хәзергә хуш. Үзеңә, Фимага, Розочка һәм Уралбайга күп сәлам. Рәхмәт.

Хуш. Кулыңны кысып: Шыяп солдат (Шәйхи Маннур)

28. XII. 42.

Якындагы яңа ел белән!

Ярми дустым!

Сиңа исән-сау килеп эшли башлаганлыгымны белдерәм. Абдулга сәламеңне тапшырдым. Каршына һәр икебездән дә кайнар сәлам. Башка иптәшләр дә сәлам әйтәләр.

Үзем озакламый командировкага чыгып китәрмен, ахры, редактор шулай ди.

Үзең белән сөйләшкәнчә, ип. Мексинага дигән хатны сиңа җибәрәм, үз вакытында аңа тапшырырсың дип ышанам.

Аннан соң, дускай, сиңа һәм Разинга үтенеч бар. Мин теге фронтта чакта передовойда булуым сәбәпле, өч айлык стаж белән кандидатлыкка үткән идем, ә монда килгәч ул бер еллыкка әйләнде — II эшелон бит. Шуның өчен, элекке урынымнан моннан биш-алты ай элек соратып алган рекомендацияләрем хәзер искереп, ярамаска әйләнде.

Димәк, кыска әйткәндә, синнән һәм Разиннан — үземнең яраткан иптәшләремнән — членлыкка үтәргә рекомендация сорыйсым килә. Аяк астына салмассыз бит? Әгәр шуны тиз генә оештырып җибәрә алсагыз, бик шәп булыр иде. Июльдә елым тула. Үтенечем шушы. Разинга да җиткерче, дустым, һәм бергәләп җибәрегез.

Сагынып сәлам белән — Маннур (Шыяп солдат).

28. VI. 43.

Хәмит яки Халит!

Менә Сезгә «Хуҗа Насретдин фронтта» дигән кечкенә җыентык җибәрәм. Әгәр дә карт Хуҗаның бу йөрүләре тарихи әһәмияткә ия була торган булса, аларны бастырып чыгару чарасын күрерсез әле. Кереш сүзем ошамаса, яисә үзегез язуны тиешле тапсагыз (бу минем өчен яхшырак) үзегез язарсыз.

Инде бастырмау хәерлерәк булса, мин кайтканчы, институтта торсын иде... Ә без: «Исән булсак, бер кайтырбыз...»

Үзегездә ниләр бар?

25 еллыкка Институт нәрсәләр хәзерли, язсагыз без бик мәмнүн булыр идек һәм газетабызда да бирер идек.

Хуш иттек. Галимнәргә фронт сәламе.

Чуктин-чук сәлам белән Әхмәт солдат — Хуҗа Насретдиннең урынбасары (Әхмәт Исхак).

14/XI — 44, Литва — Лепләвка

Ярми туган!

Тар гына кәгазьгә киң өметләр белән язылган хатыңны алдым. Мондый кәгазьгә, чыннан да, фольклор материалларын язарга кирәк. Җырлар язуны гына сорап тора торган кәгазь.

Бу хатың белән син мине ничектер уятып җибәргәндәй булдың. Без фольклор җыю эшенә монда бертөрле дә әһәмият бирмәгәнбез. Тынгысыз частьлар буйлап, ашыгыч эшләр артыннан йөгерә-йөгерә шундый әһәмиятле нәрсәне оныткканбыз. Дөрес, минем бу турыда уйлаштыргалаганым бар, ләкин һәр юлы аны иккенче, хәтта иң арткы планга куйгаларга туры килде. Шулай итеп, бүген минем биштәрле капчыгымда ике генә юл да материал юк. Хәзергә мин сиңа бернәрсә дә җибәрә алмыйм, дус кеше. «Ах, бу бәндәне!» — диярсең инде син, ачынып. Нишлисең бит, бәндә гөнаһдан хали түгел. (Шулай диләр шикелле, онытыла да төшкән.)

Кызың институтта, улың хәрби мәктәптә укый торган булгач, бик зур карт булгансың икән инде син. Балаларыңа бәхет телим, ә үзеңә тыныч «картлык»! Ах, гомер, гомер, уза да уза! Чынлап картаябыз, Ярми. Артыбызга әйләнеп карасак, озын, тар сукмак. Гомер сукмагы. Анда безнең ялангач аякларыбызның эзеннән башка бернәрсә дә юк. Коры эзләр генә.

Сез миңа Тукай томын җибәрткәнсез дип ишеткән идем. (Шушы урында ручкамның карасы бетте. Каһәр төшкән немец ручкасы! Караны аз ала. Хәзер инде гади ручка кебек итеп манып кына язам. Кул астында андый кара юк. Бу хатымны әйдән чыгып киткән җирдә язам). Искә төшереп, китап җибәрүең өчен шушы көнгә кадәр сиңа да һәм Агишка да рәхмәт әйтергә туры килгәне юк иде. Бу хатым белән бергә минем чын күңелдән әйтелгән рәхмәтемне дә алыгыз.

Яңа эшеңдә уңыш телим. Материаллар табылу белән үк җибәрә барырмын.

Сәлам белән А. Шамов.

6. 02. 45.

Х. Ярми иптәш!

Сиңа, Шиһаб абый белән Бәкер агайга, Җәләй белән Агишка, Халит белән Гыймадигә һәм Халидә, Сафияләргә, Зөләйха апага миннән күп-күп сәлам.

Мин сау-сәламәт килеп җитеп, эшкә керештем. Юл җиңел булмады, ерак икән, 10/X дә генә килеп җиттем. Редакциядә М. Максуд, башкорт шагыйре М. Кәрим һ. б. эшлиләр. Газета начар түгел. Эше дә шактый. Аз гына срокка килгән кеше, мин дә кайбер эшләрне башкарырмын дип торам. Шактый нәрсәләрне күрдем. Кабәхәт немецлар җимергән, яндырган авыл, шәһәрләрне күргәч, йөрәк яна, нәфрәт арта икән. Сугышчылар арсландай алга омтылалар, батыр сугышалар, һаман алга-алга баралар, немецларны нык тукмыйлар.

Мин срокны тутырып, 10/XI тирәсендә кайтырмын, дип торам. Өскә төшкән бурычны үтәп кайтырга кирәк.

Ярми! Мин сине Москвада таба алмыйча аптырадым. Адресыңны белеп, эзеңә төшкән идем, шул көнне китеп баргансың икән.

Минем семьядан киләләрме? Аларны истән чыгармыйсыздыр, дип ышанам.

Хәзергә җитәр. Кайткач барысын сөйләшербез әле.

Хушыгыз!

Хөрмәт һәм сәлам белән Хәсән Хәйри.

М. Максудтан барыгызга да сәлам.

13/X-43.

Иптәш Х. Ярми!

Күп сәлам сезгә.

Моннан элек бер хат җибәргән идем. Алгансыздыр. «Совет сугышчысы» редакциясе эшчесе, Башкортстан шагыйре Мостай Кәримов сездә дә булыр. Ул татар сугышчыларына Октябрь бәйрәме көненә тәбрикләүләр алырга җибәрелде. Сез дә аңа ярдәм итәрсез, дип ышанабыз. Әгәр дә институтның инициативасы белән Татарстан гыйльми, сәнгать һәм әдәбият эшчеләре исеменнән татар фронтовикларына кыскача тәбрикләү хатын (Октябрь көненә) оештырып җибәрсәгез бик яхшы булыр иде. 8—10 кеше кул куйган булса да җитә. Аның әһәмияте монда аеруча зур.

Әгәр дә мөмкин булса, бер данә орфография сүзлеген редакция өчен биреп җибәрегез әле. М. Максуд бик үтенеп сорады.

Мин эшләрнең эзенә төшеп киләм. Фронт үзенчәлекләрен аңлый башладым. М. Максуд белән бергәләп кайбер эшләрне оештырып ятабыз.

Үзегезнең хәлләр, эшләр ничек? Минем семья ничек тора икән? Әле алардан да хат алганым юк. Вакытыгыз булса, бер-ике сүз язып җибәрерсез бәлки.

Шиһаб абзыйга, Бәкер агайга, Агиш, Җәләй агайларга, Халит белән Гыймадигә һ б. барлык иптәшләргә бик күп сәлам.

М. Максудтан барыгызга да сәлам.

Хушыгыз!

Хөрмәт һәм сәлам белән Хәсән Хәйри.

17/X-43.

Хәмит Ярми иптәшкә

Фронтка китүем сәбәпле мәкаләне очлап бетерә алмадым. Сездә булган театр тарихы турындагы очеркларымнан файдаланып мәкалә оештыру хокукын сезгә — институтка бирәм.

Сәлам белән: Гадел Кутуй.

12.VIII-44.

# ШӘМДӘЛЛӘРДӘ ГЕНӘ УТЛАР ЯНА...

*Мөнирә Булатовага 70 яшь*

Шәм... Кешеләр күңеленә якты әстәүче... Татар совет музыкасы тарихында күренекле урын алган сәхнә остасы, РСФСРның халык артисткасы Мөнирә Булатова өчен шәм төшенчәсе әерата тирән мәгънәледер. Үзенең хезмәт биографиясен ул М. Вахитов исемендәге заводның шәм цехында мастер булып эшләүдән башлаган. Үзешчәннәр арасыннан атаклы җырчы дәрәҗәсенә күтәрелгән, сәнгатьнең тылсымлы шәме серләренә төшенүгә ирешкән.

Милли опера башкару сәнгатенең формалашуын, мәгаен, М. Булатовадан башка күз алдына китереп булмыйдыр. Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (1936—1938) белем алганнан соң ул Казанга кайта һәм опера театры ачылган вакыттан ук музыкаль сәхнә сәнгатенең иң күренекле вәкилләреннән берсенә әверелә. Татар дәүләт опера һәм балет театрында кырык ел буе эшләү дәверендә Мөнирә Закировна чит ил, рус, татар композиторлары операларындагы уннарча партияләрне башкара, йөзләгән концертта чыгыш ясый, Ватаныбыз һәм чит илләр буйлап бик күп тапкыр гастрольләрдә йөри.

Татар композиторлары операларында М. Булатова башкармаган партия юктыр. Һәм шунысы да игътибарга лаек, без аның артистлык мөмкинлекләрен күздә тотып тудырылган образларны да беләбез. Мәсәлән, Н. Җиһановның «Җәлил» операсындагы Хәят образы нәкъ менә М. Булатова өчен иҗат ителгән. Шулай ук «Алтынчәч» операсындагы (Н. Җиһанов) Тугзак, «Башмагым» музыкаль комедиясендәге (Җ. Фәйзи) Җиһан образлары да артистканың индивидуальлегенә ятышып торалар, һәм алар автор кузаллавының гармоник гәүдәләнешләре буларак хәтердә калалар.

Классик опера сәнгате әсәрләре М. Булатова иҗатында әерым урын алып торалар. Шулар арасында икесе артистка өчен аеруча кадерле. Ихтыярн көчле, янар хисле, хөр күңелле Кармен... Гастрольләр вакытында илебез опера сөючеләре Кармен-Булатованы ихлас яратып кабул иттеләр, һәм әлеге партия, һичшиксез, артистканың зур иҗат уңышы буларак санала. «Пики дамасы» операсы да (П. И. Чайковский) аның иҗат мөмкинлекләрен тулырак ачарга мөмкинлек бирде. Шушы операда катнашучы буларак, ул 1950 елда ССР Союзының Зур театрында чыгыш ясады. Башкала газеталары М. Булатованың башкару культурасын югары бәяләделәр.

Опера солисткасы буларак танылган М. Булатованың репертуарында камера музыкасы, аерым алганда, татар һәм рус композиторларының романс лирикасы да зур урын алып тора. Әйтик, Р. Яхинның күп кенә романсларын халыкның күңел күгенә нәкъ менә ул «очырып җибәрде». Бөек Ватан сугышы елларында исә аның иҗатчы буларак гражданлык активлыгы тагын да көчәйде. Үзенең концерт бригадасы белән ул Өченче Балтик буе фронты сугышчылары алдында дистәләрчә мәртәбә чыгыш ясады. Татар халык җырларын, романсларны һәм опералардан арияләрне ул эчке бер яну белән, һәркемнең күңеленә барып җитәрлек итеп башкарды. Концерт эшчәнлеге артисткага профессиональ яктан туктаусыз үсәргә ярдәм итте. Болгария, Румыния, Монголия кебек илләр тамашачылары да аны алкышлап каршылады.

«Коеп куйган» артистка булу белән беррәттән, М. Булатова җәмәгать эшенә дә үзеннән аерым-талмый өлеш кертә. Озак еллар буе ул Совет-Чехословакия дуслыгы җәмгыятенең Казан бүлеген җитәкләде, дистә елдан артык Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе булып сайланды, ә җитмешенче еллар башыннан, Казан дәүләт культура институты доценты буларак, үзенең бай иҗат тәҗрибәсен студент яшьләр белән уртаклаша.

Үзенең җитмеш яшен тутырган артистка күңел шәменең бетмәс-төкәнмәс нурын аерым-талмый кешеләргә өләшә. Халык җырындагыча:

Шәмдәлләрдә генә утлар яна...

**Мансур ШАКИРОВ.**

## Килен

1922 елны Заһидә Тинчурина иренә — атаклы драматург Тинчуринга әйтә:

— Кәрим, без өйләнешкәнгә ничә ел? — ди.

— Өчтән артты! — ди Тинчурин.

— Атаң-анаңны күрәсем килә. Аларның да мине күрәсе киләдер, әйдә синең авылга кайтып килик! — ди Заһидә ханым.

Җыенып, бүләк-санак алып, юлга чыгалар болар. Пенза губернасы, Торбеевка стансасына чаклы поезд белән кайталар. Стансада аларны К. Тинчуринның атасы җигүле ат белән көтеп тора. Такта арбага печән салынган, печән өстенә түшәк түшәлгән. Күрешеп, танышкач, тагын юлга чыгалар. Шылдавычка хәтле кырык чакрым барасы икән. Бик озак кайта торгач, К. Тинчурин, кулын алга сузып:

— Ә-әнә, алда тау күрәсеңме, Заһидә? Шул тау астында безнең авыл булыр! — ди.

Шулай дигәч, Заһидә тиз генә калфак киеп, әйбәт, матур чәчәкле шәлъяулык чөеп, төзәтенә башлый. Моңарчы дәшмичә баручы карт:

— Рәхмәт, килен! — ди. — Рәхмәт, ату анагыз алдына, авыл халкы каршына шулай тузган баш белән кайта икән киленебез, дип, бик кайгырган идем!

## Анысын — үзебез

«Зәңгәр шәл»не иң беренче булып сәхнәгә Кәрим Тинчурин үзе куя. Роль бүлгәндә ул кайсы персонажны кайсы актер уйнасын игълан итә, бары тик бер генә рольне, Булатны башкарырга тиешле артистны гына әйтми калдыра.

— Кәрим абзый, Булатны кем уйнаячак соң? — дип сорыйлар артистлар.

— Анысын — үзебез дип торабыз, иншалла! — ди Тинчурин.

Чыннан да, башлап Булатны Тинчурин үзе уйный.

## Юмарт Такташ

Егерменче еллар...

Такташ үзенә яңа костюм сатып алып, өенә кайтып бара икән. Юлда аңа бер язучы танышы очраган. Такташ хәл-әхвәл сораштыра башлагач, әлеге язучы тормышыннан зарланырга тотынган:

— Кияргә чалбарым да юк, Һади, — дигән.

— Мә, алайса, рәхәтләнеп киеп йөр, — дип, Такташ өр-яңа костюмының чалбарын танышына бирә дә пинжәген култык астына кыстырып, кайтып китә.

— Их, пинжәгем дә юк, дип әйтәсе калган!— дип үкенеп йөргән имеш әлеге язучы.

## Шигырь яктылыгы

1930 елда Такташ «Киләчәккә хатлар» поэмасын Татар академия театры сәхнәсеннән укый. Бер заман — кем эше булгандыр — театрда ут сүнә, Такташ та, тамашачылар да дөм караңгыда калалар. Такташ укудан туктый. Шул чак караңгы залдан кычкыралар:

— Һади, дәвам ит, дәвам ит! — диләр.

Такташ моңлы-ягымлы тавышы белән караңгыда шигырь сөйли башлый. Бераздан ут кабына, зал гөрләп кул чаба. Ут кабынганга сөенүдән битәр, шагыйрьнең каушап калмавы һәм Такташ шигыренең яктылыгы өчен була бу алкышлар.

## Маҗаралы ял

Артистка Хәдичә Җиһаншина Мисхор курортында ял итә икән. Кер юарга ул диңгезгә йөри. Бер тапкыр шулай модный өй халаты кигән килеш кенә керләр чайкап кайтып килә икән, артистка шаулаша-шаулаша йөгерешкән кешеләрне күреп, гаҗәпкә кала. Бакса, курорт территориясендә янгын, ниндидер бер корпуска ут капкан.

— Нигә сез йөгермисез? — дип сорыйлар хатыннар Хәдичә ханымнан.

— Нишләп йөгерим, — ди артистка. Шулай да сорап куя. — Кайсы корпус яна соң?

— Ак корпус яна, Ак корпус! — дип кычкыралар йөгерүче хатыннар.

Салмак кына барган җиреннән Хәдичә ханым кинәт ашыгып йөгерә башлый. Кайтып житсә, Ак корпус янып беткән, корпус белән бергә Х. Җиһаншинаның бөтен әйберләре дә көлгә әверелгән булып чыга. Артистка әлеге модный халаттан гына чит шәһәрдә торып кала. Икенче көнне ул, акча юнәтеп, Казанга кайтып китә. Шул халаты, өйдә кия торган башмаклары белән Казан урамыннан килүче, таяк белән кечкенә төенчек аскан артистканы күреп, танышлары аптырый:

— Нишләдең син, Хәдичә? Каян кайтып киләсең болай? — дип сорыйлар.

— Менә курорттан кайтып киләм әле! — дигән имеш Хәдичә ханым.

## Йокламаган арба

Ниндидер бер артист бик каты авырып киткәч, Әнвәр Фәсхетдинов аның урынына керә. Сүзен белер-белмәс килеш Әнвәрне сәхнәгә чыгаралар. Спектакль барышында ул:

— Йоклап калгандыр әле, майламаган арба,— дип әйтәсе урында:

— Майлап калгандыр әле, йокламаган арба! — ди.

Бу сүзләрне ишеткәч, сәхнәдәге артистлар, тыела алмыйча көлә башлыйлар. Спектакль өзелә.

*«Кызыклы хәлләр»не журналга Роберт Батулла әзерләде.*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

17 апрельдә узган ачык партия җыелышында Татарстан язучыларының X съездына әзерлек мәсьәләләре тикшерелде. Доклад белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миңнуллин чыкты. Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре М. Хәбибуллин оештыру эшләре турында сөйләде.

Фикер алышуларда язучылар Н. Арсланов, Г. Латыйп, Л. Ихсанова, Н. Дәүли, Г. Хәсәнов, М. Хәсәнов, Җ. Тәрҗеманов, Б. Камалов, М. Маликова, Л. Хәмидуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев һәм башкалар чыгыш ясап, съездга әзерлек эшләренә җентекле анализ ясадылар, съездны оешкан төстә һәм нәтиҗәле уздыру өчен үзләренең теләк һәм тәкъдимнәрен белдерделәр.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

22 февральдә тәнкыйть һәм драматургия секцияләренең берләштерелгән утырышы булды. Анда сүз әдәби әсәрләргә һәм спектакльләргә язылган рецензияләр турында барды. Тәнкыйтьче Р. Мостафин докладыннан соң фикер алышуларда театр һәм әдәбият белгечләре А. Әхмәдуллин, Х. Госман, Р. Игъламов, М. Вәлиев, язучылар М. Хәбибуллин, Р. Мингалимов, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов һ. б. катнаштылар.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

16 апрельдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залында Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Татарстан Язучылар союзы тарафыннан «Хәзерге татар әдәбиятында әхлак мәсьәләләре» дигән темага оештырылган фәнни-практик конференция булды. Аны кереш сүз белән Институт директоры, философия фәннәре докторы Я. Абдуллин ачты. Конференциядә язучылардан һәм әдәбият галимнәреннән Г. Ахунов, Т. Галиуллин, Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин, Ф. Әгъзәмов, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Галимуллин һ. б. әлеге проблеманың төрле аспектларын яктырткан докладлар белән чыктылар.

## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ РӘСЕМНӘРЕ

Татарстан китап нәшриятының укыту-педагогик әдәбият редакциясе татар язучылары һәм шагыйрьләренең портретларын бастырып чыгарды. Кол Гали, К. Насыйри, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Галәү, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Коләхметов, Ш. Камал, Г. Камал, К. Нәҗми, Т. Гыйззәт, Һ. Такташ, М. Фәйзи, Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Б. Рәхмәт, К. Тинчурин, Ш. Усманов, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, М. Җәлил, А. Алиш, Г. Кутуй, Ф. Кәрим, Ш. Мөдәррис, Г. Кашшаф, И. Гази, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур, Ә. Давыдовның портрет рәсемнәре зур форматлы яхшы кәгазьгә басылган.

## ГАЛИМНӘРНЕҢ УҢЫШЫ

Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы доцентлары Х. Миңнегулов һәм Ш. Садретдиновның татар әдәбияты һәм культурасы тарихына багышланган хезмәтләре университетның иң яхшы гыйльми хезмәтләр конкурсында беренче премиягә лаек булды.

## МУЗЕЙ МЕДАЛЬ АЛДЫ

Язучы-интернационалист Ярослав Гашекның тууына 100 ел тулу уңаеннан аның Бөгелмәдәге музее зур эш башкарды. Музейда 11 мең кеше булды, 270 лап экскурсия үткәрелде, язучының Совет Россиясе һәм Бөгелмә шәһәре белән бәйле тормышы, әдәби иҗаты турында уннарча лекция укылды, биредә интернациональ дуслык клубы эшли.

Күптән түгел музейга ЧССР илчелегеннән истәлекле хат һәм медаль килде. Хатта мондый юллар бар: «Чехословакиянең Мәскәүдәге илчелеге ЧССР Культура министрлыгы тәкъдиме белән Ярослав Гашекның Бөгелмәдәге музеена күренекле чех язучысының тормышы һәм иҗатын пропагандалау буенча актив эшчәнлеге өчен истәлекле медаль тапшыра».

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор Сара Садыйкова, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 9 февраль указы белән, «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен В. И. Качалов исемендәге Казан зур драма театры артисты Юрий Степанович Федотовка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 9 февраль Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе солисткасы Римма Ибраһимовага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 23 февраль Указы белән, «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Миңзәлә татар драма театры артисты Инсаф Фәхретдиновка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 23 февраль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор, Казан театр училищесы директоры Мәсгут Имашевка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 9 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен шагыйрь Хәкимҗан Халиковка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 9 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Марс Шабаевка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 7 февраль Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт консерваториясенең музыка тарихы кафедрасы профессоры, сәнгать белеме кандидаты Галина Яковлевна Касаткинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 15 март Указы белән «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен скульптор, СССР Художниклар Союзы члены Рада Хөсәеновна Нигъмәтуллинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 11 март Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре, нәтиҗәле педагогик эшчәнлеге һәм 75 яше тулу уңаеннан Казан дәүләт педагогия институтының музыка-педагогия факультеты доценты Җәлал Гаязович Садриҗиһанов КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре, нәтиҗәле педагогик эшчәнлеге өчен һәм алтмыш яше тулу уңаеннан Казан дәүләт консерваториясенең кыллы уен кораллары кафедрасы мөдире, профессор Афзал Насретдинович Хәйретдинов, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1984 ел, 17 февраль Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Сынлы сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 60 яше тулу уңаеннан ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Энәс Ибраһимович Тумашев КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# СУ БУЕ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фәйзрахман Абдрахманович Әминевнең иҗаты күпкырлы: сынлы сәнгать, графика, скульптура. Аның әсәрләре тематикасының киңлеге, чынбарлыкны төрле яклап ачып бирергә омтылуы белән безне үзенә җәлеп итә. Рәссамны үз иленең тарихы, аның героик үткәне, бүгенгесе тирән дулкынландыра. Әминев әзлекле рәвештә Тукай поэзиясенә мөрәҗәгать итә. Татар халкының бөек шагыйре әсәрләре сюжеты буенча ул картиналар циклы иҗат итте.

Ф. Әминев портретлар һәм төрле композицияләр ясауга да шактый вакытын бирә. Ләкин аның төп иҗат үзенчәлеге татар поэзиясе һәм фольклоры белән бәйләнгән әсәрләрендә тулырак ачылды. Милли темага мөрәҗәгать итеп, ул төсләрнең йомшак, сизелер-сизелмәс кенә көчүенә зур осталык белән ирешә. Аның әсәрләре йөрәккә үтеп керә торган якты, моңлы бер җыр шикелле. Шулар арасыннан «Су буе» әсәре татар халык поэзиясе һәм музыкасының гәүдәләнеше, халык иҗаты рухының җыелма чагылышы буларак кабул ителә.

Тирән моңлы, аз гына сагышлы, йомшак лиризм белән сугарылган татар халык җырлары рәссам чигә торган полотноның нигезен тәшкил итә. Картинаның сюжеты халык җыры кебек гади. Суга баручы кыз үзенең сөйгәнен юксына. Тирә-юньне нурландырып үсүче чәчәкләрдә ул үзенең ярын күрә. Уйчанлык, тыйнаклык һәм кара урманның котырып чәчәк атуы — кыз кичерешләренең чагылышы. Төсләрнең бик ачыкларын сайламый рәссам, тыенкы колорит, башларын игән чәчәкләр, көнбагышлар, җиргә иелгән каен ябалдашлары кызның уйчанлыгын көчәйтәләр, аңа теләктәшлекләрен белдерәләр шикелле.

Һәр чәчәк, һәр үлән аерым-аерым зур игътибар һәм нечкәлек белән сурәтләнгән. Ләкин мондый эшләнеш әсәрне тулы килеш, бер бөтен буларак кабул итәргә комачауламый. Рәсемнең алгы фоны чәчәкләр белән тулган, алар «сиздермичә» генә киемгә көчә дә халык сәнгатенең бизәге булып яңгырый башлый. Көйнең матурлыгы, аның моңы, күңелгә тирән үтеп керүе төсләрнең артык күзгә ташланмый торган көчешендә, гөлләр өстеннән йөзеп барган кебек тоелган кыз образында бирелгән. Күккә сузылган төз агачлар, офык артына китеп югалган киртәләр, сүрән җәйге көн — болар барысы да бәгырьне якты сагыш белән телгәлиләр.

Музыканы төсләр белән бирү шактый кыен. Рәссам үз тойгыларын теге яки бу көй белән бәйләнгән образлар аша гына сөйли ала. Шулай да Фәйзрахман Әминев җырлый торган рәсем иҗат итүгә ирешкән. Гомумән, аның иҗатында үз халкын, аның культурасын яратучы кеше кичерешләре бөтен тулылыгы белән күрсәтелә.


**Владимир РАЗУМЕЙЧЕНКО,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның өлкән фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солистлары — Зөһрә Сәхәбиева һәм Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бигичев.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)